

# РУХИ МИРАС

## ЭЗЛӘНҮЛӘР һӘМ ТАБЫШЛАР

## СӘЯХӘТНАМӘЛӘР

МИРАСХАНӘ

РУХИ МИРАС
ЭЗЛӘНҮЛӘР һӘМ ТАБЫШЛАР
СӘЯХӘТНАМӘЛӘР

13

МИРАСХАНӘ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2021

# РУХИ МИРАС

## Эзләнүләр һәм табышлар

**Сәяхәтнамәләр**

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ

## Поиски и открытия

**Путешествия**

УДК 94 (093)
ББК 63.2
Р 82

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

Проект ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**
***И. Г. Гомәров*** *(проект җитәкчесе һәм җаваплы мөхәррир),*
***А. М. Ахунов, Ә. М. Закирҗанов***

**Төзүчеләр:**
***А. Х. Алиева, Г. М. Ханнанова***

**Р 82 Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Сәяхәтнамәләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Путешествия** / төз.: А. Х. Алиева, Г. М. Ханнанова; текст., иск. һәм аңл. әзерл.: А. Х. Алиева, Г. М. Ханнанова; кереш сүз авт. А. Х. Алиева. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 13 нче чыг. – 300 б.
ISBN 978-5-93091-392-7

Җыентык татар халкының рухи мирасы нигезен тәшкил итүче әсәрләрне өйрәнү, аз билгеле язма чыганакларны бастырып чыгару, татар текстларын өйрәнү барышындагы яңа табышлар белән укучыларны таныштыру традициясен дәвам итә. Әлеге чыгарылышта ХХ гасыр башындагы төрле авторлар тарафыннан язылган сәяхәтнамә жанры үрнәкләре туплап бирелде. Аларда татар-илгизәр зыялыларының төрле максатлар белән ерак кыйтагаларга юл йөрүләре – сәфәрләре тасвирлана. Күп төрле мәгълүматларга ия һәм халкыбызның рухи дөньясын баеткан мондый юлъязмаларны халык электән үк яратып укыган, бу жанр бүген дә популяр. ХХ гасыр башы татар вакытлы матбугаты битләрендә гарәп язуында басылган бу текстлар гамәлдәге татар язуына күчерелеп, беренче тапкыр укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-392-7

© Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2021

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МАТБУГАТЫНДА СӘЯХӘТНАМӘЛӘР

Татар халкының әдәби мирасында географик мәгълүматлар тупланган, эчтәлеге ягыннан көндәлекне дә хәтерләткән, төрле чорларга караган үзенчәлекле жанрда язылган әсәрләр бар. Алар – нигездә, юл йөрүләр белән бәйле сәфәр язмалары. Мондый әсәрләрне юлъязмалар яки сәяхәтнамәләр дип атап йөртәләр. Бу жанр кайбер башка әдәбиятларда да киң таралган һәм бик популяр.

Сәяхәтнамәләрне электән үк халык яратып укыган. Бу жанрның популярлыгы хакында матбугатта аерым фикерләр күптән әйтелгән: «Тәрәккый иткән кавемнәрнең укыдыгы әдәбиятлары арасында иң кызыклы вә рәгъбәтле (көтеп алынган), инсанның фикерене ачуда, дөньяда яшәмәктә улан башка кавемнәр илә таныштыруда сәяхәтнамәләрдән артык нәрсә юктыр; шул сәбәптән тәрәккый иткән кавемнәр ел саен төрле гаҗәибне туплаган сәяхәтнамәләр нәшер итеп, укучыларның калебләрене шатландырып, фикерләрене арттырып тормактадыр»[1].

Сәяхәтнамәләр халыкның иҗтимагый аңы, үз-үзен танып белүе билгеле бер баскычка күтәрелгәндә, милли үзаң формалашуын күрсәтә торган махсус әдәби-гыйльми жанрлар рәтендә тора. Фәнни әдәбиятта бу жанрга карата төрле билгеләмәләр, аңлатмалар очрый, әмма алар барысы да бу жанрның юл йөрүләр, сәфәр белән бәйле икәнен искәртәләр, иң беренче чиратта, шуңа басым ясыйлар.

Юлъязмалар жанрын билгели торган төп шарт булып әсәрнең түбәндәгечә төзелеше тора: автор билгеле бер максат белән яшәгән җирен, өен, гаиләсен калдырып юлга чыга (пространство күчеше) (хаҗга юл тота, дипломатик миссия үтәп, сәүдә максаты белән чит илгә бара, журналист буларак командировкага юнәлә, турист булып дөнья күреп йөри һ.б.). Юлда күргән хәлләрне сурәтли. Тиешле урынга барып җиткәч, күргәннәрен, кичерешләрен тасвирлый, теге яки бу күренешләр, хәлләр турында хөкем

[1] *Гыйсмәти Г.* Мәварәэннәһердә сәяхәт // Әхбар. Казан. 1908. 29 февр. (№ 33).

йөртә һәм, алдан билгеләнгән максат, гамәлләрне үтәп, туган җиренә әйләнеп кайта. Менә шушы билгеле бер вакыт арасындагы сәяхәтче бәян иткән күренеш-вакыйгалар һ.б. сәяхәтнамәләрнең, юлъязма әдәбиятның нигезендә ята. Аның төп максаты – сәфәрченең юл йөрү нәтиҗәсендә күргәннәрен, сәяхәте барышында туган уй-кичерешләрен укучыларга җиткерү.

Теге яки бу халыкның үткәнен, тарихый географиясен, мәдәнияте, сәнгате тарихын, иҗтимагый һәм сәяси тормышның башка өлкәләрен өйрәнгәндә юлъязмалар кебек әдәбият ядкярләренең әһәмияте бәяләп бетергесез дәрәҗәдә зур. Гасырлар һәм илләрне тоташтыра торган шактый киң катламны тәшкил иткән бу әдәби язмалар, мәдәни, рухи истәлекләр билгеле бер традицияләр аша күчемлелек җепләре белән бер-берсенә нык бәйләнгән тарих чылбырын төзиләр.

Кешеләр бик борынгы заманнарда ук үзләре яшәгән тирәлек белән генә канәгатьләнмичә, төрле кыенлыкларны җиңеп, урман-чүлләр аша, җил-давыллы киң дәрья-диңгезләрне кичеп, ерак кыйтгаларга барып чыкканнар. Шул сәфәрләр нәтиҗәсен чагылдырган, сәяхәт итүче кешенең укучыга таныш булмаган җирләр, илләр, халыклар турында белешмәләр бирүе, географияне, тарихны, этнографияне, сәяси һәм рухани тормышны һәм яшәешнең башка өлкәләрен дә берләштергән симбиозны тәшкил иткән бу әсәрләр әдәби процессның хәрәкәтен, жанрның үсеш, камилләшү этапларын да күрсәтеп торалар.

Танып белү максатыннан тыш, сәяхәтнамәләр эстетик, публицистик, фәлсәфи һ.б. максатларны да эченә ала. Хикәяләү сәфәрче-автор тарафыннан беренче заттан алып барыла, вакыйгахәлләрне ул чит дөньяны күзәтүче позициясеннән торып тасвирлый. Күп кенә күренешләрне үз ватаны, үз илендәге хәлләр белән турыдан-туры яки уйда гына булса да чагыштырып бәяли, фикер йөртә. Сәях, ягъни автор, гади әдәби геройдан аермалы буларак, хикәяләү барышында кискен үзгәреш кичерми.

XIX гасыр азагы – XX гасыр башы сәяхәтнамәләрендә әдәби сурәтләнеш мәгърифәтчел карашларны алга куеп үстерелә. Моның ачык мисалы итеп З. Бигиев, Ф. Кәрими, С. Максуди юлъязмаларын күрсәтергә мөмкин. Алар үз язмалары белән бу

жанрны төрле яклап әһәмиятле фикерләрне халыкка җиткерү чарасы, коралы итеп тә файдаланырга мөмкин булуын раслый.

Бу юлъязмаларда тупланган төрле характердагы бай материал, авторларның ил, халык тормышы турында шәхси фикерләре сәяхәтнамә жанрының сәяси, документаль һәм фәнни яктан да әһәмиятен арттыра.

Беренче карашка теге яки бу халык вәкиле – сәяхнең чит-ят җирләрдә үз башыннан узган хәлләре, күргән-ишеткән нәрсәләре хакында хикәя итүе кебек кенә булып күренсә дә, чынлыкта ул үз илендәге, үз халкының тормышында күзәтелмәгән, яки бөтенләй башкача булган күренешләр турында язып, «аларда менә шулай», дип, үз иле укучыларын үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйландырырга омтыла.

Гомумән, географик, гыйльми әсәрләр белән публицистик әдәбият арасында торган бу жанрның тарихы бай. Шул ук вакытта сәяхәтнамәләр татар халкының әдәби һәм иҗтимагый фикеренең мөһим бер тармагы, аның идея-эстетик дөньясының язма ядкәрләрендә чагылышы да булып тора.

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең әлеге чыгарылышында XX гасыр башында иҗат ителгән татар сәяхәтнамәләренең бик аз өлеше генә тәкъдим ителә. Биредә географик-тематик яктан якын килеп, Иран, Төркия, Кавказ якларына баручыларның юлъязмалары бирелде. Алар төрле сәбәп-максатлар белән башкарылган сәфәр язмаларын тәшкил итәләр.

Мәсәлән, танылган журналист, педагог, җәмәгать һәм мәдәният хезмәткәре Борһан Шәрәфнең (1883–1942), «Вакыт» газетасы корреспонденты буларак, 1909 елда Иранга баруы турында «Иран мәктүпләре» исемле юлъязмалары. Автор Иранда 1905 елларда ук башланып, шактый елларга сузылган революция нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләрне, андагы яңа тормышны яктыртуны сәяхәтенең максаты итеп куйган була. Әмма әле революция хәрәкәтләренең тәмамланып җитмәгәнлеге, яңалыклар, сизелерлек үзгәрешләрнең юклыгы ачыклана. Шулай да «Иран мәктүпләре» укучы өчен мавыктыргыч итеп язылган. Автор юлда күргәннәрен җентекле тасвирлап бара. Анда күп этнографик детальләр, төрле милләт вәкилләренең

тормыш рәвешләре, холык-фигыльләре, көнкүреше, кәсепләре, өс-баш киемнәре, киенү, бизәнү рәвешләре тәфсилләп матур тел белән хикәяләнә. Мәсәлән, Гилян провинциясенең үзәге булган Рәшт шәһәрендә яшәүчеләр дүрт кат кием кияләр икән. Комзол өстеннән җилән, аннары якалы озын казаки киеп, пута белән бәйлиләр, аның өстеннән – җөббә һәм габа (йон кием). Монда халык эшләргә яратмый, хорафат илә яшәүче, иртәге көн өчен кайгырмый торган кавем, имеш. Шул рәвешле реаль-фактик мәгълүматлар әдәби сүрәтләр белән тыгыз үрелеп бара.

Тагын бер кызык деталь: Иранда сулык, елгалар һич тә бездәге кебек бушка агып ятмый. Алар катлаулы инженерлык конструкцияләре белән бүлгәләнеп, бакча-кырларны сугаруга көйләнгән. Анда бер чиләк суны да файдасызга исраф итмиләр. Шуңа да анда җимеш, йөзем, иген гаҗәп күп үстерелә, дип күрсәтә автор.

Тәһран шәһәренең тасвиры да бик үзенчәлекле, монда биналарны салу башка шәһәрләргә охшамаган, үзенә бер аерым. Урам исемнәре дә үзләренең танылган шәхесләре исеме белән түгел, нигәдер чит халыктан алынган исемнәр белән куелган дип гаҗәпләнә автор. Юлъязманың азагы Иранда «Милләт мәҗлесе» ачылу вакыйгасы һәм шул уңайдан халыкның бәйрәм итүен, гаскәри парад, фейерверклар, мәйданда оркестр уйнап торуын тасвирлау белән тәмамлана. Борһан Шәрәф бу сәяхәтнамәсен хатлар рәвешендә «Вакыт»ка җибәреп тора һәм алар газета аша укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

Тагын бер үзенчәлекле юлъязма – «Шам хатирәләре». «Сакмарый» тәхәллүсе белән язылган, 18 бүлектән торган зур күләмле, мәгълүматка бай бу сәяхәтнамәдә күптөрле проблемалар алга куела. Автор үзенең чын исемен күрсәтмәсә дә, текст эчендә үзе турында кыскача мәгълүмат китерә. Ул Россиядә Сакмар суы буендагы бер татар авылында туып үскән татар егете булуын, шушы вакытта Төркия хөкүмәте составына кергән Бәйрут шәһәрендә Америка көллиятендә укучы студент икәнлеген дә искәртә. Авторның киң эрудицияле шәхес булуы ачык сизелә: берничә тел белә, тарих, сәясәт, иҗтимагый тормыш белән актив кызыксына. Аеруча ул мәгариф өлкәсе, Төркиядә уку-укыту системасы, мәктәпләр һәм аның торышына битараф түгел. Дөньяда билгеле

булган иң борынгы шәһәр Шамда (Димәшкъ) күргәннәрен, тәэсирләрен үз карашы аша үткәреп, укучыларга тәкъдим итә.

Ул вакытларда әле Шам Төркия составына кергән Сүрия вилаятенең мәркәзе санала. Шәһәрнең гүзәл табигатенә соклануын язганның соңында, аның борынгылыгына туктала. Гаҗәп зур җамигъ мәчетләрендә була. Борынгыдан килгән бай китапханәләренең тарихын бәян итә. Күпсанлы мәктәп-мәдрәсәләрендә булып, шәкертләр һәм мөгалимнәр белән таныша, аралаша. Укытуның торышыннан канәгатьсезлек белдереп, бу артталыкның төп сәбәбен хөкүмәт чиновникларыннан, җитәкчелектән күрә.

Хәлифәләр заманыннан ук билгеле булган тарихи шәхесләрнең, исламда изге саналган затларның каберләрен зиярәт итеп, хәзер инде үткәндәге бөеклек, дан белән генә яшәргә ярамый, яшәеш, тормыш башканы таләп итә, аның өчен дөньяви белемнәр, фәннәрне үзләштерергә кирәклекне искәртә. Алга киткән Европа илләрен үрнәк итеп китерә, андагы цивилизациянең үсешен, уку-укыту системасының югары дәрәҗәдә куелышын ассызыклый.

«Шура»да авторның бу сәяхәтнамәсе белән аваздаш һәм бер үк саннарда аерым басылган тагын ике язмасын да («Сүрия әхвале» һәм «Җәлил бәк илә мөсахәбә»), темага туры килгәнлектән, сәяхәтнамә эченә берләштердек. Аларда Сакмарый Сүрия тормышын яктыртып, искелек тарафдары булган чиновникларның әхвален һәм хөкүмәт хезмәтендәге галим Җәмил бәк әл-Газыйм белән очрашуын, аның эшчәнлеген тасвирлый. Аның мисалларында, борынгы китапханәләр язмышының, фәнгә, китапка мөнәсәбәтнең бүген дә шулай дәвам итүен күрсәтә.

«Шамда мөһаҗирләр» дигән бүлектә автор бирегә килеп урнашкан татарлар белән очрашуын, алар тормышын, милләттәшләребезнең чит-ят җирләрдә дә югалып калмавын, тырыш хезмәтләре белән матур яшәүләрен яза.

Биредә сәяхәтнамәләр жанрына хас чит җирләрдә йөргән сәяхнең туган җирен сагынуы, аның табигатен дә истә тотуы кебек лирик чигенешләр дә килеп кергән: «...Беренче дикъкатемне җәлеб иткән нәрсә – тәкияне бер яктан каплап торган агачларның күләгәсенә төшеп карап йөри башлагач, үземнең Сакмар буйлары искә

төште. Чөнки балчыгы аксыл, агачлары өянке вә усак. Елганың чите таллык, агач төпләренә кычыткан, көрән, бер зәңгәр чәчәкле исле үлән, бөрлегән сабагы үскән. Нәкъ Сакмар буе агачлыкларының суга якын җирләрендә табыла торган бер табигать», – дип яза.

Юлъязмасының азагында автор: «...сүз арасында, җае чыкканда кайбер нәрсәләрне тәнкыйть итттем. Ләкин моны төрек вә гарәпләргә дошманлыгымнан түгел, бәлки дуслыгымнан эшләдем, төрек углы төрек булганлыгымнан, төрекләрнең идарә дәрәҗәләре түбән, эшлексез булганга тәнкыйть итәргә мәҗбүрмен. Мөселманнарның тәрәккый вә сәгадәтен бөтен җаным вә тәнем белән теләгәнгә күрә, моңа киртә булган гадәтләрне тәнкыйтьләдем», – дип, чын максатын игълан итә.

Тәкъдим ителгән юлъязмалар арасында Мәрьям Паташеваның «Истанбул хатирәләре» дә урын алды. Ул сәяхәтнамә язучы беренче хатын-кыз автор буларак билгеле. XX гасыр башында татар хатын-кызлары хәрәкәтен дөньяга таныткан кызларыбызның берсе дә ул. Алар дүрт кыз: Чистайда туып үскән Өммегөлсем Камалова, Перербургтан Рокыя Юнысова, Ташкенттан Мәрьям Якупова, Ростовтан Мәрьям Паташева – дүртесе дә Петербургтагы Хатын-кызлар югары педагогия курсларында укучы 4 нче курс студентлары. Дүртесе дә Балкан сугышы вакытында (1912 елда), үзләре теләп, яшьлеккә хас дәрт һәм кардәш халыкка файдалы хезмәт итү теләге белән Төркиягә баралар. Анда «Һилял Әхмәр» («Кызыл ай») хәрби лазаретында шәфкать туташлары булып эшлиләр. Юлда барганда алар «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатыйх Кәрими белән дә очрашалар. Ф. Кәрими Төркиядә аларга ярдәм итеп тора, Россия илчелегенә алып барып, килүләрен рәсмиләштерергә булыша. Әлегә төрек телен камил белмәгән кызларны княгиня Елизавета Николаевна Оболенская эшләгән хастаханәгә билгелиләр. Кызларның үз хисапларына яшәп, эшләренә җаваплы каравы төрекләр өчен дә үрнәк була.

Ф. Кәрими «Истанбул мәктүпләре»ндә болай яза: «Хастаханә һәйәтләре вә табиблар безнең Россия мөселманнарыннан гаять разый вә мәмнүннәр. Аларның армый-талмый эшләүләренә ис-

ләре китәләр. Безнекеләр үз мосрафлары (чыгымнары) илә килеп шулкадәр тырышып хезмәт итәләр»[1].

Алар шәфкать туташы булып эшләү белән генә чикләнмиләр, Төркиянең җәмгыять тормышында да актив катнашалар. Фронтка ярдәм максатында хатыннар арасында иганә җыюга өндәп, «Мөдәфәгаи миллия» («Милләтне саклау») оешмасына мөрәҗәгать белән чыгалар. Үзләрен сугыш мәйданына якын кыр лазаретына җибәрүләрен сорыйлар. Аларның һәр адымы төрекләр арасында соклану, яклау, хуплау белән каршылана. Мәсәлән, 1912 елның 12 ноябрендә «Шәкертләр җәмгыяте» чакыруы буенча оештырылган очрашуда «Петербургтан килгән Кәбир Бәкер, Шәриф Әхмәтҗанов, Фатыйх Рәхимов һәм “Төрек йорты” мөдире Йосыф әфәнде Акчура катнашты», – дип дип яза Ф. Кәрими. Гөлсем Камалова биредә чыгыш ясап, Россиядәге уку тәртипләре, «мәгариф юлындагы хәрәкәт турында мәгълүмат бирә»[2].

Кайтыр көннәре якынлашкач, Ф. Кәрими кызларны мәчеткә алып барырга рөхсәт ала. Мәчеткә төрек солтаны җомга намазына йөри икән. Кызларны хөрмәтләп, солтан кулын күтәреп сәламли. Баш вәзир Мәхмүд Шәүкәт паша барысы белән кул биреп күрешә һәм «мөселман хатын-кызларының зур калебле, галиҗәнап икәнлеген сез гамәлдә күрсәттегез», – дип, аларга рәхмәт белдерә. Кызлар үзләре хакында иң матур тәэсирләр, гүзәл истәлекләр калдырып, Төркия белән саубуллашалар. Әмма Россиягә кайткач, бу гамәлләре өчен аларны Курслардан чыгаралар. Мәрьям Паташева 1913 елда Петербург Психоневрология институтына кереп укуын дәвам итә[3].

Мәрьям Паташева Төркия тормышын, үзе шаһит булган хәлләрне тасвирлап (көндәлек рәвешендә язып барып), 1913 елда илгә кайткач, «Истанбул хатирәләре» исеме белән «Вакыт» газетасында бастырып чыгара. Авторның Истанбул табигатенең гүзәллеген һәм шәһәрнең матур, зиннәтле архитектура объектларын тасвирлап башлаган язмасында татар сәяхәтнамәләренең

---

[1] Мирас. 2001. № 7. Б. 84.

[2] Мирас. 2001. № 10. Б. 203–204.

[3] Бу хакта киңрәк мәгълүмат карагыз: *Биктимирова Т. Ә.* Хәтерләрне яңартыйк. Казан: ТР ФАның Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2012. Б. 19–23.

яңа материал белән баюын, жанрның тематик чикләре киңәюен күрәбез. Биредә иҗтимагый һәм сәяси тормыш мәйданга чыгарган проблемалар күтәрелә, шулар яктыртыла. Сугыш китереп чыгарган кыенлыклар, яралыларның авыр хәле тасвирлана, оешмаганлык, медицинаның көчсезлеге тәнкыйтьләнә. Ул Төркиядәге традицион гаилә төзелеше, гаиләдәге үзара мөнәсәбәтләр, хатын-кызның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге урыны турында фикерләре белән уртаклаша.

Шундый мәсьәләләрнең берсе – бүгенге көн өчен дә актуаль булган катнаш никах мәсьәләсе күтәрелә. Автор бу күренешнең сәбәпләрен, милләтнең киләчәге, язмышы өчен аның тискәре якларын тасвирлый.

Мәрьям Паташева, аек фикер йөртеп, гасыр башында Госманлы дәүләтендә килеп туган вазгыятьне, Европа империализмының хәйләле һәм кораллы һөҗүме каршында бөтенләй юкка чыкмас өчен ялгыз тырышуын, көрәшен яктырта. Әмма илдәге сәяси партияләр арасында бердәмлек булмау, халык арасында да ватанпәрвәрлек хисенең төрлечә чагылышы аркасында килеп чыккан хәлләрне Төркия дәүләте һәм төрекләр өчен «ачы сабак» булды, дип бәяли.

Китапта урын алган башка текстларга тукталмастан, аларга хас уртак бер якны күрсәтеп узу урынлы булыр: авторлар үзләре күргән, кичергән вакыйгалар турында язалар. Шул ук вакытта бер үк җирләрдә булган сәяхләрнең юлъязмаларында кабатланулардан бигрәк аерымлыкларны күбрәк очратабыз. Бу авторлар сәфәрләрендә күргән-белгәннәре арасында шәхсән үзләре әһәмият биргән фактлар, күренешләр турында мәгълүмат бирергә тырышканнар. Һәрбер йөргән җирләрендә, аяк баскан эзләрендә яңалыкны үзләренчә күргәннәр, шуларга тукталганнар, аны үз фикер-карашларыннан чыгып бәяләгәннәр. Бу сәяхәтнамәләр – бүгенге көн укучысы өчен нәкъ менә шул җәһәттән караганда игътибарга лаек язмалар.

Халкыбызның рухи дөньясын баеткан мондый әсәрләр киләчәктә дә языла һәм басылып торсын, даими рәвештә укучыга барып ирешсен дигән теләктә калабыз.

***Әнисә Алиева,***
*филология фәннәре кандидаты*

**Борһан Шәрәф**

## ИРАН МӘКТҮБЛӘРЕ
***(Үз мөхбиремездән[1])***

### I
### Әстерханда

*Әстерханда иранлылар, мәктәпләре, мөгаллимнәре, Париж мөгаллиме, әрмәниләр, хәммаль[2].*

Бу сәфәремдә Иран әһалисе[3] тугърысында язачагым шәйләре «Иран мәктүбләре» гонваны[4] астына җамгъ итәчәкмен. Әстерхандан язган мәктүбемдә аларның беренчесе булырга ярыйдыр. Мәгълүм ки, урта Русиядән киткәндә мокыйм[5] иранлылар беренче дәфга[6] уларак Әстерханда очрыйлар. Бинаән галәйһи[7] Әстерхандан яздыгым мәктүбне «Иран мәктүбләре»нә кертүемә тәгаҗҗеб ителмәсен[8].

Әстерханда Иран тәбәгасындан[9] берничә йөз гаилә яшиләр. Анда Иранның консулханәсе бар. Иран ысулынча сәүдәгәрләргә «таҗир башы»[10] тәгъйин ителгән.

Бонда күп мәсариф[11] илә бина ителмеш шигый мәсҗеде, дахилдә[12] яхшы нәзарәт[13] юклыгындан шикаять[14] итсә дә, хариҗдән[15] мәһабәт күренә.

---

[1] Мөхбиремездән – хәбәрчебездән.
[2] Хәммаль – күтәреп йөк ташучы.
[3] Әһали – халык .
[4] Гонван – исем, титул.
[5] Мокыйм – бер урында урнашып торучы, урнашкан.
[6] Дәфга – мәртәбә.
[7] Бинаән галәйһи – шул сәбәбле.
[8] Тәгаҗҗеб ителмәсен – гаҗәпләнмәгез, аптырамагыз.
[9] Тәбәгасындан – подданныйларыннан.
[10] Таҗир башы – баш сәүдәгәр.
[11] Мәсариф – чыгымнар.
[12] Дахилдә – эчтән, эчке яктан.
[13] Нәзарәт – биредә: карау, тәрбия.
[14] Шикаять – зарлану.
[15] Хариҗдән – тыштан.

Бер көн мәсҗеднең каршысындагы дарел-әдәб мәктәбендән[1] чыгып килә идем, каршыда саф-саф тезелгән бер гөруһ[2] балаларның үтеп китүенә күзем төште. Һәркайсы бертөрле киенгәннәр, бертөрле постау (тула) казаки, бертөрле чалбар кигәннәр. Кәләпүштән зуррак, бүректән кечерәк булган баш киемнәренә «арыслан вә кояш» сурәте[3] кадаган, якалары яшелле һәм укалы. Боларны күргәч, янымдагы Садыйк әфәндегә дидем:

– Мәктәб балалары бар да бертөрле киемдә булгач яхшы. Күрәсез, ничек дәрдле баралар.

Шагыйрь Садыйк әфәнденең моңа каршы:

– Һа, милләте хакимә[4] балалары, әфәндем! – дия җавап бирүе минем аларга дикъкатемне арттырды. Икенче көнне иртә торгач та иранлыларның мәктәбен күрергә киттем.

Сәгать 9 ярымда мәктәпкә бардым. Балалар җыелганнар иде. Низамлы ибтидаи мәктәб[5] өчен лязем[6] булган әсбаб вә мәктәп тә йитешлекле күренә. Мөгаллим Мирза Сәйфулла әфәнде кардәшчә хөсне кабул күрсәтеп[7] ярым сәгать кадәр мосахәбәт иттек[8]. Мирза Сәйфулла әфәнде, асыл тәбризле[9] улып, Истанбулда, соңра Мисырда тәхсиле голүм итмеш[10], госманлыча гүзәл сөйләшә, «Борһане тәрәкъкый» гәзитәсендә[11] мәкаләләр язгалый. Сөнни-шигый ихтилафларына[12] әһәмият вирмәенчә[13] һәм-

---

[1] Дарел-әдәб мәктәбендән – югары дәрәҗәдәге мәктәптән.

[2] Гөруһ – төркем.

[3] Арыслан һәм кояш сурәте – Иранның шаһлык заманындагы дәүләт гербы.

[4] Милләте хакимә – хаким (хөкем сөрүче) милләт.

[5] Низамлы ибтидаи мәктәб – уку-укыту эшләре тәртипкә салынган мәктәп.

[6] Лязем – тиеш.

[7] Хөсне кабул күрсәтеп – яхшы кабул итеп.

[8] Мосахәбәт иттек – сөйләшеп утырдык.

[9] Тәбризле – Тәбриз шәһәреннән. Тәбриз – Иранның төньяк-көнбатышындагы зур шәһәр.

[10] Тәхсиле голүм итмеш – белем алган.

[11] «Борһане тәрәкъкый» гәзитәсе – Әстерханда 1906 елның маеннан 1911 елның февраленә кадәр Мостафа Исмәгыйлев-Ширванский һәм Нәҗип Гасрый тарафыннан нәшер ителгән сәяси, икътисади һәм әдәби газета (*Г. Ханнанова иск.*).

[12] Ихтилафларына – каршы торуларына.

[13] Вирмәенчә – бирмичә.

мә мөселманнарга бер төрле күз илә карарга тырыша. Сөнни мәктәбләрендә ничә дәфгалар тәсадеф итдекемез[1] мәҗлесләрдә бу яшь мөгаллимнәрнең төрле мәзһәбкә интисаблары[2] һич тә сизелми иде.

Мирза Сәйфулла мине үзенең кунагы Мирза Габделхөсәен әфәнде илә таныштырды. Бу кеше ике елдан бирле Парижда әлсинәи шәркыя мәктәбендә[3] фарсы вә гарәби лисаннарына[4] мөгаллимлек итә икән.

Мирза Габделхөсәен әфәнде өстендәге кызылбаш[5] казакисының бик шома булмавы һәм башындагы татар бүрегенең калыбсыз булуы илә Парижлыга охшамаса да, үзе белгән фарсы, гарәби лисаннарын французча үгрәтә алуы илә Парижда мөдәррис булырга истихкак кәсеб итмештер[6]. Салмак кына табигатьле, озын буйлы, ир уртасы яшьләрендә бер кешедер.

Әстерханда бәгъзе[7] гаҗәмнәрнең[8] Русия тәбәгасы улдыклары илә бәрабәр[9] Иран тәбәгасы күбрәктер. Бонларның бер кыйсеме[10] сәүдә илә шөгыльләнәләр. Дөге, палас, фрукты вә гайре персидский маллар илән сәүдә итәләр. Күбрәк кыйсеме хәммаль (йөк ташучы) вә шундай кара хезмәттә йөрүчеләрдер.

Әстерханда иранииларның җәмгыятьләре юк. Фәкать лязем булганда «Агай-эне сәүдәгәрләр» иттифак илә[11] эш күрәләр, башкалар да шуларның сүзләрендән чыкмыйлар икән.

Әстерхан әрмәниләре укуга бик һәвәсле[12] булмаулары илә бәрабәр Әстерхан базарында һәрбер милләткә галәбә иткәннәр[13].

[1] Тәсадеф итдекемез – очрашкан.
[2] Интисаблары – нисбәтле, бәйләнешле булулары.
[3] Әлсинәи шәркыя мәктәбендә – шәрык телләре мәктәбендә.
[4] Лисаннарына – телләренә.
[5] Кызылбаш – шигый мәзһәбендәге иранлы.
[6] Истихкак кәсеб итмештер – лаеклы булып танылган.
[7] Бәгъзе – кайбер.
[8] Гаҗәмнәрнең – иранлыларның.
[9] Илә бәрабәр – белән бергә.
[10] Кыйсеме – өлеше .
[11] Иттифак илә – бергәләшеп.
[12] Һәвәсле – берәр эшне теләп башкаручы, күңел куючы.
[13] Һәрбер милләткә галәбә иткәннәр – һәрбер милләттән артып киткәннәр.

Галәбәләре көндән көн мәйданга чыга бара. Иран малы илән сәүдә итүчеләрдән дә иң зур фирмалы әрмәниләрдер.

Ләкин гаҗәмнәрнең хәммаленә дөньяда һич инсан вә һичбер хайван рәкабәт итәргә[1] мөмкин түгел. Гадендә 5–10 пот вә бәгъзеләре 12–15 пот күтәреп ташый торган бу мәхлуклар дөньяның бөтен рәхәтендән мәхрүм уларак яшиләр, ашлары чүрәк[2] вә су, яки карбыз. Итне һәфтәгә[3] бер дәфга ашамый торганнары да бар. Өстләрендә кыргыйныкы кырык төрле ямаулы киемнәр. Аякларына бер дә кимиләр. Әгәр кадак йә шырпы кадалса, бер аягына басып торып кадакны алып ташлый да, канына тузан сибеп, юлына китә бирә. Кан туктаусыз агарлык булмаса, җәрәхәтне бәйләп тору юк.

Берсендән сорыйм:

– Кардәш! Айга ничә манат эшлисең?

– Егерме-егерме биш манат.

– Ашарга күп хәреҗ идәсең[4]?

– Дүрт манат, биш манат.

– Агыр йөк ташыянда оруҗ зәхмәт вирмәюрме?[5]

Хәммаль бу сүзне тиешсез тапты булырга кирәк, тавышыны үзгәртеп бик ышандыру сурәтенә кертеп:

– Куәт вирән вар[6] – дия җавабы илә тәгаҗҗебнең[7] урынсызлыгын аңлатды һәм хакыйкатән[8] дә боларга бирелгән куәт әсбабы табигыя илә[9] булырга һич дә охшамыйдыр.

Әстерханда мәгыйшәтнең[10] кыйммәтлеген хәтергә алсаң, айга 4–5 сум илә тук тору да бик мөшкел булачак. Әмма эшче кешенең тук торуы өчен Әстерханда 25–30 сум кирәк.

---

[1] Рәкабәт итәргә – көндәш булырга.

[2] Чүрәк – икмәк.

[3] Һәфтәгә – атнага.

[4] Хәреҗ идәсең – тотасың, сарыф итәсең.

[5] Агыр йөк ташыянда оруҗ зәхмәт вирмәюрме? – Авыр йөк ташучыга ураза авыр түгелме?

[6] Куәт вирән вар – куәт бирүче бар (Аллаһы Тәгаләгә киная).

[7] Тәгаҗҗебнең – гаҗәпләнүнең.

[8] Хакыйкатән – чыннан да.

[9] Әсбабы табигыя илә – табигый сәбәпләр белән.

[10] Мәгыйшәтнең – тормышның.

Һәм дә 35–40 сумны айга бетерә баручы татар извозчиклар бик тук торучылардан исәпләнергә ярамасалар кирәк.

Бу хәммальләрнең бер дә аракы эчмәүләре аларга бүтән «крючник»лар арасында имтияз[1] бирәдер.

## II
## Петровсктан[2]

*Диңгез сәфәре. Петровскта мәсҗедләр. Бик бай ибтидаи мәктәб[3]. Сөнни-шигый бергә. Мөхәммәдгали шаһны[4] көтүчеләр. Янә мәсҗед.*

Әстерханнан «Каспий» пристаньнарына юлчы вә йөк ташучы ширкәтнең берсе мөселманныкы (Бакулы Тагиевның) булдыгыннан мин диңгездә шул ширкәт пароходларына утырып китмәкче идем. Фәкать, муаффәкъ була алмадым[5]. Чөнки аның пароходлары көн саен булмаганга, миңа кичекмәк лязем була иде. Аны ихтыяр итмәдем.

Почта пароходының вакытлы йиткерүенә ышанып, мин «Кавказ Меркурий» ширкәтенең пароходларына ултырмакчы булдым. Сентябрь 6 сында бу ширкәтнең «Константин Кауфман» исемле пароходына менеп, иртә 10 сәгатьтә диңгезгә таба сәфәр иттек. Һавалар көннән бирле бик яман җилле булып торганга, диңгезнең басынкы булу ихтималы юк иде. Алай булса да, җил басылуны өмидләнеп, диңгездә рәхәт баруны хыял кылучылар бер дә булмагандыр дип әйтеп булмый. Адәм баласы өмидләнгән нәрсәсенең булачагы өчен түгел, бәлки өмиднең үзе ләззәтле булдыгы өчен өмидләнәдер.

Пароходымыз диңгезгә якынлаша-якынлаша татлы өмидләр бушка чыга башлады. Шөйлә[6] ки пароход диңгезнең 9 фут тирәнлектәге урынына килеп йиткәнче, юлчыларның хәлдән таеп егылучылары булгалады. Бу 9 фут дигән урында баржаларны

[1] Имтияз – өстенлек.

[2] Петровск – 1857–1921 елларда Махачкала шәһәренең исеме (бүгенге көндә Дагстан башкаласы) (*Г. Ханнанова иск.*).

[3] Ибтидаи мәктәб – башлангыч мәктәп.

[4] Мөхәммәдгали шаһ – 1907–1909 елларда Иран шаһы (*Г. Ханнанова иск.).*

[5] Муаффәкъ була алмадым – булдыра алмадым.

[6] Шөйлә – шулай.

«якорь» илә ныгытып пристаньнар ясалган. Диңгез пароходларының олугълары Иделгә таба шуннан юагры килә алмыйлар. Нәрсәләрен вә юлчыларын шунда бушаталар вә шунда яңыны алалар. Идел пароходлары, Әстерханнан түбән төшеп, диңгезгә якынлаша алмадыклары кеби, Әстерхан илә диңгез арасында йөри торган махсус пароходлар һәм 9 футтан соң диңгез эченә йөри алмыйлар.

Шул тарика[1] без һәм 9 футта «Кафман» пароходыннан «Александр Второй» пароходына күчтек. Диңгез пароходларыныкы кеби буның да көпчәкләре астта, артта (винтовка) иде.

Диңгез пароходларының елга пароходларына башка булган тәшкилятын[2] бәян итәргә бүтән мөхәррирләргә калдырып, мин үземнең әхвальне тасвирда дәвам итәм. 7 сентябрьгә каршы төндә, Аллага тапшырып, диңгезгә чыктык. Дулкын без курыканнан да артыграк котырды. Тау-тау дулкыннар куышып килгәндә, безнең зур пароходымыз урам ташуындагы йомычка кебек бер уңга, бер суңга кагылып, бер башы күтәрелеп, бер башы төшеп, каты елгага каршы акрынлап барды. Күтәрелү, төшү даимән бер ярым-ике сажин арасында әйләнеп торганнан, безнең селкенү бик биек таганда атынуга охшап, янга авышулар моның өстенәдер. Янга авышкан кешеләр яткан урыннарыннан тәгәриләр, шуалар; нәрсәләр куйган урыннарыннан төшәләр, адәмнәр дә тотынмыйча ята алмыйлар. Пароходның астагы бүлмәләрендә һава тончыгып бозылдыгыннан кешеләр ачык һавага чыгалар, анда су чәчрәтеп, ныграк эләксә, бәреп егадыр. Диңгезнең дулкыны, көчәя-көчәя, без Петровскка йиткәнче дәвам итте. Егерме дүрт сәгать тагын атынып торган инсанның ни хәлгә киләчәген уйлау берәүгә дә читен түгелдер. Бу бер тәүлек эчендә һичбер нәрсә ашарга вә эчәргә мөмкин булмадыкын вә ярамадыкын да гыйлавә итәргә[3] кирәк.

Озак тирбәлеп тору илә адәмнең саруы кайный, күңеле болгана, укшый башлый, вә күп кешеләр ашаганнарын киредән түгәләр. 7 сентябрьдә «Александр Второй» пароходында бундый кешеләр йөздән 80 чамасында булды. Бөтенләй һушсыз булып

[1] Тарика – юл.
[2] Тәшкилятын – төзелешен.
[3] Гыйлавә итәргә – өстәргә.

ятучылар да яртылаштан ким булмагандыр. Чөнки юлчылар эчендә хатын-кыз, бала-чага күп иде. Алар тизрәк мөтәәссир булалар[1].

Бу кадәресе үлемнән шикләнмәгән вә йә курыкмаган кешеләр өчендер. Әгәр дә берәүнең күңеленә курку йә башка шикләнү керсә. Аның өчен зәхмәт ике кат, бәлки артыктыр.

Андыйлар ник чыкканнарына үкенеп яисә күрәчәк кешесен күрми калачагына кайгырып, иң ачы аһ-ваһларын фаш итәләр. Меңләрчә кешенең ыңгырашулары, егълашулары, аһ-ваһлары бергә җыелып, зәгыйфь йөрәкле кешеләргә бигүк яман тәэсир итәдер.

9 футтан Петровскка 12 сәгатьтә киләчәк юлны почтовый пароходымыз көчкә 24 сәгатьтә китереп йиткерә алды. Бу егерме дүрт сәгать, бәлки минем гомеремдәге тәүлекләрнең иң озыны булгандыр. Моннан элек Әстерхан илә Петровск вә Баку араларында ничә дәфгалар[2] йөрдекемдә бик матур һавалар илә бәрабәр яманнарны да күргән идем (бер пароходымыз комга утырып, ике көннән соң дулкын өстендә көймәләр илә икенчегә күчү, һәм бик яман дулкында кечкенә пароходта барганда, батып яткан икенче пароходны тамаша итеп узулар да шуның эчендә) һичберсендә бу кадәр агырлык булмаган иде. Хәер, ул вакытта үземез пароходның уртасында булдыгы хәтеремдә; әмма бу дәфга пароходның башындарак булуымыз миңа бигрәк яман тәэсир иткән булса кирәк. Чөнки тирбәлү пароходның уртасында кимрәк буладыр.

Сентябрь 7 сендә, караңгы булгач, Петровск лиманына килеп кердек, иркенләп суларга мөмкин булды. Шул пароходта Бакугача юлда дәвам итмәк күп юлчылар өчен имкянсыз[3] иде. Билетым шунда кадәргә булганга, мин Петровсктан төштем. 8 ендә Петровскта Мөхәммәдгали шаһны көтдекләреннән, мин аны каршы алуны ният итеп, Бакуга китәчәк поездга утырмадым. Истирахәткә[4] дә чынлап ихтыяҗ бар иде. Бер латыйфәче[5] юлдашымның тәгъбиренчә[6] «Мөхәммәдгали шаһның юлга чыгуы

[1] Мөтәәссир булалар – монда: бирешәләр.
[2] Дәфгалар – тапкырлар.
[3] Имкянсыз – мөмкин түгел.
[4] Истирахәткә – ял итүгә.
[5] Латыйфәче – шаян сүз остасы.
[6] Тәгъбиренчә – аңлатуынча.

илә диңгез котырып, безне җәфа чиктергән» булса да. Мөхәммәдгалиның киләчәге сылтавы илә Петровскта бер көн ял иттем.

* * *

Петровскта кызылбашлар, иранлы вә кавказлы уларак, бер-береннән аерымрак торалар. Мәсҗедләре аерым. Һәр ике мәсҗедкә киттем, Кавказлыларныкы гадәтән[1] бер абзар шикелле караңгы, тәбәнәк каралты, камыш намазлыклар җәелгән. Буяусыз гына садә бер минбәр, арт буен рәшәткә илә хатыннар өчен бераз аерган, вәссәлам. Михраб, минбәр кеби мәсҗед хасиятләре һәм дә мәһабәтлек вә голувияттән[2] бер шәй юк. Ахундлары мәһабәт гәүдәле, тәмиз[3] киемле. Бераз мосахәбә иттек[4]. Гыйльме кәлям[5] илә мөбтәля булганга[6] охшады. Җәһәннәмлеләрнең тәннәре яңарып торуы тугърысында яңа игътиразлар[7] нәкыль итәргә[8] башлаган иде, мин җәһәннәмлеләрне Аллаһының ихтыярына вә зобаниларның[9] мәһарәтенә тапшырып, ахунд илә саубуллаштым вә икенче мәсҗедкә киттем. Бу мәсҗед Петровск әһле хәйратыннан[10] Фәтхуллаев тарафыннан салынган. Манарасы булмаса да, түбәсенә ай куелу, михрабы булу һәм кыйбла уңаена салынуы илә тәмам мәсҗедкә охшый. Хатыннар бүлмәсе сәндерәгә ясалган мәсҗеднең эче якты вә яхшы, паласлары бар. Имам тору өчен мәгъсумлык[11] шарт булу бәһанәсе илә[12] бонда җәмәгать намазы укылмый. Ара-сыра[13] килгән вагыйзьләр[14] халыкка үгет-нәсыйхәт бирәләр. Пристаньдә бер консулханә

[1] Гадәтән – гадәттә.
[2] Голувияттән – бөеклектән.
[3] Тәмиз – пакь.
[4] Мосахәбә иттек – сөйләштек.
[5] Гыйльме кәлям – теология.
[6] Мөбтәля булганга – шөгыльләнгән булганга.
[7] Игътиразлар – каршы сөйләүләр, каршы дәлилләр.
[8] Нәкыль итәргә – сөйләргә.
[9] Зобаниларның – газап фәрештәләренең.
[10] Әһле хәйратыннан – хәйриячеләреннән.
[11] Мәгъсумлык – гөнаһсызлык, кимчелексезлек.
[12] Бәһанәсе илә – сылтавы белән.
[13] Ара-сыра – ара-тирә.
[14] Вагыйзьләр – вәгазьчеләр.

мәэмүренең[1] эшчеләрне вәгазь тыңларга мәсҗедкә чакырганын тәгаҗҗеб илә[2] күрдем. Мәгълүм ки, бездә гадәт болай түгел.

* * *

Петровскның ифтихар итәрлек[3] бер мөәссәсәсе (учреждение) – Мәликмөхәммәд Бабаевның үз исеменә салдырдыгы ибтидаи[4] мәктәптер. Русча-мөселманча бу мәктәпнең министр тарафыннан тәсдыйк ителгән[5] уставын вә программын күздән кичердем.

Бабаев бу мәктәп өчен 70–80 мең рубләлек йорт-йир вәкыф итеп[6] калдырмыш, идарәсен махсус һәйәткә[7] тапшырмыш. Полицмейстер, мировой судья, мәктәпләр директоры вә аның тарафыннан тәгъйин ителгән[8] мөгаллим бу һәйәттә лөзүми әгъза (непременный член) булып, рәисе дә түрәләр тарафыннан тәгъйин ителәдер. Сайланган кешеләрнең нөфүзе[9] юк хөкемендә. Хасил[10], бу мәктәпнең идарәсе бөтенләй хөкүмәт кулындадыр.

Ишеттекемә күрә, уставны ясаган ул замангы[11] инспектор мәрхүм Бабаевны сүзгә осталык илә генә кандырмыш[12]. Бабаев министрдан тасдыйк ителгән уставны соңыннан төшенгәч, бармагын тешләмештер.

Нә исә хәзерге баш мөгаллим вә мөдир Мирзагали әфәнде Касыймовның шәхси фазыйләте илә[13] бу мәктәп тә дикъкатькә шаян[14] гүзәл җәһәтләр булдыгы да күзгә күренәдер. Мәсәлән: мәктәпнең укыту әсбабы бик йитешлекле. Шигыйлар илә

[1] Консулханә мәэмүренең – консуллык хезмәткәренең.
[2] Тәгаҗҗеб илә – гаҗәпләнү белән.
[3] Ифтихар итәрлек – горурланырлык, мактанырлык.
[4] Ибтидаи – башлангыч.
[5] Тасдыйк ителгән – расланган.
[6] Вәкыф итеп – җәмәгать файдасына биреп.
[7] Һәйәткә – комиссиягә.
[8] Тәгъйин ителгән – билгеләнгән.
[9] Нөфүзе – сүз үтемлелеге, абруе.
[10] Хасил – кыскасы.
[11] Бу мәктәп 1901 елда тәэсис ителмеш (нигезләнгән) *(Б.Шәрәф иск.).*
[12] Кандырмыш – ышандырган, алдаган.
[13] Фазыйләте илә – игелекле гамәлләре аркасында.
[14] Дикъкатькә шаян – игътибарга лаек.

бәрабәр[1] 25–30 кадәр сөнни балалары укыйлар. Мөгаллимнәрнең миңа хәбәр бирүләренчә, балалар арасында мәзһәб фәркы[2] һич тә сизелми имеш.

Бу мәктәп ул җәһәттән караганда бигрәк тә мөһимдер[3]. Бу мәктәптәге сөнниләрнең күбрәге Дагстан әһеле гомык[4] балаларыдыр. Мин беренче дәфга[5] уларак гомык телендәге мәктәп китапларын күрдем. Әксәрисе[6] Әбү Сөфьян әл-Газанши тарафыннан җәмегъ ителеп Тимерхан Шурада[7] Мөхәммәд Мураев литографиясендә басылганнар. Гомык теле төрки асылыннан төрәп[8] Казан шивәсеннән азәрбайҗан вә кыргыз шивәсе кадәр фәрыклыдыр[9]. Бу шивәдә кыйраәт[10], тәҗвид[11], җәгърафия вә хисап китаплары азаз укып карадым. Гомык балаларын укытачак татар мөгаллименең күп зәхмәт чигәргә мәҗбүр булмаячагы аңлашылды.

Бу мәктәпнең программын вә фарсы укытылуны тәнкыйть итүнең урыны «Вакыт» сәхифәсе түгел. Әстерхандагы иранилар мәктәбен язганда да бу җәһәткә тими киткәнем укучыларның хәтерендәдер.

8 сентябрьдә Петровскның «Кавказ Меркурий» пристаненда эшсез йөрүчеләр күп иде. Бонда консулханә мәэмүре Һидаять

---

[1] Илә бәрабәр – белән бергә.

[2] Мәзһәб фәркы – мәзһәб аерымлылыгы.

[3] Кавказда хәнәфиләр илә шафигыйлар арасында да бер-берсен аңлашмау бар. 5 сәнә (ел) мөкаддәм (элек) Грозный каласында улдыгымда андагы имам Галим әфәнде Яхинның бу мәзһәб фәркын (аерымлыгын) оныттырырга муаффәкъ булуын мәмнуният илә күргән идем. Шөйлә ки, аның мәсҗедендә җомганы хәнәфиләр вә шафигыйлар аралаш уларак бергә укыдык. Хотбә укучымыз хәнәфи, җомгада имам торучымыз шафигый булды. Бәгъзеләр ихтыяты зоһыр (өйлә) укыды, бәгъзеләр юк. Бәгъзеләр 2 рәкәгать сөннәтне элек укыдылар, бәгъзеләр дүртне. Шушылар һич тә халыкның тәгаҗҗебен муҗиб булмады (халыкны аптыраштa калдырмады) (*Б. Шәрәф иск.*).

[4] Гомык – комык (Төньяк Кавказдагы төрки халык).

[5] Дәфга – тапкыр, мәртәбә.

[6] Әксәрисе – күпчелеге .

[7] Тимерхан Шура – 1834–1922 елларда Буйнакск шәһәренең исеме (бүгенге көндә Дагстан составында) (*Г. Ханнанова иск.).*

[8] Төрәп – барлыкка килеп.

[9] Фәрыклыдыр – аермалыдыр.

[10] Кыйраәт – уку.

[11] Тәҗвид – Коръәнне дөрес итеп уку кагыйдәләре.

бәк илә таныштым. Яңы[1] очрашканда гадәт булган берничә сүзне уздырганнан соң, мин аңа: «Хәзрәтеңез Мөхәммәдгали шаһны интизар итәләрме[2]?» – дидем. Ул мондый сөальне миннән көтмәгән шикелле сурәт күрсәтеп:

– Хәер[3] әфәндем! Шаһы сабикъ[4] вә инде мәхлүгъ[5] Мөхәммәдгали мирзаны интизар идәмез. Күрәек, диңгез у нанкүре ничек бурая атар[6], – диде.

Шунда таныштыгым иранлыларга да шул сөальне икенче гыйбарә илә тәкрар иттем. Алар: «Без интизар итмимез, бәлки аның килгәнен тамаша итәргә төштек», – дип җавап бирделәр.

Мөхәммәдгали мирзаны алып китәр өчен 10 гадәд[7] вагон «Меркурий» пристаненә тайяр ителгән[8]. Шәһәр вә су полицияләренең, тимер юл вә шәһәр жандармнарының баш һәм вак мәэмүрләре җыелып көтәләр, Иран консулы болар эчендә юк иде. Мөхәммәдгали ул көн килмәде. Мин дә кичке поезд илә Бакуга юнәлдем.

Петровскта «Маркс»[9] номерында, Бакуда «Иттифак» газетасының мөхәррире Һашим бәк Вәзиров илә күрештек. Шимали[10] Кавказның шәһәрләрен вә авылларын йөреп кайтып килә икән.

Петровск полицмейстеры Тарковский, округ начальнигы Әмиров, сәрдары һәм[11] Тарковский исемнәрендә мөселманнар икән. Боларның тәэсире аркасында вак мәэмүриятләргә[12] дә күп мөселман алынмыш.

---

[1] Яңа – яңа.

[2] Интизар итәләрме – көтәләрме.

[3] Хәер – юк.

[4] Шаһы сабикъ – элекке шаһ.

[5] Мәхлүгъ – тәхеттән төшерелгән, вазифасыннан азат ителгән.

[6] Күрәек, диңгез у нанкүре ничек бурая атар – диңгезнең ул рәхмәтсезне монда ничек атканын күрик.

[7] Гадәд – данә.

[8] Тайяр ителгән – әзерләнгән.

[9] Мондый яңгыравыклы исемгә тәгаҗҗеб ителмәсен (ис китмәсен). Шәрык халкы исемгә саран түгелләр, Петровск касабасында (кечкенә шәһәрендә) боннан башка «Лондон», «Версаль» номерлары, «Париж», «Европа» ресторанннары «Женева», «Нью-Йорк» магазиннары вә гайреләр бар (*Б.Шәрәф иск.*).

[10] Шимали – төньяк

[11] Сәрдары һәм – сәрдары да (биредә сәрдар – җирле жандармнар җитәкчесе булса кирәк).

[12] Мәэмүрият – вазифа.

Бу касаба[1] тугрысында озын язарга тугры килгәндә, мондагы казанлылар мәхәлләсен дә онытырга ярамастыр. Бонда имам Баязид әфәнде вә йирле подрядчик Әминев вә гайреләрнең[2] иҗтиһады илә[3] иганә җыелып, хәнәфиләр өчен таш мәсҗед бина иделмеш. Мәсҗедлеге, урыны вә бинасы җәһәтеннән бондагы башка мәсҗедләргә күп өстендер. Ләкин мәхәллә 4–5 елдан бирле зураймый икән. Чөнки шәһәрдәге бер зур фабрик эшен туктаткан. Шуңа күрә үрдән килгән татарлар Петровскта туктамыйлар.

## III
## Баку – Әнзәли

*Мөселман пароходы. Бөтен гаҗәм[4]. Хөррият мөҗаһидләре. «Шәригатьмәдар»ның угылы. Мәкәрҗә – Багдад тиҗарәте. Диңгез сәяхәте. Ленкорань. Астара. Корал күчерү.*

Мөселман пароходында йөрергә теләгәнемне 2 нче мәктүбтә язган идем. Бакудан китәргә хәзерләнгәч, пароход игъланнары тикшерә башладым. Һәр йирдә «Кавказ Меркурий» ширкәтенең игъланнары күземә төшә. Газеталарда да шул гына. Тагиев (Куринский – Каспийский) ширкәтенең пристанена бардым. Анда да расписание кеби нәрсәләр юк, кантордан сорашып белдем ки, кич сәгать 6 да пароход китәчәк икән. Тагиев Бакуның башка мөселманнары кебек үк игъланнарга хилаф. Үзе кесәсендән газета нәшер иттерә. Шунда пароходларының вә башка сәүдәләренең игъланы юк. Газетасы аңа рәкыйб[5] булган фирмаларның игъланы илә тулган.

Тагиев: «Безне игъланссыз да беләләр», – дип әйтә имеш. Казанда бер сабынчы Хаҗи да миңа шулай дигән иде.

«Меркурий» фирмасы ни өчендер бу игътикадка килми.

[1] Касаба – кечкенә шәһәр.
[2] Вә гайреләрнең – һәм башкаларның.
[3] Иҗтиһады илә – тырышлыгы белән.
[4] Гаҗәм – иранлы(лар).
[5] Рәкыйб – конкурент.

Пароходка билет алганда, кассир паспортымны да алып калды. Таможня өчен лязем имеш. Пароходка кергәндә, һәммә юлчыларның нәрсәләрен актардылар. Ливарвир[1] вә корал булмасын дип тикшерәләр имеш. Ләкин ливарвирны тикшерүләрендән тупны да качырырлык.

Без утырган «Ленкоранец» яндан көпчәкле, кечкенә иске пароход иде. Кергәч тә күзгә бәреләә торган нәрсә – Хаҗи Зәйнелгабидин Тагиевның портретыдыр. Бик күп медальләре, орденнары вә лента илә рәсми мундирда вә бүрек киеп төшкән.

Моңарчы 50–60 төрле рус пароходларына утырып, һичберсендә хуҗасының портретын күргәнем юк иде.

Командиры – җил як гына, йиңелчә бер мөселман. Карылган тавыш илә бәгъзеләренә русча, бәгъзеләренә төркичә командавать итә. Фарсыча сөйләшә.

Командирның помощниклары – руслар, лоцманнар, матрослар – кызылбашлар, официант – Сембер губернасы татары, пассажирлар – гаҗәм, гарәб, әрмән, татар вә әксәрият үзрә[2] азәрбайҗан төрекләре иде. Боларның Кавказлы булганнары да бар. Юлчылар арасында беренче класста 3–5 әрмән вә рус хатыннары, 3 нче класста 15 ләп чаршауга төренгән мәхлуклар да күренә иде.

Һава бик яхшы, су – тоз булганга диңгездә тулы айның шәүләсе үзендән дә матуррак күренә...

Диңгез кичәләренең иң гүзәле илә рәхәтләнеп барыр өчен, беренче, икенче класс юлчылары һәммәсе югары терраска чыкканнар.

Сөйләшә-сораша бер-берсе илә танышалар. Мин дә бу ике класстагыларның ярымындан артыгы илә таныштым. Бәгъзеләрен түбәндә зикер дә итәчәгем.

Боларның эчендән иң бөтен бер персиян. Пароходка кергәч тә штиблетларын салып, бөтенләй кыналы аягына башмакларын киде, безгә карап, әфьюнле пилюлянең файдаларын сөйлисөйли, берне йотты, соңра бик кәефләнеп сөйләргә кереште. Сүзләрендән аңлашылдыгына күрә, бу хаҗи асыл Бакулы булып,

[1] Ливарвир – револьвер.

[2] Әксәрият үзрә – күбесенчә.

40 елдан бирле Рәшттә мануфактур илә сату итә икән, бер кызы, бер угылы булып, соңгысыны өйләндерер өчен, 12 мең сум хәреж[1] тоткан, алай да килене вафат булган. Сипаһдар[2] (хәзерге садре әгъзам[3]) боның бик дусты имеш, бөтен әтраф бу хаҗины белә, без дә, Рәшткә баргач аңа кунак булуымыз лязем икән... вә һакәза[4].

Бу карт чәчен алдырган, фәкать кынадан кызарган сакалы, колакларының өстенә борылып менеп, башының түбәсенәчә йеткән. Бинаән галәйһи[5] башы алдан вә артдан яп-якты, ике ягындан төкледер. Кул тырнакларыны һәммәсен кынага буяган, уң кулының чәнчә бармагына бик зур бриллиант кашлы кыйммәт бәһале йөзек кигән, күзләре буш чагында шул йөзеккә карап текәлгән була.

Өстенә кигән 3 кат озын киеме вә 7–8 пот әсбаплары тугрысында сүзне озайтып укучыларны ялыктырырга теләмим.

Бакуда арурак мөселман ашханәсе «Толуг[6]»га барганда һәр көн очраган бер кеше минем дикъкатемне җәлеп иткән иде. Бу шәхес озын киемнәре вә путасы илә суфыйларга охшавына карамыйча, рамазанда көндез ашый, эчә, каһвәханәдә тик утырып бик чынлап сәясәттән, мәзһәбләр тугрысындан моназара[7] итүчеләргә, бәгъзан[8] сүзләр кушып, аларны юри саташтыра, үзе, мыек астындан көләр өчен, моназарага дә керешә иде. Соңра кайсы тарафның сүзе өстә калуга әһәмият бирмичә, гәзитә укырга керешә, яхуд игътибарсыз гына «Хода хафиз[9]» дип чыгып китә иде. Шул кеше пароходда миңа килеп эндәште: «Бә-сәламәти! Сез дә бу пароходтамысыңыз?». Соңра танышып киттек.

---

[1] Хәреж – чыгым.

[2] Сипаһдар – гаскәр башлыгы.

[3] Садре әгъзам – баш вәзир (премьер-министр).

[4] Вә һакәза – һәм башкалар.

[5] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.

[6] Толуг – туу, чыгу.

[7] Моназара – сүз көрәштерү.

[8] Бәгъзан – вакыт-вакыт.

[9] Хода хафиз – туры мәгънәсе «Хода саклаучы». Ираннарда саубуллашуны белдерә *(Г. Ханнанова иск.)*

Электә Кавказ казыйханәләренең берендә әгъза булган бу мулла андан чыгып, сәяси эшләр илә шөгыльләнә башлаган, русча өйрәнгән, Иранда берничә дәфгаләр озын мөддәткә[1] калып, мөһим хезмәтләрдә булынган.

Иран ихтиляленә катышу илә төһмәтләнеп[2], Тифлистә берничә русияле тотылганда, бу да эләккән. Шундан качып, исемен алыштырган, хәзерге паспорты Мирза Галиәкбәр Тәбризи исемендә икән.

Иран эшләренең эчендә булганга, хаҗ мөнәсәбәте илә Төркиягә сәяхәт иткәнлеге вә үзе дә Кавказда яшәгәнгә биладе исламиянең әхвәлене[3] яхшы төшенгән, сәяси мәсьәләләрне гәзитләрдә тәгъкыйб итә[4] «мөселманнар дөньяда да газиз булырга тиеш», дип ышана. Мөселман кеше. Боның бер иптәше дә бар. Хәзердә Мирза Галиәсгар Әрдәбили исемендәге бу сары егет Кавказдагы кечкенә генә кибетене тентүләгәндә качарга мәҗбүр булган.

Иранның ихтилял сугышларында һәркаюсында сафта торган мәшһүр Сәгыйд Сәлмасый[5] боның янында шәһид булган. Иранның азәрбайҗанча булган иң мәшһүр ихтилял җыры моныкы имеш.

Беренчесе шигыйлык тәгассыбындан[6] ислам тәгассыбына күтәрелгән, мәзһәб фәрыкларына[7] илтифат итми. Динне яхшы белә. Соңгысы дин гыйлемнәрен күп укымаган. Иран руханиларыннан йөдәгәнгә күрә дингә ихтирамсыз. Хаҗга бардыгын искә төшергәндә, «тамаша өчен йөреп кайттым», ди.

Берәүнең «син – бабисың[8]» диюенә каршы диде: боңа мин дә Насыйретдин шаһның катиле. Безнең имам Ризаның шул төһмәткә карашы биргән җавабын бирдем. Ул димеш: «Мин

[1] Мөддәт – вакыт.

[2] Төһмәтләнеп – гаепләнеп.

[3] Биладе исламиянең әхвәлене – мөселман илләренең хәлен.

[4] Тәгъкыйб итә – күзәтә.

[5] Сәгыйдь Сәлмасый (1887–1909) — азәрбайҗан шагыйре *(Г. Ханнанова иск.).*

[6] Тәгассыб – фанатизм.

[7] Фәрык – аермалык .

[8] Баби – Сәедгали Мөхәммәд Ширази (Баб) (1820–1830) нигез салган динне тотучы *(Г. Ханнанова иск.).*

баби да, мәҗүси дә түгел, шаһ аулаучы вә бөтен милләтнең фидаисе[1] Ризамын»[2].

Бу «мөҗаһид»ләрнең сөхбәтендән Иран сәяхәте өчен истифадә иттем[3] вә Иран ихтилялына даир күп мәгълүмат алдым.

Беренче класста урын алган чалмалы вә тәмиз[4] киемле бер егет мәракымны[5] бигрәк җәлеп итте.

Чөнки чалмалы вә озын чабулы шәхесләрнең кеше төсле йөри билгәне, өст-башын ару тотканы бик сирәк күреләдер. Өстендәге Шам җөббәсе вә башындагы гарәб чалмасы миңа җөрьәт[6] биреп, моңа тугрыдан гарәпчә эндәштем:

– Сәфәреңез мөбарәк булсын, Әнзәлигәчә барасызмы?

– Сезгә дә сәламәтлек вә гафият[7] телим, әйе Әнзәлигә, андан Рәшткә.

Ул да эшләпәле кешенең гарәпчә сөйли башлавына аз гаҗәпсенмәде. Вә тиз үк мине дә сораша башлады. Казанныкы дигәч тә:

– Ә Казанның яхшы лимонады бар. Рәшткә китерәләр, – диде.

Мин бу лимонадның «Гарахы[8]» ныкы булуын аңлап, килмешәк шул ирнең йөземне агарттыгына мөтәәссир булдым[9].

Манжетлы, сорочкалы, габалы[10], гамамәле[11] бу егет үзенең электә Бәйрутта тәхсыйль итдекен вә хәзер Венадан килдекен сөйләде.

Ихтилялчылар Рәштне алганда, бу ике иптәше илә качып киткән, атасы шәригатьмәдар[12] әсир төшкән.

---

[1] Фидаи – үз-үзен корбан итүче.

[2] نه بابی نه مجوسی غلام هشت چهار
فدائ همه ملت رضای شاه شکار

[3] истифадә иттем – файдаландым.

[4] Тәмиз – чиста, пакъ.

[5] Мәракымны – кызыксынуымны.

[6] Җөрьәт – кыюлык.

[7] Гафият – исәнлек.

[8] Гарахы – аракы (азәрбайҗанча).

[9] Мөтәәссир булдым – тәэсирләндем.

[10] Габа – плащ сымак өске йон кием.

[11] Гамамә – чалма.

[12] Шәригатьмәдар – шәригать кушканча хөкем итүче.

Рәшт вилаятенең иң олуг руханисы булган шәригатьмәдар бик бай булып, теге хаҗиның тәгъбиренчә, ярты Рәшткә малик имеш.

Ихтилялчылар 90 мең рублә нәкыд[1] пул алып азад иткәннәр.

Иранда асаешлык[2] булгач, инде бу да кайта. Югарыда мәзкүр мөҗаһидләрнең берсе аңа «Астарада көтәргә мөҗаһид тәгъйин ителгән» дип, мөзах[3] илә аның юл рәхәтен шактый җуйды.

3 нче класста киплар[4] өстендә утырып гарәпчә сөйләшеп чәй эчә торган ике кешегә дикъкать иттем. Боларның берсе кайтарма якалы киемнәр кигән вә богдай төсле чәһрәле кеше. Башына кара шакмаклы, йиңел генә чалма кигән. Икенчесе – озын Иран киемендә формат тугъры китереп чалмалысы илә таныштым. Аның сөйләгәннәрен кара кулчыларымызның дикъкатенә гарыз итәм[5].

Бу кеше Багдад сәүдәгәре икән.

Мәкәрҗәдән килә. Әнзәли – Рәшт – Һәмәдан – Кирманшаһ – Багдад тарикы илә ватанына кайта.

Үзе Төркия тәбәгасы. Алай булса да, бәгъзе сәбәбләр өчен үз ходудларындан[6] чыккач Иран паспорты илә йөри.

Мәкәрҗәгә 30 мең данә илтер[7], бәрән вә һәртөрле каракуль илткән.

Бу мал Багдадтан Мәкәрҗәгә Иран аркылы 50 көндә барып ирешә, Әнзәли илә Багдад арасында арба илә 25 көн йөреләдер. Ягъни ял итәргә тукталып-тукталып.

Багдадтан Мәкәрҗәгә илтер (тире) башына 20 тиен мәсариф[8] чыга.

Пошлина түләүләре түбәндәгечә: Төркиядән чыгарганда – сумына бер тиен. Иранга кергәндә – бер меңдән бер кыран (22 тиен).

---

[1] Нәкыд – акча байлыгы. Бу очракта залог.

[2] Асаешлык – тынычлык, иминлек.

[3] Мөзах – мәзәк, көлке.

[4] Киплар – йөк бәйләмнәре.

[5] Гарыз итү – тәкъдим итү.

[6] Ходуд – чик, граница.

[7] Илтер – тире.

[8] Мәсариф – чыгымнар.

Русиягә кергәндә потыннан бер сум 50 тиен. Русиянеке илтернең бәһасенә 5% төшә. Бу кеше, Мәкәрҗәгә малын көтеп аны сатып тапшырып бетерер өчен анда 40 көн торырга мәҗбүр булган. Бу эшен бетергәндә ярминкәнең банклары ябылганга, кулына кергән 10 мең сум акчаны Багдадта «Лионский кредит» банкысына перевод ясатыр өчен, Мәскәүгә барган. Шуңа күрә хәзер кичегебрәк кайтып килә. Багдадтан Мәкәрҗәгә килеп кайтуга, ягъни ел буе чыккан нәрсәләрне сатарга 4 ай вакыт уза, ди. Мануфактур күтәренке булганга, Мәкәрҗәдән вә Мәскәүдән мал алмаган.

Диңгездә бер дә дулкын булмаганга, кечкенә генә пароходымыз да бер дә чайкалмады. Хәтта язу язып барырга да уңайсызлык итмәде.

Иң яхшы сәяхәт – һава яхшы булганда диңгезнең инсанга баш иеп торуы, ай вә кояшның бөтен шәүкәтләрен[1] күрсәтүләре, суның саф вә чүп-чарсыз булуы, офыкта үз пароходыңнан башка нәрсәнең күренмәве, күзне мәшгуль итәргә төрле нәрсәләрнең булмавы – һәммәсе бергә җыелып, хыял вә хиссияткә киң бер мәйдан ачадыр. Икенче кич теге хаҗиның пәрәстиш итдеке[2] граммофоны тирәсенә җыелганымыз. Төрлечә фарсы вә төрки көйләр уйный. Иттифак уларак[3] «Персидский марш» вә «Тоска по Родине» (ватанны сагыну) бер пластинканың ике ягына куелганнар.

Шуларны тәкрар[4] ишетү диңгез өстендә вә мәҗһүл[5] йирләргә барганда һәм пароходның алга баруы нисбәтендә сөйгәнеңдән ераклашуны сизеп торганда, бик көчле тәэсир итәдер.

6 ел мөкаддәм[6] диңгезнең яхшы һавасында бер французның курай уйнаганын гомергә онытасым юк. Ул вакытта балача саф күңелгә нечкә вә моңсу курай тавышы бик нык тәэсир иткән.

Хәзер инде музыка тыңлау тәэсирләрне искә төшерә генә.

Ленкорань ыстансасына йитәргә 2 сәгать калганда яр кырыена якынлаштык. Комлыкта корылган авыллар һәм дә бик күп

[1] Шәүкәтләрен – көч, куәтләрен.
[2] Пәрәстиш итү – табыну.
[3] Иттифак булу – бергә булу, берләшү.
[4] Тәкрар – кабат.
[5] Мәҗһүл – билгесез.
[6] Мөкаддәм – элек.

балыкчы көймәләре күренә. Бу тирәдә балык бик күп тоталар. Ватага (балыкны хасиятләп тутыра торган урын)нар бар. Авылларның берсендә чиркәү күренде, пароход дулкынын аркылы кичәргә шаярышып килгән көймәләрнең берсендә ике кеше фуражкалылар иде. Халис[1] мөселманнар утырган бу урыннарның балыкчылары руслар булырга охшый. Сахилне[2] янә күздән җуеп, янә бераз баргач, 18 сентябрь иртә 9 сәгатьтә Ленкораньга йитештек. Пароход бонда һәм бондан соң ике Астарада якорь салып, йомышлы кешеләр көймә илә чыктылар вә төшерәсе йөкләрне көймәгә бушаттылар.

Ленкораньдан игътибарән[3] Каспий буенда яшеллек вә агачлар башланадыр.

Ленкораньда агач өйләр күп. Түбәләр кыеклап ябылган; күренә ки, бонда ягмур күп буладыр. Баку, Дәрбәнд, Петровскларда, ягмур сирәк яудыгындан, түбәләрне кыеклап япмыйлар. Түшәм өстене тигезләп кенә куялар. Ягмур яудырыр өчен, Ленкораньның артында таулар күп. Бу Талыш таулары, Ленкораньдан алдарак башланып, Әнзәли тугрысынача Каспий буенча киләдер.

Ленкораньда, махсус чиновник кереп, пароходны карады, дәфтәргә кул куйды. Ничә пассажир барлыгын белгәндән соң, хаҗилар (хаждан кайтучылар) ничә булганыны да сорады. Җавап алгач, 6 гадәдене[4] дә аерым урынга язып куйды. Бу кеше хифзыссыйхәтне[5] тикшерә имеш.

Рус Астарасына килеп йиткәндә, помощник командир[6] паспортларымызны өләште. Һәркаюсына[7] таможняда күрсәтелде, дия[8] штемпель баскан иде. Астарада 10 кадәр маэмүрләр[9] кереп, бөтен нәрсәләрне вә йөкләрне актарып чыктылар.

[1] Халис – саф.
[2] Сахилне – диңгез кырые, ярын.
[3] Ленкораньдан игътибарән – Ленкораньнан башлап.
[4] Гадәдене – данәне.
[5] Хифзыссыйхәтне – гигиенаны.
[6] Помощник командир – командир ярдәмчесе.
[7] Һәркаюсына – һәркайсына.
[8] Дия – дип.
[9] Мәэмүр – чиновник .

Мәмләкәттән чыкканда таможня тикшерү һичбер йирдә юк, чөнки Русиядән чыкканда, пошлина алынмый. Фәкать бонда, Иранга корал кертмәсеннәр дия, тикшерәләр икән. Пароходны 3–4 сәгать актардылар. Шөбһә юк ки, бер нәрсә дә тапмадылар.

Ике әрмәни Рус Астарасында чыгып, Иран Астарасында янә пароходка керделәр. Мәгълүм ки, бу ике Астара бер шәһәр булып, араларында фәкать күпер генә бар. Ләкин пароход икесенә ике йирдәрәк туктый. Бу әрмәниләрнең берсе илә Әстерханда Кернның корал магазинында[1] очрашып торганым хәтергә килә. Үзе әйтә: борадәремне күргәнсең, без икемез бер төсле, ди. Бу әрмәни үзе яхшы кеше. Астарада минем хатларымны алып чыгып почтага салды.

Пароходта корал юктыр дип уйлый алмаганга күрә, бер хәбәрдар кешедән мин бу хосуста сораштым. Диде: бу юлдан корал чыгаручы булса да туры килеп кенә булыр. Әмма шуның илә кәсеб итүчеләр коралны коры юлдан һәм Төркия аркылы кертәләр. Шундан уңайлы. Андан соң, хәзер корал Иранда Русиядәгедән арзанрак һәм анда табарга йиңелрәк, диде. Мин, Әнзәлигә йиткәч моңа ышандым. Чөнки зуррак бакалея кибетләренең алдында һәммәсендә патрон вә мылтыкларны күрсәтеп сатарга куйган. Алырга да, сатарга да рөхсәт вә шәһадәтнамә лязем түгел.

Иран Астарасында эшемез булмаса да, пароход туктап торды. Чөнки Әнзәлигә көн яктыргач кына барып йитәргә кирәк иде. 19 ында иртә берлә Әнзәлигә килеп туктадык. Бөтен тирә-якны каплаган йимеш вә гөл агачлары артындан кояш үзе безгә каршы чыкты.

## IV

*Иран ходудына керү. Акча. Лианозов. Әнзәли шәһәре. Аның куваи хәрбиясе*[2].

Бу мәктүбтән игътибарән Иран туфрагында яза башлыйм. Максудым Иран хосусында кыскача мәгълүмат бирү вә Иранны

---

[1] «Английский магазин Н. Н. Керн в Астрахани» күздә тотылса кирәк *(Г. Ханнанова иск.)*.

[2] Куваи хәрбиясе – хәрби көче.

укучыларга таныту һәм аны якынлаштыру гына булганга, мәктүбләрем бик гади булачак. Минем мәктүбләрдә Йосыф әфәндене[1] Истанбулдан яздыкларындагы кеби тәдкыйкате сәясия[2] булмаячагы, бәнем сәяхәтем Рәшид әфәндене[3] Әкъсаи Шәрыкта[4] сәяхәте кеби шәүкәтле булмаячагы һәм дә Садри әфәнденең Англиядә сәяхәте[5] кеби яңгыраулы булмаячагы мәгълүмдер. Бәнем сәяхәт каршы алусыз вә озатусыз, мәктүбләрем бик нечкә тәнкыйтьсез садә генә булачак.

Бинаән галәйһи югарыда мәзкүр фазыйльләремезнең[6] сәяхәттән язган мәкаләләрен укыган кешеләр минекеләрне күреп мәэюс булмасыннар[7]. Кануны табигый икътизасына хилаф уларак[8] минем язуларым илә «сәяхәт мәкаләләре» мәнфәгатьчә тәкямел итмәсәләр[9], янә зарар юк. Чөнки гадәдләре[10] арткан була, мәҗмугалары зурайган була.

Ирандан берничә тәэсир бик гүзәл булды. Әнзәлинең әмсалсыз[11] яхшы вә табигый мөхафиз лиманы[12]. Аның тирә-ягын чолгаган баглар[13], бакчалар, лиманда бик күп күренгән һәртөрле көймәләр – һәммәсе хәзерге байлыкны вә өмидле мөстәкъбәлне[14] күрсәтәләр.

---

[1] Йосыф әфәнде – Йосыф Акчура (1876–1935), татар һәм төрек журналисты, язучысы, тарихчысы күздә тотыла *(Г. Ханнанова иск.)*.

[2] Тәдкыйкате сәясия – сәяси эзләнүләр.

[3] Рәшид әфәнде – Габдерәшид Ибраһимов (1857–1944), татар дин һәм җәмәгать эшлеклесе күздә тотыла *(Г. Ханнанова иск.)*.

[4] Әкъсаи Шәрыкта – Ерак Көнчыгышта.

[5] Татар җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Садри Максудиның (1878–1957) 1909 елда Россия Дәүләт думасы делегациясе составында Англиягә барып кайтуы күздә тотыла *(Г. Ханнанова иск.)*.

[6] Фазыйльләремезнең – күренекле кешеләребезнең.

[7] Мәэюс булмасыннар – күңелләре кайтмасын.

[8] Кануны табигый икътизасына хилаф уларак – табигать кануны кушканына каршы төшеп.

[9] Тәкямел итмәсәләр – камилләшмәсәләр.

[10] Гадәдләре – саннары.

[11] Әмсалсыз – тиңе булмаган.

[12] Табигый мөхафиз лиманы – табигать тарафыннан ныгытылган бухтасы.

[13] Баглар – җиләк-җимеш бакчалары.

[14] Мөстәкъбәл – киләчәк.

Пароходымыз килеп туктагач, Иран мәэмүрләре кереп, нәзакәт илә генә паспортларымызны сорап алдылар. Соңра әшьяларымыз таможня йортына чыгардык.

Безнең илә бәрабәр килеп туктаган «Меркурий» пароходыннан берничә француз вә җыйнак балтырлы америкалылар да чыкты. 3 марҗалары да бар иде.

Таможня тикшерүчеләр – яшь кенә Бельгия егетләре, әрмән вә персияннар.

Паспортны кайтару вә нәрсәләрне күздән кичерүдә күп зәхмәт чиктермәделәр.

Паспорт каед итүче[1] илә кыска гына мөкяләмәмез[2] аңа тәэсирсез калмады.

– Нәрәйә кидәчәксез[3]?

– Тәһрана.

– Нә илә мәшгульсез?

– Корреспондент.

– Вәкаигънигяр?

– Бәли, вәкаигънигяр.

Аурупа вә рус гәзитәләре мохабирләре[4] анларның хәтерендә нык урнашкан булырга охшый.

Бәнем бу җавапларым паспортчыга нәүбәтен оныттырдыгы кеби әшьяларымны тикшерүче мөселман мәэмүргә дә кәрзинемне багарга оныттырды. Чемоданымны карау чишеп бәйләүдән генә гыйбарәт булды.

Граница аркылы күп йөргән юлчыларның берничәсе әшьяларын[5] бер дә зәхмәтсез таможнядан качырдылар.

Каек[6] илә лиманның икенче тарафына чыктык. Иптәшләрнең берсе әшьяларны хәммальгә[7] йөкләтеп миһманханәгә китте. Берсе илә мин, почтаханәгә кереп, шул көнге почтага мәктүбләремне тапшырдым. Иранда почта көн саен китеп килмәгәнгә күрә,

[1] Каед итүче – теркәүче.
[2] Мөкяләмәбез – диалогыбыз.
[3] Нәрәйә кидәчәксез – кая барасыз.
[4] Мохабирләре – хәбәрләшүчеләре.
[5] Әшьяларын – әйберләрен.
[6] Каек – көймәнең бер төре.
[7] Хәммальгә – йөк ташучыга.

мәктүбне ашыгыч бирүнең Русия шәһәрләрендәгендән артык әһәмияте бардыр.

Төркиядә Русия почтасы булып рус маркалары мәкъбүл булдыгын[1] белгәнгә күрә, рус почтасы булуда шөбһә дә итми идем.

Бинаән галәйһи почтаханәдә рус маркаларын ябыштырырга ниятләндем. Иранда фәкать Иран маркасы гына мәкъбүл булуны иптәшем белдерде.

Соңра кассадан маркалар алдым. Рус акчасы һәркайда мәкъбүл икән. 50 тиенлек көмеш бирдем. 3 данә ябык мәктүб өчен, бер данә ачык өчен маркалар сорадым. 4 данә марка бирде һәм берничә вак ак акчалар кайтарды. Берсен карасам, өстендә «50 динар» дия язылмыш, берсендә «100 динар».

Мин фәкать укыганда өйрәнгән динарлар – алтын, Аурупаның төрле мәмләкәтләрендәге динарлар көмеш булганга моның хисабын белергә зиһенем йитмәде. Иптәштән сорадым. «Бусы бер шаи, бусы ике шаи», – диде.

Алайса марка бик арзан икән?

Хәер! Бонда шаи – бер капик[2]. Русиянеке түгел. Кавказда 5 тиенгә – бер шаи (шаһи), 20 тиенгә бер аббаси (габбаси) дип йөриләр. Иранда габбаси – 4 тиен.

Соңындан белдем ки, 50 динар, ягъни бер шаһи, безнең бер тиендән дә кимрәк икән. Бер сумга 110 шаһи бирәләр. Базар тигез булмый. Бәгъзан артыграк, бәгъзан кимрәк тә була.

Иран харижи[3] сәүдәсенең мөһим бер кыйсеме[4] Әнзәли аркылы булганга, бу шәһәрнең Аурупа илә мөнәсәбәте бик күптер. Бу мөнәсәбат[5] шәһәргә тәэсирсез калмаган. Әнзәлинең туры урамнары бар, базары өйләрдән аерым, әһалисе төрле кеше күрергә өйрәнгән.

Әнзәлидән мал күп узганга, монда зур фирмаларның конторлары күп. Әнзәлинең үз тиҗарәте – балыктыр. Каспий

[1] Мәкъбүл булдыгын – кабул ителүен.
[2] Капик – копейка.
[3] Харижи – тышкы.
[4] Кыйсеме – өлеше.
[5] Мөнәсәбат – мөнәсәбәтләр.

диңгезенең бөтен Иран сахиле бер могаһәдә[1] буенча Русиягә калдырылган.

Бу имтиязны[2] Әстерханның бер әрмән Лианозов, 25 елга 150 мең сум биреп, Русия хөкүмәтендән алган.

Белгән кешеләрнең язуына караганда, бу имтияз бер елга 150 мең сумдан артык тора. Һәм дә торг[3] илә бирелсә елга шул кадәр түләргә теләүчеләр бар имеш.

Лианозовка бирелгән имтияз буенча, 600 чакрымдан артык бу сахилдә яр кырыенда 10 чакрым бер дә һичкемнең балык тотарга хакы юктыр. Качаклар[4] Лианозов тарафыннан алына.

Лианозовның Әнзәлидә вә башка урыннарда ватагалары күп, үзенең пароходлары йөри, йөзләрчә балыкчы көймәләре аныкы яки аңа эшлиләр.

Бу сахилләр өчен бирелгән имтияз Лианозовтан башка һичкемгә файдасыз вә Иранга бик агыр богау булмыштыр.

Безнең илә пароходта Лианозовның Әнзәлигә тәгъйин иткән яңа вәкиле бер әрмәни килде.

Без иптәшләр илә шәһәр бакчасында көндезге чәйне эчкәндә вилаять хакиме «бәһаэс-сәлтанә» бу әрмәнигә бакчаны күрсәтеп йөрде. Хакимнең янында 5–6 гадәд[5] әгъваны[6] да бар иде.

Электә шаһка махсус булган биек бакчаны хәзердә бәләдия идарәсенә[7] алып гомуми бакча ясаганнар. Шунда «Нәҗат» исемендә кыйраәтханә[8] ачканнар. Иранның һәммә гәзитәләре, русча «Русское слово», «Речь» һәм бик күп әрмәнчә гәзитәләр вә французча «Матэн» гәзитәсе бар. Шкафында китаплар да күзәтелә. Яңача төпләренә кәгазь ябыштырып, искечә бер-берсе өстенә яткырып куйганнар.

---

[1] Могаһәдә – килешү.
[2] Имтиязны – концессияне.
[3] Торг (рус.) – аукцион.
[4] Качаклар – контрабанда.
[5] Гадәд – данә.
[6] Әгъваны – ярдәмчеләре.
[7] Бәләдия идарәсенә – җирле идарәгә.
[8] Кыйраәтханә – уку залы.

Бу бакчада Насыйретдин шаһ бина иттергән «Шәмселгыймарә» сарае бар. Биш табәкалы[1] бу бинаның тышы вә эче Шәрык падишаһларына мөнасиб[2] рәвештә вә аурупалылар һөнәре илә эшләнгән. Эченә кереп йөрдем. Югары табәкасының ишек өстендәге кәгазенә башка сәяхлар[3] артына мин дә исемемне яздым. Бакулы бер яһүди сәнгатькяр шунда үзенең игъланын вә адресын язып киткән.

Бу сарай хәзердә буш, ташландык һәм хәрабәлеккә якындыр.

Бу бакчага тоташ икенче бакчада янә бер зур бина бар. Әнҗемән[4], бәлэдия идарәсе[5], хәбесханә[6] вә ма әшбәһләр[7] шунда. Кереп йөрдем. Канцеляриядә язучылар аз. Бухгалтерия юкның файдасы (?).

Шәһәрдә ысулы җәдидә мәктәбе дә ачылмыш, диделәр. Мин искесен генә күрдем. Безнең иске мәктәпләрдән ким түгел. Мөгаллимнең чилиме[8] артык.

Шәһәрнең тупханәсенә[9] киттем. Надир шаһ заманасындан калган 7 гадәд туп бар. 8 нчесенең (6 аршин буенда) көпшәсе койма буенда ята. Тупларның берсеннән ифтар[10] вакытында һәр көн шартлаталар.

Ишегалдында (йортта) ята торган бу тупларны күргәч, Петербург искә төште. Анда Петропавловский крепость атавында бер буш йиргә ничә йөзләр иске тупны тезеп куйганнар.

Әнзәли тупханәсендәге пушкалар тупханәсе илә бәрабәр үк иске нәрсәләр арасына ташланып тамаша иттерерлектер.

Иранның сугыш көймәләрен күрергә эзләндем. «Бер бозык пароход бар иде. Төзәттерергә Бакуга йибәргәннәр» җавабын

---

[1] Табәкалы – катлы.
[2] Мөнасиб – яраклы.
[3] Сәяхлар – сәяхәтчеләр.
[4] Әнҗеман – революцион совет.
[5] Бәлэдия идарәсе – шәһәр идарәсе.
[6] Хәбесханә – төрмә.
[7] Ма әшбәһләр – шуның кебекләр.
[8] Чилим – кальянның бер төре.
[9] Тупханәсенә – арсеналына.
[10] Ифтар – Рамазан аенда авыз ачу.

алдым. Әнзәлидә мәшрутият[1] көннәрендән бирле милиция дәвам итмеш.

Ягъни әһалидән сайланган (400 кадәр) кешеләргә корал бирелгән. Алар һәр көн мөгайян[2] сәгатьтә сәламлыкта хазир булалар[3], башка вакытта үз эшләре илә шөгыльләнәләр. Казанда вә башка шәһәрләрдәге «Вольный пожарный команда»га охшашлы.

Рамазан 15 ендә бу милициядән корал алынып, шәһәрне саклаварга Иран казаклары килде.

Әнзәлидә төшкән мосафирханәмезнең яртысы диңгезнең өстенә салынган, Далалов намында[4] бер мөселманныкы. Номерлары мөселманнарга махсус булгандан кандалалары күп. Венециядә бундый урындагы мосафирханә бер итальянны баета торгандыр дип зан итәм[5]. Әмма безнең Кавказлы бу мөселман мосафирханәсендән бер дә файда иткәнгә охшамый.

## V
## Әнзәли – Рәшт юлы

*«Йосыф» пароходы. Инде мәшһәди. Лашман илә бару.*
*Иранда сөнниләр.*

Әнзәлидә бер көн калып сәйях[6] өчен күрергә тиешле урыннарын гизгәндән соң, Рәшткә китәргә җыендым. Мөселман ханәмезнең төбенә килеп туктаган «Йосыф» без кергәч тә урыныннан кыймылдады. Әгәр пароходларда гадәт булганча 3 дәфга сызгыртачагын көтсә идек, пароходтан калып, артыннан көймә илә куалап йитәргә тугры килгән булыр иде.

Бу «Йосыф» пароходы Баку сәүдәгәрләре борадәран[7] Алиевләрнең икән. Әнзәлидән Рәшткә таба 15 чакрым чамасы бара, соңра якорь сала. Янә кире кайтып, иртәгә көн уртасын көтәдер.

---

[1] Мәшрутият – конституциялелек.
[2] Мөгайян – билгеләнгән.
[3] Хазир булалар – җыелалар.
[4] Намында – исемле.
[5] Зан итәм – уйлыйм.
[6] Сәйях – сәяхәтче.
[7] Борадәран – бертуган.

Пароходта чәй эчтек. Моның өчен такса-фәлән юк икән.

– Чәй өчен никадәр кирәк?

– Күңелеңез күтәргәнчә биреңез.

Берничә йомырка да ашаган бер иптәшемезнең күңеле аз теләп, аз биргән иде. Шактый ихтиляф[1] чыкты...

Бер мөселман юлчылардан, берәм-берәм, кайсыннан билет, кайсыннан акча җыеп йөрде. Мин дә 2 кыран[2] бирдем. Белмим, бу кеше хуҗа, я матрос яисә кассир иде.

Шул көнге Тәһран почтасы илә Әнзәлидә яңа гәзитәләр алынган иде. Кулымдагы «Ираны нәү» гәзитәсе мине бер кызылбаш илә таныштырды.

Озын казаки өстендән пута бәйләнгән, вә аны өстендән җөббә[3] кигән 45 яшәрле бу кешенең кулындагы тәсбихенә вә киеменең кар кеби аклыгына карасаң, аны юашның юашы дип белерсең, әмма үзе менә нәрсә сөйли:

«Казанда бер бай бар иде. Габдерахман хан дип йөртәләр иде. Фамилиясен белмим. Без мондан 25 ел элек аңарда булдык. Себердән качып кайтканда... Без бер гаҗәм[4], ике дагстанлы – өчәү идек. Забайкальский областьтан җәяү килә-килә киемнәремез тәмам телеп бетте. Габдерахман ханга барып үземезнең горбәттә[5] калуымызны һәм Ходa юлында җәфа чиктекемезне сөйләдек. Ул һәммәмезгә киемнәр бирде. Мин:

– Ни өчен Себергә киткән идеңез?

– Кеше үлтереп. Бер дәфга качып кайткач, Бакуда тагын үлтердем. Тагын йибәрделәр. Андан кайтып берничә ел торган идем. Соңгысыннан японнар коткарды.

Сахалинны японнар алганда без шунда идек. Һәммәбезгә кәгазь биреп, юлга салдылар. Бу җан коючы, инде Мәшһәде Мөкатдәскә[6] барып, гөнаһларын гафу иттергән. Башыннан кичкән вакыйгаларны сөйләгәндә, гөнаһ эшне сөйләгән шикелле

---

[1] Ихтиляф – үзара килешмәүчелек.

[2] Кыран – Иранда вак көмеш акча. Бер кыран якынча 18 тиен кыйммәтендә йөргән.

[3] Җөббә – җиләннең бер төре.

[4] Гаҗәм – гарәп булмаган, яисә иранлы.

[5] Горбәт – мосафирлык; ялгызлык.

[6] Мәшһәд – шигыйлар иманында иң изге шәһәрләрнең берсе.

түгел, ат суя торган карт кеше үзенең кулындан кичкән атларны искә төшереп санаган шикелле генә сөйли. Анычча дөрест тә... Инде ул ак вә озын киемле. Әмма гөнаһлы кеше кара вә кыска киемле була. Гөнаһ эшләгәндә ул да шулай булган...» (Иранда «хан» ләфызы[1] бер ләкаб[2] гына булып меңләрчә байларның вә йир-сулы кешеләрнең исемнәренә кушып йөртеләдер.)

(Бу персиян Казандагы Габдерахман байны үзенчә Габдерахман хан дип тәгъбир итә).

Әнзәлинең лиманы асыл бер күл булып диңгезгә тоташкан. Буе 30, иңе 15 чакрым чамасындагы бу күлдә бик күп вак, фаруслы[3] көймәләр йөри. Әнзәлинең тирә-як илә мөнәсәбаты[4] һәммәсе шул көймәләр васитасы[5] иләдер. Бу шәһәрдә бер данә улсын ат вә арба күрмәдем. Ишәкләр күренгәли.

Шушы күлгә берничә елгалар коя. Боларның берсе «Кызыл Үзән» исемендә булып, Рәшт юлындагы «Пилә Базар» мәүкыйгынача[6] зур көймәләр йөрерлектер.

«Йосыф» пароходындан төшеп, бер көймәгә утырдык. Яндан килгән йил безнең фаруслы көймәмезне бик яхшы илтә иде. «Кызыл үзән»гә кердек. Елгадан бигрәк каналга охшаган бу ермакның ике тарафы бөтенләй агачлык вә бакчадан гыйбарәт. Көймә берничә чакрым баргандан соң, фарусны төшерделәр. Көймәдән 3 эшче кырыйга чыгып аркан илә көймәмезне тарта башладылар. Элек заманда «Идел»дә «лашман» йөргәнне картлардан күп ишеткәнем бар иде. Әмма дөнья йөзендә әле дә шул кадәр килешсез эш сакланганын белми идем.

25–30 кеше утырган көймәне 3 кеше тартып баралар, йөрүләре акрын түгел.

Болай бару ишкәк илә ишүдән йингел һәм андан тизрәк була имеш.

[1] Ләфызы – сүзе.
[2] Ләкаб – мактаулы исем, титул.
[3] Фаруслы – паруслы.
[4] Мөнәсәбаты – мөнәсәбәтләре.
[5] Васитасы – ярдәме.
[6] Мәүкыйгынача – урынынача.

Юлдашлардан берничәсене кырыйдан җәяү барырга чакырдым. Һичкем күнмәде. Ялгызым, төшеп, 2 чакрым кадәр җәяү бардым вә җиләк җыеп ашадым.

25–30 кешенең 3 кешене җигеп, көлешә-көлешә барулары читтән караганда бик вәхшилек төсле күренә. Ләкин моның вәхшилек күренүе мине арудан коткармады, янәдән көймәне яр янына китертеп утыруыма манигъ[1] булмады.

Көймәдәге кешеләр бер-берсе илә тизүк танышып мөзахкә[2] керештеләр. Вә бер карт яһүдине юл буенча мәсхәрә итеп бардылар.

Пилә Базар мәүкыйгында 40–50 көймә туктаган. Төйиләр вә бушаталар.

Шәһәрдән килгән фаэтоннарның берсенә сатулашып утырдык, пар ат тигез шоссе өстендә безне алып китте. Фаэтонга дүртәү утырган идек. «Йосыф»та танышдыгым бер юнан табибы, дәүләте мәтбугасы[3] улан Төркия сәфирен[4] күрер өчен, Тәһранга бара. Янә ике гаҗәм. Табиб Иран сәясәтеннән күп сөйләде. Казвинне «фәтех»тә[5] хазир булган икән.

Ике гаҗәм һәм мине сораштылар:

– Казанилар әһле тәсәнниме[6]?

– Бәли, әһле тәсәнни.

– Без һәм әһле тәсәннимез.

– Гаҗәб, Иранда әһле тәсәнни бармыни?

– Күп бар (кулын уңга селтәп). Мин сине бу тарафка алып киттем. Шигый күрмичә өч көн барырсын, Әнзәли илә Астара арасындагы авыллар һәммәсе әһле тәсәнни вә шафигый мәзһәбендәдерләр.

15 ел Иранда торган сөннидән боларның гадәде күпме булуын соравым бушка китте. Фәкать әһле тәсәнниненең Иранда рәсми мәзһәб буларак танылдыгын белдем.

[1] Манигъ – киртә.

[2] Мөзахкә – көлкегә, шаяруга.

[3] Дәүләте мәтбуга – подданныйлык (ягъни юнан табибы Төркия подданные булган).

[4] Сәфир – илче.

[5] Фәтехтә – алуда.

[6] Әһле тәсәнниме – сөнниләрме.

Бу сәүдәгәрнең әһле тәсәнни булуы сакалын кызылга буявына зарар итмәгән.

Рәшткә якынлашкач, «Бусар» нам мәүкыйгъда русча вывескалы йорттан бер кеше чыгып, фаэтондан 2 кыран (бер кыран 18 тиен чамасында) юл парәсе алды.

Буш фаэтон узганда, бер кыран түләдекне фаэтончы сөйләде.

Рәштне тар вә борылыш урамнарындан йөреп-йөреп, теге табиб илә бер юнан миһманханәсенә туктадык, килешкән бәһагә рус акчасы, йә Иран пулы бирү тугрысында фаэтончы илә чыккан ихтиляфны[1] аның файдасына солых берлә хәл кылгандан соң, әйберләремне бер номерга берләштердем. Вә бераздан соңра ифтар тубы ишетелде.

## VI
## Рәшт

*Мәнзил[2]. Харилус. Русия вә гайре дәүләтләрнең консуллары. Шәһәр. Әһали. Тәҗәддед[3].*

Пилә Базардан Рәшткә бер фаэтонда килдекемез юнан табибы мине бер юнанлы мосафирханәсенә китергән иде. Әйберләремне куйдым да, тиз генә бу шакшы урындан качар өчен, номер эзләргә киттем. Пароходта таныштыгым бер Рәшт егете миңа юлбашчы булды. «Русия» исемендәге бер гостиницаны табып, шунда номер алдым. Мин нәрсәләремне күчергәч тә, залда бөек зәнҗал[4] чыгып, хуҗа хатын рус банкы мөдиренең өенә качып, рус консулханәсенә сыенды. Зәнҗалчы грузинлар бер адәмне яралап, тынычлыкны бетерделәр. Гостиница ябылды. Мин дә күчәргә мәҗбүр булдым. «Альберт» миһманханәсенә киттем. Мин Бакудан ук шунда төшәргә ниятләгән идем һәм кордашларыма Рәшт адресын шунда тәгъйин иткән[5] идем. Ләкин «анда кыйммәт» дип куркыттылар, мин дә «Альберт» исеменә кыйммәтлек килешкәнне чамалаган идем.

[1] Ихтиляфны – каршылыкны.
[2] Мәнзил – станция, торак.
[3] Тәҗәддед – яңару.
[4] Зәнҗал – җәнҗал.
[5] Тәгъйин иткән – күрсәткән.

Соңындан белдем: «Һотель де Европа экс Альберт»ның хуҗасы Сембер губернасының бер крестьян марҗасы икән. Рәшттәге (вә соңындан мәгълүм булганча һәм Тәһрандагы) башка гостиницачылар шикелле бу да прислуга (асрау) булып Иранга килгән. Монда аның кадерен белүчеләрдән истифадә итеп акча җыйган, җуанайган соңра, үзе гостиница ачкан. Һәм дә ир тапкан. Боның ире госманлы тәбәгасы[1] бер юнанлыдыр.

«Сәбзә Мәйдан»дагы «Альберт» миһманханәсенең ишегенә килеп туктадыгымда, ишек төбендә бер фаэтон тора иде. Шәп атлар җигелгән бу һәйбәт фаэтонның кучеры Аурупа киемендә ак якалы вә башына фәс кигән булгач, мин моны сорашмыйча уза алмадым. Мине китергән ямщиктан:

– Бу кем фаэтоны?

– Харилусның.

– Ул кем?

– Харилус. Харилусны белмисезме? Өендә бөек багы[2] вар. Пилә (эшләнмәгән ефәк) заводлары бар. Бөек зәнгин[3] адәмдер.

– Бәс, ни өчен аның кучеры фәс кигән?

– Ә, ул госманлы шәһбәндәре[4]. Унының[5] һәммә хадимнәре[6] фәс кияләр.

Госманлы шәһбәндәре булган бу грекны залда күрдем. Семьялары илә кунакка килгән булган икән.

Соңындан сорашып белдем ки, Харилус Рәшттә иң нөфүзле[7] сәүдәгәрләрдән берсе имеш. Госманлы шәһбәндәрлегенә дә тәгъйин ителгән.

Ихтилял[8] вакытларында Рәшттә госманлы тәбәгасене 150 дән 500 гә йиткергән.

---

[1] Тәбәгасы – подданные.

[2] Багы – бакчасы.

[3] Зәнгин – бай.

[4] Шәһбәндәр – консул (Төркиянең Иранның Каҗарлар заманындагы консулы).

[5] Унының – аның.

[6] Хадимнәре – хезмәтчеләре.

[7] Нөфүзле – авторитетлы.

[8] Ихтилял – баш күтәрү.

Рәштә әҗнәби[1] флаглардан иң күп күренгәне айлы флагдыр. Сахибләре әксәрисе греклар вә беразы да әрмәннәр. Берничә йирле мөселманнар да бар. Рәшт әһалисе грек берлә госманлыны бер мәгънәдә йөртәләр вә икесене дә «рум» дия тәгъбир итәләр. Башка шәһәрләрдә дә шулай аңлаучыларга очрадым. (Иске китапларда да Госманлы голямасыны Рум голямасы дия тәгъбир иттекләре мәгълүмдер).

Күп еллар буенча Төркиянең мөселманнарына хөдудтан[2] чыгарга рөхсәт ителмәдекендән, иранлылар грек вә әрмәнгә башка госманлыны күрмәгәннәр. Бинаән галәйһи «айлы флаг» астында христиан румнарын гына күргән Иран гавамы[3] госманлыларны дин кардәше белмәүләрендә мәгъзүрдерләр[4].

Рәштә рус консулханәсенә бармакчы булдым.

«Хәзер шәһәрдә бер кеше дә юк, Әнзәли янында дачадалар. Рәштән 30 чакрым йирдә», – диделәр.

Консул Штриттер җәнаблары тешен төзәттерер өчен Бакуга киткән икән.

Шундан урынына кайтмаячак имеш, дип сөйләшәләр. Сәбәбене дә Рәштә Мөхәммәдгали шаһ килүгә яхшы урын хәзерләнмәүчелек дип күрсәтәләр.

Рәштә Русиядән килгән рус тәбәгасы берникадәр бар. Шикәр, мануфактур, керосин, транспорт фирмаларының вәкилләре вә гайреләр. Рәшт әһалисендән рус химаясенә кергәннәр дә булгалаган.

Бондагы рус банкы («Иран ярдәм банкасы» исемендә) күп эш күрә, хәзер дә 15 кадәр мәэмүре бар.

Боның мөгамәляты[5] элек тә янә күп булган. Мәсәлән: 1903 елда 25 ләп мәэмүр хезмәт иткәннәр. Соңгы елларда Русиянең сугышы вә тынычсызлыгы, Иран ихтиляллары тәэсир итеп, Русия сәүдәсе вә гомумән сәүдә азайган. Шуңа күрә банк мөгамәләсе дә кимегән.

[1] Әҗнәби – чит ил.
[2] Хөдудтан – чиктән.
[3] Гавамы – халкы.
[4] Мәгъзүр – гафу ителерлек.
[5] Мөгамәляты – мөгамәләләре.

Рәшттә Америка миссионерлары мәктәп ачып, егермеләп бала укыттыгы хәлдә рус мәктәбе юктыр. Гостиницалар вә хозяйкалары, читтән килгән аракылар һәммәсе Русиядән килеп тә, Англиянең фәкать банкы, докторы вә мәктәбе булу әһалинең ике рәкыйб[1] дәүләткә карашларын тигезсез тәгъйин итә[2].

Моның өстенә экспропиатор «талаучы»ларның да Русиядән килгән булуы артадыр.

Англиянең консулы бар. Бу дәүләтнең Рәшттәге тәбәгасы: «Банкы шаһиншаһи» идарәсе, шуларның докторы, американы протестант миссионерыдыр.

Ихтилял вакытында Англия химаясенә кергән иранилар бар. Мәсәлән, могыйззес-сәлтанә[3] вә гайреләр.

Германиянең дә консулы бар. Кодсы Шәрифтән[4] килгән бер аптекчы. Аптек хезмәтчеләре Германия тәбәгасы булып язылганнар. Шуларны химая итүче[5] консул кирәк булган. Теләгән эшкә сылтау табыла бит.

Рәшттә шул 4 дәүләтнекенә башка консул юктыр.

Шәһәрне тәгърифкә[6] элек хариҗи консуллардан башлавымны иттифакый[7] гына күреп, Харилусның очравына гына хәмел итеп[8], укучылар мине мәгъзүр[9] күрерләр.

## VII
## Рәшт

*Шәһәр. Әһали. Тәҗәддед.*

Иранда һичбер дәфга тәхрире нөфүс (перепись) ясалганы юк. Мондан 50 ел мөкаддәм бер касыд итеп[10] караганнар икән.

---

[1] Рәкыйб – конкурент.

[2] Тәгъйин итә – билгели.

[3] Могыйззес-сәлтанә – Иран хөкемдарларына һәм аксөякләргә бирелгән титул *(Г. Ханнанова иск.)*.

[4] Кодсы Шәриф – Иерусалим шәһәре.

[5] Химая итү – яклау, саклау.

[6] Тәгърифкә – тасвирлауга.

[7] Иттифакый – очраклы.

[8] Хәмел итеп – сылтап.

[9] Мәгъзүр – гафу итәрлек.

[10] Касыд итү – ниятләү, теләү.

Әһалинең шомлануы вә каршы торуы сәбәбле мөмкин булмаган. Бинаән галәйһи Иранның нә бөтен мәмләкәт халкының, нә бер шәһәр халкының гадәдләрен тәгъйин итәргә мөмкин. Рәштнең исә җан хисабы түгел, йорт хисабы вә урамнар хисабы да язылган юк. Шәһәрнең зурлыгын фәкать тәхмин илә[1] генә язарга мөмкин. Рәшт әһалисен 50–60 мең чамасы тәхмин итәләр.

Шәһәрнең һичбер тугры вә киң урамы юктыр. Кыңгыр урамнар вә бер башы барып терәлә торган тыкрыклардан гыйбарәт. Фәкать ике мәйданы бераз иркен сулу алырлык.

Алыш вә биреш бик зур. Ихраҗаты[2] дөге, тәмәке вә эшләнмәгән ефәктән гыйбарәт. Елга 12 миллион сумлык ефәк чыгардыгы таможня хисабындан күренәдер. Йимеш вә палас сәүдәсе дә бөек[3]. Русиядән килгән идхаляты[4] күп. Нимес, француз маллары Тәбриз аркылы вә Төркиядән кичеп киләдер.

Бер кыйсеме дә, «коли посталь» (посылка) уларак рус почтасы аркылы китерелә. Русия хөкүмәте транзит уларак, (күчереп) чит мөмләкәтләр малын пошлина алмыйча үткәрмәдекендән Гарби Аурупаның[5] мануфактур вә галантерейный нәрсәләре почта илә килә. Бер фирманың почтадан йөзләп, меңләп посылка алдыгы буладыр.

Рәшт – Гилян вилаятенең мәркәзедер. Гилян халкы бакчачылык илә мәгыйшәт итеп, фарсычадан бозылган бер махсус тел илә сөйләшәләр. «Гиләк теле» диләр. Гиләкләр вакытлы гына эшләп, елның күбрәк вакытын буш үткәрдекләрендән, аралларында ялкаулары күбрәктер.

Рәшт әһалисенең үзен кимсетмәгәннәре даимән дүрт кат кием кияләр. Камзол, аның өстендән җилән якалы вә бик озын казаки киеп пута бәйлиләр. Аның өстендән җөббә, аның өстендән габа[6]. Эсседә бу кадәр кием кигән кешеләрнең эш эшләмәячеген белергә бер дә зирәклек лязем булмаса кирәк.

[1] Тәхмин илә – чама белән, якынча.
[2] Ихраҗат – экспорт.
[3] Бөек – зур, күләмле.
[4] Идхалят – импорт.
[5] Гарби Аурупаның – Көнбатыш Европаның.
[6] Габа – өске йон кием.

Гилян әһалисе – түбән вә пис[1] табигатьле, куркак, хорафат илә яшәүче вә иртәге өчен кайгырмый торган кавемдер. Табигатьләре илә Әстерхан нугайларына бик охшыйлар.

Өйләре кирпеч вә балчыктан ясалып, тыштан бик ямьсез вә эчтән һәм зиннәтсез. Фәкать хаҗи булганнары капуларыны[2] төрле ташлар илә зиннәтләп «Бисмилла» һәм «Инна фәтәхна»[3] вә бәгъзе аятьләр язалар. Хаҗиларның «вывескалары» шул була.

Шәһәрнең читендә гүзәл баглар бар. Болар әгъянның[4] хас милекләре саналса да, әһали гизәр өчен ачыктыр. «Мөдирия», «Салария», «Мозаффария» баглары вә хәзерге «мәшрута валисе»[5] сәрдар[6] Могтәмәднең багълары хакыйкать гүзәлдерләр.

Һәртөрле йимеш агачлары вә чәчәкләр, гөлләр илә тулы улып, ираниларның бакча зәүкындагы югарылыкларын күрсәтергә йитәрлектер.

Шәһәрдә йөрер өчен фәкать фаэтоннар бар. Очуз[7] түгел. Әһали шәһәрнең бер читендән бер читенә кыңгыр вә тар урамнардан җәяү йөри, вә барачак йирене урамдагы кешеләрдән сораша барадыр. Чөнки һичбер урынның, һичбер урамның исеме язылмаган. Рус банкасының бөйлә[8] вывескасы юк. Банкыны эзләп тапмак шактый мөшкел.

Бер мәэмүрендән сорадым:

– Ни өчен вывеска куйдырмыйсыз.

– «Безне һәркаюсы белә, лөзүм[9] юк», – дия җавап бирде.

Әмма Англиянеке булган шаһиншаһи банкка вывеска куелмыш. Һәм дә русныкы кеби тар базар урамында кәрван сарай ишегалдындагы фатирда түгел. Бәлки үз йорты кебек мәйданга каршыдыр.

[1] Пис – әшәке, начар.
[2] Капу – капка.
[3] «Фәтех» сүрәсенең 1 нче аяте күздә тотылса кирәк.
[4] Әгъянның – аристократларның.
[5] «Мәшрута валисе» – «конституция губернаторы».
[6] Сәрдар – башлык.
[7] Очуз – арзан, очсыз.
[8] Бөйлә – мондый.
[9] Лөзүм – кирәклек.

Тәһранның соң фәтехендә[1] Рәшт шәһәре мәшрутачыларның[2] беренче мәркәзе улмыш иде. Сипаһдар Мазәндәрандан Рәшткә килеп, шунда куәт җыйды. Шаһ тарафдары улан Рәшт валисе[3] «сәрдары әфхәм[4]» ихтилялчылар бомбасы илә бакчада үлтереп, хөкүмәт йортын динамит илә күтәртелмеш бүгенгәчә хәрабә ятадыр.

Рәшт шимди бер әнҗемән[5] тарафындан идарә кылына. Идарәи бәләдия[6] ясарга шөруг ителгән[7]. Полиция яңа ысул үзрә тәртип иделә.

Ләкин зыялылар Рәшттә торырга, аның юеш һавасын яратмадыкларындан, бу шәһәрнең вә вилаятьнең исляхаты хәйли[8] акрын алга барадыр. Кыйраәтханәи гомумиясенә[9] кердем. Гәзитәләр тиеш кадәр юк. Фәкать Гилян мөҗаһидләренең[10], әнҗемән рәисе вә сәркәтипләренең бөек кыйтга[11] рәсемнәре генә бар. Яңа ысул мәктәпләр «Рамазан мөнәсәбәте илә» ачылмамыш.

Иҗтимаг[12], җәмгыять, митинг кеби шәйләр һич юк. Фәкать «Иҗтимагыюны гамиюн» фиркаи саттария[13] прокламацияләре күренгәли.

Иске мәктәп (муллаханә)ләр рамазанга карамыйча дәвам итәләр. Чөнки садака һәрвакыт кирәк.

Рәшттә сәүдә кәсеп илә торучы ике Казан татары да бар. «Казан лиманаты»[14] саталар.

[1] Фәтехендә – яулап алынуында (Тәһранның конституцияче революционерлар тарафыннан алынуы күздә тотыла).

[2] Мәшрутачыларның – конституция тарафдарларының.

[3] Валисе – губернаторы.

[4] Сәрдары әфхәм – хәрбиләргә бирелә торган титул *(Г. Ханнанова иск.)*

[5] Әнҗемән – революцион совет.

[6] Идарәи бәләдия – шәһәр идарәсе.

[7] Шөруг итү – керешү, башлау.

[8] Хәйли – бик, шактый.

[9] Кыйраәтханәи гомумиясенә – гомуми уку залына.

[10] Мөҗаһид – биредә: революционер.

[11] Бөек кыйтга – монда: зур размерлы.

[12] Иҗтимаг – җыелу.

[13] Фиркаи саттария – сәяси партия.

[14] «Казан лиманаты» – биредә: аракы.

Мәкаләгә хатимә[1] уларак, Рәшт шәһәренең аурупалаша башладыгын кайд итмәк[2] ляземдер. Шәһәрдә телефон һәм электрически станция ясалмыш, бер мәйданда бульвары бар. Янә бер бульвар ясала. Базар урамына таш түшәлмеш. Хәзергә – бу кадәр.

## VIII
## Рәшт – Тәһран

*Дилижанс. Каҗҗарлардан берәү. Көрд. Әрмәни. Җирне сулау. Гилян. Гыйрак гаҗәм. Таулар. Шоссе. Кәрваннар. Казвин. «Чибәр егет» мөҗаһид. Җырлар. Тәһранга йитү.*

Рәшт илә Тәһран арасында юлчы ташыр өчен һәфтәдә ике дәфга почта арбалары, ике дәфга дилижанс вә кирәк кадәр карета (фаэтон)нар йөридер. Фәкать кыш айларындан дилижанс һәфтәгә[3] бер генә була.

Карета илә китмәкнең бәһасе 25 туман (һәр туман бер сум 80 тиен чамасында) булдыкындан бәңа башка гәзитәләр мөхбирләре кеби махсус карета илә китәргә тугры килмәде. Чөнки «Вакыт»ның абүнәсе бик очсыз вә игъланнарга да аз урын биреләдер.

Дилижанс почтага күрә бераз очсыз да булып үзе рессорлы булгач, мин шуны ихтыяр иттем. 3–4 көнлек таш юлда рессорның әһәмияте бик күптер. Почтаның тизрәк йитүене шуңа фида итәргә[4] лязем булды.

4 көн эчендә Рәшттә эшне бетереп китәргә теләсәм дә, мин теләгән көндә билет булмыйча, алдагысыны көтәргә лязем килеп, 3 көндән соң китәргә генә билет ала алдым. Тәһранга барганчы, юл өстендә «Казвин» шәһәрендә туктап, 2–3 көн тормакчы идем.

[1] Хатимә – бетем өлеш.
[2] Кайд итү – теркәү, беркетү.
[3] Һәфтәгә – атнага.
[4] Фида итү – корбан итү, коткару

Ләкин дилижанс конторында: «Әгәр Тәһранга юлчылар тулмаса гына Казвинга билет бирәмез» диюләре мине билетсыз калудан куркытты.

Мин дә, форсат кичектерми, Тәһрангача билет алдым. Казвинда туктап кичегергә чарасы табылыр дип уйладым. Соңра бәйрәмне Тәһранда күрергә теләп, Казвинга туктаудан ваз кичтем. Дилижансның китү вакытыны билетта «йәк сәгать әз дәсте гөзәштә» дия тәгъйин иделмеш иде. Боларның «иртәдән бер сәгатьләре» безнеңчә сәгать 7 гә тугры киләсен белеп, мин шул вакытта стансада хазир булдым.

Иранда Истанбулдагы кеби горуб сәгатене истигъмаль итәләр. Ягъни һәр көн кояш баеганда (батканда) сәгать 12 гә тугры китереп йөртәләр. Төш вакытында сәгать 12 булуны төшенмәүчеләре дә күптер. Бу зоһер[1] сәгатене бунда «руси» дип, Төркиядә «А-ла франка» дип атыйлар.

Дилижанс – юлчы ташырга махсус кечкенә вагон кеби бер гарәбәдер[2] . Эчендә кара-каршы өчәрдән 6 кеше ултырырлык. Әшъяларны да югары (түбәсенә) куела. Вагонның тәрәзә пыялалары урынына моның пәрдәләре бар. Ягъмур, кояш вә тузандан сакларга бераз ярдәм итә.

Дилижанста миндән башка дүрт юлчы бар иде. Бер кечкенә генә читлек эчендә ябылган 5 кеше тизүк бер-бермез илә таныштык. Вә юлны кыскартыр өчен сөйләшә башладык.

Бу кешеләрне бераз тәгъриф итеп[3] узарга телим. Миңа иттифакый очраган кешеләрнең шәхесләре укучылар өчен әһәмиятле булмаса да, гомумән Иран хосусында хәбәрдарлык өчен, боларны зикер итү файдасыз булмаса кирәк.

Болардан берсе шаһзадә Җәвад бәк Каҗар иде. Иске бабалары бер шаһның углы булган, замана алмашыну илә бу шаһзадәләр мансаб[4] вә милектән мәхрүм калганнар. Инде һәм каберлекне сакларга һәм дә биннисбә[5] фәкыйрьлекне тәхәммел

[1] Зоһер – төш вакыты.
[2] Гарәбәдер – арбадыр.
[3] Тәгъриф итеп – таныштырып.
[4] Мансаб – вазифа.
[5] Биннисбә – чагыштырмача.

итәргә[1] кирәк булган. Йенгел вазыйфа түгел. Бу шаһзадә өстенә аксыл вә шакмаклы сюртук вә аның эчендән гадәти манжетлы күлмәк кигән, әмма яка вә галстук куюны юл өчен артык тәкәллеф[2] санап, муенын ачык калдырган.

Безнең йирдә булса, тузанлы юлда аксыл сюртук кию, сюртук кигән кешенең якасыз йөрүе бик гариб[3] тоелыр иде.

Ләкин бунын Иранда икәнен онытмаска тиеш. Башында фәскә охшаган кара бүрек, яисә бүреккә охшашлы кара фәс иде. Һәммә Иран киберләре[4] шикелле бу да төркичә сөйләшүне кимсенеп, аны өйрәнмәгән.

Үзенең нәкыль итүе[5] буенча, Тәһранда бер русның ханәсенә мөдавәмәт итә имеш. Марҗаларның Иран ханымнарына күрә фазыйләтләре[6] күп булдыгыны да белеп сөйләгән шикелле нәкыль итә.

Хәзер Русиядән кайтып килеше. Өч ай чамасы Тифлис вә Батумда торган.

Докторлар аңа күңел чуалуындан [нервный расстройство] шифа өчен сәяхәткә киңәш биргән булганнар.

Боның «мәшрутиять пәрәст[7]» булуын зикергә[8] дә хаҗәт юктыр. Чөнки үзе кеби күргән кардәшләренең боның киңәшендән башка истибдад[9] итүләренә риза булу ихтималы бармы?

Икенчесе Микердич намында бер әрмәни иде. Бигүк шомалыкны илтизам итмичә[10] Аурупа киеме киенгән, башына муфтага охшашлы кызылбаш бүрке куйган.

Һамаданда, соңра Тәһранда Америка миссионерлары тәэсис иткән[11] мәктәптә тәхсил тәмам иткән[12]. Әрмәнчәдән башка ин-

[1] Тәхәммел итәргә – чыдарга.
[2] Тәкәллеф – ясалмалылык, кылану.
[3] Гариб – күрелмәгән эш.
[4] Киберләре – һавалылары, тәккәберләре.
[5] Нәкыль итүе – сөйләве.
[6] Фазыйләтләре – өстенлекләре.
[7] Мәшрутиять пәрәст – конституциялелек тарафдары.
[8] Зикер итү – искә алу.
[9] Истибдад итү – деспотизм күрсәтү.
[10] Илтизам итү – үзенә тиеш дип табу.
[11] Тәэсис иткәнү – оештырган.
[12] Тәхсил тәмам иткән – белем алган.

глизчә, фарсыча укырга, язарга өйрәнгән, гарәпчә вә сөрьяничә[1] илә бераз шөгыльләнгән. Мөкаддимәте гөлүмдән[2] хәбәрдар, китабе сәмавиягә игътикады[3] бик нык. Тәһран телеграфханәсендә мәэмүр булып берничә ел хезмәт иткән, инде Мазандеранда сәүдәсе, 2 аракы заводы бар. Һәм дә хам ефәк[4] йетештереп кәсеб итә.

Сәфәре сәүдә эшләре өчен.

Өченчесе пудралы, помадалы бер маржа, Одесса, Баку «Кафе шантан»ларында игътибары беткәч, Иранга килгән. Казвинга бара. Аның сөйләвенчә, Казвинда офицерларны җуатыр өчен бу атна гына 7– 8 кыз узган имеш. Бу үзе иранлыларны яратып сөйли. 4 нчесе – моның «телохранителе», бер көрд. Анарга мөтәрҗимлек итә.

Бу көрд ливарвирыны[4] муендан таккан, билендә ике рәт патрон, сакалын кырган, мыегы колагына йетәрлек озын, ике очын бармаклары илә бәрабәр зәгъфранлы кынага манган, башыны маңлаендан вә җилкәсендән кырдырган, ике колак тугрысында ярты башының чәче уч илле (вершок ярым) кадәр озындыр.

Озын җонлы биек бүрекне башындан бер дә салмый. Озын буйлы, таза гәүдәле, ерткыч диярлек «гайрәтле» бу кешенең сөйләвен рәгъбәт берлә[6] тыңларлыктыр.Чөнки рия[7] фәлән юк, беркатлылыгы тышына чыккан. Миңа янәшә утырдыгындан иң элек сүз аның илә башланды.

Кичдекемез урманнарның һәммәсе сәрдаре монсур (хәзерге почта вә телеграф вәзире) неке булуыны сөйләшкәч:

– Һәй, боларның сәрдарлеге ни?! Һәя[8] гаскәре улмаздан «сәрдар» улырлар. Безем көрдләр табурларын йыгыштырып команда итмәздән мөкаддәм[9] «сәрдар» улмазлар... – диде.

---

[1] Сөрьяничә – ассириялечә.
[2] Мөкаддимәте гөлүмдән – башлангыч белемнән.
[3] Игътикад – ышану.
[4] Хам ефәк – эшкәртелмәгән ефәк.
[4] Ливарвирыны – револьверын.
[6] Рәгъбәт берлә – кызыксыну белән.
[7] Рия – ийейөзлелек.
[8] Һәя – оят.
[9] Мөкаддәм – алда.

Соңра көрдләрнең гаскәрлеге вә үзенең ат өстендә йөрергә маһирлыгы хосусында шул кадәр сөеп сөйләде ки, моның «Гасәр»легенә ышанмаска мөмкин түгел иде.

«Рәшт»нең кырыендагы ефәк корыта торган вә «тилимбар» тәсмия кылынган[1] амбарларны үткәндән соң, юлымыз бакча вә кыр эчендән дәвам итте.

Озак вакыт су астында калуы лязем булган дөге җирләре вак-вак кисәкләргә бүленгән вә һәммәсенең әтрафы йимеш агачлары илә чолганган, тирәсендә казылган канаулардан су агып тора, шундан кирәге кадәрле игенлек эченә агызалар.

Иранлыларның суны бу кадәр үз ихтыярларынча агызуларына вә бер елганың суыны йөзләрчә дәфга файдалангандан соңра гына диңгезгә коткаруларына гаҗәпләнмәслек түгел.

Русиядә буш бушына аккан суларны иранлы күрсә иде, никадәр гаҗәпләнер иде. Иранда һичбер су үзенең елгасында гына агып ихтыярынча диңгезгә коелырга имкан[2] юк, һәммәсе буылган, җырылган, игенлек вә бакчалар эченә агызылган.

Бик садә тариклар илән бөтен кырны суларга (сугарырга) бик гали мөһәндислек[3] вә бик агыр мәшәкать ляземдер.

Бакчачысының суны бу кадәр кулга иятләштерүен күргәч, Иранның бу кадәр дөге вә тәмәке чыгаруыны вә бөтен Русиягә йөзем ашатуыны хаклы таптым. Ләкин бичара эшче халык җирнең һәрбер карышын кулы вә көрәге илә эшләүдән суның бер чиләген дә исраф итмәүдән бик аз файдалана, аның тамагы һаман ач, өсте һаман да ярты ялангач, тәүлектә 18 сәгатькә ирешкән эш вакыты аның гаиләсен июдә асрарлык кадәр файда бирми. Сәбәб мәгълүм: җир хуҗалары һәммәсе мөләккаб – титуллы әгъяннардыр. Ихтишам әд-дәүлә, мөдирел мамалик, һәртөрле мәнсур, насыйр, мөнтасыйр, әнтасыйр исемнәренә тагылып бирелгән җирләрдән алар гына файдаланалар.

Җирне эшләүче, аны бәрәкәтле итүчеләрнең бу йимешләрдән агыз тутырып кабарга ихтыярлары юк. Үз хакларын сорарга да меңләрчә манигъләр[4] бар ки, иң яманы – җәһәләттер.

[1] Тәсмия кылу – исем кушу, ат бирү.
[2] Имкан – мөмкинлек.
[3] Гали мөһәндислек – югары инженерлык.
[4] Манигълар – киртәләр.

Гилян вилаяте Иранның коры сахраларындан биек таулар илә аерылган, вә таулары агачлар илә капланган, вә җире түбән булганга, һавасы даимән юеш тора. Ягъмур еш, еш җава. Рәшттә ике атна, бер ай тоташтан ягъмур җава, сирәк вакыйгъ булмыйдыр.

Гилян вилаятенең урманнарында кошларның һәр нәүгысы[1] күптер. Сембер губернасындан бер татарның кош тиресе вә җоны җыярга үткән ел Рәшткә килдекене дә Әнзәлидә сөйләгәннәр иде. Монда була торган кызыллы вә яшелле төстәге вә тавык зурлыгында бер кошның тиресе зиннәт өчен Аурупага күндерелә икән.

Сәфәремезнең беренче көнене Рәштдән өч ыстанса китеп, Рөстәм Абад карьясендә кундык.

## Рәшт – Тәһран

*Гыйрак гаҗәм. Таулар. Шоссе. Кәрваннар. Казвин, «Чибәр егет» мөҗаһид. Җырлар. Тәһранга йетү.*

Рәшттән сәфәремезнең беренче көнендә өч ыстанса китеп, Рөстәм Абад карьясында кундыгымызны үткән мәкаләмдә язган идем.

Яшел вә сулы Гилян вилаяте Рөстәм Абад та тәмам булып, андан соң Гыйрак гаҗәм башланадыр.

Гыйрак гаҗәмнең бу кыйсеме, бөтенләй таулык вә ташлыктан гыйбарәт, күз күреме кадәр урыннарда бер агач вә яшеллек күренми, шушы юлы Сәфид руд, Сияһ руд вә Руде бар елгаларының яр буенда вә ташны кисеп кенә ясалган. Унар сажин биеклегендә таш киселгән урыннар очрыйдыр. Ике-өч вә биш сажин киселгән урыннар ничәшәр чакрым өзелмичә бара. Тауның текәлеген йенгеләйтер өчен, бик күп борылышлар ясалган. Каты вә тоташ ташлардан гыйбарәт булган тауларны кисеп юл салуга җөрьәт итәр өчен, адәм угылына бик күп гыйлем кирәк.

---

[1] Нәүгысы – төрлесе.

Сәфәремезнең икенче вә өченче көннәрендә йөз чакырымдан артык мәсафәтне[1] киселгән таулар эчендән баргач, 375 чакрымлык бу шоссены эшләргә 7 ел гомер, 6 миллион сум акча сарыф ителүенә бер дә гаҗәпсенмәдем. «Мәрхәмәтле күрше» Русия ярдәмгә йетешмәгән булса, иранлылар әле дә бу юлны ясата алмаслар иде.

Рөстәм Абадтан икенче ыстанса – «Мәнҗил»дер. Бонда яңа тимер күпер ярты миллиондан артыкка төшкән, имеш. Бу юлдагы таш вә тимер күперләр һәммәсе бик озак гомер өчен салындыклары бер караудан күренә.

«Мәнҗил» соңгы инкыйлабта мәшрутиятчеләр гаскәренең мәркәзе булып тордыгындан, аның исеме гәзитә укучыларының хәтерендә калган булса кирәк.

Бу Гыйрак гаҗәмнең шималь кыйсемендә вә юл өстендә көрд кабиләләре яшиләр, тау арасында тапкан чирәмлекләрдә хайваннар асрап тамак туйдыралар, кабилә-кабилә булып, һәркаюсы үзләренең башлыкларына итагать итәләр. Вә шундан башка һичбер мәэмүр вә законны танымыйлар. «Гиләкләр»гә күрә бәдәнчә куәтле, йөрәкле вә чыдам киләләр. Ләкин бер йирдә утырып, «агач тамырына ябышып» яшәргә яратмыйлар, бинаән галәйһи[2] күбесе ачлы-туклы тора, үзенең күркәм вә йөгерек атына сокланып гомер итәдер. Рәшттән 9 нчы ыстанса булган «Мелла Гали»не кичкәндә йолдызлар күк йөзен каплаган иде.

Гасан (көрднең исеме Хәсәндән бозылган) үз ватанын искә төшереп җырларга кереште. Көмеш шикелле яңгырый торган тавышы, вә һәрбер ләфызында заһир булган мөтәэссир калебе горбәттәге юлаучыларга бик тиз тәэсир итте. Һәммәсе аны ихлас илә тыңладылар. Көрдчә вә төрекчә җырлаганына аның телен аңлаганнар вә аңламаганнар тәхсин иттеләр[3]. Микердич әфәнде әрмәничә вә фарсыча шигырьләр укыды. Шаһзадә Җәвад әфәнденең фарсыча күп шигырьләр белдеке аңлашылмас иде. Ләкин бу вакытта ул Русиядән яңа өйрәнеп кайттыгы «Маргарита!

[1] Мәсафәт – ераклык (расстояние).
[2] Бинаән галәйһи – шул сәбәпле.
[3] Тәхсин иттеләр – мактадылар.

Пой, эй веселися!»ны җырлады. Әллә ничә төрле телдә җырлар булгач, комплект тутырыр өчен, татарча җырларга мине тәкълиф итә[1] башладылар. Җырлауны истихсан итүем[2] дә аларга сылтау булгандыр. Мин «Татарның гүзәл җырларын ямьсез тавыш илә күрсәтү хәмияте миллиемә хилаф[3]» булганыны бәян итеп игътизар кылдым[4]. Бәхеткә каршы атлар да туктады. Без «Йөз баш чай» ыстансасына килеп йеткәнмез. Таң атканны шунда көтәчәкмез.

Көрднең калебендәге тәэсир мине мәшгуль иткән иде. Мин аның тәрҗемәи хәлен сорашмыйча кала алмадым. Ул да бик теләп вә гайрәтләнеп сөйләде.

«Мин, – ди, Гасан әйтә, – 16 ел ватаныма кайтканым юк. Мин үзем сөйгән бер кызга өйләнмәкче идем. Икенче бер егет аңа хак дәгъва итте. Шул сәгать дошманымны хәнҗәр илә урдым да, өйдән качтым. Хатыннар өчен кан түктем, ватанымдан аерылдым, инде мондан соң һич тә өйләнмәячәкмен. Дөрест, бәнем кабиләм дүрт йөз туман кан хакы түләделәр. Менә инде кайтам. Ләкин янә озак тормаячагым». Бу гашыйк «садыйк[5]»ның яше ничәдә булганыны сорадым. Исәпләп торды да:

«Валлаһи белмим. Атам, бабам күптән бирле юклар. Бездә дәфтәргә язу гадәте юк. Һәм дә миңа бер вакытта да кирәк тә булганы юк иде. Ярты гомеремне горбәттә[6] үткәрдекемдән яшемне сорарга да кеше таба алмаз идем».

«Йөз баш чай»дан соң «Бәк кәнди» вә «Буйнак» ыстансаларын узгач, юлымыз таудан котылды.

Бу кадәр озын сузылган тауларның эчендә ниләр барлыгы мине күп мәшгуль итте.

Бәлки Иранны заводлар вә вә тимер юллар илә тутырырлык куәт шушы тауларның эчендә гизләнмештер[7]. Ләкин булса да «гизләнмеш» аны табарга кеше вә акча кирәк. Әле күз алдындагылардан файдалана белергә дә шактый эш.

---

[1] Тәкълиф итә – көчләп куша, кыстый.
[2] Истихсан итүем – яратуым, яхшы дип санавым.
[3] Хәмияте миллиемә хилаф – милли хисләремә каршы.
[4] Игътизар кылдым – гафу үтендем.
[5] Садыйк – туры, эчкерсез.
[6] Горбәттә – мосафирлыкта, читтә.
[7] Гизләнмештер – яшерелгәндер.

Бу өч көннең эчендә 40–50 кәрвандан кичкәнемездер. Бер-бер артындан йөзләп тезелгән төяләр, көтүе-көтүе илә килә торган йөкле ишәк, качыр вә ат кәрваннары бу юлда бердә күздән югалып тормыйдыр. Ишәкнең бакырулары, качырның шыңгыравыклары бер дә колактан китми. Бер качырның муенына, яннарына вә артына тагылган «колокол»лар бәгъзан 40–50 гә йитәдер. Янга тагылганнары бәгъзан кишер башы чаклы да була. 5, 10 шыңгыравыкны эчле-тышлы да куялар.

Качырдагы җиз, тимер вә калайдан чыккан тавышларны ишеткәч вә өстендәге сбруйларының һәртөрле бизәлүен вә муенының төрле төстәге төймәләр илә тулуын күргәч, бу хайванның вә иясенең санаигы нәфисәгә[1] ни кадәр «мәфтүн[2]» идекләрен хөкем итәргә бер дә тукталып торылмыйдыр.

Көн уртадан соң Казвинга килеп йиттек, бөтен шәһәрнең биек вә мөхкәм[3] крепость илә чолганганын күргән кеше боның бер уч революционерлар тарафыннан ярты сәгатьтә алынганына ышанырлык түгел.

Таш вә балчыктан салынган крепостьнең бәгъзе урыннары мәшрутәчеләрнең мылтыгы вә тубы илә казылган. Ләкин һичбер йире тишелмәгән вә хәраб булмаган[4].

Шәһәрнең капкасы – Казвинның ничә гасырлык шөһрәтенә мөнасиб[5] дәрәҗәдәдер.

Эчендә киң урамнар, биек вә мөзәййан[6] кәрвансарайлар, әһалинең бераз шомалыгы туп-тугры күзгә бәрелә. Һәм Рәштне шәһәрлектә түбән дәрәҗәгә калдырадыр.

Казвин – 30 мең чамасы әһалине хави[7] кечкенә генә вә җыйнак кына бер шәһәрдер. Олуг сәүдә юлларының берләшә торган урынында, йимеш вә чикләвек багъларының уртасында булуы боны бер базар хәленә китермеш вә шулкадәр шөһрәтен җәймештер.

[1] Санаигы нәфисәгә – матур сәнгатькә.
[2] Мәфтүн – үз-үзен онытып сокланучы.
[3] Мөхкәм – таза, нык.
[4] Хәраб булмаган – җимерелмәгән.
[5] Мөнасиб – туры килгән.
[6] Мөзәййан – бизәлгән.
[7] Хави – эченә алган.

Теге маржа вә көрд бу 13 нче ыстансада төшеп калдылар. Яңа юлдаш уларак, янә ике кызылбаш утырдылар.

Боларның берсе гөмрөк[1] мәэмүре иде. Юл акчасы түләмәс өчен, заставадан җәяү качак (контрабанда) уларак кичте.

Кырыйларындагы бер фарсы юлда хезмәтне сөя торган икән. Һәммәмезгә файдасы тиде. Икенчесе бер шома егет. «Галантарин» сатучы татар егетләре кебек ыспай киенгән, кыска казаки эчендән катыргы яка, ияк вә яңак кырган, чәч кырыккан, башында йингел генә бүрек. Яңы модаларга иң элек яраучы. Бинаэн галәйһи мөҗаһидтер.

Муенындин таккан җыелмаулы «маузеры» үзенә килешә генә. Билендә патроннар. Накидка шикелле генә вә игътибарсыз салган «габа»сы җилкәсендән тиз үк менгүгә төшәргә тора вә күзгә бәрелми.

«Кара халык батыйндагы[2] фазыйләтне[3] аңлаганча, «кибарлек[4]«не сакларга гыйбадә бар», дигән кеби генә.

Бик күп сөйләргә ярата вә үзенең сөйләвен бик сөя торган кеше икән. Казвин-Тәһран юлыны яртыга кыскартты.

Дилижансның Казвинга соң килүе вә сәфәр өчен һаваның яхшылыгы сөйләнгәч тә, сүз Казвиндагы рус гаскәренә күчте. Бездән юлдагы вә Низаме Абаддагы солдатлар тугрысында сорашты.

Хәзер Иранда ике кеше бергә килсә, рус солдаты тугрысында сөйләшәләр. Юлаучылардан беренче сөальләре: солдатларның кайда булуы, күпмелеге, кайда хәрәкәтләре һәм шуңа мөтәгалликъ[5] сөальләрдер.

Казвинның янында чатыр корган 2000 ләп ватандашларымызны бу шәһәр кешесендән сорашмыйча китү миңа да монасиб түгел иде.

---

[1] Гөмрөк – таможня.
[2] Батыйн – эчке.
[3] Фазыйләтне – өстенлекне.
[4] Кибарлек – арситократизм.
[5] Мөтәгалликъ – караган.

**Рәшт – Тәһран**

*Мөҗаһид. Дин моназарасы[1]. Әрмәни исбате важиб итә. Җырлар. Тәһранга йитү.*

Рәшт илә Казвин арасында телеграф вә телефон чыбыкларын илтергә тигезсез, җуанлы-нәзекле вә кәкре баганалар утыртылган, үсеп торган вә корыган агачлардан үз урыннарында гына истифадә ителеп[2], багана утырту мәсарифындан[3] да качылган.

Зур вә яфраклы бер агач телеграф баганасы хезмәтен итүе монда бик гадәти шәйдер. Шуңа күрә Казвинны чыккач та тезелеп киткән матур тимер баганалар ерактан килгән йимешкә охшыйлар.

Бу баганалар Аурупа-һинд телеграф хаттыныдыр[4,5]. Тәбриздән килеп, Тәһранга вә андан, Исфаһан вә Бушир аркылы, Бәлүҗистанга уза. Бу хаттның Җөлфадан Буширгәчә булган кыйсеме, могаһәдә[6] буенча, инде Иран дәүләтенә калмыштыр.

Шоссеның Казвиндәге ыстансасы йөз меңнәр сарыфы илә бина иделмештер. Казвин – Тәһран арасындагы кәрвансарайлар вә миһманханәләр[7] һәммәсе биек, мөхкәм[8] вә зиннәтле рәвештә бина иделмешләр[9]. Кечкенә-кечкенә крепость хезмәтене әда итәрлектерләр[10]. Казвин – Тәһран шоссесыны үз кесәсендән эшләткән мәрхүм Сәгъдеддәүлә[11] кәрвансарайлар өчен дә акча

---

[1] Моназарәсе – бәхәсләшүе.

[2] Истифадә ителеп – кулланылып.

[3] Мәсариф – чыгымнар.

[4] Хаттыныдыр – линиясе.

[5] Аурупа-Һинд телеграф хатты тәкърибән (якынча) бондан 80 сәнәләр мөкаддәм инглизләр тарафындан салынган. Лондондан Скандинавия мөмләкәтләре аркылы Русиянең шималенә вә андан Одесса – Тифлис – Җөлфа юлы илә Иранга, андан Бәлүҗистан – Һиндстан – Австралия – Чин – Япон мәмләкәтләре аркылы Америкага, андан Канаданы кичеп, янә Бөекбритания атасына (утравына) кайтадыр. Бу юл хәзер дә һәр көн 20 мең рубләлек чамасында эшлидер.

[6] Могаһәдә – килешү.

[7] Миһманханә – кунакханә.

[8] Мөхкәм – таза, чыдамлы.

[9] Бина иделмешләр – төзелгәннәр.

[10] Әда итәрлектерләр – үти алырлык.

[11] Сәгъдеддәүлә – Иран премьер-министрларының берсе күздә тотыла *(Г. Ханнанова иск.).*

кызганмамыш. Бу юлда могаһәдә буенча рус шоссе ширкәтенә (Әнзәли – Тәһран юлы исемендә) күчмештер. Казвиндан Тәһранга чаклы булган юл тип-тигез, рельсалар сал да машина[1] йибәр. Артык зәхмәт лязем түгел.

Ике тарафта да 5–15 чакрымнар якынлыкта таулар дәвам итә. Хикәяләрдәге хан кызларының гизләнеп[2] кияү көтеп утырулары кеби бу таулар да үзләренең гүзәллекләрен багышларга инженерлар көтеп утырганга охшыйлар. Зарар юк, моңача ничә мең еллар көткән, янә ничә йөз еллар көтүдән берни дә булмас...

Бу кичне Казвиндан икенче ыстанса булган Кышлакда ял итеп, сәфәремезнең 4 нче көнендә беренче ыстанса «Яңа Имам» булды. Монда бик кыйммәт төшереп ясалган бер «төрбә»гә (каберлек) узган-барган һәммәсе зиярәт итәләр икән. Тәәссефкә каршы[3], юлдашларым «ихласлы» кешеләр тугры килмәдекендән, мин дә барып күрә алмадым.

Мөҗаһидемез сүз арасында үзенең тәрҗемәи хәлен дә сөйләп чыкты.

Кайчандыр бер бабасы Казвинда вали[4] булган, атасы бөек голямадан икән, бу андан яшьли калган, мәдрәсәдә укыган, үзе «раузахан» (мөнәҗәтче, бездә «карый» дип йөртәләр)[5]. Чалмалы таифәдән[6] икән. Инде андан чыккан, «хөрриятпәрвәр» булган.

Мәмләкәттә сәяси алмашынуның моның кием алмаштыруына ничек тәэсир иткәнен «раузахан»ларга махсус осталык илә нәкыль итде[7] ки, озын бер фельетон итеп язарлык иде.

Тәһранга якынлашдыкымыз нисбәтендә сүз көчәя барды. Һәрбер урыннарында мәшрутачыларның[8] ничек хәрәкәтен, шаһ

---

[1] Машина – биредә: поезд.
[2] Гизләнеп – качып.
[3] Тәәссефкә каршы – кызганычка каршы.
[4] Вали – губернатор.
[5] Раузахан – шигый имамнарның шәһид китүләре турындагы дастаннарны сөйләүче *(Г. Ханнанова иск.)*.
[6] Таифә – төркем.
[7] Нәкыль итү – сөйләү.
[8] Мәшрутачы – конституция тарафдары.

сәрбазларының[1] каршы торуларын «Мөҗаһид»емез тәфсилләп нәкыль итә. Бик күп сөйләүчәннәргә мөнасиб дәрәҗәдә үзенең мөһим хезмәтләрен дә нәкыль кыла. Тыңлаучылар аның юл кыскартуына тәшәккерән[2] сүзенә каршы төшмиләр иде. Фәкать бер тапкыр гына бик кызу моназара күтәрелде. Шөйлә ки, бу «раузахан» кыза-кыза пәйгамбәрләрне вә аларны йибәрүчене инкяр итеп үзене «табигый»[3] дип игълан итте. Әрмәни моңарга каршы төшеп, исбате важиб кылырга[4] кереште.

Шаһзадә дә моңа каршы гыйбадәтләрнең «чепуха» булуын дәгъва итеп, үзенең 17 яшьтән бирле (инде чәче агара) руза тотмаганын дәлил мәкамында зикер итте.

Ике мөселманга каршы торып, пәйгамбәрләрне вә көтебе сәмавияне[5] исбат итү мескен әрмәнигә шактый мөшкелләшкән иде. Мин ярдәмгә йитешеп, мәзһәб җидальләренең[6] тәгассыбны[7] арттыруын искә төшердем.

Дин моназараларында бик кызмак Аурупа сәфәре әдәбенә хилаф танылганны да зикер иткәч[8], ике тараф та «хаклыкны өсткә чыгару»дан ваз кичтеләр. Бу моназараларның ничә гасырлардан бирле бер дә файдасыз тәкрар ителдекен сөйләп һәммәсе дә суындылар.

Моназара вакытында «хиссияте диниясе»[9] бик рәнҗегән гөмрек мәэмүре[10] дә моның тукталуыны бик истихсан итте[11]. Арадан берәүсе «мөҗаһид»не янә сугыш хәбәрләренә кертеп йибәрде. Күз алдымызда Кәрәҗ елгасы иде. Шаһпәрәстләр[12] илә

[1] Сәрбаз – гаскәри.
[2] Тәшәккерән – рәхмәт әйтеп.
[3] Табигый – бередә: табигатькә табынучы, пантеист.
[4] Исбате важиб кылырга – Алланың барлыгын исбатларга.
[5] Көтебе сәмавияне – Алла индергән китапларны.
[6] Җидаль – көрәш, тартыш.
[7] Тәгассыб – фанатизм.
[8] Зикер иткәч – телгә алгач.
[9] Хиссияте диниясе – дини хисләре.
[10] Гөмрек мәэмүре – таможня чиновнигы.
[11] Истихсан итү – яхшы дип табу.
[12] Шаһпәрәстләр – «шаһка табынучылар», шаһ тарафдарлары.

мәшрутапәрәстләр[1] арасындагы иң мәшһүр мәгъръкәләр[2] шушы урында булмыштыр.

«Шаһабад» ыстансасына килеп йиттек. Мәшрутәчеләрнең катгый[3] галәбәсе[4] шунда булган. Бондан соң сәрбазлар Тәһранга качканнар.

Без соңгы ыстанса «Шаһабад»дан кичкәндә, кичке караңгылык төшкән иде.

«Раузаханымыз» ихтилял шигырьләрен дәрд вә шәүкъ[5] илә җырлады.

Рәштнең шаһпәрәст хакиме Ага Балаханның (соңгы рәсми ләкабе[6] «сәрдаре әфхәм» иде) үлтерелүе илә мәшрутачыларның галәбәсен[7] тәбрик итеп чыгарган такмакны ике дәфга тәкрар итте. Юлчылар һәммәсе шәрык гадәтенчә кул кулга чабып:

«Милләт аждаһа шөд
А, Балаханҗә!
Мөстәбид фәна шөд
А, Балаханҗә!
Мәшрута бийа шөд.
А, Балаханҗә!»[8] –

нәкаратын[9] бер авыздан күтәрәләр иде.

---

[1] Мәшрутапәрәстләр – конституциягә табынучылар, конституцион дәүләт төзелеше тарафдарлары.
[2] Мәгъръкәләр – сугышлар.
[3] Катгый – кискен; иң соңгы.
[4] Галәбә – җиңү.
[5] Шәүкъ – көчле теләк.
[6] Ләкаб – титул.
[7] Галәбә – өстен чыгу, җиңү.
[8] Милләт аждаһа булды.
Кил, Балахан, чык!
Залим юк булды.
Кил, Балахан, чык!
Конституция килде.
Кил, Балахан, чык!
*(Г. Ханнанова тәрҗ.).*
[9] Нәкаратын – такмагын.

Рәшттән Тәһрангача безне китергән 82 гадәд ат ыстанса саен дүртәрдән алмашыналар. «Сөрүчеләр» атлар илә бәрабәр алмашындыкларындан без аларның һәрберсенә икешәр кырандан[1] чәйлек бирә килдек вә яхшы куаласыннар өчен һәммәсенә «сөрүче башы!» дия тәгъзыйм[2] илә хитаб кыла[3] идек.

[Сөрүчеләрнең 18 нчесе] Тәһранның үзенә йиткерәчәкендән чәйлекне күбрәк алачагы безгә дә, үзенә дә мәгълүм иде. Бинаән галәйһи атларны бик куалавы, кычкыруы, куалавындан да күбрәк иде. Юлчылар Тәһранга якынлашуны белеп, һәркем үзе илә мәшгуль булып фикергә талды.

Сәгатемнең караңгыда да күзгә зәхмәт бирми торган алтын уклары һәр икесе 8 гә якынлашканнар иде. Күк йөзенә иркенләп багар өчен, дилижансның пәрдәсен күтәрдем. Йолдызлар болыт һәм ай юклыкны ганимәт белеп, бигрәк ялтырыйлар.

Мине тарткан йолдызларга озак карап тордым. Җидегән йолдызы офыкка шимальдәгедән бик күп якын тора, бинаән галәйһи зур күренә вә бөтен шималь тарафын каплый шикелле тоела...

Күк йөзендә кемнеке илә күз укларымыз очрашканыны хыял итеп, үземдән кичкән заманда әлегә бик тигез килгән кыңгырау тавышлары бердән киселде.

Дилижанс туктады. Мин дә айныдым. Без Тәһранда идек.

## IX
## Тәһран

*Иске күчәләр[4]. Яңа хийабаннар[5].*
*Аурупалыларның Иран пайтәхетендәге кальгалары[6].*

Азия шәһәрләре һәммәсе безнең күзгә ят күренә вә гаҗәеп тоеладыр.

---

[1] Кыран – Ирандагы көмеш тәңкә. Г. Шәрәф Иранга барган вакытта 1 кыран 18 тиен кыйммәтендә булган *(Г. Ханнанова иск.)*.

[2] Тәгъзыйм – олылау, хөрмәтләү.

[3] Хитаб кылу – эндәшү, мөрәҗәгать итү.

[4] Күчә – тыкрык.

[5] Хийабаннар – урамнар.

[6] Кальга – крепость; замок.

Монда әхвәлнең мәҗбүр итүенчә вә гадәте миллиянең[1] теләвенчә шәһәрләр Аурупадагыга бөтенләй башка рәвештә бина иделмеш.

Сугыш вә җау басуларның еш-еш булуы качкыннар вә талаучылар гөруһысындан[2] әмният[3] юклык һәрбер йортны бер «кечкенә крепость» сурәтендә корырга гадәтләндермеш. Бондай ябык вә бикләүле хәятнең[4] гадәт булуы аның йәнәдән гасырларча яшәячәген тәэмин итмештер.

Тәһранның әксәриятен[5] тәшкил иткән иске кыйсеме ошбу рәвештәдер:

Тар гына коридор, ике тарафында балчык диварлар сузылып киткән, урам өстендә өйләр һич тә юк, алар һәммәсе хәят тәгъбир иттекләре[6] ишегалдында (ягъни йорт эчендә). Урамда капу (ишек)ләр ике яклап тигезсез ераклыкларда тезелеп киткән. Бу капулар, ни хәлдә барынча нык вә йимерелмәслек итеп мөхкәм[7] эшләнгән, байларның тышкы зиннәтләре капуны бизәкләүгә хәсыр ителмештер[8]. Һәртөрле бизәкле ташлар сахибләренең[9] матур игътикад итдеке[10] рәвештә куелмыш капуның мәһабәтлеге өчен меңләр, ун меңләрчә пул[11] кызганылмамыш.

Хиҗазны зиярәт итеп «хаҗи» булган кешеләр үзләренең ишекләренә язулы ташлар куеп игълан итү гадәте булган. Бу ташларда әксәриятчә[12] «Бисмиллаһир-рахманир-рәхим», «Инна фәтәхнә ләкә фәтхән мөбинән»[13], «Вә-ин йөкядел-ләзинә кәфәрү

---

[1] Гадәте миллия – милли гадәт.

[2] Гөруһ – төркем.

[3] Әмният – тынычлык, куркынычсызлык.

[4] Хәят – биредә: ишегалды.

[5] Әксәрият – күпчелек.

[6] Тәгъбир итү – аңлату.

[7] Мөхкәм – таза, нык.

[8] Капуны бизәкләүгә хәсыр ителмештер – капканы бизәүгә генә юнәлтелгән.

[9] Сахибләренең – хуҗаларының.

[10] Игътикад итү – ышану, күңел беркетү.

[11] Пул – акча.

[12] Әксәриятьчә – купчелектә.

[13] «Фәтех» сүрәсенең 1 нче аяте.

лә-йөзликунәкә би-әбсариһим»[1] илә ахирил-аять[2] аятьләре вә «Иннә Гали ибне Әбү-Талиб хисни вә-мән дәхәлә хисни әминә мин газаби»[3] хәдисе кодсисе[4] вә гайреләр язылган буладыр.

Арба илә керерлек капкалар бик сирәк вә гомумән экипаж тотмак Иранның бик олугларына гына махсустыр[5].

Бу күчәләрнең ягъни урам урынында ясалган коридорларның йөз сажин кадәрле тигез сузылганы да бик сирәк. Һәммәсе борылышлы, вә бик күбесенең очы барып терәлә, шәһәрне яхшы белмәгән кешенең бу урамнарга кереп адашуы, киткән урамы бетеп кире кайтырга мәҗбүр булуы күп тугры киләдер. Бу күчәләрнең исемнәрене һәркем үзенчә йөртә. Мәсәлән: фәлән бабайлар урамы, фәлән әбиләр янындан борылып кергән урам, һакәза[6]... Исемнәре өстенә язылмаган гына түгел, исем куелганы да юк.

Һичбер капуның өстендә кем йорты идеке язылмаган, бинаән галәйһи бер кирәк кешеңне табар өчен, йитәкче тотарга, яисә көне буе эзләп, сорашып йөрергә туры килә.

Йорт эчендәге һәммә тиресләр урамга чыгарып түгелә вә шунда әле «Машалла» сасытып ятадыр. Фонарьлар куелмаган, тротуар ясалмаган, таш җәелмәгән. Бинаән галәйһи һәркемнең үзен саклавы үз башынадыр. Әһали[7] дә моңа күнеккән, кич сирәк йөри вә кәгазь фонарен үзендән калдырмый.

* * *

XIX гасырда Иранның Аурупа илә һәр җәһәттән күп мөнәсәбәттә булуы, шаһларның, әгъянның[8] Аурупа шәһәрләрен зиярәт итүләре, аурупалыларның төрле максуд[9] артындан Иранга килүләре Тәһранга тәэсирсез калмаган. Шәһәрнең яңа

[1] «Каләм» сүрәсенең 51 нче аяте.

[2] Илә ахирил-аять – аятьнең ахырынача.

[3] «Гали бине Әбү-Талиб – минем кальгам, шул кальгага сыенганнар – Минем ачуымнан имин булалар» (шигыйлар арасында таралган хәдис) *(Г. Ханнанова иск.).*

[4] Хәдисе кодсисе – изге хәдисе.

[5] Махсус – хас булган.

[6] Һакәза – һәм башка шундый.

[7] Әһали – халык.

[8] Әгъянның – югары катлау вәкилләренең.

[9] Максуд – теләк.

кыйсеме Аурупадагы кеби бина ителеп, адәм вә экипаж йөрерлек урамнар ясалган. «Хийабан» тәгъбир иттекләре бу урамнар һәммәсе йитәрлек микъдарда киң, ике тарафларына агачлар утыртылмыш, ташлар җәелмеш, вә тар гына тротуарлар буендан даимән су агып торадыр. Һәртөрле пычраклар күп булу сәбәбле, тротуардан йөрү бик сирәк, урамда ага торган судан юынучы вә шунда кер юучылар күп була. Бу хийабаннарда урам буена салынган өйләр дә бар, елдан-ел арта, хәтта калын тимер рәшәткә артындагы тәрәзләрне дә күрергә мөмкин. Бондый йортларның күбесе аурупалыларныкы йә кяферләрнеке[1], вә бик азы гына «фәрәнгиләшкән[2]» мөселманнарныкыдыр.

Яңа урамнарның әксәрисе яңа кешеләр исеме илә аталган, «хийабане Фәрманфәрма», «хийабане Галәэд-дәүлә», «хийабане Зыйллес-солтан», Насыйрия, Мозаффария, Әминес-солтан вә гайреһем[3].

Иранның тарихта мәшһүр кешеләре башка мәмләкәтнеләрдән ким булмаса да, һичберенең исеменә бер урам белә хатирә ясалмамыш ки, тәгаҗҗеб итәрлектер.

* * *

Аурупа дәүләтләренең сәфарәтханәләре[4] һәммәсе бер крепостьтан гыйбарәт. Хийабанда Англия кальгасы, Германия кальгасы, Госманлы кальгасы (капкасы башына «Иннәһү Хәмиден Мәҗиден»[5] аяте язылмыш) вә болардан аерым «Паминар» мәүкыйгында[6] Русия кальгасы тәэсис иделмештер[7] ки, бу кальгалар Тәһранның иң мөхкәм[8] урыннары саналадыр. Һәм дә саналырга истихкаклары[9] бар.

[1] Кяферләрнеке – биредә Иранда яшәүче мөселман булмаган халыкларның һәм дини төркемнәрнең вәкилләре (әрмәннәр, яһүдләр, гәберләр) күздә тотыла *(Г. Ханнанова иск.).*

[2] Фәрәнгиләшкән – европалашкан.

[3] Гайреһем – гайреләр.

[4] Сәфарәтханәләре – илчелекләре.

[5] «Һуд» сүрәсенең 73 нче аяте.

[6] Мәүкыйгында – урынында.

[7] Тәэсис иделмештер – төзелгән.

[8] Мөхкәм – таза, нык.

[9] Истихкаклары – хаклары.

Тәһранның тупханәсе[1], шәһәр тирәсен чолгаган крепостьны вә аның тирәсен әйләндергән каршы тирән хәндакы (чокыры) бу «сәфарәт»ләргә каршы һич шәй дәгелдер.

Тәһранда сәфирләрнең[2] хөрмәт вә нөфүзләре[3] вәзирләрнекендән артык булдыгы кеби кальгалары да вәзирләр идарәсендәге кальгалардан мөхкәмрәктер[4]. Тәһранда башка ислам пайтәхетләрендәге кеби әҗнәби[5] флагының дәүләт флагындан көчлерәк, әҗнәби химаясенең[6] дәүләт химаясендән ышанычлырак булуы гәзитәләрне тәгъкыйб итеп[7] килгән кешеләргә мәгълүмдер.

## X
## Мәҗлес ачылуны көткәндә

*Мөкаддимә. Фитрәт[8] заманы. Гаксел-хәрәкәт[9]. Хәзерге халәттә гавам[10]. Руханилар. Таҗирләр[11]. Зыялылар. Өмид.*

Иранга килгәнемә инде биш атна узса да, бу мәмләкәтнең әхвәле сәясиясе[12] тугрысында укучыларымызга бер иҗмал[13] вә мөхакәмә[14] гарыз итүдән тартынып тордым.

Монарга сәбәб – кызылбашлар пайтәхетенең мине мәрхәмәтсез каршы алып, авыру илә булышырга мәҗбүр итүе генә түгел.

Бу бизгәк читтән беренче дәфга килгән кунакларның һәммәсенә бүләк ителә икән. Һәркемгә бурыч булган бер «дань» өчен үпкәләргә һәм үч алырга лөзүм[15] юк. Бәлки Иран әхвәле

---

[1] Тупханә – арсенал.
[2] Сәфирләрнең – илчеләрнең.
[3] Нөфүз – авторитет.
[4] Мөхкәмрәктер – ныграк.
[5] Әҗнәби – чит ил.
[6] Химая – яклау.
[7] Тәгъкыйб итү – күзәтеп бару.
[8] Фитрәт – патшасызлык дәвере; күчеш дәвере.
[9] Гаксел-хәрәкәт – реакция.
[10] Гавам – (гади) халык.
[11] Таҗир – сәүдәгәр.
[12] Әхвәле сәясиясе – сәяси вәзгыяте.
[13] Иҗмаль – кыскартып сөйләү.
[14] Мөхакәмә – хөкем чыгару.
[15] Лөзүм – кирәк булу.

сәясиясенең бик чуалчыклыгы сәбәбле тугры вә ачык хисап бирүнең мөшкел булуы мине ихтият[1] илә каләм тибрәтергә мәҗбүр итте.

Үзем канәгатьләнерлек бер фикер хасыйль итәр өчен, күп тикшермәк вә күп урындан мәгълүмат алмак лязем иде.

Хатамны игътираф итмичә[2] хәл юк, мин «Яңарган Иран»га дип сәфәр иткән идем.

Өемдәге занымча[3]: Иранның сәяси инкыйлабы сабикъ[4] шаһ Мөхәммәдгалинең Ирандан чыгарылуы илә тәмам булды, инде әсаслы яңа хәят башланачак, Иран әһалисе – мәшрутият вә хөрриятькә бик күп кан бәрабәренә наил булган[5] әһали – яңа ысуле идарәне[6] бик интегеп көтеп ала, бинаән галәйһи һәрбер ислахатны[7] бер көн элек[8] ижра итәргә[9] ашыга торгандыр, әһалинең зиядә[10] теләве илә һәрбер эшләр тиз юлга салынырга тиеш иде...

Минем фаразларым шул иде. Бабайларның «өйдәге гакыл базарда ярамый» дигән сүзләре тугры чыкты.

Иранның якты якларын гына язарга ниятләнгән кешегә караңгы тарафларына да туктарга лязем булды.

Иранның эченә кереп, аның сәясәт галәме илә танышуым элекке фикерләрнең тәсхихка[11] мохтаҗ булдыгыны күрсәтте.

Иске хөкүмәтнең йимерелүе илә әсаслы вә төпле яңа хәят башлау арасында озын бер «фитрәт заманы» мөмкин икәнчелекне күз алдыма китерде.

---

[1] Ихтият – саклык.
[2] Игътираф итмичә – үз кимчелекләреңне танымыйча.
[3] Занымча – уемча, чамалавымча.
[4] Сабикъ – әүвәлге.
[5] Наил булган – ирешкән.
[6] Ысуле идарәне – идарә итү рәвешен.
[7] Ислахатны – реформаны.
[8] Бер көн элек – мөмкин кадәр тизрәк.
[9] Ижра итү – үтәү, эшкә ашыру.
[10] Зиядә – бик, күп.
[11] Тәсхихка – төзәтмәгш.

* * *

Гадəттə ничə еллар дəвам итə алган бу фитрəт заманнары тарих моталəга иттекемездə[1] бик кыска тоела.

Бер миллəтнең дүрт-биш йөз еллык тарих сəхифəлəрен актардыкымызда очраган биш-алты, ун елларыбызның буш гомеремездəге əһəмиятсез минутлар кеби кыскадырлар.

Əмма бу 5–6 ел күз алдында булса, иранилар кеби ничə гасырлар золым астында ыңгырашкан бер миллəт инкыйлаб өчен үзенең тынычлыгын качырып, 3–4 ел кан түгеп, һəртөрле газаплар чигеп, никадəр корбаннар биреп, мəшрутиять вə хөрриятkə наил булдыктан соңра янə берничə елларны əмниятсез вə «хаос» эчендə кичерəчəк булса да, бу халəт кызганырлыктыр.

Ике-өч ел интизамсызлык[2], вə тиҗарəт кəсады[3] ничə гаилəлəрне хараб итəргə вə миллəтне ничə елларга кире йибəрергə кифая итəдер[4].

* * *

Адəмнең гомере кыска, гомеренең хезмəт вə фидакярлек вакыты бик аз, əксəр[5] əһалинең сабыры бик тиз төкəнергə мөмкин.

Бинаəн галəйһи, əгəр инкыйлаб хəрəкəте озакка сузылса, мəмлəкəтнең тынычлануы тиздəн кителмəсə, инкыйлаб зəхмəтлəренə нəтиҗə булачак интизам вə рəхəтлек нигъмəтлəре тиздəн ирешмəсə əһалинең бу хəрəкəтлəргə дəрде суына, бу хəрəкəткə куəт бирергə телəүчелəр азая, искедə күнелгəн «бер көе тору»ны сагына башлыйлар.

Иске тормышта үзенең сəяси максудларын вə икътисади мəнфəгатьлəрен тапкан кешелəр гафлəт итмилəр, форсаттан истифадə итеп[6], аумалы əһалине үз тарафларына караталар.

[1] Моталəга иттекемездə – өйрəнгəндə.
[2] Интизамсызлык – тəртип булмау.
[3] Тиҗарəт кəсады – сəүдəдə торгынлык, кытлык.
[4] Кифая итəдер – җитəрлек була.
[5] Əксəр – күпчелек.
[6] Истифадə итеп – файдаланып.

Гаксе хәрәкәт (реакция) көчәя. Бу дидекләрем кадәрлесе хөкүмәт вә хариҗи истибдадчылар[1] тәэсире генә түгел. Бәлки әһалинең әхлакы вә табигате шулай.

Русиядәге инкыйлаб хәрәкәтене вә соңгы елларда әфрады әһалидәге[2] реакцияне тамаша иткән кешеләр югарыдагы кагыйдәне татбикъ итә[3] алырлар.

Бу кагыйдәне Иранда татбикъ итүдән дә манигъ[4] күренми. Билгакес[5], әһалинең әхлак вә психологиясен тәдкыйк итү[6] боны исбат итәдер.

* * *

Иске Иранда язылган гомуми законнар юк иде. Бәгъзе нәзарәтләрдә[7] булса да муҗибенчә[8] гамәл кылынмый. Һәрбер хаким вә мәэмүр үзе белдекенчә хөкем итә, үзе теләдекенчә идарә кыла, үзенә яраганча эш йөртә, әһалинең мал вә җанына үз кәйфиятене[9] «хакиме мотлак» дип белә иде.

Валиләрне хәзердә дә «хөкүмәт» исемендә йөртәләр. Мәсәлән: «Фәләнес-сәлтанә» Кашанга хөкүмәт тәгъйин ителгән, Хорасанда «Фәләнел-мәмалик» хөкүмәтлек итә, дияләр.

Гавам вә хавасның[10] шөйлә[11] тәгъбир итүләре алар кашында хөкүмәтнең бер шәхестән гыйбарәт булдыгыны күрсәтә түгелме?

Шулай күрергә гадәтләнгән вә бар мәгълүматы гадәтенә мөнхасыйр булган[12] гавам әһали падишаһны да шундай «куәтле»

---

[1] Хариҗи истибдадчылар – чикләнмәгән монархиянең читтәге тарафдарлары.
[2] Әфрады әһалидәге – халыктагы.
[3] Татбикъ итү – чагыштырып карау.
[4] Манигъ – киртә.
[5] Билгакес – киресенчә.
[6] Тәдкыйк итү – җентекләп өйрәнү.
[7] Нәзарәтләрдә – ведомстволарда.
[8] Муҗибенчә – тиешенчә, тиешле рәвештә.
[9] Кәйфиятене – хәлен.
[10] Гавам вә хавасның – гади халык һәм югары катлау вәкилләренең.
[11] Шөйлә – шулай.
[12] Мөнхасыйр булу – бер генә нәрсәгә кайтып калу.

күрергә телиләр. («Фәгъгале ләмма йәшә’ә ля йәсьәлә гамма йәфгалә»[1] булсын).

Кулы вә аягы мәшрутият[2] илә богауланган шаһның алар кашында хөрмәт вә игътибары юк. Закон вә хакканиятнең[3] игътибары булмаганыны да гыйлавә итик[4], инде алар нәрсәгә туктаячаклар?

Мәшрутият вә хокуклылыкның файдасын укып белүчеләр вә ишетеп ышанучылар да Иранда безнең Русиядәге кеби күп түгел. Аларны көндез шәм илә эзләргә кирәк.

Мәгълүм ки, гавам ишетү илә генә бер нәрсәне дә белми. Ул, күреп вә гадәтләнеп кенә белә ала.

Бу тәфсыйлаттан[5] аңлашыла ки, хәзерге халәттә Иранның гавамы мөстәкъбәлгә[6] ышанып карый алмый «ни булыр инде?» сөале илә борчылып тетрәп тора.

Бу гавам нәзары[7] булды.

* * *

Зыялы вә аңлы халыкның фикеренә колак салсак, янә шуңа якын бер мөляхәзәгә[8] туктарга лязем була.

Дәгъва коры сүз генә булып калмасын өчен, бонда бераз тәфсыйл итик:

Иранның гавамдан югарыгы кыйсеме дүрт таифәдер[9]:

әгъян[10] вә ханнар – иске идарә заманында бөек дәрәҗәле, күп милекле вә нөфүзле[11] булган кешеләр; 2) руханилар; 3) сәүдәгәрләр; 4) зыялылар.

---

[1] Фәгъгале ләмма йәшә’ә ля йәсьәлә гамма йәфгалә – теләгәнен эшли һәм эшләгәннәре өчен бер кешегә дә хисап бирми.

[2] Мәшрутият – конституциялелек.

[3] Хакканиятнең – законлылыкның.

[4] Гыйлавә итик – өстик.

[5] Тәфсыйлаттан – җентекләп аңлатудан.

[6] Мөстәкъбәлгә – киләчәккә.

[7] Гавам нәзары – гади халык фикере.

[8] Мөляхәзә – күзәтү.

[9] Таифә – төркем.

[10] Әгъян – югары дәрәҗәле түрәләр.

[11] Нөфүзле – авторитетлы.

Русия әгъяннарының сәяси мәсләкләреннән хәбәрдар булган укучыларымыз Иран ханнарына хөсне занда[1] булмасалар кирәк.

Русиянең дворян вә помещиклары һәммәсе – беркадәр мәгърифәтле вә күбесе гали[2] образованияле булулары һәм дә хариҗдәге мәдәният галәмен биш бармаклары кеби белдекләре хәлдә, хөрриятка каршы торучыларның гомдәләредер[3].

Иран әгъянында әмляк[4] вә дәрәҗә өстенә наданлыкны да өстәргә кирәк. Яңа хәят урынлашты исә, боларның һәммәсене мөхакәмәгә тартачак бит. Алар шуны беләләр.

Руханилар – дөньяның һәрбер җәһәтендә искелек вә истибдад[5] тарафдарыдырлар.

Аның өстенә Иран руханилары дөньядан бик аз хәбәрдарлар. Олуглары – һәммәсе алпавытлар; вак руханилар олуглар ишарәсеннән чыгарлык җөрьәт вә гыйлемгә малик түгелләр.

Иранда беренче мәшрутият заманында руханиларның истибдадка каршы хәрәкәтләре мәшрутияттә үзләренең нөфүзле булуларына ышанулары кеби бер хата сәбәбле генә булган, имеш.

Алар эчендә Җәмалетдин әл-Әфганигә мәнсуб фидаиләр, ягъни мәнфәгате гомумия өчен шәхси файдаларыннан ваз кичүчеләр, әлбәттә, мөстәснадыр[6].

Инде руханилар тәҗрибә итеп күрмешләр ки, әһали сәяси хөрриятка наил булу илә бәрабәр фикри хөрриятка дә ирешә, руханиларның тырнагыннан ычкына икән.

Шул сәбәбтән бу икенче инкыйлабта руханилар беренче инкыйлабтагы кеби икъдамлы тауранмадылар[7] вә күбесе, инкыйлабка катышуның «аларга кирәкле» эш булмадыгына ышанып, бер читтәрәк тордылар. Шәех Фәйзулла кеби үзе белгәненчә бәхетен сынап, соңра дарга асылучылар да табылды. Әһали дә руханиларга суынды, бу инкыйлабта аларны бик кыс-

[1] Хөсне занда – уңай мөнәсәбәттә.
[2] Гали – югары.
[3] Гомдәләредер – таянычлары.
[4] Әмляк – мал-мөлкәт.
[5] Истибдад – деспотизм.
[6] Мөстәснадыр – чыгармадыр.
[7] Икъдамлы тауранмадылар – инициатива күрсәтмәделәр

тамадылар. Беренче Мәҗлес[1] чалма илә тулы булдыгы хәлдә, икенче Мәҗлес әгъзалары эчендә мулла исемнәре күренмидер.

Рус руханилары эчендә Г. Петров, епископ Михаил кебиләрнең табылуы бу сыйныфны хөрриятпәрвәр санарга кяфи[2] дәлил булмаса, Иран руханилары арасыннан чыккан берничә мөхтәрәм затлар да, бу голяманы һәммәсен фидаи санатырга кифаять итмидер[3].

Милләте хакимә руханилары, фидаи булып сыйнфый мәнфәгатьләреннән ваз кичмәдекләре хәлдә хөррият тарафдары була алмадыклары мәгълүмдер.

Таҗирләр, хосусан укымышсыз таҗирләр, даимән якын файданы күз алдында тоталар. Вә якындагы зыянның тәэсире астында фикер йөртәләр.

Иранның тиҗарәте[4] ихтилял башлау илә бик күп кимегән. Инкыйлаблар заманында байның иртәге көне мәгълүм булмадыктан кредит (бурычка бирү) туктаган, боның илә ничә фирмалар банкротлыкка чыккан вә ничәләр эшләрен чарасыз кечерәйткәннәр. Берничә ел эчендә шаһ галәбә итсә – шаһ, ихтилялчылар галәбә итсә[5] – ихтилялчылар икенче тараф байларыны талыйлар, төрле сурәт илә малын алалар.

Һәртөрле талаучы фиркаләр боның өстенә. Шул талаулардан әмин булыр өчен хәлле кешеләрдән күбесе хариҗгә[6] киткәннәр, акчалы кешеләр алтыннарын, көмешләрен яшергәннәр, хариҗдәге банкаларга[7] яисә йир астына күмгәннәр.

Базарда грош кына калган.

Кредит вә акчаның сәүдә галәменнән югалып торуы 3 ел кадәр озын мөддәткә[8] сузылып, таҗирләрне актык сулуга йиткергән. Мәмләкәттә интизамны сакларлык куәт хәзердә дә күз алдында булмаганнан бу бәланең кәсадның (застой) тиздән күтәрелүе көтелми.

[1] Мәҗлес – биредә: Иран парламенты.
[2] Кяфи – җитәрлек.
[3] Кифаять итмидер – җитәрлек нигез бирми.
[4] Тиҗарәте – сәүдәсе.
[5] Галәбә итсә – җиңеп чыкса.
[6] Хариҗгә – читкә.
[7] Банкаларга – банкларга.
[8] Мөддәткә – вакытка.

Ялңыз чара булачак хариҗи банкалар (Иранда дахили[1] банка юк) хөкүмәткә дә, Иран сәүдәгәрләренә дә карыз[2] бирергә ашыкмыйлар. Шушы мөляхәзалар[3] күрсәтә ки: иске идарә заманында сума ясаган байлар вә көнлек сәүдә илә генә ризык таба торган вак сәүдәгәрләр бу соңгы 3 елдан мәмнүн була[4] алмыйлар вә шуңа ләгънәт әйтүдән дә тартыначак түгелләр.

Гадәдләре бик аз булганнан 4 нчегә калдырдыкымыз зыялыларның бер кыйсеме шөбһәсез чын мәшрутият вә хөррият тарафдарыдырлар.

Милләт мәнфәгатен күзәткәннәре һәм яңа идарә заманында үзенә яхшы урын табарга ышанганнары максудларына таба хәрәкәт тә итәләр.

Ләкин әхвәлнең икътизасынча[5] төрле фиркаләргә мәнсүб булган[6] бу зыялылар мөстәкыйль вә галиб[7] бер фиркә тәшкил итәргә муафыйк була алганнары юк.

Бу фиркаләр (партияләр) хосусында киләчәктә тәфсыйл итәрмез[8]. Әһалинең наданлыгы, юлларның читенлеге, матбугатның таралмавы зыялыларның гавамга тәэсирене иң ким дәрәҗәгә төшерә. Гавам кулда булмаганның соңында, бер уч зыялыларның хәяте гомумияне[9] үз теләдекләренчә йөртә алулары шөбһә урыны булдыгы шиксездер.

Хөлясател-хөляса[10] шулдыр ки, инде Иран әһалисе хөррият бәйрәмнәренең кызуын уздырган, ачы хакыйкать илә капмакаршы килгән хәзерге халәт һичбер сыйныфны канәгатьләндерә алмый.

Әгърафтагы[11] бу интизар халәтеннән чыгарырга Мәҗлесне көтәләр.

---

[1] Дахили – эчке.
[2] Карыз – ссуда, әҗәткә акча бирү.
[3] Мөляхәзалар – фикер йөртүләр.
[4] Мәмнүн булу – разый булу.
[5] Икътиза – кирәклек.
[6] Мәнсүб булган – нисбәте булган, караган.
[7] Галиб – җиңүче, өстен чыгучы.
[8] Тәфсыйль итү – җентекләп тасвирлау.
[9] Хәяты гомумияне – гомуми тормышны.
[10] Хөлясател-хөляса – сүзнең иң кыскасы.
[11] Әгъраф – җәннәт белән җәһәннәм арасындагы урын.

Электә мәҗлеснең ачылуы беренче шәүвәлгә тәгъйин ителдекеннән бән дә ашыгып рамазан ахырына Тәһранга килеп йиткән идем.

Шуннан бирле һәр көн «бу атна ахырында ачылачак»дия мәҗлесне көтеп шәүвәл ахырын йиткердем. Әле ачылмады.

Инде зөлкагъдә башында ачылуны катгый шикелле сөйлиләр. Вә ләкин рәсми игълан ителдеке юк әле[1].

Мәҗлес ачылу илә яңа наибес-сәлтанә[2] тәгъйин ителеп вә хариҗләрнең хөкүмәткә игътимадлары[3] артып, «чарасыз хаҗәтләр» өчен бурыч бирүләрен көтәләр.

Шуннан соң мөмләкәт мәгыйшәте юлга төшеп, ислахат үз юлы илә иҗра кылынып, әһалинең мәшрутият вә хөррияткә ихлас вә игътимад итүләре өметледер.

*Тәһран, 27 октябрь*

## XI
## Милләт мәҗлесенең ачылуы

*Иртә торгач та. Тупханә мәйданы, Пустаханә вә Зыйллес-солтан хийабаннары. Бәһарстан мәйданы. Мәҗлес. Хазирун.*

Зөлкагъдәнең башы (2 ноябрь) дүшәмбе көн иртә торгач та, кечкенә генә «шир-хөршид» флагын[4] өстәлемнең өстенә асылындырып, сабыны дивардагы кадакка бәйләдем. Теге якта кечкенә шаһның бөек кыйтгадагы[5] рәсеме берничә көннән бирле бүлмәмне бизәп тора. Болар – Русия мөселманнарының берсе тарафыннан иранлы кардәшләренә күрсәтелгән дустлык галәмәтләредер. Адәм үзенең шатлык көнендә дустларын да шат күрәсе килә, Дустлары да үзләрен шат күрсәтергә тырышалар, табигыйдыр. Җуынгач-киенгәч тә бакчага чыктым, һава

[1] Мәҗлес зөлкагъдә берендә ачылды *(Идарә).*

[2] Наибес-сәлтанә – регент; дәүләт башлыгы вазифаларын башкаручы.

[3] Игътимадлары – ышанычлары.

[4] «Шир-хөршид» флагы – арыслан (фарсыча «шир») һәм кояш (фарсыча «хөршид») төшкән эмблема (Каҗарлар династиясе заманында Иранның дәүләт гербы) *(Г. Ханнанова иск.).*

[5] Кыйтга – кисәк, өлеш; континент.

саф, җилнең әсәре дә юк, кояш – ноябрьдә сирәк була торганча кыздыра, Нәһавәнд тавы үзенең газамәте[1] вә ак башы илә шәһәргә өсттән бага иде.

Урамга күз салдым, йөрүче күбәйгән, күршемездәге йорттан, бал кортлары кеби таралган балалар һәммәсе «Шәрык» гәзитәсен күтәреп төрле якка йөгерәләр.

Сулларның әфкярене[2] нәшергә[3] васита[4] булган бу гәзитә бу көн бөтенләй кызыл кара илә басылып чыккан; минем кулыма төшкән номерларының берендә гәзитәнең башыны алтынлаган да иде, каршыдан килгән балалар «Ираны нәү[5]!» дия кычкыралар кулларындагы гәзитәнең беренче бите яшел, ак вә кызыл төстә милли флаг сурәтендә чыгарылган; ак берлек өстендә сары кара илә «Арыслан вә кояш» рәсеме төшерелгән. Әрмәни Дашнаксьютун җәмгыятенең кызыл кәгазьдә, «Иттифак вә тәрәккый» җәмгыятенең ал кәгазьдә басылган прокламацияләре дә узгынчы вә тамашачыларның кулына сузылган. Ат өстендә узучыларның күплеге, әһалинең бәйрәмчә һәр якта ишетелгән музыка тавышлары бу көннең фәүкыльгадәлеген[6] аңдыра иде.

Сәгать тәмам 12 тулганда, мөхәррирләрдән «мөһәззибелмөлек» Мирза Габделхөсәен хан килеп бәңа: «Тизрәк китик, соңга каламыз», – диде. Тәшрифат идарәсеннән[7] бирелгән яшел билетыма карадым: «Сиһ сәгать бә-горуб мандә»[8] дия язылмыш. Тәҗрибәле иптәшем бондай көннәрдә ашыгуның зарары юклыгын сөйләде, мин дә кан бәйрәме өчен сайладыгым кызыл галстукны көзгегә карап янә тигезләдем, чыгып киттек. Урамымыздан кичеп мәйданга чыктык. Тупханә мәйданы килен бүлмәсе шикелле җыелган, аллы-гөлле бизәлгән шаһның

[1] Газамәте – бөеклеге.
[2] Әфкярене – фикерләрен.
[3] Нәшергә – таратуга.
[4] Васита – чара.
[5] Ираны нәү – яңа Иран.
[6] Фәүкыльгадәлеген – гадәттән тыш булуын.
[7] Тәшрифат идарәсе – дәүләт протоколы идарәсе.
[8] Ахшамга 3 сәгать калганда, димәк *(Б. Шәрәф иск.)*.

«Алмас капу»дан мәйданга чыгуына каршы «Назмия вә эмния»[1] бинасы тугрысында фәхер капусы (триумфальный арка) ясалган бу капуның башына язылган 4 мисрагътан беренчесене («Шаһ газиме мәҗлис шөдә ба икъбале әбәди»[2]) хәтердә калдыра белдем.

Бөтен мәйданның тирәләре вә уртасы телефон баганалары вә аларның аралары меңтөрле флаглар илә тутырылган; инглиз банкы (Банкы шаһиншаһига) күзем төште. Унар аршын озынлыгында Иран вә инглиз милли флаглары бинаның түбәсеннән йиргәчә төшкән, шәһәрдә иң биек флаглар шунда күренде. Банкның бөтенләй кяшидән[3] эшләнгән дивары да бәйрәм өчен булган бизәкләргә охшап тора. «Лаләзар»га борылдык, уң яктагы почтаханә комач, палас, көзге вә кандилләргә[4] күмелгән. Сул яктагы Хөсәения магазасы[5] (Тәһранның мюрмюрлысыдыр[6]) почтаханәдән калышмаган, магазаның хуҗасы «Әминел-гареб» үзе дә урамда тора икән, сәлам бирде, (банк мөдире янында тугры килеп танышкан идек) мин тәбрик иттем, ул бездә кияүләр җавап бирә торган гыйбарә илә җавап бирде, күзгә карап көлештек, ходахафизлаштык[7] «Мәһзәбел-мәлик» илә дә бу җавапның тәфсыйлатына керешеп сүз озайттык.

Менә пустаханә урамыннан борылдык, урамның һәр ике тарафында флаглар, комачлар, паласлар, кандилләр, көзгеләр... Сул яктагы франса мәктәбе бигрәк тә миллилек күрсәтергә тырышып бизәнгән. Урамның ниһаятендә югары табгының бер тәрәзәсеннән Мозаффаретдин шаһ узучыларны тамаша итеп тора. Иранда «җанлы» диярлек бер рәсем күреп гаҗәпсендем. Хийабаны Зыйллес-солтанга борылдык.

---

[1] Назмия вә эмния – полиция.

[2] Шаһ газиме Мәҗлис шөдә ба икъбале әбәди – шаһ мәңгелек бәхете белән Мәҗлескә юл тотып *(Г. Ханнанова тәрҗ.)*.

[3] [Кяши] (изразцы) – чынаяк мичләр кирпече кеби кирпеч *(Б. Шәрәф иск.)*.

[4] Кандилләргә – шәмдәлләргә.

[5] Магазасы – кибете.

[6] Мюрмюрлысыдыр – кәттәсе, кыйбатлысы.

[7] Ходахафизлаштык – саубуллаштык.

Дошманы Мөхәммәдгали заманында һәм аның илә бер вакытта да мәмләкәтеннән сөрелгән бу нәҗиб[1] шаһзадәнең өйләре бөтен гомеренең тарихына тимсаль ула белер[2].

Бик әгълә[3] вә нечкә зиннәтле өйләр бер дә кызганмыйча харап ителгән, йимерекләре төзәтелмәгән, бүген соң гына элергә башланган комачлар, бу өйдә зиннәт кеби күренми, гаеп өртүгә охшый, ләкин хәрабәләрнең өртеп бетермәячәге хәтта урамнан узучыларны хәвеф ихтималында тотуы да күзгә бәреләдер.

Бу хийабан, уңга борылып Бәһарстан мәйданына чыга; бу мәйдан, тирә-ягындагы йортларның чибәрлеге илә мактана алмаса да, анда түгелгән каннарның күплеге илә мактана алыр.

Мәҗлес бинасының каршындагы бу мәйдан – мәшрутият өчен булган биек мәгърәкәләрнең[4] бередер. Без килгәндә, мәйданнарда урамнарда кеше тулы иде һәр бер фәвеҗ (полк) үзләренә махсус аерым киемнәре вә флаглары илә үзләренә тәгъйин ителгән урыннарга узалар, марш вә музыка тавышы бер дә колактан китми. Һәммә урамнарда вә мәйданнарда. Күк күгәрченнәр кеби өй башына тезелгән мәхлуклар – Иранның тереләй кара кәфенгә төрелгән хатын-кызларыдыр. Алар да күрергә чыкканнар. Иранның ирләре алардан көнләшәләр, «Арватлар[5] һәммә ирәннәре[6] истәдекләре кеби[7] тамаша идәләр, әмма без һичберене таныя белмәез[8]», диләр.

Әгәр Иран хатыннарының хәленә хәсәд[9] кылынса, инсанның хәсәденә чик юктыр.

[«Көлле зи-нигъмәт мәхсүден[10]» дәгелме?]

Мәйданга кердек, гаскәр ике яклап текәмә уларак (шпалиром) тезелгән:

---

[1] Нәҗиб – благородный.
[2] Тимсаль ула белер – гәүдәләнеш була ала.
[3] Әгълә – бик гүзәл.
[4] Мәгърәкәләренең – сугыш урыннарының.
[5] Арватлар – хатыннар.
[6] Ирәннәре – ирләре.
[7] Истәдекләре кеби – теләгәнчә.
[8] Таныя белмәез – таный алмыйбыз.
[9] Хәсәд – көнчелек.
[10] Көлле зи-нигъмәт мәхсүден – Нигъмәт иясе һәр кешедән көнләшәләр.

Урамнан килгәндә, иң элек төрле фәвеждән[1] сәрбазлар[2], соңра казак[3], соңра бәхтиярлар[4], Мәҗлеснең капусында ике яклап мөҗаһидләр, ишек алдында яңа тәнзыйм ителгән[5] вә матур киемле жандарма бүлеге, янә эчтә хәрби «Мәдрәсәи Низамия» таләбәсе[6], мәҗлес бинасының алдында хасса бүлеге[7] вә жандармалар. Капудан кергәндә билетны тикшерделәр, ул вакыт мин капка башын тамаша иттем.

Калкытып «Дареш-шураи миллие Иран» гыйбарәсене каш шикелле әйләндереп вә аның астына беренче Мәҗлескә тарих уларак, «гадле Мозаффар» ләфзыны[8] вә «1324» рәкамыны[9] язмыш.

Мәҗлес хәятындагы[10] бакчаның фәүкальгадә зиннәтләрене вә тамашачыларны тамаша иттекен соңра тәгъйин ителгән урыныма, мөхбирләр[11] ложасына киттем. Билетны янә карап, керергә мөсагадә иттеләр[12], бу ложамда миндән элек килгән кешеләргә янә бирәү артты, икенче рәттән урын ала алмадым. Бу ложада мин таныганнар мөселманнардан башка, инглизчә «Дейли телеграф» мөхбире Базил (әрмән), «Русское слово» мөхбире Агананс (әрмән), Тифлис гәзитәсенең мөхбире Терия (грузин), Одесса гәзитәләренеке Амиражиби (грузин), «Новое время»ныкы Янчевецкий (поляктан чыккан) вә янә берничә аурупалы бар иде. Күрше ложамыз Аурупа сөфәрасының[13] хатыннарына тәхсыйс ителеп[14], алар Иран хатыннары өчен дә җөмлесене тамаша иттеләр.

---

[1] Фәвеждән – төркемнән.

[2] Сәрбазлар – гаскәриләр.

[3] Казак – Иран казак бригадасы күздә тотыла.

[4] Бәхтиярлар – Ирандагы кабиләләр төркеме (биредә ул кабилә вәкилләреннән төзелгән гаскәр төркеме).

[5] Тәнзыйм ителгән – тәртипкә салынган.

[6] Таләбәсе – студентлары.

[7] Хасса бүлеге – гвардия.

[8] Ләфзыны – сүзен.

[9] Рәкамыны – цифрасын.

[10] Хәятындагы – биредә: ишегалдындагы.

[11] Мөхбирләр – корреспондентлар.

[12] Мөсагадә иттеләр – ярдәм иттеләр.

[13] Сөфәрасының – илчеләренең.

[14] Тәхсыйс ителеп – билгеләнеп.

Мәҗлеснең ифтитах[1] көнендә лөзүме[2] булмаганнан залга урындыклар кертелмәгән, 27×12 аршын биеклегендәге озын зал мәсҗедкә охшый, ике тараф дивар биек кыйтгада[3] берәр тәрәзәдән гыйбарәт, залның буенда исә югарырак бер якта – ике ложа, икенче якта – голяма ложасы вә аның алдында тәхте падишаһи[4] вә аңа ике тарафтан менгән баскычлар вә түбәндә – ишекләр. Сәгать бер ярым булганда, депутатлар (хазыйры 68 гадәд[5]) килеп беттеләр, ике саф уларак, залның буена вә тәхеткә каршы тезелделәр, тәхетнең уң ягыннан бачкыч янында ук госманлы сәфире, соңра Германия, Бәлчика[6], Америка, Италия, инглиз вә рус сәфирләре, аларның артларында, уңларында сәфарәт һәйәтенең әгъзалары[7] рәсми вә күбесе явәри киемнәр[8] илә тезелмешләр иде. Җәмгысы[9] 40 ка кариб[10] булганнардыр.

Алар илә вәкилләр арасында әгъян тордылар, болар арасыннан шаһзадә Гайнед-дәүләне таный алдым, агыр бәдәнен күтәрүдә аксак аягына ярдәм өчен залда да таякка мохтаҗ икән. Бер дә фәрманфәрманы[11] күрсәттеләр. Әгъянның әксәре[12] вәзирләр һәм дә депутатларның берничәсе рәсми кием хилгать (халат, чуар чапан) кигәннәр. Садре әгъзам вә хәрбия вәзире булган сипаһдар, залга кергәч тә, депутатларга сәлам биреп вә сүз кушып әйләнде. Бүгенге Иранның каһарманы үзенең 8 нче унда булуына илтифат итмичә, бик йиңел хәрәкәтләнә, аякларыны бер урында ике минут тота алмый «яхшы ат шикелле» баскалый, даимән як-якка карана, сөйләгәндә кулларын бутый. Кыланышына карагапда, үзе 40 яшендә генә булып, төкләре тиешсез агарган кеби күренә, сакалы йиңелчә, йөзе ачык булганнан, картлыгы бер дә

[1] Ифтитах – ачылыш.
[2] Лөзум – тиеш.
[3] Кыйтгада – өлештә.
[4] Тәхте падишаһи – патша (шаһ) тәхете.
[5] Хазыйры 68 гадәд – [Мәҗлестә] булучы 68 кеше.
[6] Бәлчика – Бельгия.
[7] Сәфарәт һәйәтенең әгъзалары – дипломатик корпус әһелләре.
[8] Явәри кием – мундир.
[9] Җәмгысы – барлыгы.
[10] Кариб – якын.
[11] Фәрманфәрманы – генерал-губернаторы.
[12] Әксәре – күпчелеге.

агыр тәэсир бирмидер. Тәхетнең артында голямадан чакырылган кунаклар (29 гадәд) чумашып тезелгәннәр. Тәхетнең сул ягында мөҗаһидләрдән, мәэмүрләрдән һәм дә төҗҗардан «мәҗлес» ихтифаленә[1] чакырылган кунаклар урын алган иделәр.

Сәгать 2 тулганда, хилгатьле вә гадәт муҗибенчә[2] кулында озын таяклы тәшрифат назыйры[3] шаһның килдекен хәбәр бирде. Мәҗлес ишегендәге гаскәри музыка[4] милли марш уйный башлады. Уң күземез тугрысындагы ишекнең фәүкыльгадә уларак ике яртысы да тәмам ачылды, 13 яшьлек шаһиншаһ Әхмәт Мирза, уң тарафында карт наибес-сәлтанә[5] вә суң тарафында бала вәлигаһед[6] Хәсән Мирза, артында шаһзадәләр булдыгы хәлдә залга килеп керде.

## Милләт мәҗлесенең ачылуы

*13 яшьлек шаһиншаһ. Нотык ифтитахы. Атәш бази.*
*Рус музыкасы: Двухглавый орёл.*

13 яшьлек шаһиншаһ Әхмәд Мирза Милләт мәҗлесенең залына килеп кергәч, ньк-ньк басып, алдына тугры вә җөрьәтле карап, тәхет баскычыннан менде, вөкәлягә[7] вә соңра сөфәрага баш ишарәсе илә сәлам бирде. Җәүһәр тәхетнең тугрысына килеп туктады, сул кулы илә кылычына таяныбрак, вә тәмам зур падишаһлар шикелле мәһабәтен саклап бер дә каушамыйча, һәммә хазирунның аңа күз тегүләренә аптырамыйча, аягүрә басып торды. Карт вә садә[8] наибес-сәлтанәны каушаган дип хисап итәргә дәлилләр бар иде. Наибес-сәлтанә нотык ифтитахыны хилгатьнең күкрәк кесәсеннән алып, сипаһдарга бирде. Сипаһдар шаһның сул ягында вә тәхетнең өченче баскычындагы киңлектә

[1] Ихтифаленә – тантанасына.
[2] Гадәт муҗибенчә – гадәт буенча.
[3] Тәшрифат назыйры – протокол хезмәте җитәкчесе.
[4] Музыка – биредә: оркестр.
[5] Наибес-сәлтанә – регент.
[6] Вәлигаһед – тәхет варисы.
[7] Вөкәлягә – вәкилләргә.
[8] Садә – гади.

туктап хотбәне укырга кереште. Бөтен зал тынын чыгармыйча тыңларга бирелде. Шаһның сул ягы тарафыннан төшкән кояш нуры залның уртасынача йитешкән иде.

Хөтбә ифтитахының тәрҗемәсе будыр:

*«Бисмиллаһи Тәгалә шәэнел-газиз.*

*Хөррият багышлаучы Алланың исеме хәзрәте вәли гасырның[1] батыйный тәвәҗҗеһесе илә[2] милләт шурасының мәҗлесе ачыладыр. Иран мәмалике мәхрүсәсе күп карынларны[3] вә хосусан соңгы гасырны камил тынычлык илә кичергән иде. Ахырда тәрбия-и фикриянең икътизасы[4] вә мәдариҗ-е гаклиянең тәрәккыйсы[5] илә милләт инкыйлаб дәүрәсен[6] кичәргә аяк басты. Бу бохран[7] өч ел эчендә ниһаятенә иреште, милләтләрнең тәкямеле[8] өчен лязем булган гакабаты ибтидаияне[9] атлады. Аллага шөкер, хәйрият илә[10] тәмам булды. Бүген бәхтиярлык вә хөсне сәгадәт илә[11] күрәмез ки: милләтнең мәҗлисе мәбгусаны[12] олуг сәлтанәтнең[13] мөбарәк дареш-шурасы[14], милләтнең көчкә тәхәммел итдеке зәхмәтләренең нәтиҗәсе, милләтнең үз һиммәте вә җиһады[15] һәм Иран хәерхаһларының[16] күркәм мөсагадәләре[17] илә ачыладыр. Өмид идәмен ки: мәмалике мәхрүсәнең[18] вәкилләре, мәмләкәтне бу сә-*

[1] Вәли гасырдан морадлары Мәһдидер. Шигыйлар аны даимән терек дип игътикад итәләр *(Б. Шәрәф иск.)*.

[2] Батыйный тәвәҗҗеһесе илә – яшерен ярдәме белән.

[3] Карынларны – гасырларны.

[4] Тәрбияи фикриянең икътизасы – фикри җитлегүнең таләбе.

[5] Мәдариҗе гаклиянең тәрәккыйсы – гакыл дәрәҗәсенең үсеше.

[6] Инкыйлаб дәүрәсен – революция чорын.

[7] Бохран – кризис.

[8] Тәкямеле – үсеше.

[9] Гакабаты ибтидаия – башлангычтагы читен адымнар.

[10] Хәйрият илә – хәере белән.

[11] Бәхтиярлык вә хөсне сәгадәт илә – бәхет һәм шатлык белән.

[12] Мәҗлисе мәбгусаны – депутатлар мәҗлесе.

[13] Сәлтанәтнең – патшалыкның.

[14] Дареш-шурасы – киңәшләшү урыны.

[15] Үз һиммәте вә җиһады – үз тырышлыгы һәм көрәше.

[16] Хәерхаһларының – яхшылык теләүчеләрнең.

[17] Мөсагадәләре – ярдәмнәре.

[18] Мәмалике мәхрүсә – Аллаһы Тәгалә бәла-казалардан саклый торган җирләр (ягъни мөселман өлкәләре). Биредә: Иран дәүләте *(Г. Ханнанова иск.)*.

*гадәткә ирештергән гайрәт вә фәгалияттә*[1] *хөлус*[2] *вә җиддият*[3] *илә дәвам итәрләр. Үзләренең мөкаддәс вазыйфаларыны, даимчелек, ерактан күрү вә гакыйбәтне*[4] *төшенү тарикынча*[5] *күркәм әда итәрләр*[6].

*Минем дәүләтем мәмләкәтне низамга*[7] *салу вә тынычландыру һәм дә мәдәният баскычларында югары күтәрелү хосусында янә дә сәгые бәлигъ*[8] *вә җидде вафи*[9] *(ягъни иҗтиһад) сарыф итәрләр. Шуннан бик мәмнүнмен*[10] *ки: тәрәккыйпәрвәр булган яңа дәүләт милләтнең тәкъдирен үзенә җәлеп итте һәм дә гомуми тынычлык вә әмнияткә*[11] *сәбәб булды. Үз эшләреннән курыккан бәгъзе*[12] *яманнарның кай урыннарда бераз тынычсызлык ясап баш күтәрүләре дә бар; минем дәүләтем аларны арчырга газемен тасмим итмештер*[13]. *Дәүләтләр илә дустанә мөнәсәбәтләремезнең мөстәхкәм*[14] *вә бәркарар*[15] *булуына бик шатмын.*

*Аларның хөсне ниятләре*[16] *яңа рәвешләрнең тиз алга китүе өчен бик яхшы булып, киләчәктә дә бу дустлык истихкямларының*[17] *дәвамына өмидлемен. Харидҗия*[18] *гаскәренең Иран туфрагына керүеннән әһалинең*[19] *күңелене агырлык вә кәефсезлек баскан. Бу бабта*[20] *дустанә мөзакәратның*[21] *гүзәлчә җәрәяны*[22], *ачык вәгъдәләр һәм алардан күрелгән күркәм нәтиҗәләр илә күңелемез камил тынычланадыр*

[1] Фәгалияттә – эшчәнлектә.
[2] Хөлус – ихласлылык.
[3] Җиддият – җитдилек.
[4] Гакыйбәт – эшнең нәтиҗәсе.
[5] Тарикынча – юлы белән.
[6] Әда итәрләр – үтәрләр, башкарырлар.
[7] Низамга – тәртипкә.
[8] Сәгые бәлигъ – күп тырышлык.
[9] Җидде вафи – зур хезмәт.
[10] Мәмнүнмен – шатмын.
[11] Әмнияткә – иминлеккә.
[12] Бәгъзе – кайбер.
[13] Газемен тасмим итмештер – тәвәккәлләгән, катгый карарга килгән.
[14] Мөстәхкәм – нык.
[15] Бәркарар – какшамас.
[16] Хөсне ниятләре – яхшы ниятләре.
[17] Дустлык истихкямларының – дустанә нык бәйләнешләрнең.
[18] Харидҗия – чит ил.
[19] Әһалинең – ил халкының.
[20] Бу бабта – бу хакта.
[21] Мөзакәратның – фикер алышуларның.
[22] Гүзәлчә җәрәяны – матур гына үтүе.

*ки: бу агырлык тиздән күтәрелер. Әсасы исляхатка[1] керешер өчен вә киләчәктә яхшы хөкүмәт тәшкил итәр өчен милләт вәкилләре, дәүләт вәзирләре идарәләрене тәнзыймга[2] вә аларның тәшкилатын[3] мәмалике мөтәмәддинә[4] ысулына муафыйк[5] тәртип итәргә тәкатьләрене[6] сарыф итәрләр.*

*Ашыгыч кирәкле исляхат хосусында һәйәте вөзәрамызның[7] Мәҗлескә тәкъдим итәргә теләдеке програм буенча мәмләкәтнең малия[8] эшләрендәге мөһим исляхатта, назмия вә әмния (полиция вә жандарм)ны тәкмил итүдә[9] безнең яхшы ниятләремезне мөмкин кадәр тизлек илә мәүкыйгы иҗрага куярлар[10]. Бонлар исламият рухына муафыйк булган мәшрутиятнең ныгаюына вә милләтнең тынычлыгына багыйс[11] булыр. Милләт вәкилләренә Алладан муаффәкыять[12] теләп, милләтнең шәүкәт[13], истикълял[14] вә сәгадәте артуны мөтәмәннимен[15]».*

Хотбәне укып бетергәннән соң мөхбирләр[16] ложасыннан башланган кул чабу бер минут эчендә бөтен залга сираять итте[17]. Кул тавышлары туктаганнан соңра, шаһ Әхмәд шәүкәт вә мәһабәте илә залны калдырды. Шаһ Әхмәд Мирза чәһрәсе вә итләчлеге илә атасына охшадыгы хәлдә, Хәсән Мирза нәҗабәтле[18] йөзе һәм дә зифалыгы, ыспай вә җыйнаклыгы илә моңа капма-каршыдыр.

---

[1] Исляхатка – реформаларга.
[2] Тәнзыймга – тәртипкә салуга.
[3] Тәшкилат – бирედә: эшнең оештырылуы, эш башкару рәвеше.
[4] Мәмалике мөтәмәддинә – мәдәни (цивилизацияле) илләр.
[5] Муафыйк – туры килгән.
[6] Тәкать – көч, куәт.
[7] Һәйәте вөзәра – министрлар кабинеты.
[8] Малия – финанс.
[9] Тәкмил итүдә – тәмам итеп бетерүдә.
[10] Мәүкыйгы иҗрага куярлар – җиренә җиткереп башкарырлар.
[11] Багыйс – сәбәп.
[12] Муаффәкыять – уңыш.
[13] Шәүкәт – көч, куәт, бөеклек.
[14] Истикълял – бәйсезлек.
[15] Мөтәмәннимен – өмет итәмен.
[16] Мохбирләр – хәбәрчеләр.
[17] Сираять итте – таралды.
[18] Нәҗабәтле – ак сөякле.

Залдагы әһали акрынлап таралдылар. Бер кыйсеме икенче бүлмәдәге чәй вә ширбәтләрнең тәнавеле[1] илә мәшгуль булды. Нәзмия таләбәсе музыкада милли көйләр уйнап, мәҗлес ифтитахыны[2] тәбрик итеп җырладылар.

Фотографчылар һаман да үз эшләрендә иделәр. Сәгать 3 ярым булды, мин чыгып телеграфханәгә киттем, урамдагы әһалинең шатлыгына чик юк, һәммәсе янындагы кешеләргә үзенең хиссиятен нәкыль кыла[3], музыка бу вакытта аларга бигрәк тә тәэсир иткән шикелле, баручылары һәммәсе аякларын марш көенә басарга маташалар, милләте хакимәләрнең[4] шулай бәйрәм итүләреннән минем күңелемә дә бер куәтле тәэсир кичте.

«Мәҗлес» ачылуны күрер өчен көтеп кичергән көннәремне багышладым. Телеграфханә Туп мәйданында булганнан, шул ук килгән юл илә кайттым. Бөек[5] инглиз флагы җил илә үз агачына чолганган, Мәҗлес ачылганчыгы булган чәһрәсен җуйган иде.

Телеграфханә бәйрәмчә бизәнгән көе үз эшендә дәвам итә. Мәҗлес ачылу хәбәрен дә бу мәктүптән[6] ничә һәфтәләр мөкаддәм[7] укучыларга йитештергән булса кирәк. Янә Бәһарстан мәйданына йитештем. Сипаһдар[8] вә башка вәзирләр хозурында[9] гаскәрләргә рәсме кәчид[10] иҗра кылына[11] иде. Иран гаскәре хосусында махсус мәкалә язачагымнан хәзергә боны тәфсыйл итмим[12]. Кичә Бәһарестан мәйданы йөз меңләрчә тамашачыларны җыеп, «Атәшбази» дидекләре ут уенына мәркәз[13] булды. Меңләрчә фейерверклар күктәге йолдызларга рәкабәт

[1] Тәнавел – татып карау.
[2] Мәҗлес ифтитахыны – мәҗлес ачуны.
[3] Нәкыль кыла – сөйли.
[4] Милләте хакимәләрнең – хаким (хөкем сөрүче) милләт вәкилләренең.
[5] Бөек – зур.
[6] Мәктүп – хат.
[7] Ничә һәфтәләр мөкаддәм – күп атналар элек.
[8] Сипаһдар – гаскәр башлыгы.
[9] Хозурында – янында, алдында.
[10] Рәсме кәчид – парад церемониясе.
[11] Иҗра кылына – үткәрелә, башкарыла.
[12] Тәфсыйл итмим – тәфсилләп язмыйм.
[13] Мәркәз – үзәк.

идәрчәсенә[1] күтәреләләр, сүнәләр, янә башкалары аларның йирен тота, ун мең төмәннәрне[2] кызганмыйча хәзерләнгән бу «Атәшбази[3]» ираниларның ут сөюләрене бөтен көенчә күрсәтә иде. Уттан ясалган һәм төрле «ндә бад... паяндә бад»[4] язулары арыслан, ат, фил, төрле һәйәттә[5] кеше сурәтләре гавамның тәгаҗҗебен гаясенә йиткерә[6], һәртөрле шатлык тавышлары, кул чабулар бер дә киселми. Кичә Банкы шаһиншаһиның бөтен диварлары электрик лампалары илә дунатылган[7], Рус банкының (Банкы истикъразие Иран) бакчасында казаклардан полный оркестр музыка уйный иде. Кич 8 ярым сәгатьтә банк бакчасына барып кердем, бөтен Аурупа колониясе җыелган диярлек, бәйрәм, музыка «Двухглавый орел» ны уйный иде. Үзсенеп, күңел куеп тыңладым. Бу тәәссер[8], белмим, ватанны искә төшерүдән, белмим минем руслашудан булды. Яхуд бу музыка астында кичерелгән кыйммәтле минутларның хатирәсе кинәттән калебтә кузгалдымы? Банкның бинасы вә бакчасында ягылган шәмнәр 400 дән артык иде.

Хазирунга[9] чәй, каһвә вә фрукталар тәкъдим ителә. Иран Мәҗлесе ачылганга шатлык изһар итә[10] иделәр. Музыка тавышлары төн уртасынача ишетелде. Күп йөрүдән аягымның хәле беткәнне бүлмәмә кайтып кергәч кенә сиздем. Мондый чуар бәйрәмне тамаша итәр өчен бер көн ару һич шәй түгел иде.

*Тәһран*

*«Вакыт» газетасы, 1909, 19 сентябрь, 25 сентябрь, 17 октябрь, 20 октябрь, 22 октябрь, 29 октябрь, 3 ноябрь, 7 ноябрь, 10 ноябрь, 12 ноябрь, 19 ноябрь, 24 ноябрь, 28 ноябрь*

[1] Йолдызларга рәкабәт идәрчәсенә – йолдызларга көндәш булырлык, йолдызлар белән чагыштырырлык

[2] Төмән – 10 кыранга тиң Иран тәңкәсе (1917 елга кадәрге курс буенча 1 Иран төмәне 1,5–2 рус тәңкәсенә тиң булган).

[3] Атәшбази – ут уены.

[4] «ндә бад... паяндә бад» – «яшәсен...!».

[5] Һәйәттә – рәвештә, кыяфәттә.

[6] Гавамның тәгаҗҗебен гаясенә йиткерә – гади халыкны соң дәрәҗәдә гаҗәпләндерә.

[7] Дунатылган – җиһазланган.

[8] Тәәссер – тәэсирләнү.

[9] Хазирун – шунда булучылар.

[10] Изһар итә – белдерә.

**Нургали Надиев**[1]

# СӘЯХӘТ ХАТИРӘЛӘРЕ

*1909 ел*

*Бузулук[2], – Самара – Саратов – Мәскәү – Киев – Одесса – Истанбул – Измир – Афина – Искәндәрия[3] – Каһирә – Порт Сәгыйдь – Яффа – Коддес[4] – Бәйрут – Искәндәрүн – Мирсин – Траблис – Салоники[5].*

## I

Бузулук шәһәрендә тыныч кына торганда Мәскәүдә булган сәяхәт комиссиясенең чит җирләргә сәяхәт итәргә теләүче

[1] Нургали Надиев – Надиев Нургали Сибгатулла улы (1882–1940), педагог, дәреслекләр авторы, тәрҗемәче. Аның «Сәяхәт хатирәләре» дигән юлъязмасы 1909 елның 16 маеннан 1 августына кадәр вакыт аралыгында, махсус путевка алып, чит илләрне күреп, сәяхәт итәргә теләгән учительләрдән (укытучылардан) тупланган группа составында, турист буларак, сәяхәте вакытында күргәннәре, тәэсирләре турында. Н.Надиев, үзенең язуынча, Төркиядә, Грециядә, Мисырда, Израильдә, Ливанда була һәм яңадан Төркия аша Россиягә, туган җиренә әйләнеп кайта. Автор үзе күрсәтүенчә һәм путевкада тәкъдим ителгән маршрут бу илләрнең зур порт-шәһәрләрендә: (Одесса, Истанбул, Измир, Афина, Каир, Порт-Сәгыйд, Яффа, Бәйрут, Траблис, Салоники...) тукталып үткәне күренә. Димәк Россия туристлары су юлы белән йөреп, диңгез өстендә дә сәяхәт итеп, бу илләр, бу шәһәрләр белән дә танышалар. Сәяхәтнамә 1915 елда «Шура» журналында басыла башлый, әмма тулысынча түгел. Юлчылар 6 нчы июльдә пароходка утырып Одессадан Төркиягә юл ала. Текст шунда өзелә. Ни сәбәпледер, дәвамы басылмаган. Юлъязманың басылып чыккан кадәр өлешендә, киң мәгълүматлы, этрафлы белемгә ия булган авторның хикәяләү осталыгын, Россиянең төрле шәһәрләрендә сибелеп яшәгән татар халкының XX гасыр башындагы мәдәни, икътисади тормышын сүрәтләвен күрәбез. Авторның милли тарихка, Россия тарихына карашы, фәлсәфи нәтиҗәләр ясавына караганда, Россиядән читтә күгәннәрен тасвирлавы татар укучысы өчен тагын да кызыграк булыр иде. Әмма ни үкенеч ... дәвамы табылмады.

[2] Бузулук – Россиянең Оренбург өлкәсендәге шәһәр, 1934 елга кадәр Самара губернасы составына кергән.

[3] Искәндәрия – Александрия, Мисырдагы шәһәр.

[4] Коддес – Иерусалим шәһәре.

[5] Салоники – Грециядәге шәһәр.

учительләрдән группалар тәшкил кылып ятканын кулыма төшкән бер газетада укыдым. Мөгаллимнәрдән, тынычлыктан, бертөрлелектән бизеп беткән җаныма бу хәбәр кызу дәрт салды. Дәртем күп уйларга бирмәде: сәяхәткә китмәкче булып шул ук көнне бу эшнең артыннан йөри башладым. Мәзкүр комиссия тарафыннан игълан кылынган йөрү тәртипләрен, программа һәм низамнарын[1] таптым. Мәскәү, Одесса, Истанбул, Измир, Афина, Искәндәрия, Каһирә, Порт Сәгыйдь, Яффа, Коддес, Бәйрут, Салоники юлыны ихтияр иттем[2]. Тиешле йөз сум илә бәрабәр ышаныч язуларын комиссиягә бирдем.

1909 ел 16 майда Бузулуктан сәфәргә чыгып 1 августта ватаным (Петровка өязендә) Сөләй авылына кайттым[3]. Ике ай ярым тоташ йөреп, байтак нәрсәләр күрдем, күп тәэсират кичердем. Шул тәэсиратны укучы халык белән уртаклашу өчен, «Сәяхәт хатирәләре» язган һәм дә «Мәгариф» мөдиренә нәшер итәр өчен биргән идем. Ул әфәнде, нәшер итәргә карар кылып, кульязманы алса да бастырмады. Бастырмау гына түгел, кульязманы кайтарып бирмәде: «Югалттым», – диде. Ул турыда күп кәгазьләр буялды, күп каралар түгелде, күп маркалар тәләф булды[4]. Мөдир әфәндегә һичберсе тәэсир итмәде. «Югалттым» вәссәлам! Шулай итеп, нашир әфәнденең мөсаһәләсеннән[5] минем бер еллык хезмәтем әрәм булды. Вакытында хатирәләремне нәшер итә алмадым. Инде караламасын табып, шуны нәшер итәргә карар бирдем. Бәлки укып истифадә итүчеләр[6] булыр. Шуны да әйтеп китим: бу сәяхәт минем өчен бары ике йөз сум торды. Мондый сәяхәтләрне оештыра торган комиссия әле дә бар. Һәр ел яз көннәрендә Мәскәү газеталарында программа вә юл тәртипләрен игълан итәләр. Форсаты бар учитель вә мөгалимнәргә истифадә

[1] Низамнарыны – кагыйдәләрен.

[2] Ихтияр иттем – теләдем, сайладым.

[3] … ватаным (Петровка өязендә) Сөләй авылы ... – Н. Надиев 1882 елның 20 августында Пенза губернасы Петровка өязенә (хәзерге Кузнецк өязе) караган Сөләй авылында туган.

[4] Тәләф булды – әрәмителде.

[5] Мөсаһәләсеннән – игътибарсызлыгыннан.

[6] Истифадә итүчеләр – файдаланучылар.

кылырга тәүсия итәм[1]. Группага керү өчен инспектордан мөгаллимлекне исбат иткән шәһадәтнамә[2], полициядән чит мәмләкәтләргә чыгуны манигъ[3] юклыгына кәгазь генә кирәк.

## II

16 май, иртән сәгать дүртләр. Поездның ачы тавышына күземне ачканда, чиксез-кырыйсыз су буйлап бара идек. «Самар суы» белән «Волга» кушылып, киң диңгез тәшкил иткәннәр. Суның көзге кебек тигезлегенә, сафлыгына кызарып чыгып килгән кояшның шәүкәтенә[4] хәйран булып бару озак дәвам итмәде; кара, күңелсез тимер юл бинаолары җәһәннәм кеби зур, куркыныч деполар, паравозлар, эшчеләр вагон тәрәзәсеннән кылтырап үтә башладылар. Юлчылар багажларын күтәреп чыгу юлын карыйлар иде. Әлбәттә, мин дә калмадым. Багаҗларымны алып Самарага төштем. Самара һәркемгә мәгълүм иң матур шәһәр. Монда нинди юлчы да бераз туктамый булмый. Мин, сәях булгач, бигрәк тә туктaлам.

Самара – Волганың сул кенәрендә[5], «Самар суы»ның кушылган җирендә төзелмеш, яхшы гына, зур гына вилаять шәһәредер. Элек күп заманнар Сембер кеби артмаенча торса да, Себер һәм Ташкент тимер юллары салынгач, тәрәккый итмеш һәм итмәктәдер. Самара – Волга буе шәһәрләренең иң шәп сәүдәлеседер. Тиҗарәт[6] галәмендә крупчаткасы[7], безнең агай-эне арасында «Жигули»е[8] белән мәгъруф булган[9] кеби докторлар, галимнәр, байлары арасында ләтыйф[10] һавасы, әтрафындагы дачалары

[1] Тәүсия итәм – киңәш бирәм.

[2] Шәһадәтнамә – таныклык.

[3] Манигъ – тыю, тоткарлый торган сәбәп.

[4] Шәүкәтенә – көченә, гайрәтенә.

[5] Кенәрендә – ярында.

[6] Тиҗарәт – сәүдә.

[7] Крупчатка – югары сортлы ак бодай оны.

[8] Жигули – Самара шәһәрендә 1881 елда «Жигули» дигән сыра (пиво) заводы төзелә. Россиянең иң борынгы сыра заводларыннан берсе санала. Ул чыгарган продукция – «Жигули» брендлы пиво халыкта, шулай ук татарлар арасында да популярлык казанган була.

[9] Мәгъруф булган – танылган.

[10] Ләтыйф – йомшак.

белән танылмыштыр. Мондагы матур бакчалар, театрлар яңа стильдә салынган биналар, кайнап торган урамнар һәм магазиннар бу шәһәрне Европа шәһәрләре арасына кертергә хаклылардыр. Самараның йөз илле мең тирәсендә булган әһалисе[1] руслар вә еврейләр, немецлар, әрмәннәр һәм татарлардан гыйбарәттер. Сүзләргә караганда, монда өч-дүрт мең мөселман бар имеш. Ләкин алар шәһәрнең төрле мәхәлләләрендә торганга, икътисады бик түбән булганга, меңәрдән гыйбарәт булган җәмәгате миллияне күрсәтерлек бер әсәр, гомумән алганда, күренмидер. Монда татарлар барлыгына ышану өчен мотлакан[2] мәсҗед янына барырга кирәк.

Урамдагы беренче мәсҗеднең ишегалдына кергәндә, баскычка, койма буена утырышкан чалмалы, яулыклы, тәсбихлы вә тәсбихсыз хәерчеләрне, муенына сөлгесен ураган шәкертләрне күреп, бу йортның мөселман мөәссәсе[3] булуын аңлап була. Беренче мәсҗеднең ярыйсы гына чибәр генә манарасызлыктан башка гаебе күренми. Мәсҗеднең асты – мәдрәсә. Мәшһүр Шиһабеддин хәзрәт мәдрәсәсе. Бу мәхәлләнең икенче имамы – «Икътисад» журналының[4] мөхәррире, нашире мелла Фатыйх әфәнде Мортазиндыр[5].

Камил вәкарь белән үзләренең өлешләрен көтеп торучы хәерчеләрдән ишек сорап мәдрәсәгә кердем. Безнең мәдрәсәләр инде кайда да бертөсле: караңгы гына. Әрле-бирле буталып йөрүче берничә шәкертнең ишарәләре саясендә[6], үзебезчә генә, тәкәллефсез генә бер бүлмәгә кердем. Мөхтәрәм Фатыйх әфәнде утыра иде. Тик утырмый, җомга җиткәнгә карамый һаман яза. Ул хакыйкатән ачык фикерле. Заманның сөрешен, халыкның хаҗәтләрен аңлаучан, тугры, файдалы хәят юллары күрсәтеп һәркемгә

---

[1] Әһалисе – халкы.

[2] Мотлакан – ничек тә булса.

[3] Мөәссәсе – бинасы, корылмасы.

[4] «Икътисад» журналы ... – Самарада 1908–1913 елларда барлыгы 55 сан чыккан айлык журнал. Анда сәүдә, сәнәгать, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре яктыртылган.

[5] Фатыйх әфәнде Мортазин... – Мортазин Фатыйх (1875–1937), мулла, «Икътисад» журналы мөхәррире һәм нашире.

[6] Саясендә – ярдәмендә.

ярдәм итүчән, хәмиятьле[1], гайрәтле бер хәзрәттер. Аның иҗтиһады[2] ярдәмендә Самарада җәмгыяте хәйрия ачылды. «Икътисад» журналы дәвам итә (тәәссефкә[3], болар икесе дә хәзер сүнделәр). Самарага барып, бу мәсҗедне, аның мөдәррисе вә мулласын күреп киткән кеше бу шәһәргә тагы бер мәсҗед, мелла вә мәзин кирәк булыр дип фикеренә дә кертми. Шул барлары халыкның дини ихтияҗын үтәргә бик җиткән дип уйлый. Мин дә шулай уйладым. Ләкин бу халык мәсҗед арттыру хәстәлегенә мөбталя[4] булган иде. Узгынчы бер кешенең кирәксенмәвенә карап кына тукталмаслар: беренче мәхәлләдән башка монда дәхи башка мәхәлләләр дә бар. Боларның санын өзеп әйтеп тә булмый. Чөнки шәһәргә бер ишан очкыны тәшриф боерса[5], бер таифә[6] халык аерылып үзләренә мәхәллә тәшкил кылу гадәт хөкеменә кермеш. (Соңгы елларда ихтиляф[7] кимеде диләр. Чөнки өченче мәсҗедне имам үзе белән авылына алып киткән. Икенче мәхәлләдә гүзәл мәсҗед санынып ята. Самарадагы мәсҗед хәстәлеге шаять шуның белән бетсә кирәк.)

Җомга мөнәсәбәте белән мәсҗед тирәсендә булган хәрәкәт Фатыйх әфәнде яныннан шатланып чыккан күңелемә бик ачы тәәссеф[8] салды.

Самара кеби сәүдә вә хезмәт шәһәрендә, Волга буенда, тормыш кайнып торганда, мөселман кардәшләремнең хәергә кул сузулары шанлы вә мазыйлы[9] милләтебез өстендә кара тап кеби күңелемә урнашты. Тәәсефләр белән башымны салып, шәһәр буена татар хәятене эзләргә киттем. Бәгъзе адәмнәр белән мөсахәбәдә булдым[10]. Аңлашылды ки, агай-эненең тормышы гаять пәришан[11] хәлдәдер. Кеше төсле эш күрүче берничә

[1] Хәмиятьле – кешеләрне яклаучы, зарар килүдән саклаучы.
[2] Иҗтиһады – тырышлыгы.
[3] Тәәссефкә – кызганычка каршы.
[4] Мөбталя – дучар.
[5] Тәшриф боерса – килсә.
[6] Таифә – төркем.
[7] Ихтиляф – үзара килешмәүчәнлек, каршылык.
[8] Тәәссеф – кайгы, ачыну.
[9] Шанлы вә мазыйлы – үткәне данлы булган.
[10] Мөсахәбәдә булдым – сөйләштем.
[11] Пәришан – таркау, начар.

подвалчыдан, бер комиссионердан башка кулга алырлык бер адәм дә юктыр. Талчукта, Троицки базарда иске-москычы, яшелчәләр күтәреп йөрүче татарлар күп. Ләкин аларда шатланырлык бер нәрсә күренми. Шуның өстенә исерек ломовойларны, йөкчеләрне кушсак, Волга буендагы читек-кәвеш кибетенә һәм пычрак харчевняларына кереп чыксак, Самара мөселманнарының хәятене тәмам күздән кичергән булабыз.

Самара татарлары яшьләрне хөкүмәт мәктәпләрендә укырга тиеш дигән заһир[1] хакыйкатьне игъзаз итү[2] дәрәҗәсенә китмәгән, ирләр вә кызлар өчен низамлы[3] милли мәктәпләрне кирәксенмәгән әле (Соңгы елларда мөхтәрәм меллаларның тәшәббесе саясендә[4] ирләр вә кызлар өчен шәһәр идарәсе тарафыннан русско-татарский школалар ачылды. Ана теле дәресләре һәм тәэмин ителде. Бу хатирәләр язылгач булган бу үзгәрешкә мәмнүн булмаска мөмкин түгел. Башка шәһәрләргә үрнәк булырлык мондый мөһим эшне вөҗүдкә чыгартучы затларга самими тәшәккер итәм[5]). Йөрисен йөреп, күрәсен күргәнемчә күп вакыт үтте.

Император Александр Икенченең[6] һәйкәле каршында, аның шәрәфенә куелган, кул изәвенең мәгънәсен аңларга тырышып басып торганда, «Самолет»ның[7] беренче боргысы[8] булды. Тәэсиратем таралды, чәчәкләр арасында, чәчәкләрдән дә матуррак, уйнап торган балалар арасыннан үтеп китмәкче булдым. Бу балаларның рухлылыкларына, шат күңеллелекләренә хәйран булып, тукталырга мәҗбүр булдым. Хәят! Менә ичмасам хәят, менә болар яхшырак яшәячәкләр, дип торганда, үзебезнең милли киемдә, өстенә караганда, кызганырлык бер кыз бала кулын сузып: «Әй абзый, сәдака рәхим ит әле...», – диде. Башыма таш

---

[1] Заһир – ачык.

[2] Игъзаз итү – хөрмәтләү, тану.

[3] Низамлы – тәртипле, законлы.

[4] Тәшәббесе саясендә – инициативасы белән.

[5] Самими тәшәккер итәм – чын күңелдән рәхмәт әйтәм.

[6] Император Александр Икенче... – Александр Николаевич Романов (1818–1881), 1855–1881 елларда Россия империясе императоры.

[7] «Самолет» – ул чорларда Иделдә йөргән пароходлар ширкәте исеме. Биредә: «Самолет» ширкәте пароходы мәгънәсендә.

[8] Боргысы – пароход гудогы (кычкыртуы).

илә орган кеби булды. «Мин бай түгел», – дидем дә киттем. Ләкин хәятнең бу күренеше күңелемнән һич китәсе юк. Менә безнең башкаларга мөнәсәбәтебез ни рәвештә! Ашыгып пароходка төштем. Багажларымны алып, пароходка кереп урнаштым. Конторда, пароходта халыкның буталуына чама юк.

Волгада йөргән кешеләр моны үзләре беләләр. Әмма йөрмәгән, күрмәгән кешеләргә мондагы хәятне тасвир итү күп кәгазь өстенә хосусый осталыкка да тәүкыйф кыладыр[1]. Шуның өчен тасвир кыла алмыйм. Фәкать без монда да юк; монда без хәммаль[2], без бурлак.

Пароходта өченче класста берничә казанлы сәүдәгәр, дүртенче класста Әстерханга, Бакуга баручылар арасында ике мелла бар. Мәхәллә кешеләренә кунакка баралар. Халыкның буталуына карамыйча, калай чәйнек янына идәнгә утырганнар. Ясаган стаканнары суынып беткән; меллалар моназара[3] кылышалар: берәүнең үзе сәламәт вакытта кабер урыны билгеләве дөресме, юкмы? Беркадәр халык җыелган. Хәзрәтләрнең «гыйлемлек»ләренә хәйран калып торалар!..

Пароход кузгалды. Багажларымны өченче класста җирләштереп, чәй эчә башладым. Каршымдагы урынга шома гына, русча киелгән бер егет килеп-килеп йөреде. Әтрафта булган буталуга һәм миңа һич илтифат итмәенчә, кулындагы рус газетасыннан күзен алмый иде. Никтер бу «рус» минем дикъкатьне җәлеп итте. Ләкин озак вакыт сөйләшергә җаен чыгара алмадым. Чәйдән соң югары палубага чыктым. Кояш офыкка якынлаша. Су өсте күзгә кебек тигез, Волга чиксез таралган. Аккош кебек матур юлчы пароходлар, өчәр-дүртәр баржа таккан йөк пароходлары суның тигезлеген бозалар. Аларның тәгәрмәчләренең тигез сугулары үзәккә үтә торган боргылары моннан йөз ел элек монда булган сөкүнәтне[4] бетерәләр. Волгага шагыйранә хәят бирәләр. Юлчылар да, шәһәрләр дә, авыллар да изелеп торуларын онызталар, саф һава белән иркенрәк сулыйлар, бер-берләре белән

[1] Тәүкыйф кыладыр – мәҗбүр итә.
[2] Хәммаль – күтәреп йөк ташучы.
[3] Моназара – бәхәс, полемика.
[4] Сөкүнәтне – тынлыкны, тынычлыкны.

аркадашланалар[1]. Без дә Волганың шигърияте сизәбез, Волгада йөрергә бик яратабыз. Ләкин аның базарлыгын һич тәкъдир итә[2] алмыйбыз. Бу бит – Русия мәмләкәтенең өч меңнән артык чакрымга сузылган базары вә миллионнарча халыкның мәнбәгъ хәятедер[3]. Әллә ничә миллион сумнар белән төзелгән ширкәтләр, заводлар, пароходлар шул Волга аркасында миллионнар казанган кеби, «Спас» вә «Ослан»[4] мужиклары да кечкенә генә пароходлары, баржалары белән меңнәр табалар. Өч-дүрт ел укып кына әллә никадәр егетләр пароходларда эшләп хәятләрене тәэмин итәләр. Без исә юл йөрүнең уңайлыгына канәгатьләнеп, Алланың бу зур бүләге белән файдаланырга мөмкинлекне уебызга да кертмибез. Без пароходчылыкны, фабрикачылыкны, иген сәүдәсен башка милләткә махсус дип беләбез. Идел буенда лимон, апельсин, башмак кеби вак-төяк сатудан артмыйбыз. Сәбәбе нидер? Белем юкмы, акча юкмы? Спас мужигының да, Ослан калын корсагының да әллә никадәр белеме юк инде. Аларда табылган акча бездә дә табылыр иде. Әлхасыйль, «Идел буе татарлары» исемен тагып йөрсәк тә, йөрәксезлегебез, гайрәтсезлегебез аркасында Иделебезне чит күрәбез, мөмкин булган кадәр файдаланмыйбыз, язык!

Менә шул уйлар Волганың шагыйранә манзарасыннан алынган тәэсиратымны себереп ташладылар, башымны өеп урыныма кайттым. Пароход яктыртылган, кулыма газета алып югары урынга мендем, укый башладым. Теге «рус» егете, корзинасын ачып, мондалинасын чыгарды. Күңелем газетадан бизде. Егетнең уйнавын көтә башладым. Колакларыма ышана алмадым, сикереп тордым; егет «Баламишкин»ны чала башлады. Сикереп төштем, син, иптәш, татармыни, дидем. «Әлхәмдүлиллә, татар углы татармын», – диде. Сөйләшеп киттек. Милләтне кайгыртып, авызыбыздан күп сөремнәр чыкты. Ул әфәнде бер мөгаллим икән. Озак сөйләшкәч, ерак түгел бер урында ятып китап укып килгән ак күлмәкле – штанлы урта яшьтәге бер татар ки-

[1] Аркадашланалар – танышалар, дуслашалар.
[2] Тәкъдир итә – таный.
[3] Мәнбәгъ хәятедер – тормыш чыганагы.
[4] «Спас» вә «Ослан» – Идел елгасы ярында Казаннан түбәнрәк урнашкан пристаньнар.

леп: «Менә шул, әфәнделәр, безне дә бик сүгәргә ярамый. Сез икәвегез мөгаллимнәр икәнсез, милләтебезнең кадерле, алдынгы кешеләре. Таныштыгыз, сөйләштегез. Ә бу шайтан думбырасы булмаса, сез моннан мәхрүм идегез; сезне һәм безне болай аерган нәрсә бер генә бит; башыгыздагы эшләпәләрегез, киемнәрегезгә һич сүзем юк. Хәзер заман шулай инде. Мин аңа каршы килмим, балаларым да шулай киенәләр, ләкин болай да бер-беребез белән берләшергә яратмаган халыкка эшләпә белән милләтне каплау бер дә ярамый инде», – диде.

Без дә бу адәмнең сүзендә беркадәр тугрылык барлыгын танырга мәҗбүр булдык. Озак сөйләшкәч, йокыга киттек. Ләкин озак та үтмәде пароход эчендә булган фәүкылгадә[1] куркынычлы бер тавышка бөтен халык сикерешеп тордылар вә нишләргә белми йөгерешә башладылар; ачы тавыш белән: «Пожар, пороход яна», – дип кычкырдылар. Ишеккә йөгереп бардым, матрослар җибәрмиләр. Дүртенче класстан төтен исе килә, матрослар су сибәләр. Капитан һәм помощниклары: «Һич хәтәр юк, курыкмагыз», – дип, халыкны тынычландырып йөриләр. Шулай да төрле почмактан хатын-кыз еглаган тавыш килә. Бу вакыйгадан соң халык озак көлешеп-көлешеп сөйләштеләр. Без дә мөгаллим әфәнде белән йоклый алмадык.

Таң атты. Волга кичә генә ничә өлеш матур иде. Һинд ысулында булачак дарелфөнүне[2] белән мәшһүр «Хвалын» шәһәренә җиттек. Бу бик кечкенә, тиҗарәтсез[3], шулай да алмасы белән фруктачылары, Минһаҗ Һиндиләре[4] белөн байлар арасында

[1] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

[2] Дарелфөнүне – университеты.

[3] Тиҗарәт – сәүдә, алыш-биреш.

[4] Минһаҗ Һиндиләре – Һиндстанда укып каткан Һинди Минһаҗ кушаматлы кеше – Минһаҗетдин Йосыф улы Кадермәтов (1871–1925). Бу кеше, Һиндстанда укып кайтып, Саратов губернасы Хвалын шәһәрендә Һиндстан мәдрәсәләре тибында югары уку йорты (университет) салдырам дип, халыктан акча җыйный. Әмма ул акчаны үз кирәгенә тотып бетерә. Бу турыда «Казан мөхбире», 1906, 21 июль санында да хәбәр басыла; «Яшен»нең 1908 елгы 1нче (3 август) санында мондый рәсем урнаштырылган: тау башындагы шәһәр уртасында колонналы зур бина. Аның уртасында Һинди Минһаҗның фәс кигән башы калкып тора. Аска: «Хвалынский тавы башында Минһаҗетдин Йосыф тарафыннан салынган университет», дип язылган.

мәшһүр. Монда беркадәр татарлар да торалар. Мәсҗед, әлбәттә, мелла кеби нәрсәләре лә бардыр. Ләкин ибтидаи[1] мәктәп ачып балаларны укыту, ни дарелфөнүнгә бирүдән ерак торалар. (Бу хәтирәләр язылгач, монда һәм школа ачылды). Дарелфөнүн мөдәррисләр чыгаргач, һинд ысулында мәктәп ачарга теләп торулары ишетелә. Ул вакыт дарелфөнүнгә нигез салалар дип сөйләделәр. Ләкин пароход өч кенә минут торганга, барып күрү мөмкин булмады. Инде дәресханәләрен барып күрергә Алла насыйп итсен иде.

## III
## Саратов (Сары тау)

Майның 17 көне аерым рәвештә матур; кояш ифрат нурлы, һавада акрынлык, су өстендә тигезлек. Юлчыларның кәеф-хәтерләре тасвирлаудан өстен иде. Каршыда, тау битендә, Волга буе шәһәренең иң гүзәле – Саратов киңәеп ята. Волгадан аерылуыма күңелсезләнебрәк кенә, мин дә башкалар белән пароходтан төштем. Хәер, инде Саратовтан түбән Волга урта агымындагы матурлыкны югалта. Урманнар, таулар бетә. Киң сахра эчендә киң су юлы гына кала. Идел буенда шул Самарадагы шикелле үк хәят. Төрле милләт халыклары йөриләр; эшлиләр, баш-башка бәреләләр. Без, әлбәттә, монда да юк. Фәкать кайнап торган халык арасында башларына киез эшләпә кигән өч-дүрт мишәр. Аларның комач күлмәк кигән, француз яулык өстеннән җылы шәл белән авызларына кадәр томаланган хатыннары, өзгәләнгән-ерткаланган бала-чагалары. Алама-шаламаларын күтәреп, пароходка керергә торалар. Болар – безнең якташлар. Авылда бурлак булып, боярдан боярга йөреп изелеп беткәч, түгелеп калган бәхет очрамасмы дип, «Саричин»га[2] җиңел тормыш эзләп баралар.

Саратовның үзендә ике меңләп татар хисапланадыр. Ләкин тормышлары, Самарадагы шикелле үк пәришан[3]. «Безнең Сара-

[1] Ибтидаи – башлангыч.
[2] Саричин – Иделнең түбән агымында урнашкан Царицын, хәзерге Волгоград шәһәре.
[3] Пәришан – начар.

товта шулай, безнең Саратовта болай», – дип мактанырлык бер нәрсә генә дә юк. Монда да ике меңләп булган җәмәгате исламиянең тимсале мөҗәссәме[1] булган мәсҗед янына баргач кына, даими торучы татарларның барлыгына ышанасың. Шәһәренә мөнасиб[2] гүзәл мәсҗедләре, аның янында өч тәрәзәле мәктәпләре – Саратов татарларының дини, иҗтимагый, мәдәни таянычларыдыр. Мәсҗед хозурында ахунд мелла Мөхәммәдҗан хәзрәт илә ачык фикерле, киң мәгълүматлы мәхдүме Зиятдин әфәнде вазифаларын бик яхшы башкаралар. Бу ике мөхтәрәм зат агай-эне арасында нөфүзле[3], игътибарлы булу өстенә рәсми даирәләрдә дә бик мәкъбүлләр[4]. Җәмәгать эшләре бик пәришан хәлдә исә, ул берлек юклыктандыр. Монда халык әллә ничә горуһка бүленгән. Горуһланырга сәбәп исә һаман шул ишанлыктыр. Монда ишанлыкта дүрт силсилә тартыша: Кизләү, Нижгород, Зимничә һәм Сафарка мөридләре. Болар бер-берсенә ут белән су кеби мөнәсәбәттәләрдер.

Хөкүмәт мәктәпләренә керү һич юк диярлек (соңгы елларда булгалый башлады. Мелла Мөхәммәдҗан хәзрәтнең бер мәхдүме Саратов университетына, икенче Реальный мәктәпкә кереп, укуларын иҗтиһад илә, мөдавәмәт итәләр[5]). Мелла Зиатдин әфәнденең иҗтиһады саясендә[6] русско-татарский мәктәп ачылды. Моннан халык яхшы истифадә итәләр[7]. Шунда да халыкны күндерү өчен, балаларга аш, кием бирү кебек чараларга мөрәҗәгать итү лязем булган диләр. Саратов татарларының күбрәге халатчы, бик азы кибетче, беразы үләксәче. Бу шәһәрдә татар урамында «үләксә биржасы» дигән бер почмак бар. Монда һәрвакыт бер төркем халык утыра. Ат үлү, зыянлану булса, шунда йөгерәләр. Әлеге утыручыларны барып алалар да атны суялар. Табигый хатыннарга эш, гаиләгә аш була.

[1] Тимсале мөҗәссәме – гәүдәләндерелгән сурәте.
[2] Мөнасиб – яраклы, туры килгән.
[3] Нөфүзле – абруйлы.
[4] Мәкъбүлләр – яхшы яктан гына танылганнар.
[5] Иҗтиһад илә, мөдавәмәт итәләр – тырышып дәвам итәләр.
[6] Иҗтиһады саясендә – тырышлыгы белән.
[7] Истифадә итәләр – файдаланалар.

Саратов халкы, бик аз гына яшьләрдән башкалары, барысы да йөз ел элек булган кеби уйлыйлар, яшиләр, күз алдында булган хәятне, тәрәккый вә тәкәммелне[1] күрергә теләмиләр. Тәкъдир боларга «пәйгамбәр» дә җибәреп карады, ләкин хәерле нәтиҗә чыкмады. Менә шулар арасына кереп, милләткә хезмәт итәм дип кара әле, ни эшләрсең икән?

Саратов вилаятенең Петровский, Кузницкий, Хвалын һәм Вольски өязләрендә йөз меңләп мишәрләр торалар. Боларны бәгъзе мөэррихләребез[2] мищера, мордваларга нисбәт итсәләр дә, мин бу фикерне хата дим. Минемчә, бу мишәрләр Сарайда хөкүмәт сөргән татар урдасыннан, Казаннан таралмыш татарлардыр. Бу фикеремне исбатка дәлилләр дә бар. Ләкин монда урыны түгел. Мондагы татарлар зур-зур авыллар булып утырганнар. Башлыча кәсепләре игенчелек, көн күрешләре авыр. Тормышлары кара. Моннан унбиш ел элек мишәрләрдә искечә дә, яңача да уку юк иде. Соңгы унбиш ел эчендә һәр авылда икешәр-өчәр мәктәп ачылды. Ысулы җәдид белән укытыла.

Ысулы җәдид мәрхүм Ишмөхәммәд хаҗи Дибирдиев һиммәте саясендә[3] мишәр авылларында һич ихтиляфсыз[4] кабул ителде.

Кузнецкий өязендә Пилдәнге, Троя, Биги һәм Колчура авыллары башка мишәр авылларыннан күп мөмтазлардыр[5]. Бу авыллар үткерлек, сәүдәгәрлек, мөгамәләгә осталык белән әтрафтагы рус авылларыннан икътисадый һәм мәдәни югарылардыр. Пилдәнге борынрак мәдрәсәсе, әтрафның тарикать мәркәзе[6] булу һәм сукно фабрикалары белән мәшһүр иде. Шуның өстенә мәрхүм Ишмөхәммәд хаҗи һәм Йосыф хаҗи саясендә бу авыл ысулы җәдиднең дә мәркәзе булды. Хәзер исә фабрикаларның күбесе бетте, мәдрәсәләрнең кирпечләре дә калмады. Ләкин Пилдәнгедә беткән фабрикалар урынына аннан унбиш чакрым җирдә Кадады (Кодады) суы буенда гаять зур, гаять монтазам[7] меңгә

---

[1] Тәрәккый вә тәкәммелне – алга китү (прогресс) һәм үсешне.
[2] Мөэррихләребез – тарихчыларыбыз.
[3] Һиммәте саясендә – тырышлыгы ярдәмендә.
[4] Ихтиляфсыз – каршылыксыз.
[5] Мөмтазлардыр – өстәнрәкләр.
[6] Тарикать мәркәзе – дини, рухани үзәге.
[7] Монтазам – тәртипкә салынган.

якын эшчеле сукно фабрикасы туды. Бу фабрика, Ишмөхәммәд хаҗи Дибирдиев тәэсис иткән[1], «Ишмөхәммәд Дибирдиев ширкәте» милкендә булып, хәзер Йосыф хаҗи Әмин углы Дибирдиевнең тасрифындадыр[2]. Бу фабрика иң соңгы ысул машиналары, аппаратлары белән төрле сорт сукно эшләп чыгара. Аның биек морҗалары, җәһәннәм кадәр корпуслары, яхшы, җыйнаклы фасадта салынган өйләре ерактан күренә. Моны күргәндә ихтыярсыз көлеп җибәрәсең, күңел шатлана.

Менә бу утыз ел элек караңгы урманнан гыйбарәт комлык җирләрне Самарадагы «хәер»гә кулын сузган кызчыкның, чалмалыларның «надан» бабалары, бәлки йөз меңләп халкына хәят чишмәсе ясаганнар, моны мәрхүм Габделмәннан бабай бик кечкенә итеп тәэсис иткән, кул станоклары белән сукно эшләткән. Ишмөхәммәд хаҗи аны зурайткан, паровой машиналар белән җиһазлаган. Мәрхүм Мәхмүд бай Дибирдиев үз осталыгы, тырышлыгы белән иң яңа ысул машиналар куйдырган, турбиналар ясаткан, электрик белән яктырткан. Мәрхүм Әхмәтҗан хаҗи да фабриканың тәрәккыйсына күп хезмәт итте. Инде бу мөхтәрәм затлар фабриканы мөкәммәлләштереп, дөньядан аерылдылар. Алланың рәхмәтендә булсыннар! Аларның эшен, сәләфләренән[3] артык итеп, Йосыф хаҗи идарә итмәктәдер. Аның угыллары гүзәл тәрбияле, гали мәгълүматлы булып, гамәли сурәттә фабрика эшләре белән танышып үскәнгә, бу мөәссәснең[4] күп дәверләр безнеке (мөселманныкы) булып торуына өмидем камилдер.

## IV
## Мәскәү

1 июнь. Иртә сәгать алтылар. Ачы свистокка башымны күтәрдем; кояш чыгып аз гына күтәрелгән. Урманнар, бакчалар, кызлар кеби зиннәтле киенеп, кояшның шәүкәтенә[5] хәйран

[1] Тәэсис иткән – төзегән, корган.
[2] Тасрифындадыр – үзгәртүендә (үзгәрткән) мәгънәсендә.
[3] Сәләфләренән – элгәреләреннән.
[4] Мөәссәснең – бинаның (фабриканың мәгънәсендә).
[5] Шәүкәтенә – көченә, куәтенә.

калып торалар. Урман эчендә тимер юл буена салынган матур, гаять матур дачалар; җәйнеңләтыйф һавасы белән файдаланып, чәчәкләр арасында чәчәк кебек яшүсмерчекләр җәннәтне тәмсил итмәктә иделәр[1]. Вакыйган, шикләнеп китәсең: «Бу урын җәннәт түгелме?» – дисең. Бу дачаларда кайгы да, тынычсызлык та юктыр, дип уйлыйсың. Барган саен дачалар күбәя, матурая. Чакрым саен дачный поездлар очрый. Сылу, матур егетләр, май күбәләге кеби матур кызлар станцияләрдә бер-берсе белән күрешәләр, шатланышалар, көлешәләр, култыклашып китәләр. Бу урыннан Мәскәүнең сәгадәт почмагы: монда халык эшсез, тыныч, шат, киенгән. Һәркем уйнак.

Мин милләтчелегем белән монда да «үзебезнекеләрне» эзлим. Эзләгәч табыла: башына кечкенә Казан бүреге кигән кучерлар, казаки өстенә ак алъяпкыч бәйләгән сторожлар еш кына күренеп калалар. Безнең кеби садәдилләргә[2] шул да җитә кала: «Кара син, агай-энеләр кайда торалар... Монысы да ярый бит», – дип уйлыйсың.

Кинәт урманнар, дачалар бетте. Каршыда гаять зур күренешле биналар. Аларның күккә чыккан морҗалары күренә. Ачы тавышлы свистоклары дөньяны гөрелдәтеп, әйләнеп яткан машиналар тавышы гына ишетелә. Бу икенче галәм: монда әгъла[3] фәйтуннар урынына күмер вә тимер ташый торган тачкалар, дачалардагы күбәләк кеби матур егетләр вә туташлар урынына тачкага җигелгән, күмергә капланган адәм балалары күренә. Дачалардагы сәламләшү урынына монда кабахәт сүзләр илә сүгенүләр генә ишетелә. Монда һавада май, күмер, төтен вә тимер исе генә килә. Ләкин бу төтен, нефть галәме белән теге дачалар, «күбәләкләр» арасында әллә нинди бер мөнәсәбәт сизелә. Төтенләп, морҗалары гөрелдәп торган фабрик вә заводлары булган милләтнең дачалары, чәчәкләре һәм матурлары да була.

Фабрик вә завод корпуслары, морҗалары арасында Мәскәүнең чиркәү гөмбәзләре кояшка каршы ялтырый башлады. Берничә минуттан соң мин моннан мең ел элек барлыкка килгән

[1] Тәмсил итмәктә иделәр – хәтерләтә иделәр.
[2] Садәдил – эчкерсез, саф күңелле.
[3] Әгъла – бик затлы.

безнең милли-мәдәни тарихыбызга күп мөнәсәбәте булган Мәскәүдә булам.

«Рязанский» вокзалга килеп төштек. Вокзал зур. Ләкин башка имтиязы[1] юк, Пайтәхетлек[2] бер дә күренми. Ишек катында ике якка сафка тезелгән лакейлар: «Номерлар илле тиеннән биш сумга, ун сумгача, трамвай янында, биржа янында, шәһәр уртасында», – дип кычкырып торалар. Берсенең карточкасын алып, саквояжымны бирдем. Трамвайга утырып, Милютинский тыкрыгына «Родина» номерларына төштем. Вокзалда илле тиенлек номерлар бар, дип кычкыручы лакейым хәзер, ике сумнан очсызлы номерлар буш түгел, дия башлады. Тартышып-талашып, бер номер алдым. Самавыр китергәнне көтеп торганда, тәрәзәне ачып, урамга күз салдым: көн болытлаган, яңгыр сибәләп тора. Шулай да урамда халык – баш башка бәрелә. Һәркем каядыр ашыга, һәркем үз эшенә бара: мәэмүрләр[3] – мәхкәмәләренә, шәкертләр – мәктәпләренә, читтән килгән мөгаллимнәр вә мөгаллимәләр – курсларына, сәүдәгәрләр – магазиннарга, конторларга баралар. Вагоннар, автомобильләр, әгъла фәйтуннар выж-выж үтеп китәләр. Әлхасыйль, хәят кайнап тора. Шалтыр-шолтыр бутылкалар белән сыра, куас ташучы татар килеп чыга да, икенче яктан, дворник татар берлә очрашалар, сәламләшәләр, сөйләшәләр, көлешәләр. Ахрысы болар да мәсгудләрдер[4]. Күз алдындагын тамаша кылып бетермәгән әле син, әллә кайдан «шурум-бурум, старьё берём» тавышы ишетелә. Күп вакыт үтми кызыл ыштаннан, казакиының чабуларын ачкан, җылы тупый бүреген маңгаена гына салган, кулына иске-моски чалбарлар, күлмәкләр салган агай-эне килеп чыга. Бу кешенең «гайрәтенә» бик ачуым килде. Сәүдәсенә бәрәкәт теләп, тәрәзәмне яптым.

Чәй эчкәч, «Образовательный экскурсия» комиссиясенә киттем. Бу бер контора. Монда Мәскәүнең фидаи[5] галимнәре, җәмәгать хәдимнәре эшлиләр. Болар хезмәтләре өчен матди

---

[1] Имтиязы – башкалардан аерылып торуы, өстенлеге.

[2] Пайтәхетлек – башкаларга хас булу.

[3] Мәэмүрләр – чиновниклар.

[4] Мәсгудләрдер – бәхетлеләрдер.

[5] Фидаи – фидакяр.

һич файда өмет итмичә, идеалларына хезмәт итү шәрәфе белән мәсгудтер. Графиня Бобринская кеби олуг фамилияле ханымнар, мөгаллимәләр, профессорлар. Авыл мөгаллим вә мөгаллимәләре белән бик самими сөйләшәләр. Барачак юлларында кирәкле булган киңәшләр бирәләр. Бу конторага аяк баскан кеше анда кемне дә чит күрми, аны һәм чит күрмиләр.

Сәяхәтләр өчен хәзерләнмеш урыннар барлыгын белеп, тиешле кәгазьне алып, номерыма кайттым. Мин номердан китмәкче булгач, яныма өч-дүрт кеше кереп: «Барин, на чайок, барин, на чайок», – дип кычкыра башладылар. Мәгълүм инде без бит «на чай»ларга бик каушамыйбыз. Бу хәерчелек өчен бераз үгетләп, бераз орышып, бирми чыгардым. Арба алып, Икенче Мещанский урамында «Саладовников» исеменә салынган очсызлы фатирларга киттем. Бер ярты сәгатьләр баргач, дүрт катлы гаять зур йорт каршына җиткәч, югарыдагы язудан моның миңа кирәк йорт икәнен белдем. Каршындагы бакчада уйнап торган бик күп балалар арасыннан үтеп канторга кердем... «Хәер, әфәндем бу гаиләле кешеләргә махсус йорт. Әнә, сез тегесенә барагыз!» – диделәр. Икенчесенә китеп урнаштым. Монда үзем кеби провинциал мөгаллимнәр вә мөгаллимәләр белән бик тиз танышылды. Бер ярты сәгать эчендә күптәнге аркадашлар кеби үзләшеп киттек. Бу йортта йөреп өйрәнгәч, мин моны бик әһәмиятле таптым. Салодовников фамилияле бер миллионер Мәскәү управлениясенә миллионнар илә акча калдырып, мохтаҗларга вә укучыларга махсус очсызлы фатирлар салдырырга васыять иткән. Васыяткә бинаән[1], гаиләлеләр һәм ялгызлар өчен аерым-аерым гаять зур вә мөкәммәл ике йорт салынмыш. Гаиләләргә махсус булганында ничә фатир барын белмәдем, әмма ялгызаклар өчен мең данә бүлмәсе бар. Бүлмәләр кечкенә булсалар да, биек, якты, электриклы булып, карават, матрас, өстәл, урындык кеби лязем булган нәрсәләре дә бар. Бүлмәнең айлыгы биш сум, тәүлеге 18 тиен.

Шул йортның үзендә үк бик яхшы ашханәсе, мөкәммәл мунчасы, буфеты, зур заллары бар. Мондагы ашханәдәге 20 тиенлек аш башкалардагы 50–60 тиенлек аштан артык буладыр. Шуның

[1] Васыяткә бинаән – васыяткә нигезләнеп.

өстенә бу йортлар трамвайга да ерак түгел, шуның өчен Мәскәүгә баручы уртарак хәлле адәмнәргә һәм укучыларга моны хәтердә тотуны тәүсыя итәм[1].

Мәскәү искелектә[2] Русия калалары арасында өченче урын тотадыр. Моннан тугыз-ун гасыр мөкаддәм[3] тәэсис ителгән[4] бу шәһәрдә Русиянең тарихы тәрәккыйсе, икътисадый үсүе Мәскәүгә баглыдыр. Шуның өчен монда килгән кешенең тарихи әсәрләр[5] эзләве табигыйдыр. Ләкин үзем генә йөреп караганда, бер тарихи әсәр дә алдыма килмәде. Гаять зур, ифрат хәрәкәтле, матур гыймарәтле[6] Аурупа шәһәре. Башка юк. Шулай да монда һәммә нәрсәдән рус исе килә, рус рухы куәтле. Миллионнарга төшкән чиркәүләр, монастырьлары гына да рус халкы каршында бу шөһрәтнең кыйммәте ни дәрәҗәдә икәнлекне күрсәтергә җитә.

Мәскәүдә Кремль (Кальга), Красный площадь, Третьяков картинный галереясы, Румянцев музәханәсе,[7] нәбатат вә хайванат[8] бакчалары кеби күрелергә тиеш урыннар барлыгын беләм идем. Ләкин боларны күреп йөрер өчен җаен тапмый идем. Комиссиягә бер бардым да өч-дүрт аркадашым[9] белән сөйләшеп утырганда, Комиссиянең секретаре Проппер әфәнде килеп, сүзебезгә катнашты. Без дә Мәскәүнең тарихи ядкәрләрен күрергә арзуымызны[10] әйткәч, хуш кабул итте. Бу тугрыда графиня Бобринская белән сөйләшмәкче булды.

Озак та үтмәде Мәскәүне яхшы белгән асаре гатика[11] мөтәхассыйсләреннән[12] берәүне безгә җитәкче итеп чакырырга карар

---

[1] Тәүсыя итәм – киңәш бирәм.
[2] Искелектә – борынгылык ягыннан мәгънәсендә.
[3] Мөкаддәм – элек.
[4] Тәэсис ителгән – төзелгән.
[5] Тарихи әсәрләр – тарих эзләре.
[6] Гыймарәт – төзелеш, биналар (архитектура).
[7] Музәханәсе – музее.
[8] Нәбатат вә хайванат – үсемлекләр һәм хайваннар.
[9] Аркадашым – иптәшем.
[10] Арзуымызны – теләгебезне.
[11] Асаре гатика – борынгы заманга караган әйберләр, археологик истәлекләр.
[12] Мөтәхассыйс – белгеч, специалист.

чыгарды. Икенче көн Комиссиягә җыелган иллеләп сәяхләрне бер мөтәхассыйс адәм Мәскәү буена алып китте.

Кремльгә барганда әллә никадәр колонналар (баганалар), террасалар белән зиннәтләнгән бер йорт каршына туктап, җитәкчебез моның Петрга кадәр[1] дәвердән калган бердәнбер олуг бояр йорты идекене сөйләде.

Кремль – Мәскәү елгасының биек ярына салынмыш биек бер кальгадыр. Моның элек заманнарда хәрби әһәмияте, әлбәттә, зур булгандыр. Ләкин хәзер ул җәһәттән аның һичбер әһәмияте юктыр.

Кальганың эчендә бик күп яңа биналар һәм тарихи чиркәүләр арасында Грановитый һәм Оружийный палаталар, кенәзләрдән калган әсәрләр бар.

Өченче Иван дәверендә[2] салынган Гранатовитый палатага кереп, мәзкүр кенәзнең китапханәсен, кабинетын, аш вә ятак бүлмәләрен, анда булган җиһазларны күргәндә, бик ерак заманнар искә төшә. Ул заман халкының әхлак вә гадәтләренең, санагатьләренең[3] ни дәрәҗәдә булганлыгын аңлап була. Кайчандыр бервакыт безнең бабайларыбызның монда кадәрле кунак яки шул кабинеттагы бармак ишарәсе белән корбан булулары күз алдыннан узып китәләр. Ул вакыт бу палатаның тәбәнәк сводлары[4], караңгы, тар бүлмәләре эчендә җан өши, идән убылган, имән урындыклар селкенгән кебек булалар. Тизрәк моннан чыгарга карыйсың.

Бу палатада залларның берсе өстендә булган сәндерәне: «Бу залда зур мәҗлесләр булганда, музыка уйнатылган; менә бу кечкенә тәрәзәләрдән кенәз гаиләсендә булган хатын-кызлар качынып[5] кына мәҗлесне тамаша кыла булганнар», дип күрсәтәләр.

---

[1] Петрга кадәр... – Петр I Алексеевич Романов (1672–1725), Петр Великий. Россиянең соңгы патшасы. 1721 елдан Россиянең беренче императоры.

[2] Өченче Иван дәвере ... – Иван III Васильевич Рюрикович (1440–1505). 1462–1505 елларда Мәскәү Бөек кенәзе, государь всея Руси дип аталган хөкемдар.

[3] Санагать – сәнгать; һөнәрчелек; индустрия.

[4] Сводлары – гөмбәзләре.

[5] Качынып – яшеренеп.

Димәк, өч-дүрт йөз ел элек рус хатын-кызлары да хәят иҗтимагыягә[1] шул кечкенә тәрәзәләрдән генә карарга хаклы булганнар...

Кремльдә моннан башка Оружийный палата, Царь-пушка, Царь-колокол, төрле сугышларда ганимәт[2] алынган кораллар, Иван Великий манарасы[3], Александр Икенче хәзрәтләренең һәйкәле кеби тарихи әсәрләр бар. Моннан Красный площадька чыгып, хөкүмәткә хыянәте сизелгән адәмнәрне борында җәза кыла торган «Лобное место» дигән урынны күреп, Мәскәүнең «Китай город» дип йөртелгән җиренә чыктык.

Бу урын – тиҗарәт мәркәзе[4] булганга, гаять матур биналар белән мәгъмүр[5] вә Мәскәүнең иң кайнашкан, иң җанлы урыныдыр. «Третьяковская галерея» – Третьяковский фамилияле бер адәм үзенең бик күп картиналардан гыйбарәт музәханәсен шәһәр идарәсенә тапшырып гомуми картиналар музәсе ачарга васыять итмеш. Монда рус хөкемдарларының, әдипләренең, галимнәренең рәсемнәре, дөньяның мәшһүр рәссамнарының иң мөһим әсәрләре сакланадыр. Бездә сәнәгате нәфисә[6] зәүкы гаять түбән булганга, мондагы әсәрләрнең матурлыгына, күпләгенә хәйран калудан башка әсәр чыгара алмадым. Шулай да ике картина минем дә хосусый дикъкатемне җәлеп иттеләр: берсе – Верищагинның[7] «Төрек-рус сугышы»[8], икенчесе – «Төркестан җамигъларыннан берәүсенең капусы»[9].

«Төрек-рус сугышы» каршында торганда кеше үзен тәмам сугыш мәйданында кебек хис кыла, адәмнәрнең бер-берсенә

---

[1] Хәят иҗтимагыягә – иҗтимагый тормышка.

[2] Ганимәт – трофей.

[3] Иван Великий манарасы – Мәскәү Бөек кенәзе Иван III Васильевич (1440–1505) хөрмәтенә 1505–1509 еллар аралыгында төзелгән храм-колокольня.

[4] Тиҗарәт мәркәзе – сәүдә үзәге.

[5] Мәгъмүр – төзекләндерелгән (благоустроенный, населенный).

[6] Сәнәгате нәфисә – нәфис сәнгать.

[7] Верищагин... – Василий Васильевич Верищагин (1842–1904), рус әдибе һәм танылган рәссам.

[8] «Төрек-рус сугышы» – Биредә В.А. Верищагинның 1877–1879 елларда иҗат ителгән «Русско-турецкая война» исемле картиналар циклы турында сүз бара.

[9] Биредә В.В.Верищагинның «У дверей мечети» (1873) исемле картинасы күздә тотыла булса кирәк.

мәрхәмәтсезлекләренә хәйран кала, әгъзалар тетри. Дөньяда һәммә нәрсә тәкәммел[1] вә тәгали иткәндә[2] җәмгыяте бәшәриядә[3] инсаният[4] хисе ни өчен бер дә тәгали итми икән? кеби сөальләр ихтыярсыз күңелгә киләләр.

Румянцев музәсе. Монда Руссиядә яшәгән вә яшәүче күп милләтләрнең дөнья көтешләренә, гореф вә гадәтләренә караган гаять күп асар бар. Күп кауемнәрнең тормышлары, өйләре, йорт хайваннары, кошлары, көндәлек эшләрне эшләп торулары тәмсил кылынган[5]. Йөрергә ике-өч атна гомерен кызганмаган кеше монда Руссиянең җәнүбендә[6], шималендә[7], гарбендә[8], шәркында[9] булган кауемнәрнең тормышлары, гореф вә гадәтләре белән таныша алыр. Тәәссефкә[10], безгә андый форсат чыкканы юк әле. Ул форсатны эзләгән миләттәшләремә дә очраганым юк.

Моннан башка набатат вә хайванат бакчаларына да барып йөрдек исә дә, алар турында язу сүзне озайтачак булганга, сөкүт белән үтәргә тиеш табам.

## Мәскәүдә мөселманнар

Сүзләргә караганда, Мәскәүдә ун меңләп мөселман бар. Бу халык күбрәк фабрикаларда эшләүчеләрдән, талчукчылардан, арбачылардан, кучер һәм дворниклардан гыйбарәттер. Шулай да, сирәк кенә булса да, читек-кәвешче, каракульче татар фирмалары да күзгә чалынып калгалый. Шул халыкның дини ихтыяҗларын үтәр өчен, өч мелла, ике мәзин бар. Боларга караган бере Татарский урамында, икенчесе Дүртенче Мещанский урамында – ике мәсҗед бар. Татарский урам мәсҗедендә Хәйретдин ахунд (мәрхүм) халыкны искә ала. Халыктан аерылмаска, ысуле

[1] Тәкәммел – камилләшкән.
[2] Тәгали иткәндә – бөеклеккә ирешкәндә.
[3] Җәмгыяте бәшәриядә – кешелек җәмгятендә.
[4] Инсаният – кешелеклелек.
[5] Тәмсил кылынган – мисал итеп күрсәтелгән.
[6] Җәнүбендә – көньягында.
[7] Шималендә – төньягында.
[8] Гарбендә – көнбатышында.
[9] Шәркында – көнчыгышында.
[10] Тәәссефкә – кызганычка каршы.

җәдидә кабул итмәскә, рус мәктәпләренә кереп каралмаска өндәүче бер заттыр. Бу затның һәр эшне «сүзгә осталык белән бетерәм» дәгъвасында булуы, үз тугрысында булган анекдотлары миңа электән мәгълүм булганга, аны зиярәт итүне тиешсенмәдем. Икенче мәсҗеднең яшь имамы Сафа мелла (мәрхүм) янына киттем. Мәсҗед ишек алдына кергәч, капкага каршы торган бер ишеккә барып, мелланы сорадым. Дәрхаль[1] Сафа мелла тәкәллефсез[2] генә чыкты. Үзенә алып керде. Хәзрәт ачык йөзле, тәмле телле булганга, байтак утырырга тугры килде. Хәзрәт Мәскәү халкыннан бик зарланды: уку-укытуга һич хирыслары юк, рус мәктәпләренә балаларын бирмиләр, гәзитә вә журналларымызны укымыйлар, мәктәпләремезне тиешле дәрәҗәдә тәрбия итмиләр, халатчылыктан башка эшкә керешмиләр, диде. Чыгып киткәндә, хәзрәт мәсҗедне күрсәтеп йөрде. Мәсҗед бик яхшы, зур, ике катлы, электрлы. Аскы каты – мәктәп. Бу да зур, фәкать караңгы, парталар юк, сыйныф тактасыннан башка укыту әсбабы һич юк. Аңсыздан барып кергән кеше моны мәктәптән бигрәк манеж (ат өйрәтә торган урын) дип белер иде.

Бу мәктәп бер сарт[3] баеның һиммәте[4] белән салынган. Урыны җәннәттә булсын. Татарлар кайда да артта, ләкин Мәскәүдәге кадәр мәдәни вә икътисадый артка калу һичкайда сизелми. Сәбәбе нидер? Инде тәкъдир монда риясәтне дә башкартты[5]. Шулай да мөһим үзгәрешләр ишетелми әле.

## Мәскәүдән Одессага

Өченче июнь. Кич сәгать бишләрдә Смоленский бульварда сәяхәт Комиссиясенең бүлмәләре, коридорлары сәяхләр вә анларны озатучылар белән тулган иде. Бу халыкны күздән кичергәч, сәяхләрне күкрәкләрендәге зәңгәр бантларыннан, озатучылардан аергач, Трубчинков: (бу малорус егете садәлеге, сүзгә осталыгы, киң мәгълүматы, мәзәкчеллеге белән һәркемнең

[1] Дәрхаль – шунда ук.
[2] Тәкәллефсез генә – гади генә.
[3] Сарт – үзбәк.
[4] Һиммәте – тырышлыгы.
[5] Риясәтне дә башкартты – рәислек итүне дә үзгәртте.

дикъкатен җәлеп иткән кеби, Салодовников номерларында яткан арада мине дә мөсәххәр кылырга[1] өлгергән иде).

«Минем яратмаганым – дамское общество. Ә безгә аннан котылу мөмкин булмас төсле күренә. Кара син, дамалар никадәр күп! Югалды баш!» – дип куйды. Исәпләп карасак, безнең группада 12 ир, 33 хатын-кыз булып чыкты.

Комиссия әгъзаларыннан берәү кыска гына нотык сөйләп, хәерле юл теләде. «Хәзер сезгә Брянский вокзалда вагон хәзерләнде, йөрегез!» – диде. Һәркем үзенең нәрсәләрен алып урамга чыкты. Монда танышмаганлык бетте. Зәңгәр бантлы кешеләр арасында «үзлек» башланды. Кушылып-кушылып арба алып китә башладылар. Мин дә, ничектер Трубчинковтан аерылып, Томский гимназиясенең телләр мөгаллимәсе булган бер немка белән арбага утырып, вокзалга киттем. Вокзалда безнең иптәшләр, аларны озатучылар башка халыклардан күбрәк иде. Вокзал «безнеке» иде. Һәркем шат, һәркем көлеп кенә сөйләшә, таныша, тәкәллефсез серләшә. Шул арада яшь кенә бер мөгаллимәнең артыннан бер карчык еглап йөри. Очраган бер кешегә яшь сәяхәтчене әманәт итә. Миңа да сөйләшергә тугры килде. Яшь мөгаллимә «инородец» булып чыкты. Карчык миңа хосусый аңлата.

Вагоннарга кергәч, Комиссиянең вәкиле: «Ирләр кечерәк бүлмәгә, хатын-кызлар зур бүлмәгә урнашсыннар», – диде. Дамалар: «Монда ирләр, дамалар юк. Мөгаллим вә мөгаллимәләр генә бар. Барыбыз бергә утырамыз», – диделәр. Шулай һәм утырдылар.

Моннан соң сәяхләрнең списогы укылды. Биш-алты еврей, биш-алты поляк, шул кадәр үк немец фамилияләре ишетелеп калды. Болардан һәм миннән башкалары руслар иде. Комиссиянең вәкиле сәяхәтчеләрне группаларга бүлүне мәгъкуль күрде. Шуңар күрә мин, малорус Трубчинков, поляк студенты пан Вилһельм һәм тугыз дама бер группа тәшкил иттек.

Өченче звонок булды. Һәркем, Аллага шөкер, кузгалабыз, дип куйды. Вокзал тирәсендә булган күңелсез биналар, фабрикалар, заводлар буеннан үтеп, дачаларга чыкканда, безнең җыйнаклы

[1] Мөсәххәр кылырга – сихерләргә.

вагонда хор белән җырлаулар, Мәскәү, Петербург кеби шәһәрләрнең гөрелтесеннән, мәктәпләрнең тузаныннан вакытлыча гына булса да котылуга шатланышып сөйләшүләр башланган иде. Хосусан, мөгаллимәләр хикәяләрдән генә үзләренә мәгълүм булган шәрыкны, ислам шәркын күрәчәкләренә шатланалар. Күп мәгълүмат, чиксез тәэсират алып кайтырга өмидләнәләр. Бу мөсахабәләрнең[1], башлыча, мәүзугълары[2] төрекләр, гарәпләр, гомумән, мөселманнар иде. Яшьрәк, садәдилрәк[3] ханымнар, әкият тыңлаганда курыккан бала кебек, үзләренең куркуларын да белгертәләр иде: «Төрекләр, гарәпләр әле дә булса вәхшиләр бит, алар арасында безгә уңайсызлыклар да очрар әле», – диләр. Шәрык халкының хатын-кызга карашларын да искә төшерәләр. Икенчеләре куркучыларны юаталар. Хәзер иске Төркия түгел. Анда бит хәзер идарәи мәшрута[4]. Халык та шулай мәдәниләшкән инде, диләр. Мин дә төрекләр, гарәпләр тугрысында белгәнемне сөйләдем: «Алар нәзакәтлеләр, читләргә ихтирамлылар. Хатын-кызлар тугрысында гаять намуслылар, гаять әминнәр[5].

Әмма бер төркем сәяхләрнең, журналистларның алар тугрысында язган чүп-чарлары барысы яла. Чөнки бу язучылар сәяси максат белән ислам кауемнәрен Аурупа әфкяре гомумиясе[6] каршында мөмкин кадәр начар күрсәтергә тырышалар. Ни булса да барырбыз, күрербез», – дидем.

Икенче урында беркадәр халык лөгать китабы[7] тотып, төрек вә гарәп сүзләре, акча хисаплары өйрәнәләр. Мин дә берничә белгән төрек вә гарәп сүзләрен кыстырдым. Араларында төрекчә «белгән» кеше табылуына иптәшләр шатланыштылар. Ханымнар шунда ук: «Истанбулга баргач, почтага, магазинга, театрга барамызмы?» – дип, үтенечләр дә ясадылар. Шуннан соң иптәшләр арасында минем турыда ихтималлар зур иде. Ләкин

[1] Мөсахабәләрнең – сөйләшүләрнең.
[2] Мәүзугълары – темалары.
[3] Садәдилрәк – эчкерсезрәк.
[4] Идарәи мәшрута – конституцион идарә.
[5] Әминнәр – ышанычлылар.
[6] Әфкяре гомумиясе – массаларның карашы, җәмәгать фикере.
[7] Лөгать китабы – сүзлек.

шунысы тәәссеф[1] ки, «Мин татар углы татармын, Чыңгыз токымыннанмын», – дигәч, аркадашлар арасында татар булуга тәгаҗҗеб иттеләр[2]. Татарларның мондый гыйльми сәяхәт кеби мәдәни эшләрдән ерак халык икәнен тартынмый сөйләүчеләр дә булды. Шулай да шәрык халкын, төрек-татар кабиләләрен чын-чыннан яратучы ханымнар табылды. Миңа мөдафәга[3] урын калдырмадылар.

Бу озын мөзакәрәнең холасасы[4] минем зиһенемдә болай калган: ирләр, гомумән татарларны кучер, лакей, дворник, халатчы дип кенә саныйлар; әмма хатыннар, немкалар белән еврейлардан башкалары, татарлар тугрысында күбесе яхшы фикердә булганлыкларыны белгерттеләр. Мөзакәрәнең ахырында берәүнең: «Монда бер татарыбыз да булды», – диюенә каршы яшь бер мөгаллимә: «Гафу итегез, мин дә татарка булам. Поп кызы булсам да, ул минем татарлыгыма манигъ[5] түгел. Миндә татар каны кайнап тора. Мин кан кардәшләремне яратам. Аларны ихтирам итәм. Алар никадәр надан булсалар да, аурупалылар кадәр бозык түгелләр», – диде.

Иртә белән уянсам, урманнар беткән. Әтраф тип-тигез ялан. Гогольнең[6] авыз суын корытып тасвир кылган «Малорус эстибы[7]«на җиттек. Элек куе үлән, чуп-чуар чәчәклектән гыйбарәт булган бу ялан хәзер куе, биек, ямь-яшел бодай белән капланган булмаса да, әле дә Гоголь эстибын[8] хәтерләтә торган урыннары да аз түгел. Чиксез яшеллек уртасында биек тирәкләр, бакчалар арасыннан күренеп калган ап-ак утарлар, озын фургонга куш[9] үгез җиккән хахоллар юлчыларга ят манзара тәшкил итәләр. Бу манзара гел бер төсле булса да, күз туймый. Карап баруга гына канә-

[1] Тәәссеф – кызганыч.

[2] Тәгаҗҗеб иттеләр – гаҗәпләнделәр.

[3] Мөдафәга – (үз-үземне яклап) каршылык күрсәтергә.

[4] Мөзакәрәнең холасасы – сөйләшүнең (фикерләшүнең) нәтиҗәсе.

[5] Манигъ – каршылык, киртә.

[6] Гоголь – Николай Васильевич Гоголь (1809–1852), бөек рус язучысы, әдәбият классигы. Милләте белән украинлы. Күп әсәрләрендә Украина табигатен, дала-киңлекләрен сурәтләүгә зур урын биргән.

[7] Малорус эстибы – Украина даласы.

[8] Эстиб (степь) – дала, ялан.

[9] Куш – пар (ике).

гатьләнмисең, болын буенча йөгереп китәсе килә. Менә шул яшел диңгез уртасында барганда, алда ак көмеш кеби киң бер тасма килеп чыкты. Ул тасма Русия тарихында бик мөһим урын тоткан Днепр елгасы иде. Днепрның бер ягы – киң сахра, икенчесе – тау-сурак. Тауның өстендә биек матур очлы тирәкләр (пирамидальные тополи) эчендә Киев шәһәре безне каршы алмакта иде.

Киев шәһәре[1] Русиядә кенәзлек дәвере башлануга[2] кадәр үк тәэсис ителгән[3] булса да, кенәз Олег[4] белән генә тарих сәхифәләренә керә башламыштыр. Кенәз Олег Киевтән Византиягә юл ачты[5]. Владимир Киевтә Православиене кабул итеп, ул һәм аның халыклары ул динне славяннарга тараттылар[6]. Шуның белән бөек Русия дәүләтенә Киевтә нигез корылды.

Бу тарихи шәһәр. Мәгънәви яктан русиялеләрнең калебен үзенә җәлеб иткән кеби аның матур манзарасы[7] һәм безне дә мөсәххәр итте[8]. Сәяхәт маршрутында монда туктау булмаса да, поездның өч сәгать калачагын белгәч, форсаттан файдала-

---

[1] Киев шәһәре – борынгы шәһәрләрнең нигез салыну датасы төгәл билгеле булмаса да, Киев шәһәре, сакланып калган елъязмаларга нигезләнеп, V–VI гасырларда барлыкка килгән дип фаразлана.

[2] Русиядә кенәзлек дәвере башлануга ... – «Повесть временных лет» дигән истәлеккә таянып Россиядә кенәзлек дәвере IX гасырдан, Рюриковичлар династиясеннән башлана дип фаразлана. Рюрик 862 елда Новгород шәһәренә килеп төпләнә. Россиянең дәүләтчелек тарихын шул датадан башлап саныйлар.

[3] Тәэсис ителгән – төзелгән, салынган.

[4] Кенәз Олег – (Вещий Олег, ? – 912), Рюрикларның дәвамчысы 879 елдан Новгород князе, 882–912 елларда Киев Бөек князе.

[5] Кенәз Олег Киевтән Византиягә юл ачты – кнәз Олег 907 һәм 911 елларда Византиягә гаскәр белән бара. Бу походта ул җиңүгә ирешә. Нәтиҗәдә греклар белән Киев кнәзлеге арасында сәүдә килешүе төзелә. Аның нигезендә Киев дөньякүләм аренада үз урынын ала. Рус сәүдәгәрләре Константинопольгә барып, үз товарлары белән сәүдә итәргә хокук алалар.

[6] Владимир Киевтә Православиене кабул итеп... ул динне славяннарга таратты... – Кенәз Владимир, Владимир Великий, Красное Солнышко, Владимир Креститель һ.б. (?–1015), кенәз Владимир (идарә еллары 980–1015) көнчыгыш славяннарны Киев Русе составына берләштерә. Шул вакыттан башлап башкаласы Киевтә булган борынгы Рус дәүләте барлыкка килә. 988 елда кенәз Владимир христиан динен кабул итә һәм православиене Киев Русенең дәүләт дине дип игълан итә.

[7] Манзарасы – күренеше.

[8] Мөсәххәр итте – сихерләде.

ныып, өстән генә булса да шәһәрне күреп кайтмакчы булдык һәм һәр дүрт кешегә бер фәйтун яллап киттек. Крищатик[1] урамын, Купеческое собрание бакчасын, театр, музәханә[2], университет мөәссәсаларын[3] һәм дә Софийский собор, «Киевско-Печерская лавра» кеби тарихи ядкәрләрне күрдек. Софийский собор XI гасырның матур Византия ысулы мәгъмүриясендә[4] салынган мөҗәссәм[5] хатирәседер.

Софийский собордан киң урам белән барып, шәһәрне чыктык. Таш койманы үтеп, икенче шәһәргә кердек. Мондагы сатучылар, кибетләр, йөрүчеләр Крищатиктагыдан бөтенләй башка күренәләр: кибетләр тәре, икона, тәсбих кеби нәрсәләр белән тулы. Капчыгын аркасына асып, озын таягын кулына тоткан акрын гына баручылар чиркәү ишек төпләрендә, койма буйларында күләгәдә утырып, ятып, ашап торучылар арасында Великий рус, малорус, белорус, вотяк, чуаш, чирмеш, пермяк, мордва, керәшен кеби Русиядә яшәүче халыкларның һәркайсыснннан нөсхәләр бар кеби иде. Бу урын этнография мөтәхассыйслары[6] өчен хакыйкатән гыйлем вә тәтәббыг[7] мәйданы булырга ярыйдыр. Мондагы зияратчеләргә безнең унбер фәйтун нинди тәэсир биргәндер, анысын бермим. Әмма шунда булган хәерчеләрне шактый хәрәкәткә китерде: һәркайсының йөзендә, хәрәкәтендә алга килгән белән файдаланырга тырышу беленеп тора иде. Ләкин исәпләре ялгыш чыкты.

Бу мәйданда берничә чиркәүгә кереп, архитектураларыны тамаша кылгач, Русиядә беренче монастырь саналган Печорага кердек. Хисапсыз күп баскычлардан төшеп, караңгылыкка кергәч, шәмнәр алып, мәгарәнең беренче галереясына кердек. Бу галерея тар даирә шәкелендә булган юлдан гыйбарәт иде. Дивар буйларына киртләчләп православие газизләренең табутлары куелган. Алар янында монахлар шәм тотып, зияратчеләргә мөкад-

[1] Крищатик – Киев шәһәренең үзәк урамы.
[2] Музәханә – музей.
[3] Мөәссәсаларын – биналарын.
[4] Ысулы мәгъмүриясендә – ысулында, шуңа ошатып төзелгән биналар.
[5] Мөҗәссәм – олуг, мәһабәт.
[6] Мөтәхассыйслары – белгечләре.
[7] Тәтәббыг – тикшерү, өйрәнү, эзләнү.

дәс су сибеп утыралар. Газизләрнең исемнәрен, мөхасиннәрен[1] сөйлиләр. Йөри торгач, һава начарланды, тын алу кыенлашты. Күреп бетерә алмый чыгарга мәҗбүр булдык. Соңра, тау башына барып, Днепр өстенә карап тордык. Днепрның ары ягындагы эстиб, өстендә ак пароходлар, бу яктагы озын тирәкләр тәэсиремезне сакладылар. Шуның белән канәгатьләнеп, вокзалга кайттык. Киевтә хасил булган тәэсирләребезне бүлешеп сөйләшкәнчә, көн-төн үткәнне сизми калдык. Икенче көн соң гына торып, чәй эчкәнче станцага килдек. Кичен үк телеграм илә монда аш хәзерләргә кушылган иде. Аш өчен расчёт бирү минем өлешкә төшкәнгә, буфетка акча түләргә бардым. Буфет тирәсендә йөренгән ике егетнең татарча сөйләшүләрен ишетеп, мин дә максудны[2] үзебезчә ифадә иттем[3]. Егетләрнең берсе гаҗәпләнеп миңа карап куйды да, бер нәрсә дә эндәшмичә: «Хәсән!», – дип кычкырды. Ул арада Хәсән әфәнде килде. Гыйззәтулла әфәндене алып килделәр. Бу ике зат бик гаҗәп бер нәрсә тапкан кебек шатланыштылар. Минем шәхесем боларга таныш түгел, шуның өчен аларның шатлыклары, ихтирамнары миңа түгел, бәлки аларның күз алларыннан үткән әллә ничә йөз сәяхләр арасында бер булган татарга иде. Аларны хәрәкәтләндергән милли хис иде.

«Безнең юлдан берничә группа сәях-мөгаллимнәр үттеләр инде. Шулар арасында үз кешебез булмауга без бик ачына, бик гарләнә идек. Менә, әлхәмдүлилла, руслар арасында үз татарыбызны да күреп шатландык», – диделәр.

Поезддан калуымнан куркуымны белгерткәч: «Хафаланмагыз, калсагыз без сезне иптәшләрегездән элек Одессага җиткербез», – диделәр. Ике сәгатьләп кунак иткәч, Гыйззәтулла әфәнде үзе вагонга озатты. Юл кирәкләреннән кирәк булган иң мөһим нәрсә бүләк итте. Бу миңа аслан таныш булмаган затның илтифатыннан аркадашлар хәйран калдылар. Арабызда булган милләт җепләренең ныклыгына тәхсиннәр укыдылар[4].

[1] Мөхасиннәрен – кешеләргә карата булган яхшы мөгамәләләрен.
[2] Максудны – максатны.
[3] Ифадә иттем – аңлатып бирдем.
[4] Тәхсиннәр укыдылар – мактауга лаек күреп, хупладылар.

Гыйззәтулла әфәнде Максудов илә кияве Хәсән әфәнденең бу илтифатына[1] чын күңелемнән тәшәккер итәм[2].

## Одессадан Истанбулга

6 июнь. Иртән сәгать җиделәрдә Одессага җиттек. Бу шәһәр зурлыгы вә әхалисенең[3] күплеге, сәүдәсенең исәплеге белән Русия шәһәрләре арасында дүртенче урын тотып, һич туңмый торган Кара диңгез өстендә булганга, хариҗи тиҗарәт[4] өчен беренче дәрәҗәдәге портлардан хисаплана. Һавасының ләтыйфәте, бакчаларының матурлыгы, халкының төрлелеге белән пакьлеге, тазалыгы бу шәһәргә җәнүб[5] һәм Аурупа төсе бирмәктәдер. Решильевский урам, Андреевский лиман[6], Александровский парк кеби гүзәл урыннарны, төрекләрдән калган иске крепость стенасыннан гыйбарәт булган «Хаҗи бәк» кеби тарихи ядкәрләрне күреп көн буе йөргәч, лиманда торган «Ольга» пароходына йокларга төштек. Лиман пароходлар, баржалар, җилкән көймәләре илә тулы иде. Болар тирәсендә көн-төн туктамыйча эшләп, үзләрен һәм башкаларны асраучы хезмәтчеләр унар меңләп хисапланадыр. Шул хезмәтчеләрнең хәленә кызыгып, шулар кеби эшләсәң, тамак туйдырсаң иде, дип аһ-ваһ орып, трактир тирәләрендә, койма буйларында ятучы эшсезләр дә меңәрләп хисапланадыр. Боларның хәле бигрәк аяныч: болар ач-ялангач, почмаксыз бичаралардыр. Одесса «ялан аяклары» кадәр кызганыч эшсезләрне һичкайда күргәнем юк. Безнең шәһәрнең кайсы да бу бичаралардан мәхрүм булмаса да, Одесса, – ихтимал, бу тугрыда иң бәхетлеләрдәндер.

«Ольга» – Кара диңгез пароходларының иң зурысыдыр. Безнең Волга пароходларының иң зурлары да моның янында әрҗә булып кына калырлар иде. Әмма матурлыкта, тазалыкта диңгез пароходлары безнең Волга пароходларыннан күп түбәндер. Беренче вә икенче класслары чибәр генә булса да, өченче классы

[1] Илтифатына – игътибары, хөрмәт күрсәтүе өчен.
[2] Тәшәккер итәм – рәхмәтемне белдерәм.
[3] Әхалисенең – халкының.
[4] Хариҗи тиҗарәт – тышкы сәүдә.
[5] Җәнүб – Көньяк.
[6] Андреевский лиман – Андреевский дигән диңгез култыгы.

кайтыш. Диңгез пароходлары гадәттә өч класслы булып, югары ике каты беренче вә икенче классларга һәм пароходның командасына махсус булып, асткы каты (трюм) өченче класс юлчылар өчен билгеләнәдер. Монда сәке фәлән булмаса да, Комиссиянең үтенүе буенча, безгә салам түшәкләр бирелде. Һәркем үзенең түшәген табылган урында җәеп йокларга хаклы булды. Аскы катка яктылык бик кечкенә генә тәрәзәләрдән кергәнгә, башта бик караңгы күренде. Ләкин күз ияләште. Аяк эзе табылырлык булды. Бу класс белән бер буйдан товарный отделение дә булганга, тычкан вә күсе кебек хайваннар монда үзләрен тулы хокуклы пассажир хисаплап юлчылардан бер дә тартынмыйча йөриләр. Пассажир мескен берни дә әйтә алмый. Пайтәхетләрдән хозурсафага, саф һавага чыккан иркә табигатьле мөгаллим, мөгаллимәләргә трюм охшап ук бетмәде. Икенче палубаның буш урыннарында йөрергә, хәтта урын табылса йокларга да рөхсәт булды. Шуның белән файдаланып, көндезләрен югарыда, ачык һавада үткәрергә мөмкин. Безгә, Комиссиянең үтенүе буенча, беренче вә икенче класслар палубасында йөрергә рөхсәт иде. Шуның өстенә пароходның капитаны һәм аның ярдәмчесе рөхсәте булгач, безгә диңгездә бер уңгайсызлык та күрергә туры килмәде. Икенче көн иртә белән без урыннан торганда, пароходка пассажирлар килә башлаган иде.

Петергоф гимназиясе һәм Петербург кадетский корпусының шәкертләре дә трюмның ике буш почмагында урнашып, кайнап торалар иде. Бу өч группа сәяхләр арасында башка пассажирлар ятсынып кына, читләп кенә йөриләр иде. Юлчылар арасында бер почмакта бер төркем фәсле, бүрекле адәмнәр күреп, яннарына бардым. Шулар арасында үземнән русча укыган бер шәкертне танып, аның аркылы башкалар белән дә таныштым. Казылык, чәкчәк, ит-май, бал кеби юл ашамлыклары белән тулы ашъяулыгы янына мамык мендәргә таянып, Семипалатның Габделхак хәзрәт чәй эчәдер иде.

Ул үзенең мәхдүмен һәм аның шәрикен[1] Истанбулга тәхсилгә[2] алып бара икән. Хәзрәт минем мөгаллим вә мөгаллимәләр

[1] Шәрикен – иптәшен.
[2] Тәхсилгә – укырга, белем алырга.

белән юлдаш булуымны белгәч, бераз игътиразлар кылды[1]. «Бу кадәр марҗа арасында Алла тәүфыйк бирсен инде», – диде. Җавап кайтарып маташмадым, «Башка эшләпә, өскә шул адәм мәсхәрәсене кигәч, шулар белән бер сохбәттә булгач, бер ашын ашагач, сөйләшеп торасың юк инде, энекәем», – дип кырт кисеп куйды. Сүзебез киселүгә мәмнүн булдым[2].

Хәзрәттән аерылгач, читтәрәк торган ике егет яныма килеп сүз куштылар. Боларның берсе фәстән, икенчесе студенческий фуражкадан иде. Аңлашылды ки: болар сүрияле гарәп егетләре икән. Элек Казанда инородецлар семинариясендә тәхсил итеп, соңра берсе дарелфөнүндә, икенчесе Духовный академиядә икмаль тәхсил иткәннәр[3] дә ватаннарына кайталар. Болар бик дәртле вакытларыны Русиядә үткәргәннәр, рус тәрбиясе алганнар. Диннәре дә православиедыр. Шулай да болар – гарәпләр. Гарәпләрне сөяләр. Гарәпләр тугрысына килгәндә, мөслим, гайре мөслимне[4] аермыйлар. Төрекләрне дә яраталар. Төркиядә яңа гына булып үткән тәбдилатка[5] шатланалар. Сүзләренә караганда, моннан соң ватаннарының әҗнәби нөфүзеннән[6], коткысыннан котылачагына өметләнәләр. Ватаннарына җитди хезмәт итәргә бил баглап кайталар.

Өченче боргы булды. Машиналар шалтырый башлады. Пароход кузгалды. Шуның белән без туып үскән җирдән, ата вә аналарыбыздан, ыруг-кардәшләребездән, безгә сөекле булган һәммә нәрсәне эченә алган ватаныбыз Русиядән аерылдык. Киткән саен кенәрдән[7] ераклашу, пароходның гаять ачы тавыш чыгарып җир белән «бәхилләшүе» җаннарны тетрәтә башлады. Аркадашларның бәгъзыеләре[8] «Аллага шөкер, күпкәме-азгамы хәят буталуыннан котылдык» дисәләр дә, күбрәге «аерылу»дан

[1] Игътиразлар кылды – тәнкыйть белән намуска тукынды.
[2] Мәмнүн булдым – шатландым.
[3] Икмаль тәхсил иткәннәр – укып белемнәрен күтәргәннәр.
[4] Мөслим, гайре мөслимне – мөселманны да, мөселман булмаганны да.
[5] Тәбдилатка – үзгәрешләргә.
[6] Әҗнәби нөфүзеннән – чит ил кешеләре үтеп керүдән.
[7] Кенәрдән – ярдан.
[8] Бәгъзеләре – кайберләре.

гаять мөтәэссир[1] булдылар. Мөтәэссир булмаслык та түгел; җир ераклаша, Одесса бинокль аркылы томан эчендә генә күренә. Әтрафка күз салсак, җир кисәге юк. Чиксез су өсте көзге кеби тигез, зәңгәрсу, ләкин дәһшәтле, куркынычлы. Әнә еракта, бик еракта болытлар. Алар арасында «безнең авыл». Анда минем Хәлимәм, Нәзыйфәм, гүяки су кенәрендә басып торалар, миңа яулык селкәләр. Күземә яшьләр килә. Ләкин дамалар алдында егетләнү йөзеннән, тәэсирләремне яшерергә мәҗбүр булам. Янымда чиксез суга карап сөйләшеп торган иптәшләрнең сүзенә катышам...

Аштан соң уен-көлке, җыр белән вакыт үткәрелде. Кич кечкенә генә, ләкин күп мәгънәле (характерный) скандал булды; урта палубада бер төркем юнаннар[2] үзләренең милли музыка коралларында төрле матур көйләр чалып, җырлашып озак утырдылар. Юлчылар өчен бу бик яхшы гына концерт иде. Сәгать ун булды. Моннан соң, пароход низамнарынча, музыка һәм җыр манигъ булуга карамыйча кызып киткән юнаннар эшләрендә дәвам иттеләр. Юлчылар тарафыннан тәкърар тәнбиһ[3] ясауга да карамадылар. Шуннан соң арабыздан бер «батыр»ыбыз юнаннарның өстенә бер стакан су сибеп, аларны аякландырды: револьверлар тотып безне, русиялеләрне дә бик кабахәт сүзләр белән орыштылар. Шулвакыт теге гарәп егетләре арага төшеп вакыйганы бастырырга муафыйк булдылар.

Озак үтмәде, Македонияле бер болгар сәяхләр бүлмәсенә кереп урнаша башлады. Тәнбиһ ителде. Файда чыкмады. «Мәдәни болгар» тәкәллефсез чишенеп ята башлады. Нәзакәт әһеле моңа түзмәделәр, протест ясадылар. Болгарны яклаучы юлчылар табылды. Шулар арасында әлеге безнең ашны ашап, суны эчеп, дарелфөнүннәребездә укып, кеше булып кайтучы гарәп егетләре артык гайрәт күрсәттеләр. Рус галәмен, ватаныбыз булган Русияне җан ачытырлык сүзләр белән кабахәтләп, оршышып, болгарны урынладылар. Тел белмәгән юнан вә болгар «кардәшләребез» белән тартышу ул кадәр авыр булмаса да, ике гарәп кулында

[1] Мөтәэссир булдылар – кайгыга төштеләр, тәэсирләнделәр.
[2] Юнаннар – греклар.
[3] Тәкърар тәнбиһ – кабат кисәтү.

булган үз галәмебез, үз телебезгә каршы тору бер дә мөмкин булмады. Бу ике вакыйга безгә бик яман тәэсир итте. «Әле болар үзебезнекеләр. Аурупалылар, төрекләр, гарәпләр белән очрашканда болай гынамы булыр!!!

Менә инде син аларны кан вә дин кардәшләре дип йөре, ә безне алар бер тиенгә санамыйлар. Ашыбызны ашап, каныбызны эчәргә торалар...», – диючеләр дә булды.

Одессада көн буе йөреп арган булып, үткән вакыйгалардан бозылган нерваларыбызга истирахәт[1], йокы бик кирәк иде. Ләкин диңгездә генә була торган күренешне, кояш чыгу манзарасын[2] һәркем күрәсе килә, диңгездәге беренче кичне гафләт йокысы белән уздырырга теләми иде. Шуның өчен трюмнан чыгып, матрослар отделениесенең башына менеп урнаштык.

Кореневның акрын моңлы җырлары, һөҗүле[3], кызыклы анекдотлары бездән йокыны ерак качырды. Таң атты. Кызыллык җәелә. Диңгез сафланганнан сафлана. Һәркем кояш чыгышына юнәлгән. Менә бервакыт су өстендә күзне чагылдыра торган нур ноктасы пәйда булды, нурлары чәчелде. Су башка төс алды. Нокта акрын-акрын зурая, нурга баткан су өстенә зур нур шары чыга. Тәгәрәп китәр төсле була. Тагы бер нур көзгесе арасында тагын бер сызык хасыйл була; пароход, юлчылар, болытлар нурга батып кала. Кояш чыккач, су дуңгызлары (дельфиннар), сикереп, пароход артыннан иярә башладылар. Без, күмәч ташлап, аларны шаяртабыз.

Ул арада аркадашлар йоклый башладылар. Без дә Трубчинков белән минем мендәргә, минем пальтога төренеп яттык. Һава саф, салкынча, гомер арткан төсле була.

*Сәяхәтнамә Нургали Надиев тарафыннан язылып,*
*«Шура» журналының 1915 елгы 5 (140–143 б.), 6 нчы (175–177 б.),*
*7 нче (215–216 б.), 8 нче (248–249 б.), 9 нчы (276–278 б.),*
*10 нчы (308–310 б.) саннарында дөнья күргән*

[1] Истирахәт – ял.
[2] Манзарасын – күренешен.
[3] Һөҗүле – көлкеле, мәзәкчән.

**Г.И.**

# ТӨРКИЯДӘ БЕР СӘЯХӘТ
## *(Истанбулдагы хосусый мөхбиремездән)*

Мин хәзер иске кальга корылган тау өстендә утырам. Бу кальга (крепость) Измирдән 50, 60 сажин биеклекдәге бер тау өстенә ясалган булганга, Измир, Измирнең күрфәзе[1], күрфәздәге Румания, француз, рус байракларын күтәргән пароходлар минем аяк астымда торалар. Бөтен тарафдан Измирне чоргап алган биек-биек таулар, шул таулар арасындан сызылып кына, тараеп кына, озаеп кына киткән күрфәзнең бугазы да кечкенә кебек, әһәмиятсез кебек тоела. Измир, өчйөз мең әһалисе Измир үзенең кычкырышлы, тавышлы тормышы берлә, үзенең гайре мөтанаһи[2] урамнары берлә корамаланып-корамаланып ята. Мин хәзер шул көчле, гайрәтле диңгезгә шул өчйөз меңле шәһәргә, шул йөз миллионлы тиҗарәтле, базарлы пристаньга югартын гына карыйм. Аларга исем китми. Диңгез никадәр куәтле булса да, дулкыннары берлә, тавышлары, гөрләүләре берлә миңа килеп җитә алмый, ул минем утырган шул таза, нык тауларымны юа алмый, бөтен дөнья берлә сәүдә итә торган, бөтен дөньяга үзенең бөтен мәхсулатыны[3] сата торган, бөтен мадди вә мәгънәви байлыкларын Аурупаның капиталына фида итә торган шәһәрдә үзенең сатуы-алуы берлә миңа килә алмый. Аның да маклерлары, сатучылары, инглиз алучылары мине борчый алмыйлар. Мин һәммәсеннән – сатуыннан-алуыннан да, диңгезеннән, тавыннан, корысыннан, суыннан биек. Мин кош бакышыннан[4] бөтен дөньяны карыйм, кош бакышыннан шул тавышлы тормыштан, шул бетмәс-төкәнмәс хәят тартышыннан көлеп утырам. Менә мин тагы тырмаландым, тагы биш-алты мажин югары чыкдым. Хәзер мин иске кальганың эчендә. Безнең Казан

[1] Күрфәзе – култыгы.
[2] Гайре мөтәнаһи – чиксез.
[3] Мәхсулатыны – әйберләрен, уңышларын.
[4] Кош бакышыннан – монда: кош биеклегеннән.

крепосте кадәр зурлыкда, аңардан берничә дәрәҗәдә таза итдереп ясалган шул биек тау башындагы кальганы карыйм. Менә мин кальганың эчендә. Анының иң саклаулы, иң нык йирендә әллә ничә йөз еллар, бәлки мең еллар мөкаддәм падишаһлар, вәзирләр акланган йирдә бүген бер көтүче сарыклар, куйлар, кәҗәләр көтә. Сарыклар, куйлар да гүя шул кальга, шул туплар, мылтыклар алмый торган крепость үзләренә үлән яхшырак үссен өчен ясалган кебек итеп, кальганың хуҗасы булып, анда барып, монда килеп, ятып торып ашап йөриләр. Бер кәҗә элгәреге заманда каравылчы гаскәр өсткә чыгар өчен ясалган баскычдан крепостьның өстенә чыгарга маташа. Һәммә йирдә бушлык, һәммә йирдә хәраблык. Диварларның күбесе йыгылган, капкалар вә ишекләр җимерелгән, элгәреге кечкенә тәрәзәләр зурайган, киңәйгән, мин алга таба атладым. Әллә кайдан бер эт килеп чыгып, өрергә тотынды. Ул шул йирдә, шул көтүне генә күрергә өйрәнгәнгәдер, ахырысы, ят эш, ят кешене күреп өрергә, уларга тотынды. Анының һәр «Һам! Һам!» дигәне шул буш кальгадан кайтып килеп, шул бушлыкны тагы бушалтды, шул җансыз крепостька да тагы бер җансызлык кушды. Вакыты берлә әллә ничә мең гаскәрләр берлә сакланган, шул крепостьның бүген коры бер эт тарафыннан саклануы башымда әллә ниләр уятды. Шул крепостьны салучылар, салдыручылар, шуңарга хезмәт сарыф кылучылар, бер көн килеп дә, шул крепостьның куй, кәҗә көтүе ашар йир булуын, көне-төне саклаучы гаскәрләр шуның сакчысы япа-ялгыз бер көтүче эте булуын хәтерләренә китергәннәрдерме? Әлбәттә, юк. Бүгенге көндә безнең дә мең бәла берлә ясаган биналарымыз, корыган нигезләремез бәлки шул крепость кебек кирәкмәгән бер йир булып калыр. Бүгенге көндә бөтен көчемез, куәтемез берлә сакларга тырыша торган гадәтләремез, әхлакларымыз, мәдәниятемез дә җимерелеп, ватылып бетеп, киләчәк буынның хәтереннән чыгар. Бу дөнья – тәрәккый вә тәдәнни[1] дөньясы, бу дөнья алга китү, артка чигү дөньясы! Моңардан һәрнәрсәне көтәргә ярый! Суфиюнча әйтсәк, бу «вафасыз[2]» дөнья. Мин хәзер тырмашып, тырмаланып крепостьның

[1] Тәдәнни – артта калу.
[2] Вафасыз – тотнаксыз.

өстенә мендем. Диңгездә, диңгездәге күбекләр кебек йилкәннәрен ачкан каек-көймәләрдән армый-талмый гөрли торган Измирдән, аның биек, мәһабәт манараларындан, аның кырыендагы инглиз фабрикаларының морҗаларындан күзне аласы килми. Шул манзарадан, шул табигатьнең байлыгындан күз туймый, караган саен карыйсы килә, күргән саен шул матур дөньяның эчен, мәгънәсене аңлыйсы килә. Алдымда, артымда тезелгән таулар кояшның җәнүбкә махсус сөреме берлә капланып намәхрәмнең[1] күзеннән матур йөзен яшергән төрек кызы кебек үзенең ярларын, ярыкларын пәрдә аша күрсәтеп, тагы матурландыра, тагы дикъкатьне җәлеб итә төшә! Мин һаман карыйм, һаман шул матурлык берлә ләззәтләнәм, шул йирләрнең тарихларын уйлап төшенәм. Шуның киләчәкене уйлап бер өмидләнәм, бер өмидсезләнәм. Еракдагы валинең[2] өе башына эленгән кызыл айлы төрек байрагы акыртын гына җилбердәп миңа бер өмид бирә, бер өмидсезлек уяндыра. Мин арып-туеп крепостьның теге ягына борылым. Күз алдымда бөтенләй икенче манзара: ике якдан капланган зур таулар арасында ямь-яшел тигезлек уртасыннан бормаланып-бормаланып су ага, тигезлек корамаланып бетеп, корама төсенә кергән бер йирендә куе яфраклы зәйтүн агачлары гаскәр кебек сафланып торалар. Бер йирдә хәзрәте Хавага яфрагын биргәч, үзе ялангач калган кебек инҗир агачы шыр ялангач көенчә ботакларын туздырып ята. Бер якда вак-вак йөзем агачлары хәлфә алдына тезелгән шәкердләр кебек тезелеп яталар. Бер тарафта аклы-аллы чәчәкләр берлә капланган бадәм агачы[3] (чикләвек бирә) матур кызлар кебек үзенең исен чәчеп ята. Еракта гына ямь-яшел богдай үсеп тора. Мин якынлашам, крепостьның астына таба башымны бөгеп карыйм, түбәндә яшь кызлар, ямьсез карчыклар, пычаклар берлә кисеп, әллә нинди үлән җыялар. Крепостьның янында гына бер хатын суган чәчкән дә шуның түтәлене төзәтеп, чүбене утап ята. Әнә бер матур гына, яшь кенә кыз пычагын күтәреп үлән җыярга килә. Мин аның том-кара сачләрен, матур, нурлы күзләрен күрәм. Күземне

[1] Намәхрәмнең – чит ирнең.
[2] Валинең – губернаторның.
[3] Бадәм агачы – миндаль.

текәп карарга тотынам. Кызны агулы күзем берлә әйләндереп карарга мәҗбүр итәм. Ул да, әллә нинди бер кешене күреп, бераз карап тора да үләнене җыярга тотына. Мин тагы алдымдагы манзараны карарга керешәм. Әнә бер төтен чыга. Ул төтен якынлаша. Ул тимер юл икән. Ул Анатулыны зур Анатулыны диңгез берлә тоташтыра торган, Анатулының йөземен, богдаен, әфьюнен диңгезгә ташый торган, Анатулыга Аурупа малыны, Аурупа фикерен, Аурупа байлыгын, ахырдан Аурупа сәфаләтен[1], былчыраклыгын китерә торган тимер юл икән. Монда мәдәният дә шул юл буйлап китә, фәкыйрьлек, сәфиллек[2] дә шул тимер юллап ашыга-ашыга яңа йир, яңа ватан эзли. Мин тагы бер мәртәбә Измирне күздән кичерәм. Аның иң уртасындагы зур бер җәрәхәт кебек ачылыб ята торган җимерек яһүди зиратыны күздән кичереп, Измирнең иң урта бер йирендә генә матурланып тора торган сәрви агачлары берлә тулы мөселман зиярәтен үтеп китеп, рум[3] мәхәлләсенә туктыйм. Анда биек-биек өйләр, зур-зур сарайлар, әллә ничә мең под, бәлки әллә ничә йөз мең под мал алырлык амбарлар, ыскладлар, анда конторлар, магазиннар, анда тормыш, анда җан! Моңарга ачуым килеп, шул Анатулының бөтен байлыгын имеп торулары өчен ачуым килеп, шул ачуны онытыр өчен тагы теге матур төрек кызына карарга борылам. Ул хәзер ялгыз түгел, аның янында аның матурлыгыннан да ямьсез бер карчык басып тора. Алар сөйли, ләкин мин аңламыйм. Тагын тыңлыйм, румчага охшый, бик күп «къ», «ф» сөйләнә. Мин аларның Криддан килгән мөселман румнар мөһаҗири икәнен аңлыйм! Менә таудан төшәм, хәзер мөселман мәхәлләсендә. Урамнар тар, йортларның күбесе крепость төсле итдереп таш койма берлә әйләндерелгән, урам ягында тәрәзәсе юк, булса намәхрәм күзе кермәсен өчен бик тыгыз решеткалар берлә капланган, әнә почмакта бер кара гарәп хатыны бик күп чуерташларны яулыгына җәеп салган да, янына туктаган ике яшь кенә хатынга фалының багуының мәгънәсене сөйли. Мин аягымны сирәгрәк атлый башлыйм, бөтен көч вә колагымны би-

[1] Сәфаләтен – түбәнлеген.
[2] Сәфиллек – түбәнлек.
[3] Рум – грек.

реп тыңлыйм – диңгез аша сәфәр күренә дигән сүзне ишетеп үтеп китәм. Менә бик кычкырып бер карт төрек әфлисун сата. Тагы бер почмакта бер кара гарәп хатыны куырган борчак, чикләвек, кәләвәләр сата. Әнә алда гына бик күп бала күренә, әллә нинди көйләр берлә ерлый, укый торган бала тавышы ишетелә. Күземне күтәреп карасам, ирләр, кызлар бергә укый торган бер мәктәп күрәм. Мин тагы борылам, күз алдыма зур хәреф берлә язылган тиҗарәт мәктәбе дигән сүз сугыла, капкадагы кешедән сорашып, иртәгә килергә булып китәм. Менә базарда кырык төрле тавыш берлә кычкырып хәлвә, әфлисун, лимон, катык, хөрмә, коры йөзем, чикләвек, куырган борчак саталар. Бу мөселман базары, монда магазиннар юк, кибетләр кечкенә, былчырак. Алучы, сатучы төрек, мин тагы үтеп китәм. Бер зиярәт өстенә үскән зур бер хөрмә агачыны күреп туктап карарга тотынам. Хөрмә агачын кулым берлә тотып карыйм, исним, каты булганга тешем берлә чәйним. Быел монда кыш бик суык булганга, аның бик күп яфраклары корыган, ул картайган кеше кебек моңаеп тора. Мин аны кызгансам да, кулымнан берни килмәгәнгә, үтеп китәм. Мин хәзер, әфәнделәр, яһүдиләр мәҗлесендә. Алар монда безнең Русиядә белдекемез яһүдиләргә төс җәһәтеннән дә, тел ягыннан да охшамыйлар, болар өч-дүрт йөз ел элек Испаниядәге инкизисьюн[1] золымыннан качып килмешләр. Телләре Испания теленең бозыгы булса да, төрекчә дә төрек кадәри беләләр. Йөзләре, кыяфәтләре дә Русия яһүдләренә бик аз охшаган, икълим[2], һава, тирә-як боларны Төркия төсенә керткән. Болар аз гына төреккә, аз гына румга охшый торган бер милләт булганнар. Ләкин хатыннарының матур күзләрен икълим дә, һава да бетерә алмаган. Менә зур бер өйнең эчендә вак-төяк бүлмәләргә бүленеп утырган яһүди җәмәгатьләр, башына хәфтәдән теккән такыя кигән (бу такыя никах галәмәте имеш, никахлы хатын моны сала алмый имеш) хатыннар керләр юалар. Зур, калын толымнарын артка җибәреп утырган таза, нык кызлар машина[да] эшлиләр. Кәвеш-ботинка тегәләр. Менә миңа каршы бер көтү яшүсмер яһүди кызлары киләләр, алар барысы

[1] Инкизисьюн – инквизиция.
[2] Икълим – климат.

да кара алъяпкычлар япканнар, икешәр-икешәр кулга-кул тотынып, көлешә-сөйләшә киләләр. Болар – инглизләрнең палас фабрикасыннан эштән кайтучы эшче кызлар. Әнә тагы бер дөркем вак-төяк яһүди балалары букчалар күтәргәннәр, фәсләр кигәннәр төрек мәктәбеннән дәрестән кайталар. Болардан зур сатучылар банкирлар булса да, монда боларның иң күбесе – фәкыйрь эшче. Болар бу вакытка кадәр төрекләрнең башларына бәла чыгарганнары юкка, нә румнар, болгарлар кебек Юнан, Болгарстан мәмләктенә кушылырга уйлаганга, нә әрмәннәр, гарәпләр кебек үзләренә мөстәкыйль әрмән мәмләкәте, гарәп хәлифәлеге ясау фикере артыннан йөрмәгәнгә, төрекләр үзләрен яраталар. Алар монда бөтен хокукта башка милләтләр берлә тигез. Җитте түгелме – мин Измирнең иң зур, иң бай Фрәнк базары дигән базарын үтеп, рум мәхәлләсенә китәм. Фрәнк базарында зур магазиннар, безнең Петербург, Мәскәүдәге кебек зур кибетләр, биек-биек зиннәтле өйләр, киң урамнарга башка бернәрсә юк, боларның берсе дә төрекнеке түгеллеген кушсаң, төрек мәмләкәт хуҗасы була торып та, кунак төсле генә, хатынына корсет, ботинок, кружева алырга гына килеп китүен искә төшерсәң, болар ачу китерүдән башка фикер уятмый. Һайди[1], алга! Менә монысы – рум мәхәлләсе, менә шул озын урамнар, шул тәрәзәләре, ишекләре тимер решетка берлә тазартылган зур таш өйләр – рум өйләре! Әнә, тәрәзәдән дүрт шалкан кебек җиткән кызлар карап торалар, әнә, каршыдан зур гәүдәле, таза тәнле мул күкрәкле, киң очалы[2] рум хатыны килә. Әнә, аның артыннан тагы берсе алды-арты үсеп килә торган дүрт баласы берлә үтеп бара, менә 11, 12 яшьлек рум кызлары! Битләре никадәр бала булса да, күкрәкләре, билләре хатынлык дәрәҗәсенә чыкканнарын күрсәтеп тора. Менә унөчдә бер кыз тәмам тулган, җиткән кыз булган! Бу хатыннарны табигать бала табарга, үстерергә генә яраткан кебек, балага кирәкле әгъзаларны, ирләрне кызыктырыр өчен кирәкле йирләрне бик тулы мул биргән! Шуның өчен болар румнарга батыр-батыр бала тудырып яталар, рум милләтен көннәнкөн күбәйтәләр. Ышанмасаң, әнә шул өйгә кара, мыек чыгып

[1] Һайди – әйдә.
[2] Киң очалы – оча сөякләре киң.

килә торган, яше кырык бишләргә җитсә дә һаман таза, һаман нык шул рум хатыны янына, үзенә охшаган үсеп килә торган өч егет, дүрт тулып йиткән кыз утырган! Ул гына түгел, күршесенә дә кара, анда да шулай ук аның теге ягында да шулай, бөтен рум мәхәлләсендә шулай! Менә шул румнар берлә төрекләрне чагыштырыр өчен кебек, язмыш дүрт төрек хатынын каршыма китереп бастырды, аның берсе – карчык. Битләре җыерылып бетсә дә, өстенә чаршау кигән, мине күргәч тә гүя матурлыгына кызыкмыйм дип, битенә чаршауны япты. Икенчесе яп-яшь, зифа, нечкә билле, нечкә муен ап-ак булып, матураеп күренеп тора, ләкин бөтен килеше, килбәте бала үстерергә ярап йитәрлек кебек тоелмый. Хатынлык галәмәтләре үсеп йитмәгән кебегрәк калган! Менә ул тирен сөртергә дигән булып, матур күзен күрсәтер өчен, чаршауны ачты. Күзе генә түгел, үзе, йөзе дә матур. Ләкин йөзе ап-ак. Кан әсәре юк. Төрмәдә ун ел ятып, бу көнгә чыккан дип белерсең! Әнә, чаршауга тыгылган ундүрт яшьлек бер кыз ул да икълиме һаваның тәэсире берлә никадәр үсеп җиткән булса да, ул да теге рум кызы кебек мул түгел, аның йөзендә моңлык бар. Рум кызы кебек аның бөтен әгъзалары ана булам дип кычкырып тормый! Әнә, ире берлә генә килә торган авыл хатыны. Аның да бөтен эше кырда, бакчада, ачыкда булса да, ул да бик ямьсез кара чүпрәкләргә бөркәнгән дә, башына бик зур, үзенә кәфенлеккә җитәрлек ак яулык берлә башын, йөзен өреткән, алдын-артын күрә алмаенча куркып-куркып кына басып килә! Аның да йөзенә әллә нинди кысылулык, хаксызлык чыгып тора, аның да йөзе ачык, көләч түгел, инде кая китим! Әллә әнә Измирнең Каршы яка дип йөри торган инглиз мәхәлләсенә чыгыйммы? Зур-зур бакчалар, бакчаларның эчләрендә салкын су атып тора торган фонтаннар – бакча уртасында гына зур тәрәзәле чәчәк кебек иттереп эшләнгән өйләр, болар да монда килеп оҗмах ясамакчы булганнар, болар да Измирнең иң матур йирләрене алып, табигатьнең шул матурлыгына чәчәк, гөл, хөрмә, сәрви агачы кушып, тормышларын оҗмахка әвергәннәр.

Монда төрекләр юкмы? Бар әфәндем, бар! Әнә шул эшчиблит[1] чистартучы төрек, шул каекчы төрек, шул почтада хатлар

[1] Дөресе: штиблет.

алып торучы 250 горушлык жалование алучы да төрек. Әллә тагы төрек мәхәлләсенә китимме? Андагы фәкыйрьлек, андагы мескенлек, тагы эчемне поштырачак түгелме? Андагы төрмә кебек өйләр, андагы кара кәфеннәргә сарылган хатыннар, анда якты кермәсен өчен тәрәзәләргә ясалган решеткалар, андагы тар урамнар үз мәмләкәтендә хуҗа булып тора алмаган төрекләрне бер тарафтан кызгандырып, бер тарафтан ачуны гына китермәсме? Ташлыйм, туйдым. Иртәгә мәктәпләр, газета идарәләрене, мәдрәсәләрне, җамигъларны[1] карыйм! Бүгенгә җитәр түгелме? Хуш, сау булыңыз.

*Измир. 6 март.*

Тугызынчы март. Сәгать 11 ләр. Без Солтан җамигысы дигән Кануни Солтан Сөләйманның анасы салдырган мәсҗеднең йортына килдек. Йорт шыгрым халык берлә тулган, яшьләр, картлар, авыл халкы, шәһәр халкы – һәммәсе дә монда. Җамигъның зур йортының тирәсе мәдрәсә берлә әйләндерелгән булганга, йорт зур бер зал кебек күренә. Уртасында бик җуан, калын чинар агачлары үсеп яталар. Аларның җуанлыклары, ботакларының озын зурлыклары читтән кешенең исен китәрерлек. Шуларның берничәсенең ботакларына шәкертләр менеп утырганнар да, алларында камыш капчыклар тотып торалар. Мәдрәсәнең бөтен түбәләренә, җамигъның да түбәсенә шундый капчык тоткан шәкертләр, җамигъның мөәззиннәре тезелгән. Мәсҗед йортының иң урта бер йирендә зур су чанының (тәһарәт алыр өчен һәр җамигъның йортында зур чан була, аның тирәсендә әллә никадәр крантлар була) түбәсенең ике ягына ике шәкерт менеп утырып, текә түбәдән шуып төшмәс өчен, икесе дә фонтанның иң түбәсендәге айга (хәлфәгә) үзләрен җепләр берлә бәйләп куйганнар. Халык улый, җулый. Матур язгы кояш шул кырык төрле киемдәге халыкның җиз төймәләрен, билләреннән чыккан пычак сапларын, зур ат тышавы калынлыгы сәгать чылбырларын җем-җем итдереп ялтырата. Озын манараларга менгән мөәззиннәр, шәкертләр бер туктамаенча сузып-сузып салават укыйлар. Халык күбәйгәннән күбәя бара. Менә без теге капчык-

[1] Җамигъларны – мәчетләрне.

лар берлә әллә нәрсәләр тоткан шәкертләр, мөәззиннәр янына мәсҗеде җамигъның түбәсенә чыгамыз. Минем күз алдымда бөтен Мәгъниса күренеп тора. Аның артында озын иттереп апак сузылып, Гәдүс елгасы борылып-бормаланып ята. Кай якка карасам да, ямь-яшел зәйтүн берлә тулган аллы-гөлле чәчәккә чумган бадәм агачлары берлә капланган тигезлек күрәм. Ерактаеракта гына таулар күренә. Аяк астымда җамигъ йортында дүртбиш меңле кеше, югартыннан караганда, кырмыска кебек кайный. Күземне сул якка борам. Ул якдагы зур мәйданында кара чаршафлы[1], зәңгәр чаршафлы, ал чаршафлы, башына ак яулык япкан, кара башлык кигән хатыннар. Кайсы-берсенең күтәргән аллы-гөлле зонтиклары шул дүрт-биш мең хатын җыенын, югартын караганда, кырык төсле чәчәкдән ясалган зур бер букет кебек күрсәтә, ләкин ул букет сөйли, тавышлы, ул букет туктамаенча яңгы матур чәчәкләр, карт кычырткыннар берлә зурая, киңәя. Уртада көтү-көтү балалар чабышып, кычкырышып уйнап йөриләр. Мәйданның ике тарафында да атлы жандармалар шулкадәрле букетны ирләрнең сугылуыннан, араларына кереп, шул бер төрлелекне бетерүдән саклыйлар. Мөәззиннәр һаман озын тавышлар берлә салават укыйлар. Менә без капчыкка әллә нәрсә тутырган кешенең янына киләмез, ул капчыкыннан алып простой кәгазьгә төргән җуан мужик канфит кебек бер нәрсә бирә. Бу – мәсир[2], бөтен шул мәйдандагы ун-унбиш мең халык, бүген шуның берсен алыр өчен, иртәдән бирле көтәләр, шуны алыр өчен, әнә шул озак авыллардан ирләр, хатыннар, балалар килгәннәр. Әнә шуны алыр өчен читлекләреннән чыгып, бөтен шәһәрнең хатыннары урамга тулганнар. Үзләренең әйтүләре буенча мәсир кырык бер төрле шифалы үләннәрдән ясалган, әлбәттә, җитмеш җиде төрле авырудан файдалы. Мин аны кәгазьләреннән аерып, каеп карыйм: борыч, имбир, дарчин, канәфер, шикәр тагы мин белмәгән әллә никадәр тәмнәр! Менә өйлә вакыты җитте. Мөәззиннәр азан әйтәләр. Намаз башланды.

---

[1] Чаршафлы – чаршаулы.

[2] Мәсир – мәсир мәгъжуны – шифалы үләннәрдән һәм тәмләткечләрдән әзерләнгән паста. Мәгниса шәһәрендә үткәрелгән бәйрәмнәрдә мәсир атышу уены булган.

Ирләр мәйданында да, хатыннар мәйданында да халык күбәйгәннән күбәя бара. Менә җамигъ башындагы бер кеше «Фатиха!» дип кычкырды. Миңа намаз укып бетергән голямалар халык алдына чыгып шул мәсирнең шифалы булуы хакында дога кылалар, диделәр. Теге кеше «Фатиха! Фатиха!» дип кычкырды, халык «Амин! Амин!» дип җавап бирде. Шул сүзне ишеткәч, хатыннар мәйданы команда ишеткән кебек бердән үзгәрде, никадәр зонтиклы хатын булса, барысы берьюлы кебек зонтикларының эчен югары каратып тоттылар. Мин элгәре аңламасам да, ахырдан шул югартын ыргытылачак мәсирне тотар өчен икәнен белдем. Менә теге абзый «Амин!» диде. Бөтен түбәдәге кешеләр берәмләп-берәмләп мәсир ыргыта башладылар. Ирләр ягында бердән дүрт-биш мең кешенең кулы югары күтәрелде, зур бер рәхмәт көткән кебек аларның ялтыраган күзләре ыргытучыларга тегәлде. Тавыш куәтләнде. Бер мәсир йиргә таба иңә башлагач та, шул әллә ничә меңле халык шуңарга таба тау кебек ишелергә өлгермәде, икенче якга ыргытылган икенче мәсир аларны икенче тарафка борды. Кычкырыш-талаш куәтләнгәннән куәтләнде. Егылдылар, тордылар, шул кеше диңгезе төрле якка дулкынланудан туктамады. Бара-тора зур, таза ирләрнең битләренә тирләр чыкты, маңлайларыннан су ага башлады, ләкин алар аны сизмәенчә дә, мәсир өчен тартышу, кычкырышуда дәвам иттеләр. Менә бер читтәге кеше тотты. Аның күзе ялтырады, авызы колакларына кадәр ерылды. Алтын кош тоткан кебек мәсирне зур билбауының эченә тыгып, яңгы гайрәт берлә тагы тоту мәйданына атылды. Хатын-кыз ягында да кычкырыш-тавыш зурайды, бая букет кебек күренә торган аларның җыеннары бер туктамаенча бер җиргә иелеп, бер күтәрелеп торганга, бер-бер якка таба, бер икенче якка таба чабып килгәнгә, букет төсен бетерде. Менә мин дә ыргытучылардан мәсир алдым, ыргытмакчы булам. Ләкин мин моңганчы тота алмаганына тоттырмакчы булам. Әнә ун-унбиш бала-чага баядан бирле йөрсәләр дә, зурлар аркасында тота алмаганнар, мин шуларга ыргытам. Ераклыгыны белеп, үлчәп бетерә алмаганга, минем мәсирем бер кызның алдына килеп төшә!

Аның күршесендәге бер кыз кулы берлә ишарәт итеп: «Миңа ат, миңа!» – дип кычкыра.

Мин атам, тагы яңлыш китеп, бер бик ямьсез ак яулык ябынган хатынга барып төшә. Мин, ачуланып, тагы теге кызларга атам, менә аларның берсе тотты. Ул көлеп миңа рәхмәт укый. Мин тагы гайрәтләнеп ыргытмакчы булам. Күзем берлән кая дип карарга тотынам, шундагы тынычлыкны саклар өчен куелган атлы жандарма кулын бутап: «Миңа! Миңа!» – дип кычкыра. Аның астындагы аты да урынында тора алмаенча бийи. Мин эчдән кешеләрнең ничек үзләрен-үзләре онытуыннан көлеп, аңарга ыргытам. Жандарма кулларын күтәрә, аты берлә алга-артка күчә, ләкин бәхетсез икән, мәсирне бер малай каба. Менә мин тагы кулыма мәсир тутырып, аз эләккән йирләрне эзлим. Бик ерак тора торган, бик бөркәнгән хатыннарны күреп, аларга таба ыргытам, моңганчы бик вәкарьле тора торган шул хатыннар бердән кыймылданырга, селкенергә, куллары берлә буташырга тотыналар. Мәсир өй түбәсенә эләгеп төшми кала. Халыкның тавышы һаман азламаса да, ыргыту әле һаман бетмәсә дә, без җамигъ башыннан төшәмез. Йорттан халыкны көчкә ерып, урамга чыгамыз, урамда да юл юк, кысыла-кысыла киңрәк урамнарга үтәмез. Бөтен урам буе сатучылар «Мәсир!», «Мәсир!» дип кычкырып торалар. Болар ялган мәсир, тәкълид[1] мәсир саталар. Әлбәттә, бу мәсирнең шифасы да юк, хаҗәте дә юк. Бу балалар алдар өчен генә – моны тегендә, бәхетенә тугры килмәгәннәр генә, балаларны шатландырыр өчен генә алалар. Менә берсе чын мәсир, тотылмаган мәсирне сата! Аның бәһасе ике горуш! Бара-тора биш горуш, ун горуш, хәтта егерме горушка кадәр чыга. Без урам буйлап йөри-йөри арып бетәмез. Кая карасаң халык, кая карасаң мәсир сатучы. Мин мәсирнең тарихы хакында мәгълүмат эзлим. Ахырдан берсе: «Бер вакытны солтан вәлидәләреннән[2] берсе авырган икән. Бер «дәдә» (дәдә – бәгъзе тарикларның дәрвишләре) әллә ничә төрле үләннән ясаган даруны биргән дә, падишаһның анасы терелгән. Вәлидә шуның берлән халык файдалансын өчен, шул даруны җамигълар башыннан халыкка чәчәргә кушкан, һәм дә вәкыф калдырган», – диде. Ләкин аны тик иранңарның яңа ел көнендә ясаганнар. Әлбәттә,

[1] Тәкълид – чын булмаган.
[2] Вәлидәләреннән – аналарыннан.

монысы бу гадәтнең иराннардан калган икәнен белдерә. Элгәре шул мәсирдән солтан өчен дә аерым мәсир ясап, махсус бер һәйәт[1] берлә Истанбулга солтанга да җибәрәләр икән. Аңарга берничә йөз лиралар акча тоталар икән, хәзер ул беткән. Мәсир Мәгънисаның вә Мәгъниса тирәсенең генә даруы булып калган.

Унынчы мартта без «Иттихад вә тәрәккый» җәмгыяте тарафыннан ачылган бер мәктәпне карыймыз. Мәктәп рөшди[2], ибтидаи[3] генә булса да, шактый яхшы иттереп куелган. Мөгаллимнәр тырышып укыталар. Иң гаҗәбе шул: әлифба кыйсемендә бер мөгаллим ысулы сәүтия[4] берлә укыта башлаган. Моның ысулы сәүтиясе һәр нәкадәр бездәге кебек эшләнеп бетмәгән булса да, Истанбулда, Измирдә, Сәланикдә булмаган бу яңа ысулның татбикы[5] – әлбәттә, алга таба бик зур адым. Мин аның төрек әлифбасы берлә гарәп әлифбасын аермаудан килгән бәгъзе бер авырлыкларын күрсәтеп, ике әлифбаны аеруны монасиб икәнен сөйлим. Ләкин мөгаллимгә аңлата алмыйм. Мәктәпнең мөдире дә, минем шул фикеремә каршы, әллә нинди мантыйксыз җаваплар бирә. Ахырдан мин боларның халыктан куркудан алтыйиде яшьлек балаларга тәшдидләр, тәнвиннәр[6] бикләтүләрен аңлап, тешемне кысам. Рөшдинең зур сыйныфына гарәпчә укыталар, мөгаллим алар берлә гарәпчә сөйли, алардан гарәпчә җаваплар ала. Рәхмәтләр укып, мәктәпнең тәрәккыйсен теләп чыгып китәмез. Менә без хәзер шәһәрдә алты-йиде чакрымнар «Боз көе» дигән авыл юлында. Юл тау буеннан барганга, әллә кайчан шасси булган, ләкин хәзер җимерелеп, бозылып беткән. Авыл күренсә дә, без тугры юлны сорар өчен йөзем бакчасын йомшартып тора торган бер бабайга сәлам бирәмез вә бабай сәлам алып: «Мәрхабә, боерыңыз», – ди. Үзе кәтмәнен ташлап, безгә каршы килә. Без койма кебек иттереп юл буена өстерәлгән чатырлы чыбыклардан үтеп, бакчага керәмез. Бабай-

[1] Һәйәт – делегация.
[2] Рөшди – урта.
[3] Ибтидаи – башлангыч.
[4] Ысулы сәүтия – аваз методы.
[5] Татбикы – ярашуы.
[6] Тәшдидләр, тәнвиннәр – гарәп язуында хәреф өстенә яисә астына куела торган махсус тамгалар.

ның янына утырамыз. Бабай сораша. Минем русиялелегемне белгәч: «Озак икән! Кырымдан?» – ди. Мин: «Юк, бабай, тагы озаграк, Казаннан», – дим. Бабай: «Батум ягыннан икән», – ди. Мин бабай берлә җәгърафия моназарасына керешәсе килмәгәнгә, «әйе-әйе»; дип сүзне бетерәм. Бабай менә, язмыш, дип капчыгын тишәргә тотына да, капчыктан корыган инҗирләр түгә. «Менә мин моны кичә ашамакчы булган идем, әллә нәрсә сизгән кебек, күңел тартмады, бүген менә кырга ашарга дип алып киләм, бу үз инҗиремнең былтыргы корытылганының иң актыклары, менә кемгә насыйп булган икән! Маскуфтан[1] килгән мосафирга! Менә Аллаһының кодрәте!» – диде дә, чын да үзенең күңеленең уйлавын тикмә тигәнгә булмаганга шадланган кебек булды. Ун-унбиш минут бабай янында утырып күрешеп, авылга киттек. Таудан ага торган инеш янына, тау битенә утырган авылга барып җиттек. Төрек авылларында бик күп эт (көчек) булганга – зур-зур агачлар күтәреп авылга кердек, юлда тугры китергән бер-ике малайны алып, авылның читенә киттек. Авылның да өйләре шәһәрнеке кебек, тирә-ягынннан таш койма берлә тотып алган да, йортның түренә генә өй салып куйган. Малайлар безне мәсҗед, мәктәп янына илттеләр. Мәсҗедкә кердек. Авыл өчен шактый пөхтә, пакь иттереп эшләнгән. Мәктәпкә киттек. Мәктәпнең бер бүлмәсе мөгаллим өчен аерылган, бер бүлмәсе килгән мосафирлар өчен, бер бүлмәсе уку өчен ямалган. Тәбәнәк парталар өелеп куелган. Нә китап шкафы, җәгърафия хариталары, берсе дә юк. Идәне былчырак, тузанлы. Мөгаллим, тугрысы хуҗа әфәнде мулла да булып тора, балалар да укыта икән. Ләкин бүген мәсирнең икенче көне булганга һәм дә Мәгънисада базар булганга, өйдә юк икән. Башка бер-бер кеше юкмы дип сорадык, барысы да йә базарда, яисә кырда. Авылда хатыннар да балалар гына калган. Балалардан яздырып, укытып карадык, яза-укый беләләр. Җәгърафия, тарих-фәлән белмиләр. «Кызлар да бергә укыймы?»– дип сорадык, «Бергә» – диделәр, ләкин аларга язу өйрәтмиләр икән. Урам буйлап киттек, урам уртасында ун-унбиш бергә җыелып утырган хатыннарга очрадык, алар безне күргәч дә, шундагы капкалардан йортларга

[1] Маскуфтан – Россиядән.

яшеренделәр, һәммәсе дә бездәге иске ирләр чалбары кебек киң бөрмәле чалбарлар кигәннәр дә күлмәкләрен чалбар астына тыгып бәйләгәннәр. Башларында ак яулыклар, аяклары йә ялангач, яисә ялангач аякка агач башмак кигән. Киемнәре бик ямьсез. Төрекләр никадәр кунакны сөйсәләр дә, ирләр өйдә булмаганга, әлбәттә, безне кунак итә алмадылар. Без шуларның нәрсә ашаганнарын белер өчен, янымыздагы малайга акча биреп: «Ашарга бер нәрсә алып кил», – дидек. Малай зәйтүн берлә икмәк алып килде. Икмәк богдай онынннан пешерелгән, шактый ак. Ләкин ул шулкадәр тәмсез, шулкадәр чи, аны ашау мөмкин түгел. Зәйтүн дә, шәһәрләрдә күрелгән зәйтүн кебек түгел. Ул да бик тәмсез, яртылы черегән. Мин шул шәһәрнең янындагы авылда икмәк пешерә белмәүгә гаҗәпкә калам. Сөт, катык сорамаенча – мөгаллимгә визитный карточка калдырып китәмез. Кем белсен, бәлки хуҗа әфәнде кайтып, визитный карточка күргәч: «Мөфәттиш[1] килгән икән» – дип коты очкандыр. Авылның читендә бик матур зур зиярәт, аның тирәсе бик яхшы тотылган, өстенә әллә никадәр сәрви агачлары утыртылган, бик күп ташлар кадалган. Ташлар өстенә яулыклар, чүпрәкләр бәйләнгән. Янымдагы ыстудент[2] ташның башыны кеше башы төслерәк, кеше муены кебек казып ясалганыны күрсәтеп, бу яшь зиярәте ди, икенче бер ташның башына фәс кигезеп куйганына күрсәтеп, монысы ирнеке, тагы берсенә күрсәтеп, монысы тагы хатынныкы ди. Мин хатыннар-кызлар өчен куелган ташларның матуррак, нечкәрәк иттереп, бигрәк муен сурәте ясап куелганын өйрәндем. Икенче юлдан кайтып, бер тауның өстендә искедә чиркәү булган, хәзер мәсҗедкә әверелгән сәгатьле җамигъны карадык. Аның манарасына чыктык. Аннан кайтуымызда безне Мәгънисаның бәләдия[3] докторы татар Мөхәммәд әфәндедән өенә чакырып, записка көтеп тора иде. Киттек. Казан пәрәмәче берлә зур кайнап тора торган самавыр берлә бик озын чәй эчтек. Анатулының уртасында, төрек мәдәниятенең эчендә шул татар хәяте бик кызык, бик үз төсле күренде. Мөхәммәд әфәнде Русиядән егерме-егерме

[1] Мөфәттиш – тикшерүче, ревизор.
[2] Дөресе: студент.
[3] Бәләдия – муниципалитет.

биш ел элек килгәнгә, Русия хәбәрләрен ара-тирә генә ишеткәләгәнгә, бик ихлас берлә сорашып утырды. Казандагы тәбдилләрне[1] ишетеп, бик шадланды. Менә мин хәзер Мәгънисаның күреләчәк йирләрен карап бетердем. Кич берлә тагы дүрт-биш кешегә кунакка барып, иртәгә китәргә хәзерләнәм.

*12 март. Истанбул*

Мин тагы Измирдә. Мине Измирнең баш мөстантыйкы[2] татар Гыяс әфәнде көтеп тора икән. Аның берлә бераз йөрдек, күрештек. Тагы аның өенә барып, самавыр белән чәй эчтек. Ул татар әхвәлене бик ихлас берлә сорашты. Мәмләкәтне бик сагына икән!. Бала-чагасы шактый күп булганга, «кайта алмыйм инде» дип кайгырды. Татарлардан доктор Габдрахман әфәнде һәм дә аның агасы бер карт доктор (исемене оныттым) берлә күрешеп килгән юлым берлә Истанбулга китәрем.

* * *

«Измир, Измир» дип эш бетми. Әлбәттә, анда төрек тә бар, рум да бар, яһүди дә бардыр. Ул Измир диңгез буенда да булыр, корыда да булыр. Ләкин син ник ул Измирнең кайдан килгәнене кайвакыт бина ителгәнене, кемнәр тарафыннан фәтех ителгәнене[3] язмыйсың, дия torгансыз. Хакыңыз бар.

Тугрысын әйтсәм, моңганчыга кадәр Измир хакында тарих вә икътисади мәгълүмат булырлык бер әсәр таба алмаган идем дә, Измирнең өстеннән көн бакышыннан очкан идем. Менә хәзер бер китап таптым, ләкин монда да мәгълүмат тулы түгел. Нә исә белгәнемне языйм. Измир шәһәренең кайчан бина ителгәне тарихка мәгълүм булмаса да, моннан өч мең ел элек Измир шәһәренең дөнья йөзендә барлыгы мәгълүм. Тарих белә башлаган вакытта Измир Лидия хөкүмәтенең бер шәһәре булган. Алар мөнкарыйз булгач[4] та, фарсыларның кулына кергән. Искәндәр Македони да шул шәһәрне үз мәмләкәте эченә

[1] Тәбдилләрне – алмашынуларны.
[2] Мөстантыйкы – тикшерүчесе.
[3] Фәтех ителгәнене – яулап алынуын.
[4] Мөнкарыйз булгач – инкыйразга дучар булгач.

кертмәенчә калдырмаган. Тарихның көпчәге башка тарафка таба әйләнә башлап, дөньяның иң куәтле мәмләкәте Рума[1] булгач та, аларда тиҗарәт җәһәтеннән шул кадәр әһәмиятле Измиргә кул сукмаенча үтә алмаганнар. Ул гына да түгел, Рума мәмләкәте Шәрык вә Гареб императорлыгы исеме берлә икегә аерылган да, Измир никадәр Румадан Истанбулга якын булса да, үзләренең кулларында калдырырга муаффәкъ булганнар[2]. Ләкин дөньялар үзгәреп киткән, моңганчы падишаһлык тоткан халыклар инкыйразга йөз тоткан кебек, уйламаган йирдән яңгы милләтләр, яңгы кавемнәр мәйданга килгән. Анатулыга төрек кавеме йирләшә башлаган, сәлҗүк солтаннарыннан берсе 1048 миладидә Измирне сугышып алган, шуннан соң Истанбул императорлыгы бер мәртәбә тагы Петранс[3] мәмләкәтенә кушарга муаффәкъ була алса да, икенче сәлҗүк төрекләренең солтаны тагы Измирне каптыра алган. Шуннан соң һичбер вакыт төрекләрнең кулыннан чыкмаган, шул тирәләрдә госманлы төрекләре мәмләкәт ясый башлагач та, солтан Урхан Гази, сәлҗүкләрдән алып, Госманлы мәмләкәтенә кушкан. Шул көннән бирле Измир госманлыларның кулыннан ычкынмаган. Шул сигез-тугыз йөз ел мөселман кулында зурайган, үскән шәһәр, әлбәттә, бөтенләй мөселманлашып йиткән. Әллә никадәр мөселманлыкка махсус биналар, даирәләр, мәхкәмәләр мәйданга китергән. Шул озын гомердә шул шәһәр Төркия хөкүмәтенең иң мәшһүрләреннән һәм дә сату-алу җәһәтеннән Истанбулдан кала беренчелек дәрәҗәсенә кадәр барып җиткән. Бүгенге көндә дә Измир шәһәре – Төркиянең иң зур шәһәрләреннән, иң зур сату-алу мәркәзләреннән берседер. Хәзер Измирдә 53 җамигъ бардыр. Җамигълар Истанбул җамигълары рәвешле бина кылынса да, Айя-Суфия, Солтан Фатих, Солтан Әхмәд кебек зур булмаенча, Истанбулның икенче дәрәҗә җамигълары кадәр генәдер. Боларның барысы да бик матур, яхшы иттерелеп бина кылынган вә күбесе янына мәдрәсәләр дә ясалганнар. Ул җамигълар гына җитеп бетмәгән

[1] Рума – Рим.

[2] Муаффәкъ булганнар – ирешкәннәр.

[3] Монда Бизанс (Византия) мәмләкәте күздә тотыла булса кирәк (*Г. Ханнанова иск.*)

булырга кирәк, бишвакыт өчен кечкенә 51 кадәр мәсҗед дә бина ителгән. Бу мәсҗедләр, җамигъларның зур-зур вакыфлары булганга, һәркайсы бик яхшы каралып тәрбия ителәләр. Җамигъларның янында бина ителгән, вә әллә никадәр вакыфлары калдырылган 15-20 кадәр мәдрәсәләр дә бар. Ләкин мәдрәсәләрдә уку-укытуның ысулы бик иске булганга, мәгълүмат иясе булыр өчен бу мәдрәсәләр эшкә ярамаганга, Габделхәмид гасырында гаскәрдән качар өчен (taләбә гаскәргә бармый иде), әллә никадәр шәкертләр тулса да, хөррияттә имтихан мәҗбүри ителгәч тә, бик күбесе качып беткән, мәдрәсәләр буш калганнар.

Бөтен шул мәдрәсәләрдә 150 кадәр шәкерт юк. Булганының күбесе дарелмөгаллимингә кереп, мәдрәсәне фатир итеп кенә торалар. Бу мәдрәсәләр элгәре дә хөкүмәтнең ихтыяҗатын үтәргә җитмәгәнгә, элгәредән үк игъдади мәктәбе, сәнагать мәктәбе ачылган булган. Хөррият игълан ителгәч, төрек кавемене румнар, яһүдиләрдән артта калдырмас өчен, әллә никадәр мәктәпләр ачарга лөзүм[1] күрелгән. Өч ел эчендә биш-алты хосусый игъдади мәктәбләре ачылган, бонларның иң әһәмиятлесе – «Иттихад вә тәрәккый» фиркасе тарафыннан ачылган тиҗарәт мәктәбедер. Үземез кебек сатуның мәркәзендә төрекләрнең бер тиҗарәт мәктәпләре булмавы бик зур гаеп булганны белеп, төрекләрне сату-алуга алыштырып, ач карга кебек хөкүмәтнең күзенә карап «урын бир!» дип торудан котылыр өчен, «Иттихад вә тәрәккый» фиркасе бик һәйбәт мәктәп тәэсис иткән[2], әле яңгы булганга ул кадәр ныгып җитә алмаган булса да, бу ел бинасына эшләвенә 25 мең лира акча бирелгәнгә (җәмгыятьтән, хөкүмәттән түгел), өч-дүрт сәнәдән[3] мәктәпнең Измирнең иң шәп мәктәбе булуында шөбһә юктыр. Бу ел 250 кадәр бала укыса да, урын-йир булса, тагы шуның кадәр өч-дүрт мәртәбә арту ихтималы бик якындыр. Шунысы гаҗәп, «Иттихад вә тәрәккый» фиркасе шул мәктәбе аркылы рум, яһүди, әрмәниләрне дә төрек мәктәбенә алыштырыр өчен, кирәгеннән артык французчага әһәмият бирсә дә, яһүдиләрдән башка һичбер кергән кеше булмаган. Әрмәниләрдән

[1] Лөзүм – кирәк, тиеш.
[2] Тәэсис иткән – оештырган.
[3] Сәнәдән – елдан.

бер бала керсә дә, ул да чыккан. Румнардан нә кергән, нә чыккан! Измирнең сәнаигъ[1] мәктәбе дә начар түгел. Хөкүмәтнең искедән калган игъдадиясе[2] дә, хәзер программасы киңәйтелеп, мәктәп төсенә кертелгән. Боларга башка дүрт-биш данә хосусый игъдади мәктәпләре булса да, әллә нигә Төркиядә Русиядәге кебек хосусый мәктәпләр шәп булып китә алмыйлар. Һәр мәхәлләдә балалар өчен билгеле ибтидаи мәктәбләр дә барлыгын безнең күргән «хәдикател-вилдан» мәктәбе кебек булсалар, боларның булуыннан булмавы кырык мәртәбә артыктыр «хәдикател-вилдан» мәктәбенең исемене ишеткәч, сез балаларыңызны шул «балалар оҗмахына» кертергә бәлки ашыгырсыз, ләкин безнең шул мәктәпнең мөгаллимнәре безнең иске мәдрәсәләрдәге «суфи абзый»лар берлә бер «дарелмөгаллимин»дә педагогия укыган икәнен, шул мәктәпләрдә иң шәп ысул баланы кыйнау икәнене белсәңез, үз күзеңез берлә шул «балалар оҗмахы»нда, балаларның шул зобани мөгаллимнәрдән бәла чиккәнене күрсәңез, моның «балалар тәмугысы» икәнендә шөбһәңез калмас иде. Мин шулкадәр зур шәһәрдә, шундый безнең иң иске авылларда гына калган ысулы кадим мәктәбенең яшәвенә, шуның «мөгаллим» исемене күтәргән хуҗаларына хөкүмәттән жалование бирелүенә исем китте. Измирдә мәдәният мәркәзе бу мәдрәсәләр, мәктәпләргә генә түгел, анда җиде-сигез кадәр китапханә дә бар, ләкин боларга бару гадәт булмаганга, берникадәр шул китапханәләрне эзләсәк тә, белүче булмады. Йөри-йөри без гәзитәләр янына килеп җиттек. Измирдә өч төрек гәзитәсе бар. Боларның өчесе дә «Иттихад вә тәрәккый» фиркасының гәзитәсе булса да, араларындагы «Көйле» (авыл кешесе) тел җәһәтеннән дә, мәсләге җәһәтеннән дә башкалардан яхшырак булганга, аның редакциясенә киттек. Төрекләрнең күбесе Русия хакында, хосусан Русия татарлары хакында, бернәрсә белмәсә дә, монда күптән халык «Тәрҗеман» гәзитәсене укып килгәнгә, кирәк баш мөхәррире Рафәт бәк, кирәк башка мөхәррирләре шактый белешеп, сорашып тордылар. Татарларның сәяси хәлләреннән, мәгарифләреннән, әдәбиятыннан озын-озак сөйләшдек, һәммәсе

[1] Сәнаигъ – сәнгать.

[2] Игъдадиясе – мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү класслары.

дә Русиядәге соңгы тентүләр, ябуларның сәбәбләрен сорадылар, авыл халкына гәзитә кертүләре өчен үзләренә рәхмәтләр укып аерылдым, ләкин «Аһәң»нең вә «Иттихад» исемле гәзитәләре минем күз карашымнан әһәмиятсез булганга, китмәдем дә, белешмәдем дә. Измирнең тиҗарәте хакында танышыр өчен бер сатучы эзләргә тотындым. Төркиядә мәэмүр[1], түрә табу никадәр җиңел булса да, сатучы табу ул кадәр авырдыр. Нә исә Аллаһы ярдәм бирде, бер ни булдык, үзе Шам гарәбе булса да, хатыны төрек булганга, шактый төрекләшкән, мине өенә ашка чакырды, киттем. Аяктан шиблетны[2] салып, оекчан көенчә кердем. Бездәге кебек итеп калын көрпәгә[3] аякны бөгеп утырдым. Саглык-сәламәтлек сораштым. Зур бер сай таш китереп куйдылар, ул да булмады, җиз савытлар берлә аш ташырга тотындылар. Куырган йомырка, пылау, фасолияле ит, кәбестәле ит, әллә нинди үлән, сөттән, дөге оныннан ясаган «мөхәлләби» исемле бер гарәп татлысы, һәммәсене бердән куйдылар, һәммәсеннән бергә ашарга тотындык, ашап бетереп, кулларны юып, икенче бүлмәгә чыктык, гарәп мангалга куеп чәй пешерергә тотынды. Чәйнең чәчәкләреннән генә җыелган бик хуш исле, бик кыйбатлы чәйне пешерә белмәенчә бозып эчергәннең соңында, тиҗарәт мәгълүматы бирергә тотынды.

Аның сүзенә караганда, һәр елны Измирдән бер миллион кынтар тешсез йөзем Аурупа, Америкага китә (кынтар өч пот та унике кадак) һәр кынтар 25 франктан 50 франкка кадәр сатыла, һәр елны ярты миллион кынтар инҗир йимеше Аурупага китә. Боның бәһасе 20 франк берлә 35 франк арасында була, һәр елны ярты миллион лира бәһасендә әфьюн сатыла, әллә никадәр «паламут» дигән агачның имән әкәләсе кебек әкәләсе сатыла, моны Аурупа буяу ясар өчен ала, диде. Башка Аурупага китә торган малларымыз әһәмиятсез, диде. Мин аның сүзе берлә генә канәгатьләнмичә, тиҗарәт гәзитәләреннән, календарьларыннан мәгълүмат эзләдем. Моның бу сүзе тугры чыкты. Шуның өстенә тагы календарьдан карап, моннан зәйтүн, мамык та

[1] Мәэмүр – түрә, чиновник.
[2] Дөресе: штиблетны.
[3] Көрпәгә – келәмгә.

чыкканлыгыны белдем. Бүгенге көндә Измирнең бөтен Аурупага күндергән малының бәһасе җиде-сигез миллион лира чамасында, Аурупадан Измиргә килгәннең чамасы 3–4 миллион чамасында икән. Менә шул шәһәр көннән-көн зурая, көннән-көн байый икән. Халыкның барысы өч йөз мең чамасындадыр, моның 180 мең кадәресе мөселман булса да, тиҗарәт банк эшләре һәммәсе дә румнар, әҗнәбиләрнең кулында булганга, төрекләр ач, мохтаж дияр дәрәҗәдә булмасалар да, күбесе фәкыйрьдер.

Шул елларда юнаннарга байкот фикере берлә төрекләргә дә тиҗарәт уе керә башлаганга, бәлки унбиш – егерме еллардан соң болардан зур-зур сатучылар булыр, бәлки болар да үзләренең акчаларын чит банкларга биреп, аларны баету урынына үзләренә банклар ачарлар. Әҗнәби, рум кулыннан сатуны алып, мәмләкәтнең сәяси хуҗалары, икътисади җәһәттән дә хуҗа булып, үз йортларында үзләре баш булырлар. Аллаһы бирсен.

Ләкин әлегә әле ул дәрәҗәгә барып җитәргә бик ерак, бик озак төсле күренә. Артта калган кешегә куып җитәргә бик озын аяклар, бик таза ботлар кирәк. Сугыш мәйданында күршеләрне куып җитәргә бәгъзе бер йирләрдә узып китәргә дә көче җиткән төрекләрнең сату-алу базарында да шулкадәр җитешлекләрен исбат өчен вакыт – заманның үтүе берлә халык да сату-алуга күз карашының алмашуы тиештер. Соңгынчага кадәр бөтен төрекнең идеалы «мәэмүр», «кятип» булып, хөкүмәттән «мәгаш[1]» алып яту булган! Кызлар кияүгә чыгуны уйлаганда, «бәкем кятип булыр, ике йөз горуш мәгаш алыр» дип уйлыйлар икән. Аннары балаларны тирбәткәндә: «Йокла балам, йокла, шәп атка менәрсең, сугышларга китәрсең, ганимәт малы берлә кайтарсың! Янчек-янчек мәгаш алырсың», – дип йырлыйлар икән.

Бүген дә әле шулай йырлыйлар, бүген дә әле кызлар шул ак яка кигән, Австриянең черек малыннан тегелгән ун тәңкәлек шик костюм кигән, мыеклары борган «кятип»кә баруны сәгадәткә саныйлар. Сатучыга кияүгә чыгу, углыны сатучы булырсың дип үстерү, тәрбия итү сатуны, сәүдәгирлекне идеал итү, аның тирәсендә матур хыяллар йөртү – әле төрекләрдә уянмаган. Сатучы дигән сүзне әйткәндә, алар әле һаман өстән генә иттереп

[1] Мәгаш – жалование.

карап, бераз мыскылча көлеп дә куялар. Төрекләрне, сугыш сафында каһарманлык күрсәтә торган, иске сугышларның ләззәте берлә яши торган, киләчәктә булачак сугышларны искә төшергәндә авызыннан су агыза торган төрекләрне кылыч-мылтыктан башка да хәят барлыгыны ышандырырга мең еллар, аларның шул кылыч-мылтык тотарга өйрәнгән кулларыны аршын, бизмән, үлчәү тотарга өйрәтергә, Төркиядә бик зур уй-фикер инкыйлабы[1] тууына ихтилялы мәгънәвиянең[2] тизрәк үсүе дә зураюына ихтыяҗ бик шәптер. Төрекләр шул егерме – егерме биш ел эчендә сугышчылыктан чыгып, сатучы, игенче булырга да өйрәнеп китмәенчә, шул сатуда, иген игүдә дә сугыштагы кебек дәрд-гайрәт берлә алга китмәгәндә, Төркиянең нигезе ныгу ихтималы, Төркиянең таза, нык Аурупа падишаһлыклары кебек бер падишаһлык булуына өмид юктыр. Гаскәри никадәр сугышчы булса булсын, флоты никадәр куәтле булса булсын, бөтен сату-алу читләр кулында булганда, төрек милләте фәкыйрьлегеннән фәкыйрьләнеп, Аурупаның әсире булып калудан башка чара юктыр. Моны мин генә түгел, төрекләрнең дә күбесе аңлаганнар, күбесе шул юлдан башка тугры юл юк икәнлегенә ышанганнар. Ләкин шунысы начар, аңлаганнары да аңламаганнары берлә бергә баралар. Алар да икесе инерция куәте берлә һаман «кятип», «мәэмүр» булалар. Балаларын «мәэмүр», «кятип» булу юлына кертәләр. Аларны «мәгаш мең горуш, мәгаш сигез йөз горуш» тирәсендә тәрбия итәләр. Нә исә шул сатуга керешү фикере туа башлаган, Иншалла, тиздән туып бетәр дә, үсеп җитеп, Төркиянең шул һавасы, икълиме, табигате берлә бай вилаятьләрендә ачлы-туклы яши торган төрекләрне туйдырыр, киендерер дә яртылы ач, яртылы ялангач, өмиден оҗмахтан гына көтә торган төрекләрнең күңелләрене үзгәртүдә алардан таза, нык яңа буын дөньяга китерер. Алардан дөньяның байлыкларыннан файдалана, ләззәтләнә торган угыллар-кызлар тудырыр. Менә шул буын дөньяга килгәч тә, Төркиянең дошманнарыннан куркусы бетәр. Шул көннән соң Төркия дә тарихның олуг юлына чыгып, башка

[1] Инкыйлабы – революциясе.
[2] Ихтилялы мәгънәвиянең – мәдәнии инкыйлабның.

халыклар берлә бергә үзенең төрек йырын йырлар, алга таба атлый башлар.

*8 март. Измир*

Иртәгә тугызынчы мартта Мәгънисада бәйрәм булганга, бүген сәгать 11дәге поезд берлә Мәгънисага китәмез. «Измир касабы» тимер юлының вокзалы халык берлә тулган. Измирнең әллә никадәр кешесе, хосусан төрекләре, Мәгънисага баралар. Озын поездның бөтен вагоннары шыгрым тулган, халык сугышып-сугышып йир ала, дүрт-биш аерым хатыннар вагоны да шактый тыгыз булырга кирәк, аның янына да җыелган хатыннар кычкырышып-кычкырышып урын дәгъвалашалр. Төрекчә киенгән ямьсез чаршаф ябынган бер хатын, кулын сугып-сугып, грекча тимер юл хезмәтчеләре берлә оршыша. Бу күчеп килгән мөселман грек хатыны, менә бер төрек безнең әйберләрне алып ыргытып, урынны алган, минем иптәш ыстудентым ачулана, кычкырыша, теге төрек шул сүзләр гүя аңгарга әйтелмәгән кебек тәмәкәсен тартып, күзләрен әйләндереп утыра, аның шул салкын канлыгы кызу канлы яшь ыстудентның ачуын китерә. Минем алдымда төрекнең шул тәрбиясезлеге өчен хурлана. Менә поезд кузгала, Измирнең яртысын әйләнеп, без диңгез буйлап китәмез. Ыстудентлар шактый еш. Бәйрәм мөнәсәбәте берлән ыстудентларга күрше авылларның ирләре, хатыннары, балалары, чагалары җыелган, балалар поездны күрү берлә кычкырышырга тотыналар. Киң бөрмәле чалбар, кыска казаки, биленнән бик түбән, бик зур билбау бәйләнгән, фәс өстенә колакларын яшереп гүя суык тиюдән курыкган кебек иттереп, төрле төстә яулыклар бәйләгән төрекләр, бик ямьсез кара чаршаф берлә бөркәнеп, үзенең кәфененә йитәрлек ак яулык берлә башын өреткән хатыннар дөркеме берлә юл буенда торалар, алар, бик зур бер сөенечле хәбәр көткән кебек, поезд якынлаша башлагач та, хәрәкәткә киләләр. Поезд туктагач, көн дә үтә торган поездны, шул вагоннар тулы халыкны бөтен көчләрен күзләренә биреп сузалар, карыйлар. Ирләр кычкырышалар, сөйләшәләр, хатыннары борчак куркыткычы кебек тик катып басып калалар. Ыстансада суык су, симит

лимонат, куырган борчак, (ләбләби), кәләвә, бал берлән катырган куырган тары, хөрмә саталар. Кычкырышалар, бакырышалар, «Суык су!», «Суык боз!» кебек тавышлары бөтен ыстансияне яңгырата. Ыстансадан тагы әллә никадәр ирләр, әллә никадәр хатыннар керәләр, урын тагы тыгызлана. Менә без хәзер ике тау арасыннан үтеп барамыз, тау битенә, сыгылып-сыгылып тора, зәйтүн агачлары утыртканнар. Алар шул зур-зур ямьсез ташлар берлә капланган тауның бераз гаүрәтен өретеп, аңарга рух бирәләр, тауның якасындагы ап-ак өйләрдә тауны җанландыралар. Менә без тауларны үттек. Поездның бер ягыннан сап-сары сулы, безнең Казанка зурлыгында, бер елга ага. Ул шул тирәнең халкына кырларын су берлә каплап шактый зарар китерә торган Гәдүс елгасы икән. Күз алдымызда ике ягыннан еракка таулар берлән чормаланган тигезлек, уйсу йир, бу Мәгъниса увасы[1]. Бөтен тигезлек корама-корама бүленгән, бөтен тигезлектә ямьяшел зәйтүн агачлары һаваланып катып торалар, яп-ялангач (әле яфрак чыгарырга өлгермәгән) инҗир агачларының ялангачлыгыны яшерер өчен, шуларның ямьсезлеген матурайтыр өчен кебек аклы-аллы чәчәкләр берлә башыннан аягына кадәр капланган бадәм агачлары чәчәкләре берлә кояшка каршы ялтырап яталар. Күз күргәнгә кадәрге тезелеп киткән йөзем агачлары йирдән аршын – аршын ярым кадәр биеклектә чыгып, шул кояшка карап яфрак чыгарырга – ботак җибәрергә хәзерләнеп торалар. Шул матур көндә, шул язгы кояшта йөземнәрнең ялангачлыкларыннан оялган кебек, күз бер туктамаенча бадәмнәрдән алынмый. Яз исе берлә бергә бадәм исе борынны сөя, кәеф ачылганнан ачыла бара. Менә ерак түгел генә таштан салынган өйле авыл, әнә аның янында тагы әллә никадәр баягы төрекләр, әллә никадәр төрек хатыннары, әнә бик зур түбәле чалбар кигән, чалбарының төбе җиргә тиеп йөри торган ачык йөзле бер хатын, бу рум хатыны. Әнә тагы шул күргән төрекләрчә киенгән дә биленнән түбән кара билбау ураган, башына чалма кебек иттереп яулык сарган бер рум – грек, бу грекларның авыл кешесе, аның билендәге озын кара билбавы аның мөселман түгеллеген белдерә. Менә зур билбау буган, зур төпле чалбар кигән, кара бите өстендәге

[1] Увасы – тигезлеге.

ак тешләрен ыржайтып негр (кара гарәп) басып тора, ул шул поездга каршы, аларга өйләр итеп карап, балалар кебек көлә. Шундый өйләрнең чабып, кыр буйлап йөрүләре, шул өйләрнең Измирдән Мәгънисага кунаклар ташулары, бәлки аның башына әле һаман сыймый тогандыр, бәлки әле шул кара маңгай берлә капланган аның мие шул мәсьәләне һаман хәл итә алмагандыр. Менә тагы ыстанса, тагы поезлар, меңләр халык, тагы ямьсез чаршафларга бөркәнгән төрек хатыннары, вокзал буенда басып тора торган кып-кызыл нык төрек егетләре! Шул егетләрнең тазалыгын, ныклыгын күрү минем күңлемә өмид уята, эчемнән шундый таза авыл егетләре булса, шундый таза ирләр булса, теге Измирдәге зур битле, зур учлы киң күкрәкле рум хатыннары үзләренең таза балалары берлә басып китә алмаслар кебек тоела. Истанбулдагы черегән, кипкән «кятиб бәкләр» Истанбулның иске румнардан калган бөтен начар гадәтләрен үзләренең чаршафлары астына яшергән төрек ханымнары, төрек гыйркының азалуына[1] төрле юллар берлә хезмәт итсәләр дә, зәгыйфь, кансыз җитлекмәгән балалар тудырып, Истанбулның бөтен урамнарын, мәхкәмәләрен, даирәләрен эшлексез, булдыксыз «Сөкүт[2]» дегенерадлар берлә тутырсалар да, шул таза егетләрнең балалары, шул җан вә тән ягыннан черегән шәһәрлеләрне басып, изеп китәләр кебек тоелды. Мин күңелемнән Төркиянең тазару вә ныгаюының маясы менә монда, шул инҗир, зәйтүн агачы арасында, шул йөзем ботаклары, бадәм чәчәкләре астында икән, дидем. Шул фикерне исбат итәр өчен кебек вагонга унбиш-егерме кып-кызыл, тап-таза егетләр килеп керде. Барлыюклы урынны алып, алар кычкырышып сөйләшергә тотынды, ерларга башлады. Менә без Мәгънисаның янындук, юл буйлап ике яктан ирләр, хатыннар тезелгән. Алар нәрсә көтәләр? Шул матур һава, бадәм чәчәге берләнбизәлгән кырлар аларны решеткалы тәрәзәле өйләреннән өстерәп чыгарган. Алар да бүген кеше кебек саф һава сулыйлар, кеше кебек килгән-киткәнне карыйлар, кәефләнәләр, хозурланалар. Мәгънисаның вокзалы шыгрым кеше берлә тулган. Әллә никадәр кешеләр минем ибдәшем

[1] Гыйркының азалуына – кавеменең азаюына.
[2] Сөкүт – дәшми торган, телсез.

ыстудент берлә күрешәләр, аңардан сорашалар, минем яныма килеп: «Сафа кәлдең[1]!»– диләр, бер-бер каһвәханәгә утырып, шунда җыелган халыкны тамаша итәмез, ыстудент танышлары берлә сөйләшә. Менә тагы бер яңа таныш! Һәммәсе дә «Исәнме? Истанбулда ни бар?»дан соң «Кая укыйсың, дарелфөнүндәме, кайсы шәгъбәсендә?»дән соңында да «Мәгаш (жалование) никадәр булачак?» дип сорашалар. Шул сүзнең җавабын алгач та, үзенең шәһәренең башка ыстудентларын сораша, аларның да кая укуын белгәч, тагы «мәгаш күпме?» дип сүзне тәмам итә. Шуның артыннан болар арасында дарелфөнүн, хокук, мөлкия мәктәпләренең[2] кайсы яхшылыгы хакында сүз башлана. Дарелфөнүннән чыкканнар мең горуш мәгаш берлә башлыйлар икән! Хокук мең дә ике йөз горуш, мөлкия тугры килсә, мең дә бишйөзгә кадәр, әлбәттә, милекия яхшы! Болар минем ибдәшемнән, хокукта мең дә ике йөз горуш мәгаш булгач, ник хокукка кермәвен сорыйлар. Ул да, бер яктан, шуларга җавап таба алмаенча, бер яктан, минем көлеп торганымны күреп, кызарып кала. Тагы башкалары килә, тагы исәнлек-саулыктан соң «мәгаш күпме?» мәсьәләсе ачыла. Мин бөтен тормышын «мәгаш» идеалына гына фида итә торган шул «кятип»ләрне күреп, тагы кәефем бозыла. Тагы ихлассыз, халкына мәхәббәтсез, «мәгаш» өчен генә туган иттереп уйлый торган төрекләрне күреп, өмидем азая, тагы шул эшсез сорыкортлар берлә, шул әрәмтамаклар берлә төрек мәмләкәте тәрәккый итә алмас кебек хис итәм. Күз алдыннан үтә торган авылдан килгән таза егетләр «мәгаш» дигән сүз урынына «йөзем», «инҗир», «тарла» (кыр) белә башын тутырган егетләр миңа тагы өмидне кайтаралар. Менә без хәзер шәһәргә керәмез, тау итәгенә утырган шәһәр үзенең иксез-чиксез манаралары берлә, үзенең өстеннән каравыллап тора торган биек таулары берлә матур кебек тоела ...

Юл буе кешеләр күрешәләр, сөйләшәләр, сорашалар. Без кәкре-бөкре тар урамнарны үтеп, хәзер ыстудентның өенә барамыз, юлда безне туктатып, бер чалмалы каһвә эчерә, аның берлә сөйләшеп, үтеп китәргә өлгерә алмыймыз, ыстудентның

[1] Сафа кәлдең – хуш килдең.

[2] Мөлкия мәктәпләренең – чиновниклар әзерли торган мәктәпләрнең.

тагы бер танышы туктатып, каһвәханәгә чакыра, (аяк атлаган саен каһвәханә) анда да керәмез. Тагы уймактан аз гына зур каһвә чынаягыннан (финҗәннән) куе каһвә эчәмез, тагы баягы ишеткән сөальләрне ишетәмез, дүрт-биш каһвәханәдә утырып, дүрт-биш уймак каһвә эчеп, өйгә килеп җитәмез. Менә зур гына бер ишек яисә капка! Кердек, йортның уртасында буш йир, шунда берничә агач үскән, уртасында кое, йортның иң түрендә ике катлы иттереп өй салынган. Менә безне «сәламлык»ка керттеләр (сәламлык төрекләрнең мосафир кабул итә торган бүлмәләре), анда безне күрше шәһәрдән бәйрәмгә килгән ыстудентның җизнәсе мөфти каршы алды. Хуҗа абызтай да, ябынып, бөркәнеп булса да чыгып, «хуш, сафа кәлдеңез» диде. Төрек гадәтенчә тагы каһвә эчәргә тиеш булса да, эчмәдек. Тиздән кояш батты, төрекчә сәгать 12 булды (төрек сәгате кояш баеганда 12 була) безне аш бүлмәсенә чакырдылар. Берсе артлы берсе ашлар килде. Тазә[1] фасолия, баклалы ит, чәчәк, кәбестәле ит, спанатлы[2] әллә нәрсә, тагы әллә нинди үләннәр, әлбә кебек бер татлы, җимеш суы, ашлар күбе сулы булса да, төрек гадәтенчә, кул берлә генә икмәкне суына батырып, бармаклар берлән итне, үләнен эләктереп ашадык, ашап бетергәч китеп, клублар, каһвәләр, кешеләр күрергә чыгып киттек. Иң әүвәл зур бер җамигъның янында ясалган мәдрәсәнең мөдәррисе, искедән хөрриятпәрвәрлек берлә исем тоткан, әүвәлрәк бәләдия рәисе[3] булып торган Җәүдәт эфәнде янына кердек, ул кич берлән үзенең дәресханәсендә утыра икән дә дуст-ишне шунда кабул итә икән (мәдрәсәдә хәзер шәкерд беткәнгә, дәресханә кунак кабул итүдән бүтәнгә ярамый икән). Кердек, дивар буена сузылып куелган тәбәнәк төрек кәнәфиләренә аякларымызны җыеп менеп утырдык. Һәммә кеше берлә тагы кулларымызны җиргә таба төшереп, аннары сакалымызга тиереп, аннары маңлаемызга тиереп күрештек (кул биреп күрешү төрекләрдә бик аз). Русиягә сүз күчте. Мосафирлардан берсе «Исмәгыйль бәк нишләп тора?» диде. Истанбулда берничә таныш Исмәгыйлем булганга, кем

[1] Тазә – яңа өзелгән.
[2] Шпинатлы.
[3] Бәләдия рәисе – муниципалитет башлыгы.

икәнлегенә аптырап калдым. Ул Гаспринский дип, «иске» дигән сүзне аерым итте. Мин белгәнем кадәр Исмәгыйл Гаспринскийның хәленнән вә иткән хезмәтләреннән сөйләп, бу төрекләрнең кайдан аны белүенә гаҗәпләнмичә белгерттем. Без монда Мәгънисада бик озак «Тәрҗеман»ны укыдык, аны бик беләмез, диделәр. Шуннан берсе: «Ул хәзер инде карт кеше булырга кирәк, бик зур хезмәтләр итте. Шул хезмәтенә каршы аны Русиянең мәҗлесе әгъянына (Государственный Совет) әгъза иттереп тәгъйин итмиләрме[1]?» – диде. Мин аптырабрак: «Кем итсен?» – дидем. Төрек: «Мин сезнең Русиянең канунын белмим, солтан тәгъйин итә. Әнә мәҗлесе әгъянда әллә никадәр рум, әрмән, һәм яһүди бар, менә бу ел гына Сөләйман Әлбастани дигән бер христиан гарәпне, каләм хезмәте өчен, мәңгелек әгъянга әгъза итеп заты шаһанә тәгъйин итте. Гаспринскийның Русиягә хезмәте шул гарәпнең хезмәтеннән киммени?» – диде. Мин: «Юк ким түгел, артык та, ләкин бездә хезмәт өчен мәҗлесе әгъянына тәгъйин кылу гасырлары кермәгән әле», – дидем. Русиянең шул көнге тентүләре хакында сүз ачылды. Без, күрешеп, клубка киттек «Иттихад вә тәрәккый» җәмгыяте, халыкны бергә җыяр өчен, шәһәрләрдә клублар ачканга, әлбәттә, Мәгъниса кебек кырык мең халкы бар шәһәрдә онытылмаган, менә монда да алты кадәр клуб ачканнар. Иң якынына кердек, безне бик зур кадер-илтифат берлә каршы алдылар. Һәммәсе дә бер авыздан Русия мөселманнары хакында сораша башладылар. Мин, билгеле, белгәнем кадәр сөйләдем. Үзем сорашырга тотындым. Төрекләрнең гадәте буенча, элгәре истибдадтан[2] зарланганның соңында хәзерге хәлгә килделәр. Әллә никадәр эш эшләнсә дә, халык уянды, җыелып-җыелып үз хәлемезне кайгыртамыз, диделәр. Измирдәге сату-алуның румнар, әҗнәбиләр кулында булуыны яратмавыма каршы, шулай шул без һәммәмез дә хөкүмәткә карап «мәгаш» көтеп торамыз, бездә үзеннән эш башлап акча табу уе бөтенләй беткән булган, аннан тагы гаскәрлек дә манигъ[3] булган. Монда илдә кебек рәдифләр (запасной) җыялар. Илдә мәмләкәтнең

[1] Тәгъйин итмиләрме – билгеләмиләрме.
[2] Истибдадтан – деспотизмнан.
[3] Манигъ – киртә.

әллә кайларына барып сугышып, ырлашып кайталар, алай булганда ничек сату итәргә кирәк, хәзер инде мөселман түгелләр дә гаскәрлеккә алынганга, төрекләргә дә йорты-йире берлә маташырга вакыт калыр, диделәр. Шуннан мәсьәлә Мәгънисаның сату-алуына китте. Монда да бөтен сату-алу румнар кулында булса да, шул бер-ике ел эчендә халыкта да сату-алу фикере уйганып, берничә магазиннар ачылуын, берничә мәхәллә эчендә сату итә торган румнарның кибетләрен ташлап китәргә мәҗбүр булуларын шатланып сөйләделәр. Шул сүзләрдән һәм дә күргәннәремнән дә сату-алу фикере уянганын, һәм дә шул юлда румнар берлә тартышырга керешкәненә инандым. Русия татарларының сату-алуда алдалыгын һәммәсе бик ихлас берлә тыңлады, монда да тентү мәсьәләләрен соралды, Плевна сугышында булган бер карт: «Барда безнең зәгыйфьлектән! Без куәтле булсак, болай булмас иде», – диде. Клубның икенче бүлмәсенә безне чакырдылар. Анда да киттек, анда да шул сүзләр сөйләнде. Мин: «Мәгънисада күпме мәдрәсә бар? Күпме шәкерт бар?» – дип сорадым. Бер мөдәррис: «Монда мәдрәсә күп, әллә никадәр вакыфлар бар, хәтта бәгъзе җамигъларымыз, мәдрәсәләремезнең вакыфлары Кырымда, Кизләүдә вә башка йирләрендә дә булган икән, ләкин мәдрәсәләр монкарыйз булды, шәкерт бик аз, егермеләп мәдрәсә булса да, йөз шәкерт йә бардыр, йә юктыр», – диде. «Соң инде нишли ул мәдәсәләр?» – дидем. «Шулай тора, әлегә», – диделәр. Чын да җамигълар янында зур мәдрәсәләрнең ябык көенчә бушка әрәм булып торганын үзем күзем берлән күрдем. Клубның бу бүлмәсендә шул Мәгъниса тигезлегендә 195 авыл барлыгын вә шул авылның ун-унбиштән башкасы һәммәсе төрек икәнен, авыл халкы фәкыйрь түгел икәнен белдем.

Бүлмәдәгеләрнең күбесе мәэмүрләр, кятипләр булгангадыр ахрысы, сөйләгәндә «Иттихады тәрәккый» фиркасен бик мактап сөйләделәр (чыккач кына белдем, боларның күбесе мине «Иттихад вә тәрәккый» фиркасенең бер-бер кешесе булып ниятеп, үзенең мәгашенә зарар китермәсен дип, шулай кылынганнар икән) төн буе күргәннәр-ишеткәннәрдән арып бетеп, өйгә кайтып киттек. Истанбулдан алып килгән чәйне кайнатып, чәй эчеп, озын кәнәфиләргә ятып, мөфти ыстудент берлә әллә ни-

кадәр сөйләшеп, төрекчә әйтсәк, сохбәт итеп утырдык, клубның әгъзалары кемнәр икәнен белдем. Күбесе шундагы шәһәрнең мишчаннары[1] булса да, мәэмүрләр, кятипләр дә аз түгел икән. Иртәгә «мәсир» дигән бәйрәмнәре, нәүрузлары. Тагы бик кызык булыр кебек тоела.

Мин күргәннәремне, ишеткәннәремне рәткә салып, йокларга ятам. Диварлардагы матур язулар берлә язылган аятьләр, хәдисләр, мәшәехләрнең[2] исемнәре үзләренең шул иске язуларыннан чыгып карап торалар кебек сизелә, аларга мин тугры карап торам да, шуларның язучыларын, менә шул биш-алты сүз язып, хәрефләрнең аерылуыннан, сузылуыннан кош сурәте ясый белгән шул салават догалыкның бәрелүеннән-киерелүеннән Бикташи бүрке (Бикташи Төркиядә бер тәрикаты махсус, бүрекләре бар) ясый алган язучының осталыгына исем китеп торам. Ислам диненең җанлы рәсемнәр ясарга рөхсәт бирмәве мәшһүр рәссамнарны, бәлки икенче Рафаилләрне нинди тар юлга сугуын уйлап, никадәр талантларның әрәм булуына кайгырам. Тагы шуларга карыйм, алар бу юлы күңелсез, ачулы, моңлы кебек күренәләр. Бәлки шул Казанның кайнаулары, Архангелның суыклары, Петербургның былчыраклары арасыннан алып килгән минем фикерем, аларга кызганган булып каравым, аларны хурландыргандыр. Мең еллык төрек хәятенә кереп, бер татар малаеның тәнкыйд күзе берлә каравы, бәлки аларны ачуландыргандыр .... Нишлисең? Заманасы шул, шул!

Шул догалыкларга, шул шәехләргә йокымны сакларга биреп, юрганның астына башны тыгам.

*8 март, Мәгъниса*

*«Идел». 1911, 1 апрель, 5 апрель, 15 апрель, 22 апрель, 29 апрель, 6 май, 13 май*

[1] Дөресе: мещаннары.
[2] Мәшәехләрнең – шәехләрнең.

**Мәрьям Паташева**

# ИСТАНБУЛ ХАТИРӘЛӘРЕ

## I

Италия мөхарәбәсе[1] туктар-туктамас, Төркия дәүләтенә рәхәт вирмәмәк өчен[2], Яурупа сәяхәте балканлыларны Төркия өстенә йибәргән иде. Мөхарәбә башланды. Балкан христианнарына һәр тарафтан, һәр төрле ярдәм күндерелә башлады. Әүвәлге мөхарәбәдә хәлдән тайган Төркиягә һичбер тарафтан ярдәм юк иде.

Ватан юлында, дин юлында җаннарын фида кыла килгән төрек гаскәрләренең хасталарына, яралыларына мөхарәбә мәйданнарында хезмәт кылу өчен, дәресләремезне ташлап булса да, без, дүрт кыз, Петербургтан сәфәр итеп Истанбулга килдек[3]. Истанбулда Кадәрга хастаханәсендә тәмам биш ай хезмәт иттек.

Истанбул тәмам дөнья җәннәтедер: вакыт кыш фасылы булса да һәр тарафта яшеллек, күк йөзе ачык. Кояш иртәдән кичкә кадәр матур йирләрне һәр тарафтан яктырта, җанлылык бирә; һәр йирдә зур җамигъләр, гүзәл мәсҗедләр, озын матур манаралар биек-биек, шәһәргә үзенә махсус бер зиннәт биреп торалар.

Без кайттык... Ләкин минем күңелем һаман Истанбулда. Хасталар янында биш ай хезмәт минем күңелемдә бик тирән эз калдырды. Истанбулда һаман буласым килә: дин юлында җаннарын фида иткән хасталарның мосалли[4] тавышларын һаман ишетәсем килә; һәр йирдә, һәр нәрсәдә бар гүзәллекне күрәсем

[1] Мөхарәбәсе – сугышы.

[2] Вирмәмәк өчен – бирмәс өчен.

[3] ...без, дүрт кыз, Петербургтан сәфәр итеп Истанбулга килдек... – дүртесе дә Петербургтагы Хатын-кызлар югары педагогия курсларының (Курслар институт программасы белән эшли) дүртенче курс студентлары – Чистайда туып үскән Өммегелсем Камалова, Петербургтан Рокыя Юнысова, Ташкенттан Мәрьям Якупова, Ростовтан Мәрьям Паташева. Дүртесе дә Балкан сугышы вакытында (1912 елда) үзләре теләп төрекләргә ярдәмгә баралар. Анда «Һиляле Әхмәр» («Кызыл Ай») хәрби лазаретында шәфкать туташлары булып эшлиләр. Бу гамәлләре өчен аларны Курслардан чыгаралар. Мәрьям Паташева 1913 елда Петербург Психоневрология институтына кереп укуын дәвам итә.

[4] Мосалли – намаз укучы кеше.

килә; төрекләрнең һәрбер эшләрендә күренеп торган аяныч ялкаулыкларына хәсрәт күзе илә карап, утлы сүзләрем илә аларга бераз булса да җан бирәсем килә, күңелемезгә авырлык, йөземезгә кызыллык бирә торган ялкаулыкларын әллә нинди бер куәт илә бетерәсем килә...

Күңелемдә калган хатирәләремне Русия мөселманнарына белдерәсем килә, төрек кардәшләремә әйтәчәк сүзләремне «Вакыт» газетасы васитасы илә[1] әйтәсем килә.

Истанбулга барудан элек тә, Истанбулга ирешүнең әүвәлге көннәрендә дә төрекләрнең чигенүләренә без ышанган идек. Ләкин төрекләрнең хасталарының хәлләрен белә башлагач, әүвәлге иманымыз берничә көннән соң янә куәтләнә башлады. Һәр тарафта төрек гаскәрләренең җиңелү хәбәрләре һәр көн, һәр сәгать килә башлады. Кадәрга хастаханәсенең баш табибы яһүди Сухами төрек гаскәрләренең җиңелүләрен, качуларын һәрвакыт шатлык илә көлеп сөйли иде. Кыска буйлы, калын тәнле, зур корсаклы, исерек яһүдинең шатлыкларына протест ясаучы һич юк диярлек иде. Табиб Сухами илә бу хосуста мин һәрвакыт талаша идем. Табиб Сухами һичбер вакыт үзенең шатлыкларын үзгәртмәсә дә, миңа һәрвакыт: «Мәрьям ханым, син һичбер шәй аңламаюрсың, кафагы динiштер[2]!» – дия торган иде.

Бара-тора шатлыклары арта башлады. Яһүди Сухами, студент Жозеф хастаханәдә мадам Дәрузән одасында[3] тупланып, һәр кичә шәраб мәҗлеслре ясый башладылар. Мадам Дәрузәннең романсларын алкышлап, төн буена кәеф-сафа кора башладылар.

Һиндстаннан «Һиляле Әхмәр»[4] җәмгыятенә күндерелгән егерме ике адәм Кадерга хастаханәсенә урнашып, бер ай кадәр эшсез тордылар.

Көндезләрдә Истанбулны тамаша итеп йөреп, кичәләрдә Сухами, мадам Дәрузән компаниясендә кәеф-сафа сөрә иделәр.

[1] Васитасы илә – ярдәме белән.

[2] Кафагы динiштер – башыңнан чыгар, тынычлан.

[3] Одасында – бүлмәсендә.

[4] «Һиляле Әхмәр» – «Кызыл ай», халыкара медицина ярдәме күрсәтү җәмгыяте.

Мадам Дәрузән зур тавыш илә романслар йырлый иде, компаниясе хастаханәне яңгыратып алкышлыйлар иде.

Кәеф-сафа одасы безем одамызга якын иде. Исерек компания тавышлары бичара хасталарның рәхәтен ала иде. Бутылкалардан атылып чыккан пропка тавышларыннан җанымыз газаплана иде. Истанбул капусы төбендә ислам каны түгелеп торган сәгатьләрдә, мескен хасталарны да онытып, бер мадам гыйшкына бутылкалардан әллә нинди шәраб түгеп, кәеф-сафа кылмак безгә бик авыр, бик гаҗәп күренә иде.

Һиндстан адәмнәре Чаталҗа якынына хастаханәләр ачу өчен киттеләр. Кәеф-сафа компаниясенең әгъзалары аз калды. Хастаханәдә яхшы гына әдәпле аптекарь Газыйм бәк бар иде. Элек бик яхшы чалыша[1] иде. Мадам Газыйм бәкне дә компаниясенә тартты. Бичара Газыйм бәк шәраб мәҗлесенә ияләшеп, Сухами кебек һәрвакыт сәрхүш була башлады. Хастаханәдә мондый әдәпсезлек без киткәнче дәвам итте. Хасталар, хастаханә адәмнәре бу әдәпсезлекләргә бәлки разый да булмаганнардыр, ләкин баш доктор Сухамига авыз ачып бер сүз әйтүче булмады. Берничә кат мин яһүди Сухами илә шул хакта да талаштым; һичбер илтифат кылмады, һаман үз эшләрендә дәвам итә иде.

«Һиляле Әхмәр» рәисе доктор Бәсим Гомәр пашага без һәм дә бәгъзе адәмнәр шикаять кыла идек. Доктор Бәсим Гомәр паша дия торган иде: «Сәсеңезне[2] чыгармаңыз!». «Һиляле Әхмәр» намусын пислатмәңез[3]! Төркиягә рәхәтсезлек вирмәңез! Ул эшләрне мин кәндем бакармын[4]». Ләкин нигәдер һичбер вакыт бакмады. Әдәпсезлек хастаханәдә һаман дәвам итә иде. Алай гына түгел, бәлки Сухамига:

«Хастаханәне фәхешханә яптың[5]!» – дигән доктор Әхмәт әфәндене, төрле фетнәләр кылып, Сухами сөрдерде.

Хастаханәдә тәртип тә юк иде. Баш доктор күп вакыт исерек була иде. Хасталарны карау сәгатьләрендә дә һаман исерек була.

[1] Чалыша – эшли.
[2] Сәсеңезне – тавышыгызны.
[3] Писләтмәңез – пычратмагыз.
[4] Кәндем бакармын – үзем карармын.
[5] Яптың – ясадың.

Бик күп вакыт хасталарның өстенә ава иде. Хадимәләр хакында башкача да күп әдәпсезлекләр кыла иде.

Депо мәэмүре[1] Хәнифә ханым хасталарга да, хезмәтчеләргә дә һичбер вакыт рәхәт бирми иде. Юк-бар нәрсәләрне сәбәп итеп, бичара хезмәткәрләрнең җаннарын ала иде. Хасталарга чамашир[2] йә чаршаф[3] алган сәгатьләрдә талашмыйча һичбер вакыт алып булмый иде. Хасталарның чаршафлары вә чамаширләре күбрәк вакыт пис кала иде.

Яралыларның гамәлияте[4] хакында да хастаханәләрдә бик күп илтифатсызлык күренә иде. Кадәрга хастаханәсендә күбрәк гамәлият мадам Дәрузән мәгърифәте илә ясала иде. Берни белми торган мадам Дәрузән гамәлият вакытларында да, яралыларны сару[5] вакытында да бичара хасталарга бик зәхмәт бирә[6] иде.

Ялгыз[7] практика өчен генә килгән немец студентлары мескен төрек гаскәриләрен хайван кеби турап-кисеп, яраларын казып, бик күп хасталарны тәҗрибә юлында фида кылганнар. Башка хастаханәләрдән Кадәрга хастаханәсенә күчеп килгән мәҗрух[8] хасталарны күреп, аларның шикаятьләрен ишетеп, мин хәйран була идем. Күңел сыкрана иде. Бичара хасталарның аяныч хәлләрен күреп, Кадәрга хастаханәсендәге әрмән Җәрах Якубян әфәнде илә Капамаҗьян әфәнде һәрвакыт шикаять кыла торганнар иде.

Мондый аяныч хәлләр бер түгел, ун түгел, бик күп иде. Яшь чактан хәтеремдә калган әбием әйтә торган иде: «Ий Мәрьям, күргәнең бер тугыз, күрмәгәнең унтугыз». Мәрхүмә әбиемнең шул хикмәтле сүзе Кадәрга хастаханәсендә һәрвакыт хәтеремә килеп, бичара төрек гаскәриенең бик тә авыр хәлләренә күңелем яна иде, газаплана иде, баш ватыла иде, йөз кызара иде.

---

[1] Депо мәэмүре – склад хезмәткәре.
[2] Чамашир – эчке кием.
[3] Чаршаф – җәймә, юрган тышы.
[4] Гамәлияте – (дәвалау) процедурасы.
[5] Сару – бәйләү (перевязка).
[6] Зәхмәт бирә – кыенлык тудыра.
[7] Ялгыз – бары тик.
[8] Мәҗрух – яралы, җәрәхәтле.

Бу хәлләр бер миңа түгел, бәлки хөкүмәт адәмнәренә дә, төрекләрнең үзләренә дә, хастаханә табибларына да, әлбәттә, мәгълүм иде.

Балаларын, ата-аналарын ачлыкта ташлап, бичара гаскәри мөхарәбәгә китә. Дин юлында, ватан юлында ун көн, унбиш көн ач-ялангач йөреп, мөхарәбә мәйданнарында гакыйбәт[1] шәһид була, яһүд әгъзасы сына, җәрәхәтләнә, хасталана. Кыш көннәрендә кырда кала. Салкынлыктан, ачлыктан, сусызлыктан, ялангачлыктан дәһшәтле газап күрә дә үлә. Меңнән бере үзенең көче илә, кесәсендә бар акчасы илә миллион зәхмәт күреп, көчкә генә Истанбул хастаханәләренә үзе килеп йитә. Җәрәхәтле булса, әгъзасы сынган булса, бичара гаскәри, мадам Дәрузәннәрнең «мәрхәмәтләренә», алман студентларының «мәгърифәтләренә» тапшырыла да, зәхмәт, мөшкыйләт күреп, күбрәк вакытта теге дөньяга китә. Мөхарәбәдә ач-ялангач йөргән гаскәри хастаханәдә дә һаман ач тора. Һаман хәкарәт[2] күрә, һаман зәхмәтләнә.

Бер уфак бер парча[3] ит кисәге, суда пешерелгән аз гына дөге бирәләр. Бичара гаскәри икмәк өчен дә талаша. Илтифат юк. Туйдыру юк. Ачлыктан йөдәгән бичара хаста тапса чала[4], тапмаса һаман ач кала. Парәсе булса сатып ала.

Мондый хәлләрне белә торып, күрә торып хөкүмәт адәмнәренең разый булуларына, мөселман төрекләрнең тик торуларына мин бик гаҗәпләнә идем. Алман студентларына айга йөзәр лира биреп тә, мөселман гаскәриләрен, хасталарын ач-ялангач тоту, мадам Дәрузәләрнең гыйшкына чамасыз хөрмәт күрсәтеп тә, мөселман гаскәриләрен, хасталарын тәхкыйр кылу[5] бөтенемезгә гаять уңайсыз күренә иде, гакылдан шаштыра торган иде. Шикаять кыла идек, ләкин файдасы юк иде. «Сәсеңезне чыгармаңыз!». «Һиляле Әхмәр» намусын پислэтмәңез!» диюдән башка бер җавап юк иде.

[1] Гакыйбәт – соңында, нәтиҗәдә.
[2] Хәкарәт – хурлау, кимсетү.
[3] Уфак бер парча – кечкенә бер өлеш.
[4] Чала – ашыгып ашый.
[5] Тәхкыйр кылу – хурлау, түбәнсетү.

Мин моңа бик аптырап кала идем. Сәс[1] чыгармау ни өчен иде? Куркуданмы ... иде? Хыянәтләргә, хәкарәтләргә разый булуның сәбәпләре ни иде? Хөкүмәт нигә болай булган? Төрек халкы ник бу хәлләргә калган?

Мондый сөальләр күңелемә килә башлады.

Моңа күрә төрекләрнең һәрбер эшләренә хасталарның хәлләренә, сүзләренә хәсрәт күзе илә, игътибар күзе илә карый башладым.

Биш ай эчендә вак-төяк байтак хәлләр күрдем, гаҗәп нәрсәләр ишеттем. Хатирәләремне яза бара идем. Бәгъзеләрен «Вакыт» сәхифәләрендә язуны тиеш күрәм.

## II

Бөтенләй һәлакәт булмаса да, бөтен Төркиянең мондый хәкарәт[2], хурлык астына калып, зур фәлякәтләргә[3] төшүенең сәбәпләре нидер?

Моның сәбәпләре төрле-төрле улып, бик күптер. Аларны тикшерү вазыйфам түгел кеби исә дә, шул вәхшәтле тарихи вакыйгалар вакытында Төркиядә улдыгымнан, бәгъзеләре хакында аңлаганым кадәр язуны тиешле күрәмен. Төркияне бу кадәр бәхетсезлекләргә китергән сәбәпләрнең кайсылары шул вакыйгалар чорында мәйданга килмеш улып, кайсылары исә искедән дәвам итеп килмештер. Бу сәбәпләрдән бере Төркиядә гаилә мәсьләсе дип беләм. Чөнки бу мәсьәлә аларда хәзергә кадәр хәл ителмәгән. Моннан ничә йөз еллар ничек булган булса, хәзер дә шул көедер.

Гаиләдә ниндидер бер уңайсызлык бар: ир илә хатын хәяте бер түгел. Ире бер дөньяда, хатыны икенче дөньяда тора. Берсен икенчесе аңламый һәм аңларга да теләми. Шулай итеп, гаиләдә иң кыйммәтле булган мәгънәви рабыйт[4] югалган һәм гаилә дә үзенең төсен югалткан. Шул сәбәптән булса кирәк, балалар тәрбиясе уңайсыз бер хәлгә килгән: ата булган кешесе балалар тәрбиясе турында уйламый, бәлки бала тәрбиясе илә мәшгуль

[1] Сәс – тавыш.

[2] Хәкарәт – хурлау, кимсетү.

[3] Фәлякәтләргә – бәлаләргә, бәхетсезлекләргә.

[4] Рабыйт – бәйләүче.

булырга вакыты да юктыр. Чөнки ул иртә берлән йокыдан торгач та каһвәсен эчә, бала-чагасын күрмәстән чыгып китә. Көндез исә аш вакытында өенә кайтып хатыны, бала-чагасы илә сөйләшеп, рәхәт-рәхәт аш ашап ял итәсе йирдә, бер ашханәгә кереп тамагын туйдыргач, эше булса, эшенә китә, булмаса, тулып яткан каһвәханәләрнең берсенә кереп, уймак кадәр бер чынаяк каһвә илә сәгатьләрчә гомер үткәрергә һич авырсынмый. Иренеп кенә сугыш мәйданында булган муаффәкыятьле[1] яки муаффәкыятьсез хәлләр турында мөхакәмә кыла[2]. Яки аны да бик авыр эш санаган кеше шикелле һичбер нәрсә сөйләмәстән наргилә[3] тартып, яртылый йоклап, үзенчә рәхәт итәдер. Шул рәвешле, ата балалар тәрбиясенә һич катышмый, бәлки көн буена балаларын исенә төшергәне дә юктыр.

Аналары да бала тәрбиясенә зур игътибар, әһәмият бирмәгән шикелле күренәләр.

Бала кечкенә икән, аны ашатып-эчертеп, тамагын туйдыруны тәрбиягә санап, бала зурая төшкәч, аны мәктәпкә йибәрәләр. Шуның белән эш тәмам буладыр. Бала ничек укый, әхлагы ничек, бу хакта һич уйламаган төсле күренәләр.

Гомумән диярлек, төрек хатыннары ялкау. Дүрт-биш көнлек ашны берьюлы пешереп (һәр көн аш пешереп үзен рәхәтсезләтми) шуны һәркөн йылытып кына ашыйлар. Шуннан башка эше юк, шуңа күрә тик утыра, эче пошса, тәмәке тарта, каһвә эчә. Баерак гаилә булса, пионинода уйный. Әҗнәбиләрдән[4] тәрҗемә ителгән юк-бар, мәгънәсез романнар укый, шулай итеп көнен үткәрә.

Төрек хатыннары урамда йөргәндә дә, ялкаулыкларын ташлый алмыйлар. Берничәсе бергә урам буенча акрын-акрын гына йөриләр. Читтән караган кешегә боларның бер дә эшләре юк төсле күренә. Йөзләре чаршаф[5] илә капланган булса да, үткән-барган кешеләрне дикъкать берлә карап калалар.

[1] Муаффәкыятьле – уңышлы.
[2] Мөхакәмә кыла – хөкем чыгара.
[3] Наргилә – кальян.
[4] Әҗнәбиләрдән – чит телдән.
[5] Чаршаф – пәрдә.

Гомумән төрекләр, үзләре вә хатыннары акрын йөрергә яраталар, ашыкмыйлар. Ашыгып-ашыгып, эшемнән калмыйм, тиз генә йитешим дип йөргән шикелле бер төрек күрергә никадәр теләсәм дә, һич күрә алмадым.

Хасыйл[1]: төрекләрдә иҗтиһад юк, бөтен милләтне ниндидер куркынычлы ялкаулык, эшсезлек, хәтта өмидсезлек чолгап алмыштыр.

Төрекләр шулкадәр ялкау улдыклары хәлдә тышкы якны матурлауга иренмиләр. Хатыннарда һәм ирләрдә булсын тышкы яклары кирәгеннән артык тәртипледер: сачлары гаять яхшы таралган булып, һичбер сач чыгып тормас, киеме яңа гына тегүчедән алынган шикелле таза, бөкләнгән, җыерылган йире юк, ботинкалары иң соңгы модада ясалган, һичбер сүз әйтерлек түгел; ике кулын кесәләренә тыгып тик йөри, киеме бозылыр дип утырырга да курыккан шикелле күренәдер. Мондый кешеләр тәмам ясап куелган кеби матур, ләкин җансыз курчак кеби күренеп, карауга да бик аянычтыр.

Кешеләр тәртипсез, пычрак йөрергә тиешле дип әйтмим, әлбәттә, һәркем үзен пөхтә, ару йөртергә тиеш. Ләкин төрекләр бу яктан бигрәк тә артык кылананалар. Карт кына ирләр, башка эше беткән шикелле, үтеп барган хатын-кызның киеменә дикъкать итеп «бу хатынның киеме тар, моныкы киң, килешсез...» шикелле мәгънәсез сүзләр сөйләп торудан тартынмыйлар. Хәтта минем иске, зур якалы туным да аларның дикъкатеннән котыла алмады. Аны да сөйләп калганнарын ишетергә туры килә иде. Болай иткәнче бу әфәнделәр бер-бер кирәкле эш илә мәшгуль булса иделәр! Эш юкмыдыр? Эш күп, эшләүче юк... Ватан шундый типкедә улып, һәр угылыннан ярдәм көткән бер вакытта, төрекләрнең болай эшсез, һичнәрсә уйламый йөрүләре кешегә бик авыр тәэсирле буладыр.

Иштә[2] бу тыштан күренеш, әмма мәгънәви хәят төрекләрдә күренмидер. Гаиләдә бердәмлек юк. Ире, хатыны бөтенләй башка-башка, һәркайсы үз дөньясында тора. Ире хатынына тәмам хуҗа, хатыны да иренә кол шикелледер. Ире ни әйтмәсен,

[1] Хасыйл – нәтиҗә.
[2] Иштә – менә.

ни кушмасын, хәтта бер ахмаклык булса да, хатыны бер сүз әйтмәстән шуны эшләргә мәҗбүрдер. «Бездә хатыннар ирләрнең гакылга сыймастай әмерләренә итагать кылмыйлар» дисәң, төрекләр чынлап бик гаҗәпләнәләр. Хатын ирнең әмеренә буйсынмауны төрекләр һич-бер төрле аңлый алмыйлар. Чөнки алар фикеренчә, хатын – бөтенләй ихтыярсыз бер колдыр.

Гаилә хәле, югарыда әйтелгәнчә, уңайсыз бер рәвештә булудан, һәммәсеннән бигрәк, балалар зарар күрәләр. Ата-анасы яхшы гына тәрбия итә алмый. Яхшы тәрбия бирерлек мәктәпләр дә юк диярлек.

Хосусан, кызлар өчен яхшы мәктәп бик сирәк. Бу кеби мәктәптән Әдибә Халидә ханым мәктәбе иң яхшылардан саналырга тиешледер. Бинасы зур, бүлмәләре якты, һәр йирдә тәмизлек, парталар, уку әсбаплары да бик яхшы. Барып кергәч тә кешегә яхшы тәэсир итә, күңелгә шатлык бирәдер. Бу мәктәптә кызлар да яхшы, гакыллылар, үзләрен хөр генә тоталар, куркып-өркеп тормыйлар. Хәтта бөтен Төркия хәятендә беренче булган хатыннар җәмгыятендә шул мәктәп шәкертләреннән нотык сөйләгәннәре дә булды. Мөгаллимәләр илә шәкертләрнең мөгамәләсе иптәшләр мөгамәләсе шикелледер. Белмәгәннәрен шәкертләр һич тартынып тормый, сөекле мөгаллимәләреннән килеп сорыйлар. Алар да, аналары шикелле, бик якты йөз илә генә аңлатып, аларның тәрәккыйсенә ярдәм итәләр. Иштә бу мәктәпкә әйтәсе бер сүз юк. Фәкать, тәэссефтер[1] ки, мондый мәктәпләр бик аз, күбрәк булса иделәр!

Башка мәктәпләргә кереп карап йөрергә тугры килмәде исә дә, тыштан караганда бик начар күренәләр: тәрәзәләре аз, кечкенәләр, ишекләре дә тәбәнәк, зуррак балаларга башларын иеп керергә тугры киләдер, коридорлары пычрак... Шуларны күргәндә бик уңайсыз була. Өмид өзү дәрәҗәсенә киләсең Тышы болай булгач, мәктәпнең эче дә тәртипсездер дип уйга килә...

Айя Суфия җамигы яныннан үткән вакытымда урамның икенче ягында ике яки өч катлы бер йорт күрдем. Бинасы таш, сөйкемсез, тәрәзәләре кечкенә генә, пыялалары ватык... Ватык тәрәзәләрнең берсендә үсеп утырган матур кызыл чәчкә күрен-

[1] Тәэссефтер – үкенечтер.

мәсә, бу йорт тәмам хәбесханә[1] дип уйларлык иде. Ләкин бу хәбесханә түгел: бәлки киләчәктә Төркияне коткарачак, Төркиянең өмиде булган балалар мәктәбе, имеш... Монда шундый хәбесханә шикелле мәктәпләрне күп күрдем. Болар аз түгел, әмма «Мәктәп Солтани», «Вафа Әгъдадиси» кеби күңелгә шатлык, өмид бирә торган мәктәпләр бик аз.

Бугаз эчендә бик яхшы мәктәпләр күрдем. Биналары зур, тәрәзәләре дә зур, якты, диңгез янында гына, манзаралары да бик матур, һава яхшы. Әтрафларында җәннәт кеби зур-зур бакчалар. Бу мәктәпләр Төркиядә, әмма төрекләрнеке түгел – әҗнәбиләр мәктәбе. Боларның шәкертләре сәламәт, тазалар, шатлар. Югарыда сөйләдегем төрек мәктәпләренең шәкертләре арык, йөзләре сары, күңелләре төшенке булып, араларында аерма бик зарурдыр. Тышларында аерма булган шикелле, боларның рухларында да аерма булачагында шөбһә юктыр.

Үзләрендә шундый яхшы мәктәп булмаганга, төрекләрнең зурлары үзләренең балаларын шул әҗнәби мәктәпләргә бирергә мәҗбүрләр.

Мәгълүмат фәния[2] алу өчен бу мәктәпләр никадәр яхшы булсалар да, төрек балаларының мәгънәви тәрбияләренә зарарлы булачагы шөбһәсездер. Бу мәктәпләрдә ислам, Ватан хисләре тәмам бетерелә. Балалар Төркияне сөймәс дәрәҗәгә киләләр; бала вакытыннан Ватаннан аерылган рух зурайгач та Ватанга якын булмый. Шул рәвешле төрекләр, үзләре дә сизмәстән, төреклекне һәм Төркияне бетерүгә ярдәм итәләр.

Хәтеремдә калды: шураи дәүләт әгъзаларыннан берсенең балалары француз мәктәбендә укый иделәр. Балаларның аналарына: «Әҗнәби мәктәбендәге тәрбия төрек балаларындагы Ватан вә ислам мәхәббәтенә күп зарар китерәләр, бәлки ул мөкаддәс хисләрне бөтенләй бетерәләр» дип сүз арасында әйткәнемдә, ханым әфәнде: «Юк, болай булмас, мин үзем аларны тәрбия кылам. Ватанга мәхәббәтләрен арттыруга тырышам», – диде. Мин бу сүзләргә бөтенләй ышанып бетмәгәнгә, ханым әфәнденең кәефе китә төште. Кайсымызның фикере тугры икәнлекне ачык

[1] Хәбесханә – төрмә.
[2] Мәгълүмат фәния – фәнни мәгълүмат.

хәл итү өчен, ханымның иң кечкенә кызын чакырып сөйләшергә тәклиф иттем[1]. Бу кызчык та әҗнәби мәктәбендә иң аз вакыт тәрбияләнгән балаларның берсе иде. Кызчык килгәч, анасы сүз арасында: «Төркиянеме, Франциянеме күбрәк сөясең?» – дип төрекчә сорагач, бала һич уйламастан: «Әлбәттә, Францияне күбрәк сөям», – дип французча җавап бирде. Мескен бала, төрекчә сөйли белсә дә, ана телендә сөйләмәскә тырышадыр. Ханым әфәнде аптырап калды, ни әйтергә белмәде. Ниһаять, бик төшенке тавыш илә: «Үземездә яхшы мәктәпләр юк, балаларымызны шулай тәрбия итәргә мәҗбүрмез инде...» – диюдән башка бер сүз тапмады.

«Сез үзеңез яхшы мәгълүматлы бер ханым, сезнең кеби башка ханымнар да юк түгел. Җыелышып берәр милли мәктәп ачсаңыз да шул мәгъсүм төрек балаларын төреклек вә ислам рухында тәрбия итү шикелле мөкаддәс бер эш башласаңыз, киләчәктә Төркия әҗнәби бәйлелегеннән котылмыш булып, сезгә һәм милләт, һәм тарих рәхмәтләр укырлар иде...» – дидем.

Ханым әфәнде бик уңайсызланды исә дә йөзендә күренгән йас[2] галәмәте бу эшләрнең булуына ышанмаганлыкны күрсәтә иде.

## III

Мөхтәрәм җәридәңездә[3] төрекләрдә гаилә мәсьәләсе вә аның уңайсыз яклары хакында, балалар тәрбиясе ни рәвештә вә ул тәрбиянең Төркия истикъбаленә[4] ничек тәэсир итәчәге тугрысында бераз язган идем. Бу хосуста язар өчен Төркиядә, төрекләр арасында шаигъ[5] булган катнаш никахлар хәтергә киләдер.

Христиан кызларына өйләнү төрекләрдә гадәт булып киткән, мода булган. Бу эштә шәригать рөхсәт итә бәһанәсе илә[6] төрекләр бу юлда сүи истигъмаль итү[7] дәрәҗәсенә киләләр. Ләкин

[1] Тәклиф иттем – (көчләп) куштым, боердым.
[2] Йас – матәм, траур.
[3] Җәридәңездә – газета.
[4] Истикъбаленә – киләчәгенә.
[5] Шаигъ – һәркемгә билгеле.
[6] Бәһанәсе илә – сылтавы белән.
[7] Сүи истигъмаль итү – явыз ният белән куллану.

миңа калса, катыш никахларның зарары бик күп, һәм төрекләрнең истикъбале өчен хәвефледер.

Бер гаилә рәхәт яшәсен өчен, аның әгъзалары арасында берлек булу һәм берсенең башрак булып, башкалары бераз аңа итагать итү лязем шикелле күренәдер. Минемчә, бер дәүдәт гадәттә бер зур гаилә хөкемендә улып, анда булган һәр милләтләр дә бер хәят илә яшәргә, һәммәсе бер кеше кеби булырга һәм гаилә хәятен идарә итүче баш әгъза урынындагы хөкүмәт аталган бер һәйәтнең[1] тәдбирләренә[2] күнәргә һәм тәрәккый вә мәдәният юлында ул һәйәткә әһали (милләт) ярдәмендә булырга тиешледер: табигый уларак һәр дәүләттә хөкүмәт әрбабы[3] шул дәүләттә күпчелек тәшкил иткән милләт кешеләреннән булып, аның исеме илә исемләнә. Ул милләт тә милләт хакимә[4] саналадыр. Төркиядә милләт хакимә – төрекләрдер.

Төркия мөстәкыйль, куәтле, бәхетле булсын өчен, төрекләр аны Ватан танып, аны саклауны үзләренә мөкаддәс вазыйфа санарга, аның тәрәккыйсы өчен һаман иҗтиһад кылырга, кирәк чакта аның өчен җан бирүдән дә курыкмаска тиешләр. Юкса төрекләр истикъляльны[5] саклый алмый, башка бер милләт кул астына кереп, төреклекне югалтулары шөбһәсездер.

Күп төрекләр, хәтта зур гына урында торганнары да мөстәкыйль булып тору илә икенче бер милләт кул астында торуның аермасын аңламаганнар шикелле: «Бер зур дәүләт безне үз химаясенә[6] алса иде дә, без дә аякка басар идек...» шикелле гакыл аңламастай сүзләр сөйлиләр. Мондый сүзләрне ишетү бик авыр була иде.

Бичаралар, «химая»не һаман аңламыйлармы?

Ислам дәүләтеннән шундый химая астына кергәннәре азмыдыр? Мөстәкыйль яшәү мөмкин икән, аз гына иҗтиһад итүгә

---

[1] Һәйәтнең – комитетның, коллегиянең.
[2] Тәдбирләренә – чараларына.
[3] Хөкүмәт әрбабы – хөкүмәт әһелләре, биредә җитәкчеләре мәѓънәсендә.
[4] Милләт хакимә – өстен милләт (господствующий).
[5] Истикъляльны – бәйсезлекне.
[6] Химая – берәүнең кул астында торып саклану.

иренгән шикелле «башкалар ярдәм итсә иде» дип көтеп тору тәмам мәэюс[1] булу түгелме?

Истикъляль, бик газиз булдыгы шикелле, бер мәртәбә кулдан китсә, аны кайтару да бик читен, хәтта мөмкин дә булмыйдыр. Төрекләр дә, теләкләренчә, бер дәүләтнең химаясенә керә калсалар, аннан котылулары бик шөбһәле, бәлки өмидсездер.

Яхшы бер хәяткә чыгу өчен иҗтиһад кылу[2] бу мөселманнарда юктыр. Бер мәртәбә кол булса, шул көе калына һәм шул хәл табигый саналадыр. Шул юлда төрле кыенлык, читенлекләр күренсә, һәммәсе дә тәкъдиргә йөкләтелеп, эш дип, шуның илә тәмам була, яхшылатырга тырышмыйлар.

Истикъляльны югалткач, аны кире кайтара алмый, даимән кол булып калган милләтләр аз түгелдер. Бер вакытлар истикъляльны югалтып та, соңыннан кинәт мөстәкыйль булган милләтләр дә юк түгел.

Русияне татарлар астылар, кистеләр, ике йөз ел кадәр татарлар хуҗа булып тордылар исә дә, руслар һәммәсе бер кеше шикелле иҗтиһад иттеләр, татарлар исә бер-бере илә сугышудан бушамадылар. Ниһаять руслар хаким, татарлар исә мәхкүм булдылар[3]. Икенче мәртәбә Русия французлар истилясыннан[4] котылды. Әмма Төркиядә болай булу ихтималы юк. Чөнки төрекләрдә Ватан хисе, берлек юктыр. Коллыктан курку вә аны уйлап дошман илә көрәшерлек гайрәт юклыкны кинәт исбат иттеләр.

Төрекләр берничә сәяси партияләргә бүленгәннәр, бер-берен һич яратмый, кулыннан килсә, бер-беренә зарар итәргә тырышалар. Хәтта Ватаннарына шулкадәр зур һәлакәт килгән вакытта да берләшә алмадылар. Һаман партия низагы дәвам итте. Боларның үзара низаглары Төркиягә дошманнан да артыграк зарар китерде.

Кырым ханнары Польша кенәзләренең үтенүе илә анда ярдәм өчен үз гаскәрләрен йибәрмеш иделәр. Бу мөселман гаскәре Польшада озак кына торгач, поляклар илә катыша-катыша,

[1] Мәэюс – өметсез.
[2] Иҗтиһад кылу – тырышу.
[3] Мәхкүм булдылар – биредә җиңелделәр мәгънәсендә.
[4] Истилясыннан – басымыннан (басып алуыннан).

ниһаять поляк кызларына өйләнә башладылар. Алардан балалар туды. Бу балалар христиан ана тәрбиясендә булу сәбәпле, татар телен, гадәтләрен һәм Ватаннары булган Кырымны белми үстеләр. Ватаннарына мәхәббәтләре булмады. Шул рәвешле тәмам мөселман түгел, тәмам христиан түгел, татар да түгел, поляк та түгел – милләтен югалткан бер Литва татары булып калдылар. Бөтен бер милләт үз телен, гореф-гадәтен югалтып, бөтенләй бер чит милләт арасында үзе дә югалу дәрәҗәсенә килмештер. Бичаралар бу хәлгә үзләре дә кайгыра, уңайсызланалар. Чынлыкта бик аяныч хәлдер!

Литва татарларының бу аяныч хәлгә килүләренә сәбәп нидер? Минемчә, бер сәбәп – ул да булса, аналарының христиан кызы булуыдыр.

Катыш никах хәзер дә Төркиядә бик күбәеп бара.

Төрек яшьләре искедән уку өчен Яурупага бара иделәр һәм хәзер дә баралар. Боларның бәгъзеләре, Аурупада озак тору сәбәпле, шунда христиан кызларына өйләнергә мәҗбүр булалар. Анда өйләнми кайтканнары исә Төркиядә үзләренә тиң, сөйләгән сүзләрен аңларлык, укыган, тәрбия күргән төрек кызы таба алмагач, чарасыз, яхшы укыган, тәрбия күргән христиан кызы алуга мәҗбүр булганнар.

Төрек кызлары исә, хөррият дәверенә кадәр чит мәмләкәтләргә чыгып йөрү хокукыннан мәхрүм, үзләрендә яхшы тәрбия алырлык мәктәпләр улмадыгыннан, әлбәттә, читтә укып кайткан яшьләргә үзләрен яраттыра алмый иделәр; чөнки хөр тәрбия күргән, яхшы укыган христиан кызы илә, һичбер йиргә чыкмый, һаман хәрәмдә генә утырган, бернәрсә дә күрмәгән, яхшы тәрбия һәм мәгълүмат алмаган төрек кызы арасында, әлбәттә, аерма булырга тиеш. Әүвәлгеләр никадәр хәятле булса, соңгыларда шулкадәр рухсыз, төшенке күңелле булучылык бик табигыйдыр.

Укыган яшьләрдә күрелгән бу хәл килә-килә гадәт, мода шикелле булып һич кирәкмәгән кешеләр дә, ягъни гади, һич Аурупаны күрмәгән төрекләр дә шулай кыйлана башлаганнар. Шулай итеп, әүвәлдә чарасыз уларак эшләнгән бер эш хәзер миллият һәм милләт кирәкләрен оныттырырлык дәрәҗәдә бер гадәткә әйләнмештер.

Минемчә, инсан үз милләтен онытмаска, миллиятне югалтмаска тиештер. Хәлбуки катыш никахлар исә моның киресенә хезмәт итә һәм миллиятнең нигезен какшатадыр.

Төрекләрдә күренгән катыш никахлар, арада булган сөешү һәм тирән хиссият нәтиҗәсе дип тә булмый, бәлки һичбер фикергә нигезләнмәгән йиңелчә генә бер хәрәкәттер.

Христиан кызына өйләнгән гади, аз-маз гына укыган бер төректән: «Ни өчен төрек кызы алмадыңыз? Хатыным, балаларымның анасы диярлек бер мөселман кызы юкмы иде?» – дип сорадым да, һич тартынмастан, бертөрле эреләнеп кенә: «Милләтемез кызларыннан үземә тиң, үзем яратырлык бер кыз таба алмадым», – җавабын бирде.

Бөтен һөнәре матур киенүдән артмаган төрек, үзен шулкадәр мәдәни санап, мөселман кызын хатын итеп алуны бер түбәнчелек саный. Шуларны күрү кешегә бик авыр тәэсир итә, хәтта елыйсылар киләдер...

Христиан кызын алып, мөселман баласын христиан ана тәрбиясенә бирә вә моның илә милләтенә әйтеп бетергесез зарар китерә. Ислам вә төркиятнең зәгыйфьләнүенә сәбәп була. Бичара шуны аңламый яки аңларга теләмиме?!

Өйләнмәк шикелле инсанның хәятендә иң мөһим бер мәсьәләне хәл итә икән, аның нәтиҗәләрен аз гына да уйламастан инсан хәрәкәт итәрме?

Анасы христиан икән, баласының чын мөселман, ватанпәрвәр булып тәрбия кылынуы читен, гадәттә, мөмкин түгелдер.

Чөнки бала анасына газиз, вөҗүдкә килгәч исә аралары бигрәк тә якынаядыр. Ана сөте илә баланы туйдыра, мәхәббәт илә тулы күкрәгенә кыса, һич арымастан балага һаман йомшак сүзләр генә сөйли. Шунлыктан бала һаман христиан ананың сүзләрен генә ишетә, аның телен аңлый һәм ул тел бала өчен газиз ана теле булып кала. Бер христиан кызының да Төркиягә вә төрекләргә мәхәббәт күзе илә карау ихтималы юктыр. Моңа һич ышанып та булмый. Чөнки христиан кызы Төркиягә дошман, аны сөйми һәм үзендәге дошманлык хисен баласына да, чарасыз, иң зарарсыз улдыгы сурәттә, һич фәрекъсыз рәвештә[1] тәрбия итәчәктер.

[1] Фәрекъсыз рәвештә – бернинди үзгәрешсез (нәкъ үзе уйлаганча).

Искедән бирле һаман зәхмәт эчендә килгән бичара Төркиянең тышында һәм эчендә дошманнары аз түгелдер. Катыш никахлар исә төрекләрнең үз араларында да Ватанга дошманнарны күбәйтүдән башка бер файда бирми, һаман эшне авырлаштыра гына. Шуңа күрә Төркиядә мондый катыш никахлар бетәргә тиеш. Минемчә, бер дәүләтнең тәрәккыйсы андагы хатыннарның мәгълүматлы яхшы ана булуларына баглыдыр.

Форсат бар икән, төрек хатыннары укырга, мәгълүмат алырга, тәрбиядә христиан кызларыннан югары торып, ирләрен үзләренә багларга, мөселман балаларын ислам рухында, Ватанга мәхәббәт үзрендә тәрбия итәргә тиешледер. Шулай иткәндә төрек балалары Ватан баласы булырлар. Төркиянең коллыктан котылуына хезмәт итәләр. Һәм шөбһәсез Төркия дә бәхетле дәүләт, төрекләр дә бәхетле милләт улырлар. Иншалла.

**IV**

Истанбулга мәҗрухларны[1] карар өчен бармыш улдыгымыздан, әлбәттә төрекләрнең күп офицерларын һәм солдатларын күрергә туры килде. Бөтен вакыт шулар илә үтә иде. Яхшы вә күңелле хәлләр дә күрәсең, шатланасың. Ләкин күңелсез, яраксыз нәрсәләр күреп тә хафаланасың.

Никадәр авыр булса да, төрек гаскәре арасында укый-яза белмәгәннәренең күплеген әйтергә тугры килә. Укый-яза белмәгәннәр гаскәрдә бик күп. Хәтта яза, укый белми торган унтер офицерлар, офицерлар да очрыйдыр. Әлбәттә, алар хезмәт күрсәткәннәр, сугышчан батырлыкка ияләр. Шуңа күрә аларга беркадәр дәрәҗә бирелгән. Шулай булса да, алар укый-яза белми торган кеше булып, алардан зур эшләр көтәргә тугры килмидер.

Офицерлар илә гади солдат арасында, аңлаганыма күрә, рабита[2] юк.

Офицерларның күбесе үзләрен солдаттан бик аерым тоталар. Кечкенә кардәшләре булган солдатка якын булырга тырышмыйлар. Моның сәбәпләрен офицерлардан сорашкаладым, белергә тырыштым исә дә, канәгать итәрлек җавап ала алмадым. «Һәр

[1] Мәҗрухларны – яралыларны.

[2] Рабита – бәйләнеш

гади нәфир[1] илә бик якын, кардәш кеби мөгамәлә итә башласаң, алар бик үзсенеп китәләр, санга санамый, хөрмәт итми башлыйлар. Шул рәвешле, гаскәрлектә иң мөһим, иң кирәкле нәрсә – дисциплина бетә, югаладыр» кеби сүзләр сөйләделәр. Бу мәсьәләне мин аңламыйм, әһеле түгелмен, бәлки аларның бу сүзләре тугрыдыр. Әмма офицер илә нәфир арасында яхшы, кардәшчә мөгамәләдән дисциплина югалуны аңлау бик читен, хәтта мөмкин түгелдер. Чөнки үзен хөрмәт иткән, сөйгән кешенең әмерен тоту кеше өчен бик күңелле, рәхәт булырга тиештер. Офицерлар дисциплина өчен нәфирнең мәхәббәтен корбан кыйлып файда итмәсәләр кирәк. Чөнки офицерларга «дошманнарымыз» дип нәфирләрнең әйткәннәрен ишетә идек. Аралары шулкадәр бозылмыш вә ераклашмыш икән, офицерлар илә нәфирләрнең берберләрен аңлап эш күрүләре уңайсыз булырга тиеш.

Һәрвакыт кеше кайнап торган «Яңа күпер»дә, карап торсаң күренә иде: үткән-барган нәфирләр офицерларга честь бирәләрме. Кайчак берәр бичара нәфир чын күңелдән, хөрмәт илә забитка[2] честь бирә; әмма забит үзен гаять югары тотып, аны күрмәгән шикелле җавап бирмәстән узып китә. Бичара нәфирнең күңелен төшерә, җәрәхәтли. Бер мәртәбә шулай булгач, икенче дә ул забитка хөрмәт илә честь бирми. Әлбәттә, бирмәс. Чөнки аның гыйззәте нәфесе[3] бер мәртәбә аяк астында тапталып калды.

Соңгы фәлякатле[4] сугышта төрек гаскәрен сүктеләр, куркак дип тә гаепләделәр. Ләкин бу бик тугры булмаса кирәк. Минемчә төрек гаскәрендә гаеп юк. Гаскәр мөкаммәл, батыр, гайрәтле һәм шулкадәр дә шәфкатьледер. Гаеп бар исә – гаскәрнең башлыкларындадыр.

Хәтеремдә калды: хастаханәмезгә өч затны китерделәр. Доктор яныннан чыгып барганда, боларны беренче мәртәбә күрдем, әмма һич хастага охшамаганнар – бөтенләй сәламәт кеше кеби күренделәр.

[1] Нәфир – сугышчы, солдат
[2] Забитка – офицерга
[3] Гыйззәте нәфес – үз-үзен сөюе (самолюбие).
[4] Фәлякатле – афәтле, кайгылы.

Гаҗәп, боларда нинди хасталык бар икән, дип уйга килде. Хастаханә башлыгы доктордан: «Бу өч офицер ни илә авырыйлар», – дип сорагач: «Боларның хасталыгы куркыныч хасталыктыр, боларда «ялкаулык» хасталыгы бар. Башка бернәрсә дә юк. Хастаханәгә кабул итмәс идем, ләкин Кадәрга хастаханәсенә урнаштырырга әмер алдым, чарасыз кабул итәргә мәҗбүрмен», – җавабын бирде. Мин доктор уйнап сөйлидер дип уйладым. Ләкин доктор дөресен сөйләгән, имеш.

Кич нәүбәт саклаганда бу өч забит[1] яткан палатага кердем. Яннарыннан узганда, бераз туктап, баш очларына куелган хаста кәгазенә күз салдым. Кәгазьдә: туйганчы ашарга, хәрарәт[2] юк дип язылган, бәйләнгән җәрәхәт-фәлән дә күренми... Ниһаять: «Сездә ни чир бар соң?» дип үзләреннән сорадым. Берсе бераз саңгырау, икенчеләрендә бизгәк шикелле бер нәрсә, имеш. Саңгыравы гаять таза бер кеше. Кычкырып көлә, хәтта ул көлгәндә колак авырта. Бераз сөйләштек. Сүз арасында, ялкаусыз-фәлән кеби сүзләр илә бераз үзләрен ачуландырдым да. Соңра бер сүз дә тапмагач: «Без бик ардык, ял итәргә хастаханәгә кердек», – диделәр. Димәк, болар һич хаста түгел, фәкать эштән качып монда килгән булалар. Мин дә истиһза илә[3]: «Алла сезгә тизрәк сәламәтлек бирсен дә, мөкаддәс вазыйфаңызга кайтыңыз», – дип киттем.

Берничә көннән боларның саңгыравын тәмам офицер киемендә коридорда күрдем. «Янә мөхарәбәгә китәм», – диде – «Бераз рәхәт улдым», дип шул көе калды.

Моннан берничә көн соңында тыйббия мәктәбенә[4] барырга тугры килде. Мәктәп бакчасында хасталар йөри иде. (Мәктәптә лазарет бар). Ни күрим: хасталар арасында теге саңгырау офицер да йөри. «Сез монда мыни? Ни эшлисез?» – дип, гаҗәпләнеп сорадым. Саңгырау офицер да бераз оялган сыман булып: «Бу хастаханәдә ятам. Кадәрга хастаханәсеннән сез безне кудыңыз бит», – диде. Мин дә аның яныннан киттем. Бәлки

[1] Забит – офицер.
[2] Хәрарәт – эсселек (тән температурасы).
[3] Истиһза илә – көлеп, мыскыл итеп.
[4] Тыйббия мәктәбе – медицина институты.

хастаханәләрдә мондый хасталар болар гына булмаган, боларның ишләре күп булгандыр, кем белсен?

Бу язганнарым һәммә офицерлар хакында түгелдер. Әлбәттә, мондый яраксызлары булган шикелле, хәмиятле[1], гайрәтле, Ватан юлында җан фида кылудан тартынмаганнары да аз түгелдер. Шулай булса да, хәмиятлеләр нәфирләр (гади солдатлар) арасында күптер. Бер нәфир алты мәртәбә җәрәхәтләнеп, һәрберендә җәрәхәте төзәлгәч тә, кире мөхарәбәдәге[2] полкына китә иде.

Бер таныш төрек ханымы, офицер хатыны бар иде. Мөхарәбәгә кадәр гаиләсе илә (ире һәм кечкенә угылы) Әдернәдә торганнар. Сугыш башланды. Балкан ярым атасының[3] кубрәк кыйсьме канга буялды. Дошманнар да Әдернәгә якынлашып киләләр иде. Ул вакытта Әдернә әһалисе шәһәрне ташлап китә башлады. Сөйләдегем төрек ханымы да китүгә хәзерләнгән. Шул вакытта бу ханым кан илә буялган бу йирләрдән тизрәк читкә китәргә ирен никадәр димләсә дә, ялынса да, ире күнмәгән. Үзенең туган шәһәрен һәм ислам илә Төркияне саклаудан качмыйча, Әдернәдә калган. Төрек ханымы баласы илә Истанбулга килгәннәр.

Кем белсен, бу бичара, бәлки, актык тамчы канына кадәр шул Әдернәне саклап, шунда шәһид булгандыр.

Ире шундый фидакярлеккә хәзер икән, аны шул мөкаддәс эшеннән аерырга тырышкан бу хатын шуны сөйләгәндә бик ямьсез, сөйкемсез күренә иде. Мин дә бу мөгамәләсе өчен аны (хакым булмаса да) шелтәләүдән үземне тыя алмадым. Хатын да, кәефсезләнеп, минем янымнан чыгып китте.

Хастаханәдә нәүбәт саклаган төннәрнең берендә бер палатага кердем. Ягылган мич янында хадимә Зәйнәп ханым (карчык) утыра иде. Шулкадәр тирән уйга чумган. Хәтта минем кергәнемне һич сизмәде. Хасталар рәхәт йокыларында. Башка бер эшем булмагач, Зәйнәп ханым янына килеп утырдым. Матур кара күзләренең карашы бертөрле моңлы, кайгылы булып, мәрхүмә сөекле әбиемне хәтеремә төшерде. Шулвакыт уянган хиссиятемә бертөрле каршы тора алмый, Зәйнәп ханымны сөя-сөя кочып

[1] Хәмиятле – башкаларны саклый, яклый торган.
[2] Мөхарәбәдәге – сугыш кырындагы.
[3] Ярым атасының – ярымутравының.

үбүдән үземне туктата алмадым... Күзләреннән яшьләр килде... Мин дә аптырап калдым. Нидән еглаганын аңлый алмадым. Соңра тәгәрәп-тәгәрәп төшмәктә булган яшьләрен сөртә-сөртә сүзгә кереште: «Бу вакытка кадәр бер кайгым барлыгын бер кешегә дә сөйләгәнем юк иде. Сезне, һәммәңезне үз балаларым шикелле сөйдегемнән, хәзер сиңа сөйлисем килә», – диде һәм хәлен аңлата башлады. Мөхарәбәгә киткән дүрт угылымнан өчесе өйләнгәннәр, бала-чага сахибләре. Зәйнәп ханым тәрбиячесез калган. Шул мескин балаларның хәлләре ничек булачагы хакында уйлап утыра, имеш. Үзеннән туган балалар мөхарәбә мәйданында һәр дәкыйка[1] үлемгә хазыйр булдыгы вакытта шулардан калган мәгъсумнар[2] хакында мескинәнең аналык шәфкате илә уйлап утыруы миңа бик нык тәэсир итте. Шул дәкыйкадә Зәйнәп ханым үзе дә мәгъсум фәрештә шикелле күренә иде. Хакыйкатьтә шул зәгыйфә карчыкта күренгән кадәр хәмиять[3] башка беремездә бар микән? дип уйга килә, хәтта инсанны хәсәд иттерә[4] иде.

Зәйнәп ханымнар фәрештә кеби саф җанлы төрек хатыннарыдыр. Болар чын мәгънәсе илә ана һәм чын мәгънәсе илә хатындыр. Алла бирсен дә Төркиядә болар кеби хатыннар күп булсын!

Бер-бер эш илә хастаханәдән чыгып китсәң, тизрәк кайтасы, шул саф күңелле мәҗрухларны[5] күрәсе килә. Хасталар арасында рәхмәт була. Боларда булган дин, Ватан мәхәббәте, бер-беренә шәфкать сөйләп бетергесез. кешедәге кайгыдан мөтәэссир булу[6] монда бик куәтледер. Иртә берлән палатага керсәң, һәммә нәрсәне онытасың, гакылыңда шул сөекле хасталар гына буладыр. Бере артыннан бере уяна баралар, «Сабах шәрифләр хәер улсын!» сүзләре берлән безгә һәм дә бер-беренә хәерхаһлык изһар кыйлалар[7]. Иртә берлән ишетелгән шул сүзләр көн буена музыка шикелле колактан китми тора. Күзләрендә мәхәббәт, шәфкать бөтенләй күренеп тора. Боларны күргәндә инсан шатлана, шулар

[1] Дәкыйка – минут.
[2] Мәгъсумнар – гөнаһсыз яшь балалар
[3] Хәмиять – башкаларны зарар күрүдән саклау.
[4] Хәсәд иттерә – көнләштерә.
[5] Мәҗрухларны – җәрәхәтлеләрне, яралыларны.
[6] Мөтәэссир булу – хәсрәтләнү.
[7] Хәерхаһлык изһар кыйлалар – теләктәшлек күрсәтәләр.

шикелле шәфкатьле, рәхмәтле буласы килә. Начар мөгамәләдә булынган булсаң – үкенәсең. Көн буе бик яхшы гына булып бербер кешегә авыр килердәй эш эшләмәскә тырышасың.

Болар гаҗәп халыктыр: берсенең шатлыгы – икенчесенә шатлык, берсенең кайгысы – икенчесенә кайгыдыр.

Ватаннары дошман кулына төшкән, харап ителгән мәҗрухлар да аз түгел иде. Бичаралар үзләре хастаханәдә, әмма гаиләләре Алла белсен кайдадыр, бәлки бөтенләй дөньяда да юклардыр. Бу кадәр мескеннәрдән безнең палатада икесе бар иде. Берсе – өйләнмәгән, яшь генә, Танаш исемле бер рум (грек) баласы, икенчесе исә – гаилә сахибы Мөхәммәд ага. Боларның кроватлары янәшә иде. Бу бер мөселман илә бер грек арасындагы дуслык бик куәтле иде. Боларны аерып куярга кирәк булган вакытлар да булды. Алар елый-елый «безне аермагыз» дип ялынып, һаман бергә калдылар.

Хастаханәмездә мөселман солдатлары илә христиан солдатлары арасында нәфрәт шикелле хиснең әсәре дә сизелми иде.

Мөхәммәд ага күп вакытларда уйга чума, зур күзләре яшь илә тула. Ахрысы гаиләсе хакында уйлана иде. Танаш вә башкалар да аның кайгысын таратырга тырышалар, чәй эчерәләр яки янына утырып берәр нәрсә сөйләргә тотыналар. Шулай итеп, Мөхәммәд аганың кайгысын таратып, үзләре дә шат була иделәр.

Иттифакчыларның сугышып кергән йирдәге әһали илә ничек мөгамәлә иткәннәренә Мөхәммәд ага, күзе берлән күргәнгә, үз гаиләсе илә шул дошманнар тарафыннан тәләф ителмеш[1] дип уйлый вә бик хафалана иде булырга кирәк.

Мөхәммәд ага беркөн хастаханәдән китәчәк; кайттым дисә, гаиләсе юк. Кая барырга да белми. Бу уйлар да аны борчый иде булса кирәк. Анатулы[2] хасталарының күбесе гаять шәфкать илә, җәрәхәтләрен яңартмас өчен, бик сакланып кына, Мөхәммәд аганы, хастаханәдән чыкканда үзләренә, кайсы шәһәргә, кайсы авылга кунакка чакыра иделәр. «Соңра Алла бирер дә, гаиләң булыр», – дип тели иделәр. Кулларыннан килгән кадәр Мөхәммәд

[1] Тәләф ителмеш – үтерелгән.
[2] Анатулы – Төркиянең Анатолия өлкәсе.

агага ярдәм итәчәкләренә дә, вакытлыча булса да, аны яхшы мосафир итеп шәфкать, мәхәббәт илә тәрбия итүләренә дә һич шөбһә итәргә тугры килмидер. Чөнки Анатулының саф төрекләре – гаять шәфкатьле, мәрхәмәтле вә инсаниятле бер милләттер.

Хәлил исемле хаста да һич хәтеремнән чыкмыйдыр. Гаҗәеп бер кеше! Һәркемгә лаек йомшак сүз табар, кешене һич рәнҗетмәс, аның җанының сафлыгы кешене хәйран итәдер. Укымаганнитмәгән шул төрек мужиклары үзләренең саф күңелләре, шәфкатьле табигатьләре илә кешене хәйран калдыралар. Аларның мөгамәләләрендә ниндидер йомшаклык, матурлык, инсанлык бар ки, башка кешеләргә дә тәэсир итеп, инсанны рәхәт хәлгә китерә. Яшьләре картларына атага лаек хөрмәт күрсәтә, картлары яшьләренә угыллары кебек сөеп мөгамәлә итәләр.

Әдернә китте хәбәре килгән вакыт хасталар бик уңайсызландылар. Елаганнары да булды. Хәтта шул хаста көенчә янә мөхарәбәгә китәргә, Әдернәне кире алыр өчен барырга теләгәннәре дә аз түгел иде.

Рус газеталарын укыганны күрсәләр: «Әҗнәби газеталары ни язалар», – дип сорашырга тотыналар. Бервакыт рус газеталары «Төрек гаскәре сугыш мәйданыннан качалар», – дип язалар, дидем. Бичараларның күзләре яшь илә тулды.

Соңра, сугышның иң кызу вакытында офицерлар гаскәрне ташлап качалар. Офицерсыз гаскәр нәрсә эшләргә дә белми, мәгънәсез җан корбан иткәнче, алда бер-бер йиргә ярармын фикере илә, табигый, гаскәр дә кача башлый. Шуңа күрә бөтен гаеп забитларда дип сөйлиләр. Бәгъзе фирка гаскәре һичбер тупсыз калган. Дошман исә ягъмур кеби туплардан яудырып тора. Шул хәлдә дә төрекләр качмый, тәмам кырылып беткәнгә кадәр сугышкан йирләр дә булган. Чөнки башлыклары булган офицерлар хәмиятле кешеләр тугры килеп, үзләре дә ут эчендә йөреп, гаскәрләргә үрнәк булганнар. Шуңа күрә төрек гаскәре башына килгән хурлыкларның сәбәбен, минемчә, гаскәрдә эзләргә кирәкми, ул сәбәпләр башка йирдәдер. Чөнки төрек гаскәре куркак түгел, җәсүрдер[1].

[1] Җәсүр – батыр, гайрәтле.

Күп вакытта, операция кебек нәрсәләр ясаганда, хасталарның сабырлыгына докторлар хәйран кала иделәр. Исмәгыйль исемле бер хастаның кул сөякләрен шрапнель ватып бетергән, җәрәхәтенә караганда куркыныч. Бер көн доктор, Исмәгыйльнең җәрәхәтен бәйләгәндә, эчтә бер сөяк ватыгы барлыгын аңлаган. Шуны алырга кирәк булган. Сөяк ватылган булса да, бер кырые тәннән аерылмый, сеңергә бәйләнеп тора икән. Доктор сөякнең буш тарафын кыскыч илә эләктереп бора башлады. Ниһаять сеңер өзелеп, сөяк алынды. Шул вакытта бичара Исмәгыйль һич тавыш чыгармый сабыр итеп торды. Бу кеби хасталар бик күп. Боларның һәркайсы хакында язачак булсак, әлбәттә, бик озын булачактыр. Бәгъзе вакыт аптырап «Операция вакытында бик тыныч кына тордың, бик авыртмады булырга кирәк», – дип сорасаң: «Авыртмасмы йә, авыртыр. Әмма аны кешегә белдерергә, зәхмәт чиккәнеңне кешегә сиздерергә ярамый. Аны тик бер Алла белергә тиеш. Чөнки без газиләрмез[1], бөтен чиктегемез зәхмәтләр бары тик бер Алла өчендер», – дия иделәр.

Бу хәтле яхшы сыйфатларга ия булган төрек гаскәре бераз укыган булып, укый-яза белә торган булса иделәр, болар хакыйкый беренче гаскәр булыр иделәр.

Хасталар арасында Траблистан кайткан гаскәриләр дә була иде. Бичаралар ватаннарыннан еракта, Ватан, дин юлында сугышып, зәхмәтләр чигеп, Истанбулга кайтканнар. Бераз ял итәргә боларның, әлбәттә, хаклары бар иде. Ләкин Ватанны саклау өчен үзләренең арыганлыкларын, хәлсезлекләрен онытып, Балканда булган мөхарәбәгә киткәннәр.

Иштә ошбулар игътибарга алынса, сугыш төрек гаскәрләре өчен ни кадәр фәлякатьле[2] булса да, гаскәрнең яхшылыгына, аның тарихи шөһрәтенә һич зарары тимәскә тиештер. Хакыйкатьтә сәнәләр[3] буенча әле мәмләкәт эчендәге дошманнар тарафыннан, әле тыштагы дошманнар тарафыннан ясала килгән бу

[1] Газиләрмез – дошман белән сугышучы; сугышта җиңеп чыгучы.
[2] Фәлякатьле – кайгылы, афәтле.
[3] Сәнәләр – еллар.

сугышлар уен түгел, боларга тәхәммел итәргә[1] күп гайрәт, күп сабырлык кирәктер.

Төрекләр әүвәлләрдә дә ялгыз булганнары кеби, бу мөхарәбәдә дә алар ялгыз үзләре калдылар. Балкан иттифакы бу сугышка мәзлумнәрне[2] коткару төсе бирде; сугыштан максат һич йир фәлән алу түгел, салибны ай коллыгыннан, мәзлумнәрне золым кулыннан коткару өчен[3] итеп күрсәттеләр. Бөтен дөнья шуңа ышанды. Шуңа күрә бөтен әфкяре гаммә[4] Балкан иттифакы тарафына булды. Ләкин бу алдану озакка бармады. Төрек илә сугыш бетәрбетмәс иттифакчылар, алынган йирләрне бүлүгә керештеләр. Башта бер-берсенә борадәр[5] дип йөргән булсалар да, соңра сөяк өчен талашып, үзара сугышка керештеләр. Һәм үзләренең кемлекләрен бөтен дөньяга күрсәттеләр.

Мәдәни Яурупа газеталары «Исламның соңгы көннәре, ислам шимди олуг түшәгендә, ислам инде бетсен...» шикелле бөтен галәм исламга авыр нәрсәләр яздылар. Аны хәкарәт иттеләр[6]. Яурупада «инсан» дигән сүз мәгънәсез бер сүз булып, мәйданда бары тик «христиан» булырга тиеш дигән фикерне ачыктан-ачык әйтеп күрсәттеләр. Без шәрыклылар да моны Яурупаның «Инсан» дигән сүзгә биргән мәгънәсен аңлап калдык. Бу да зәһәр дәрестер[7].

*Мәрьям Паташеваның «Истанбул хатирәләре» исемле юльязмасы «Вакыт» газетасының 1913 елгы 1201 нче, 1211 нче, 1223 нче, 1245 нче саннарында дөнья күргән. Текст шуннан алып тәкъдим ителә*

[1] Тәхәммел итәргә — түзәргә, чыдарга.

[2] Мәзлумнәрне – рәнҗетелгәннәрне.

[3] Салибны ай коллыгыннан ... коткару өчен ... – салиб – хаҗ, тәре (христианнарның дини символы), исламның символы – ярымай. Биредә ислам дәүләте булган Госманлы империясе составында яшәгән христианнарны азат итәр өчен, Төркияне җиңәргә кирәк, дигән мәгънә салынган.

[4] Әфкяре гаммә – күпчелекнең уе, җәмәгать фикере.

[5] Борадәр –

[6] Хәкарәт иттеләр – хурладылар.

[7] Зәһәр дәрестер – ачы сабак.

**Сакмарый**

## ШАМ ХАТИРӘЛӘРЕ

### I

Иран сәяхләреннән берсе үз вакытындагы мәшһүр ислам шәһәрләрен зиярәт итеп, һәр шәһәрне өч сыйфат берлән тәүсыйф итә[1] барган имеш, бу сәяхнең һәр шәһәргә өч сыйфат сайлавы тәсаддефи[2] я кәйфи генәме[3], яки шәһәрләрнең манзарасы, әһалисе[4], хәяте шикелле нәрсәләргә бина ителгәнме[5], миңа мәгълүм түгел. Ләкин Шамга[6] барырга чыккан вакытта ул шәһәр хакында минем башымда да ишеткән вә күргәннәремә бина кыйлынган өч сыйфат бар иде. Шамны бер типичный шәрәф шәһәре дип тануым өстенә аның башкалардан имтиязы[7] шул өч сыйфатта дип белә идем. Аның характеристикасы дип таныганым ул өч сыйфат: аның матурлыгы, халкының мәгыйшәте әсхаб мәгыйшәтә[8] якын булуы, мөкаддәс[9] урыннар вә мәшһүр төрбәләрнең анда күп булуы иде.

Шамның гүзәллеге хакында язылган вә сөйләнгән сүзләр бик күптер, Әсмәгый[10]: «Дөньяның җәннәте өч. Берсе – Шам», –

[1] Тәүсыйф итә – сыйфатлый, сыйфатларын бәян итә.

[2] Тәсаддефи – очраклы.

[3] Кәйфи генәме – кәефенә карап кынамы (шулай теләгәнгәме).

[4] Әһалисе – халкы.

[5] Бина ителгәнме – нигезләнгәнме.

[6] Шам – Сүриядәге Димәшкъ (Дамаск) шәһәре. Бик борынгы шәһәр. 661–750 елларда Өмәвиләр хәлифәлеге башкаласы. 1516 елдан 1920 елга кадәр Госманлы империясе составына керә. 1943 елдан – Сүрия дәүләтенең башкаласы.

[7] Имтиязы – өстен булуы.

[8] Әсхаб мәгыйшәтә – сәхәбәләр тормышын.

[9] Мөкаддәс – изге.

[10] Әсмәгый – Галделмәлик бине Кораеб әл-Бәлхи (740 – 828), гарәп галиме һәм шагыйре.

дигән имеш. Әбүбәкер Мөхәммәд бине Гыйас әл-Харәзми[1] дә: «Шам – дөньяның дүрт җәннәтеннән берседер», – димеш. Әбүл-Фида[2]: «Җирнең дүрт могҗизасы бар», – димеш. Ибн Баттута[3]: «Шам күркәмлектә бөтен мәмләкәтләрдән өстен», – димеш. Бәгъзеләр Аурупаның мәшһүр курортларын, Италия вә Испаниянең гүзәл манзараларын күргән булсалар, бу затлар Шам хакында ул сүзләрне сөйләгән булырлар идеме, юкмы, мәгълүм түгел. Ләкин Аурупа вә Американың мәшһүр могҗизаларыннан хәбәре булган, Американың мәшһүр язучысы Марк Твенның[4] да Шам хакында язганнары Ибн Баттутаныкыннан вә Әбүл-Фидаларныкыннан артык булмаса да, ким түгел. Бу язучының бер китабында Шам хакында ошбу сүзләр бар: «...кояш баер алдыннан мин дөньяның бөтен тарафында мәшһүр бер урынга якынлаштым... Таулык вә ташлык берлән ихата ителгән бер яшеллек эчендә утырган бу шәһәр зөбәрҗәт диңгезе уртасында утырган бер энҗе җәзирә[5] шикелледер... Шамны беренче дәфга[6] күргән кеше үзен шатланудан тыя алмый... Мөхәммәд пәйгамбәр дә бу шәһәргә якынлашкач: «Инсан бер генә мәртәбә җәннәткә керә ала», – дип, тау яныннан аның тышкы манзарасын гына тамаша итеп торган вә күк җәннәтен җир җәннәтенә тәрҗих итмеш[7]... Шамның җәннәте, рәхәтләндереп җибәргән ләтыйф[8] җиле сине, бу шәһәр галәме әҗсадтан[9] бигрәк, галәме әрвахка[10]

---

[1] Әбүбәкер Мөхәммәд бине Гыйас әл-Харәзми – Әбүбәкер Мөхәммәд әл-Харәзми (935–1002), Харәземдә белем алган филолог, бик күп афоризмнар авторы.

[2] Әбүл-Фида Гыймадеддин Әбүл-Фида Исмәгыйль бине Гали (1273–1331), гарәп тарихчысы һәм географ.

[3] Ибн Баттута – Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Габдулла әт-Танҗи (1304–1378), атаклы гарәп сәяхәтчесе.

[4] Марк Твен – Америкалы фантаст язучы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Газета журналисты буларак, Европа һәм Якын Көнчыгышның күп илләрендә сәяхәттә була.

[5] Җәзирә – утрау.

[6] Дәфга – мәртәбә.

[7] Тәрҗих итмеш – өстен күргән.

[8] Ләтыйф – күркәм.

[9] Галәме әҗсадтан – җисми дөньядан.

[10] Галәме әрвахка – рухи дөньяга.

якын дип уйларга сәвекъ итә[1]... Шамга күз салганда, бу җир инсан күзе төшкән җирләрнең иң матуры дип хәтергә килә...»

Шам мәдехе[2] хакында шулкадәр күп язылу, бу шәһәрнең күркәмлеген вә анда һәркемнең күңелен җәлеп итәрдәй хосусиятләр барлыгын күрсәтәдер. Шамның манзарасы[3] хакыйкатьтә дә гүзәл. Ләкин бу шәһәрне ул кадәр матур күрсәткән вә аның хакында шулкадәр мәдхияләр яздырган нәрсә, аның манзарасыннан бигрәк, вәзгыяте вә аның күренешендә булган сиррияте[4] булса кирәк. Шам утырган вади[5] читтән караганда бер зур бакча тәшкил итә. Өйләр, дөкяннәр[6] җамигълар[7], тәкияләр[8], башка биналар агачлар белән аралашып күренеп торалар.

Вадиның бер тарафы ташлы тау вә икенче тарафы комлык, сахра булганлыктан шәһәр утырган урын берлән аның әтрафы арасында зур бер задият (контраст) бар. Шамны ул кадәр гүзәл күрсәткән нәрсә – шул задияттер. Ике җәһәннәм нәмунәсе[9] арасында кысылып утырган бу җәннәт мисалын күргәч, «кеше шатланудан үзен тыя алмый»дыр.

Шул яшеллекләр эченнән һавага күтәрелеп чыккан озын-озын манаралар, мәһабәт коббәләр[10] дә күңелгә әллә нинди бер сиррият биреп, күрүченең бу шәһәргә мәхәббәтен тагын да арттыралар. Гүзәллек берлән сирриятнең бергә җыйналуы исә – инсанның күңеленә иң нык тәэсир итә торган нәрсәләрнең берседер. Шамның манзарасындагы сирриятнең мәнбәгы[11] да аның искелеге булса кирәк. Шул искелеге саясендә[12] аның бик күп

[1] Сәвекъ итә – юнәлтә, этәрә.

[2] Шам мәдехе – Димәшкъне мактау, шәплеген сөйләү.

[3] Манзарасы – тышкы күренеше.

[4] Сиррияте – серлелеге.

[5] Вади – таулар арасында уйсу җир, тарлавык.

[6] Дөкяннәр – кибетләр.

[7] Җамигълар – мәчетләр.

[8] Тәкияләр – мөридләрнең ишан кул астына зекер әйтү өчен җыела торган урыннары (бина).

[9] Нәмунәсе – үрнәге.

[10] Коббәләр – гөмбәзләр, түбәсе түгәрәкләп ябылган биналар.

[11] Мәнбәгы – чыганагы.

[12] Саясендә – күләгәсендә.

милләтләр каршында бер мәүкыйгы[1] бар. Ул безнең арабызда да җырларыбызга килеп керү дәрәҗәсендә бер урын казанган. «Шам-шәриф дигән шәһәрдә ясихсыз[2] капка ябылмас...» дип башланган бер җырны кечкенә вакытта ук ишетә башлыйбыз. Бу шәһәрне башлап күргәндә тарихтан аз-маз хәбәрдар булган кешеләрнең башына ошбу фикерләрнең килүе табигыйдыр: «Менә бу шәһәр никадәр дәүләтләрнең зоһур вә инкыйразын[3] күрде. Мисыр, Бабил, Ассурия, Иран хөкүмәтләренең газыймәт вә шәүкәтләрен[4] тамаша итеп торды. Рамзес[5], Искәндәр[6], Ганнибал, Бәхет Наср, Юлиус Кайсар, Сөйләйман галәйһиссәлам, Чыңгызхан, Наполеон, Халид бине Вәлид,[7] Саләхеддиннәрнең[8] эшләгәннәрен хатирә дәфтәренә кайд итә[9] барды. Яһүдилек, христианлык вә мөселманлыкның зоһур иткән[10] урыннарына якын булганлыктан, ул диннәрнең тарихында бик мөһим роль уйнады. Моның өстенә караганда, син гади бер шәһәр түгел, биш-алты мең сәнәлек хатиратын күрәсең...»

Шундый фикерләр берлән берләшкән аз гына матурлыкның да бик матур булып күренәчәге вә аның күңелендә бик тирән эз калдырачагы шөбһәсездер. Марк Твенның «Шамга күз салганда, бу җир – инсан күзе төшкән җирләрнең иң матуры, дип хәтергә килә» диюе дә ошбу мәгънәдә генә тугры булыр. Юкса Бәрда елгасы (нәһре Барад), үзен генә алганда, безнең Сакмар, Агыйдел вә Дим буйларыннан матуррак түгел.

[1] Мәүкыйгы – урыны.

[2] Ясих – ястү намазы, караңгы төшкәч укыла торган соңгы бишенче намаз.

[3] Зоһур вә инкыйразын – барлыкка килүен һәм юкка чыгуын.

[4] Газыймәт вә шәүкәтләрен – бөек дәрәҗәләрен һәм көч-куәтләрен.

[5] Рамзес – борынгы Мисыр фиргавене.(Алар өчәү – Рамзес I, Рамзес II, Рамзес III – барысы да фараоннарның 19 нчы династиясе вәкилләре).

[6] Искәндәр – Александр Македонский (б. э. к. 356–323).

[7] Халид бине Вәлид – Халид бине Вәлид әл-Мәхзүми (592–642), Мөхәммәд пәйгамбәрнең көрәштәшләреннән берсе, яу каһарманы.

[8] Сәлахеддин... – Саләхеддин Йосыф бине әл-Әюби (1138–1193), Мисыр һәм Сүрия солтаны, күренекле хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, мөселман полководецы.

[9] Кайд итә – терки, язып куя.

[10] Зоһур иткән – барлыкка килгән.

Шам әһалисенең хәяте[1] әсхаб мәгыйшәтенә[2] якын булуы үземезнең мәшһүр бер шәехемез тарафыннан сөйләнгән сүз булып, без аннан ишеттек. Шамда зиярәт мәхәлләренең[3] күп булуын исә безгә мөхтәрәм бер хәзрәтебез сөйләгән иде. Бу хәзрәтнең хаҗ шәрифтән кайтышлый Бәйрутта берничә көн калуыннан истифадә итеп[4], берничә дәфга[5] сохбәте берлән мөшәррәф булган[6] идек. Бер сохбәте әснасында[7]: «Хәзрәт, Шамда бөек адәмнәр берлән танышып, мосахәбәт иткәнсездер[8]» – диюебезгә каршы хәзрәт: «Әвәт[9], Шамда бөек адәмнәр чук имеш, ләкин берсе дә хәяттә түгел»[10] – җавабын биргән иде. Бу ике фикернең вакыйгка[11] ни дәрәҗәдә мотабикъ булганын[12] бер мөнәсәбәте берлән зикер итмәк[13] кирәк.

## II

Бәйрут берлән Шам арасына бер француз ширкәте чуен юлы салган. Шул ук ширкәт Бәйрут берлән Хаб вә Халеб берлән Траблис-Шам[14] арасын да тоташтырган. Шам берлән Бәйрут арасындагы юлның озынлыгы йөз кырык километр чамасы гына булса да, поезд ул араны тугыз-ун сәгатьтә генә катыйг итә[15] ала. Чөнки бу ике шәһәр бер-берсеннән җәбәл Либнан силсиләсе[16] берлән ае-

[1] Әһалисенең хәяте – халкының көнкүреше.
[2] Әсхаб мәгыйшәтенә – сәхабәләр тормышына.
[3] Зиярәт мәхәлләренең – зиярәт кылу (күреп, карап йөрү) урыннарының.
[4] Истифадә итеп – файдаланып.
[5] Дәфга – мәртәбә.
[6] Сохбәте берлән мөшәррәф булган – сөйләшеп утыру бәхетенә ирешкән идек.
[7] Сохбәте әснасында – сөйләшеп утырган вакытта.
[8] Мосахәбәт иткәнсездер – кара-каршы сөйләшеп утыргансыздыр.
[9] Әвәт – дөрес, әйе.
[10] Хәяттә түгел – исән түгел.
[11] Вакыйгка – чынлыкка.
[12] Мотабикъ булганын – туры килүен.
[13] Зикер итмәк – әйтеп үтәргә.
[14] Траблис-Шам – Триполи, Төркиянең Кара диңгез ярында урнашкан шәһәре.
[15] Катыйг итә – кичә, (юл) үтә.
[16] Җәбәл Либнан силсиләсе – Либнан таулары чылбыры.

рылганлыктан, чуен юлы шул тауларны үтәргә тиеш. Поезд тырнаклы юл берлән, акрын-акрын урап тауга менеп йиткәнче бик күп вакыт үтә. Әмма шул мөддәттә[1] мәсафәт[2] игътибары берлән өчтән берсе дә кителми. Тауга менгәндә, поезд бәгъзе урыннарда җәяү атлаган кешедән дә акрын китә.

Без Бәйруттан иртә берлән сәгать җиде ярымда кузгалып киткән идек. Шамга икенде[3] вакытында, сәгать бишләр чамасында барып йиттек. Бәйруттан Шамга һәр көнне ике юлчы поезды бара. Берсе иртә берлән сәгать йиде ярымда вә икенчесе төн уртасында сәгать уникедә китә. Шамга баручы мотлакан иртәнге поездга утырырга тиешле. Чөнки ул тәкъдирдә бөтен юлны күреп тамаша итеп бара. Төнге поезд белән киткән кеше исә моннан мәхрүм була. Төнлә китүнең икенче уңайсыз җәһәте – вагоннарда йоклау мөмкин түгел. Монда безнең Русия вагоннары юк. Бер эскәмиягә биш кеше кысылып кына утырып китәсең. Бер эшсез-нисез, йокламый төнне үткәрү дә бик кыен. Бәйрут тарикы[4] берлән хаҗга килүчеләр өчен бәлки файдасы булыр дип, моны язып китүне монасиб[5] таптым.

Шамга ике-өч сәгатьлек юл калгач, Зибдани дигән станциядән башлап, чуен юлы елга буйлап бакчалыклар эченнән китә. Баштарак бу бакчалыклар өзлекле-өзлекле булса да, бер сәгатьлек калгач, өзлексез, бер тоташтан сузылып китәләр. Шул хәлдә Шам эченә барып керәләр. Шамга җитәр алдыннан елга буена корылган зур-зур су тегермәннәре күренеп калалар. Бер сәгатьлек арада электрик станциясе бар. Трамвайга вә шәһәрне яктыртуга электрик шуннан килә.

Вокзалга җитәр алдыннан гына Шамның манзарасы күренә башлады. Бәрда нәһере[6] буендагы бакча вә агачларның гүзәллегеннән мәфтүн булган[7] күңелем Шамның гүзәл күренешләреннән

---

[1] Мөддәттә – вакыт эчендә.
[2] Мәсафәт – ике урын арасындагы ераклык.
[3] Икенде – кояш батканчы укыла торган өченче намаз.
[4] Тарикы – юлы.
[5] Монасиб – тиешле.
[6] Нәһере – елгасы.
[7] Мәфтүн булган – сокланган, хәйран калган.

тагын да артыграк мөтәәссир булды[1]. Күккә чыгып торган манара вә коббәләрне[2] бер кодсиять[3] әллә нинди бер сиррият[4] каплап торган шикелле тоелды. Җырларыбызга керер дәрәҗәсендә хәятебездә ингыйкяс иткән[5] бу шәһәргә күңелемдә бер мәхәббәт хасыйл булды.

Сәгать бишкә чирек калганда, Шамның җәнүбендә[6] булган Бәрмәки вокзалына барып туктадык. Мондагы Бәрмәки исеменең Һарун әр-Рәшид[7] вәзирләре Җәгъфәр вә Фазыл Бәрмәкиләргә бер мөнәсәбәте бармы-юкмы, миңа мәгълүм түгел. Ләкин мин вокзалның ишеге өстенә куелган кечкенә вә пычрак кына бер тактада «Шам, Бәрмәки» дигән сүзләрне укыгач, Рәшид дәверләрен искә төшердем. Ислам дәүләтенең ул вакытлардагы шәүкәт вә гыйззәтләре күз алдымнан үттеләр. Үземне ислам дәүләтенең иң парлак[8] бер дәверендә, халифәте исламия мәркәзенең иң шанлы бер вакытында ислам даһилары тарафыннан тәэсис ителгән бер дәүләтнең бөтен хокуклары берлән файдаланучы бер гражданы да шикелле хис иттем. Шамның һавасы вә мохите Багдад вә Куртубаларның Рәшидләре[9] вә Габдрахманнары[10] дәверендәге шикелле сизелде. Шамда күргәннәремне сөйләүдән элек, бу шәһәрнең тарихындагы мөһим дәверләрен зикер итеп[11], аның бүгенге хәленә гаять кыска гына бер статистик мәгълүмат биреп үтүне мөһим табамын.

---

[1] Мөтәәссир булды – тәэсирләнде.

[2] Коббәләрне – гөмбәзләрне, түбәсе түгәрәкләп ябылган биналарны.

[3] Кодсиять – изгелек.

[4] Сиррият – серлелек.

[5] Ингыйкяс иткән – чагылган.

[6] Җәнүбендә – көньягында.

[7] Һарун әр-Рәшид – Әбү Җәгъфәр Һарун бине Мөхәммәд (Һарун әр-Рәшид буларак мәгълүм, 763–809), 786–809 елларда гарәпләрнең габбасилар династиясе хәлифәсе.

[8] Парлак – шанлы, шөһрәтле, данлыклы.

[9] Багдад... Рәшидләре – Һарун әр-Рәшид дәверендә (786–809) хәлифәлекнең башкаласы Багдад шәһәрендә була.

[10] Куртубаның... Габдрахманнары – Кордовада (Әндәлүстә) Өмәвиләр династиясенең беренче әмире (756–788 елларда) – Габдрахман әд-Дахил (731–788).

[11] Зикер итеп – искә алып.

## III

Шам – Сүриянең беренче шәһәре вә Сүрия вилаятенең мәркәзедер. Бу шәһәрнең кайчан вә кем тарафыннан бина ителгәнлеге[1] ачык мәгълүм түгел. Ләкин бу көндә күпләр назыйрында[2] дөньяның иң иске шәһәре дип игътибар ителә. Бу фикер тарихи дәлилләр белән исбат ителмәгән булса да, хакыйкатькә якын булуы мөмкин. Марк Твен да «тарих Руманы[3] кадим[4]» дип атый, ләкин бу исем Шамга бирелергә тиеш», ди. Шам исеме бик иске язуларда вә Тәуратта китаб әл-Харуҗның XIV фасылында зикер ителгән. Җир өстендә инсанның зоһурыннан соң[5] беренче мөһим вакыйга саналган Кабил вә Һабил кыйссасының бу шәһәр берлән берләштерелүе дә Шамның искелегенә дәлаләт итә. Бүген дә Шамның шималь шәркыйсында «Җәбел Касиюн» исемендә бер тау бар. Шул тауның башындагы киртләчләнеп яткан кызыл ташны Һабилнең агып төшеп килгән каны дип күрсәтәләр.

Фәләстыйн Мисыр фиргавеннәре кул астында вакыт Шам кечкенә бер провинциянең мәркәзе[6] иде. Ләкин арамийлар истилясыннан соң[7], мөстәкыйль бер хакимлек мәркәзенә әйләнде вә исеме дә «Димәшкъ»тән «Дармәшкъ»ка алмаштырылды. Моннан соң Шам хөкүмәте зур куәт вә кодрәт сахибы булды. Бөтен шамлы Сүрияне истиля итеп[8] шөһрәте берлән Мисыр фиргавеннәрен үзенә һәдияләр күндерергә сәвекъ иткән[9] «Дармәшкъ» хөкүмәте өстенә йөрде. Чөнки бу шәһәр, Дауд галәйһиссәламнең дошманы Субә хакиме һәдид[10] Газәргә ярдәм иткән иде. Дауд галәйһиссәлам арамийләрдән егерме ике мең кадәресен үтертте вә калганнарын салым түләргә иҗбар итте[11]. Ләкин бу күп дәвам

---

[1] Бина ителгәнлеге – төзелгәнлеге, нигезе салынуы.
[2] Назыйрында – карашынча.
[3] Руманы – Рим шәһәрен.
[4] Кадим – борынгы.
[5] Инсанның зоһурыннан соң – кешелек җәмгыяте барлыкка килгәч.
[6] Мәркәзе – үзәге (башкаласы).
[7] Истилясыннан соң – басып алгач.
[8] Истиля итеп – басып алып.
[9] Сәвекъ иткән – этәргән.
[10] Һәдид – хакимнең титулы.
[11] Иҗбар итте – мәҗбүр итте.

итмәде. Һәдид Газәрнең кул астында булган адәмнәрдән Ризван исемле берсе Шамда бер солтанат тәшкил итүгә муафыйк булды[1].

Миладидан өч йөз утыз өч сәнә мөкаддәм исә мохарәбәдән[2] соң, Шам шәһәре хаиннәр тарафыннан Искәндәр кәбирнең генералы Парминиюга тапшырылды. Милади икенче гасырның урталарында бөек Рума дәүләтенең бер правинциясе булып калды.

Алты йөз утыз бишенче сәнә миладидә мөселман гарәпләр тарафыннан фәтех ителде[3]. Вә хәзрәти Галинең шәһадәтеннән соң[4] хәлифәт мәркәзе шунда күчерелеп, халифәлек габбасилар кулына күчкәнче, пайтәхет[5] булып калды. Бер вакытлар мисырлылар, кармәтиләр, сәлҗукыйлар кулына кереп чыкты. Салиб мохарәбәләре[6] вакытында Сәлахеддин Әюбинең баш квартиры шунда булды. 1260 сәнәсендә монголлар вә аннан бераз соңда мәмлүкләр кулына күчте. 1399 сәнәсендә солтан Сәлимнең дәвере солтанатында төрекләр кулына күчте. Вә шул көннән игътибар Төркиянең мөһим бер шәһәре булып яши башлады. 1834 сәнәсендә Мөхәммәдгали пашаның угылы Ибраһим паша тарафыннан алынды исә дә, яңадан госманлы хөкүмәтенә игадә ителде[7] вә бу көнгә кадәр госманлы хөкүмәте кулында торып килә.

Моннан соң күпме калачак, моны бер Алла гына белә. Гарәпләрнең мөстәкыйль бер гарәп хөкүмәте тәшкил итеп, хәлифәтне дә үз кулларына кайтарып алу хыяллары эш булып чыкса, бу шәһәрнең яңадан пайтәхет вә хәлифәт мәркәзе булачагы бәгъзеләрнең авызында сөйләнелә.

Бу көндә Шам өч кыйсемнән гыйбарәт булып, иң мөһим кыйсьме, ягъни төп шәһәр, мәркәздәдер. Шәһәрдә табыла тор-

[1] Муафыйк булды – иреште.

[2] Мохарәбәдән – сугыштан.

[3] Фәтех ителде – җиңелде, басып алынды.

[4] Хәзрәти Галинең шәһадәтеннән соң – хәзрәти Гали үтерелгәннән соң (661 нче елдан соң).

[5] Пайтәхет – башкала.

[6] Салиб мохарәбәләре – тәре яулары.

[7] Игадә ителде – кайтарылып бирелде.

ган мөәссасатлар[1] башлыча ошбу кыйсемдә. Монда урамнар да бераз мөнтазам[2], биналар да Аурупа ысулында.

Шималь[3] тарафында, тау буенда, «Салиха», вә җәнүбтә[4] «Сәвика» мәхәлләләре бар. Бу ике мәхәлләнең мәркәзгә нисбәте Иске бистәнең Казанга нисбәте шикелледер. Боларда өйләр балчыктан эшләнгән. «Салиха»да консуллар тора торган урамда гына Аурупа ысулында өйләр бар. Башка урамдагылары читтән караганда зимләнкә[5] шикелле булып күренеп торалар.

Шамның иң иске кыйсьме – «Шәвика» мәхәлләседер. Хиҗаз тимер юлының баш вокзалы ошбу мәхәлләнең җәнүбендә.

«Салиха» мәхәлләсе күптән түгел салынган булырга охшый. Чөнки анда да өйләр балчыктан булса да, урамнар бераз мөнтазам. «Сәвика»да исә интизам[6] фәлән дигән нәрсә юк, бәгъзе урыннарында урамнар ике кеше каршы үтәрлек кенә. Мин аларның арасында йөргәндә «Әлфе ләйлә вә ләйлә»дә тасвир ителгән тар урамнар хәтеремә килде.

Төп шәһәр «Бәрда» елгасының ике тарафына салынган. Елга шәһәргә кергәч, бераз урам буйлап агып килә дә, соңра бишкәме, йидегәме бүленеп, махсус ясалган каналлардан йир астына кереп китә. Бу су йир астыннан бакчаларга тарала булса кирәк. Чөнки эчелә торган су башка бер бик суык вә саф чишмәдән килә.

«Бәрда»ның шәһәргә агып кергән йире гаять гүзәл манзара тәшкил итә. Яр читендә гүзәл каһвәханәләр, бер читендәрәк гүзәл Милләт бакчасы бар. Мәшһүр отельләр, хөкүмәт кунагы, бәләдия даирәсе[7], гадлия мәхкәмәләре[8] урамның елга агып яткан кыйсьмендә, яр читендә. Үткән ел гына бик матур вә бик тәмиз[9] иттереп дарелмөгаллимин[10] бинасы да салып куйганнар.

[1] Мөәссасатлар – биналар.
[2] Мөнтазам – тәртипкә салынган.
[3] Шималь – төньяк.
[4] Җәнүбтә – көньякта.
[5] Зимләнкә – землянка.
[6] Интизам – тәртип.
[7] Бәләдия даирәсе – шәһәр идарәсенә караган.
[8] Гадлия мәхкәмәләре – юстиция, хөкем йортлары.
[9] Тәмиз – пөхтә.
[10] Дарелмөгаллимин – ирләрдән укытучылар әзерли торган уку йорты.

Хөкүмәт кунагы хили[1] зур. Гаять гүзәл ысулда бина ителгән. Вә урыны да бик күңелледер. Ләкин эшләнеп тәмам булган көннән бирле ремонт фәлән кеби нәрсә күрмәгәнлектән, бу көндә хәрабәгә якын бер хәлгә килгән. Ышкатуры[2] урыны-урыны белән кубып төшкән, төтеннәнме, нәрсәдәндер стеналары юлюл булып саргайган. Тәрәзәләренең ватылганы ватык көе тора. Тузаннарына бәлки төзелгәннән бирле кул тимәгәндер. Ишекләренең кул берлән этеп ачылган йирләре кап-кара булып тора. Шулкадәр гүзәл бина эшләнгәннең соңында аны һич булмаса өч елда бер известь суы белән буяп торырга кирәк иде. Бу мосрафлар[3] бер нәрсә түгел. Төрекләрдә бер гадәт бар: бер бинаны ясаганда гүзәл итеп ясыйлар, ләкин соңыннан ремонт вә яңарту нидер – белмиләр. Иштә Бәйрут почтаханәсе: эшләнеп тәмам булган вакытта ул һәркемнең дикъкатен җәлеп итеп торган, һәркем тәхсин иткән[4]. Хәзер исә, ясалып тәмам булганнан бирле тәмизнең[5] исен дә иснәмәгәнлектән, кеше җирәнерлек бер хәлдә. Ишекләренең тоткалары сынык, тәрәзә пыялалары кайсысы ватылган, вә ватылмаганнары тузаннан пыялалыгы беленмәс бер хәлгә килгән. Урам ягындагы диварга ясалып куелган зур сәгать тә, кайсы вакытта гына барсаң да, биш ярымда тора. Мәктүп язар өчен уртага куелган өстәлнең пычраклыгы да әйтеп бетергесез. Марка сатыла, акча вә посылка кабул ителә торган тишекләрнең алдындагы шүрлекләргә түгәрәкләнеп кер катып калган.

Шул ук Бәйрутнең хөкүмәт кунагы: монда да пыялалар тузан берлән капланганлыктан, тыштан караганда – эчтәге нәрсә, эчтән караганда, тыштагы нәрсә ачык күренми. Зур ишекләрнең урталары кап-кара булып кергә катып тора. Стеналарга языпсызып пычратып бетергәннәр. Игътибарсызлык берлән барып бер урынга сөяләә йә таяна калсаң, өст-башың тузанга буяла.

Әлхасыйл, кайсы бер йиренә генә күз салсаң да, пычраклык күрәсең. Шул пычраклыкларны бетерү күп акча да таләп итми

[1] Хили – байтак.
[2] Ышкатуры – штукатуркасы.
[3] Мосрафлар – чыгымнар.
[4] Тәхсин иткән – мактаган.
[5] Тәмизнең – чисталыкның.

инде. Мәсәлән, почта ишегенә тотка алып кую алты тиен тора. Тәрәзә пыялаларындагы тузанны ике көнлекче хатын бер көндә сөртеп чыга ала. Диварларны известь берлән буяп чыгу да күпкә төшми. Күптән түгел минем фатир хуҗасы өенең биш бүлмәсен утыз грушка (ике сум 10 тиен чамасы) буятты. Әгәр дә валиләр вә почта мөдирләре бераз нәзафәт[1] хисенә малик булсалар, хөкүмәтнең ремонтка тәгъйин итәрлек[2] акчасы булмаганда да, һәр вилаять өчен күрелгән расходларга тәгъйин ителгән берничә мең груштан төзәттерә алыр иде. Вә бәгъзы валиләр[3] ул акчаны мәмләкәтнең ихтыяҗын бәян итеп нотык сөйләүчеләргә бирәләр. Мәсәлән, Шамның бүгенге валисе Гариф бәк тәгъйин ителеп килгәч, солтанның фәрманын укыганда, Шам сәүдәгәрләреннән берсе уртага чыгып, бер нотык сөйләгән вә Шамның ихтыяҗларын вә ислахка[4] мохтаҗ урыннарын зекер иткән икән.

Гариф бәк соңынан шул кешене хозурына чакыртып, бер ничә лира мөкяфәт[5] биргән вә айлык берничә мәҗидия мәгаш[6]та тәгъйин иткән. Бу бер урам хәбәре генә булса да, соңгы гасырдагы госманлы идарәсеннән хәбәрдар булган кеше аны тасдыйк итүдә[7] тәрәддед итә алмыйдыр[8]. Бөтен дөнья алга китеп ятканда Төркиядә дә ислахның лөзүмен[9] аңлаган вә аны сорап тавыш чыгарган кешеләр булмады түгел – була килде. Аларның авызлары алтын берлән каплана торды. Соңга таба эш шул дәрәҗәгә килде ки, «менә моны ислах итәргә кирәк» дию «миңа мал, дәрәҗә кирәк» дию берлән бер мәгънәдә йөри башлады. Биреп туктату түгел, соралган ислахатнең беразын булса да бирергә тиешле дип таптылар. Әгәр дә түрәләр берничәсенең авызын капларга түккән алтыннарын мәмләкәтләренең хәлен ислах итүгә

[1] Нәзафәт – арулык, пакьлек.
[2] Тәгъйин итәрлек – билгеләрлек, бүлеп бирерлек.
[3] Валиләр – губернаторлар.
[4] Ислахка – яхшыртуга, яңартуга.
[5] Мөкяфәт – бүләк.
[6] Мәгаш – хезмәт өчен түләү.
[7] Тасдыйк итүдә – раслауда, дөреслеген тануда.
[8] Тәрәддед итә алмыйдыр – бер карарга килә алмыйлар.
[9] Лөзүмен – кирәклеген.

вә халыкның тормышын яхшыртуга сарыф иткән булсалар иде, «госманлылык», «Төркия дәүләте» исемнәренең бу көндә Төркиядә яшәгән милләтләр каршында бераз кыйммәте вә әһәмияте булыр иде.

Ләкин ни чара, әһалисенең күбесенә мәгаш тәгъйин итеп, Мәккә берлән Мәдинәне гаталәт[1] дөньясына чөергән бер идарә Шамын да, Бәйрутен дә, Хәлебен дә кире калдырмаган. Дәүре истибдадның[2] чире булган бу гадәтнең дәүре мәшрутияттә[3] дә дәвам итеп килүе гакыл ирешерлек бер нәрсә түгелдер. Моның мисаллары соңгы вакытларда да булып тора ди. Ислах хәрәкәтенең башында йөрүчеләрдән Шөкри әл-Гаслы исемендә берсен Бәйрут валисе бер йиргә каим мәкам[4] итте. Ләкин Шөкри Гаслы рәд итте[5]. «Сораган нәрсәләребез үтәлми торып, мәэмүрият[6] кабул итмим», диде. Гаслыны бу хәрәкәте өчен бөтен гарәп дөньясы алкышлады. Вә шулай итеп, Бәйрут валисе гарәпләргә бер национальный герой ясап бирде. Мисырдагы Рәфыйк бәк әл-Газыймны да Истанбулдан садре әгъзам[7] дәгъвәт иткән[8] дип газеталар яздылар. Аңарга зур бер мәэмүрият биреләчәк икән, диделәр. Ләкин Рәфыйк бәк тә Истанбулга бармады.

Бу көннәрдә исә яңа гына Парижда булып үткән гарәп ислахчыларның җыелышында рәислек иткән Габделхәмид Заһравиның шәйхелисламлык мәнсабына[9] күчереләчәген яздылар. Америкада нәшер ителә торган могтәбәр бер газета (гарәпчә) бу мөнәсәбәт берлән Заһравины вә шул гарәп дөньясын тәбрик итеп тә үтте.

Шам валисе[10], шул ислахчы сәүдәгәргә биргән лира вә мәҗидияләре янына, үзенең киләчәк буынга ялкаулык дәресе биреп

---

[1] Гаталәт – эшлексезлек, артталык.
[2] Дәүре истибдадның – деспотизм заманының.
[3] Дәүре мәшрутияттә – конституция кабул ителгәннән соңгы заманда.
[4] Каим мәкам – урынбасар.
[5] Рәд итте – кире какты, кабул итмәде.
[6] Мәэмүрият – вазифа.
[7] Садре әгъзам – элекке Төркия хөкүмәтендә баш вәзир.
[8] Дәгъвәт иткән – чакырган.
[9] Мәнсабына – дәүләт хезмәтенә, хезмәт урынына.
[10] Валисе – губернаторы.

ислам дөньясының тамырына балта чабып ятучы мәүләви дәрвишләренә аш йибәрергә (бу хакта киләчәктә язылыр) сарыф иткән акчаларын да кушып, кул астындагы хөкүмәт йортын төзәттерсә иде – Төркиягә хезмәт иткән булыр иде.

Бәрда елгасының бүленеп, аска таралып киткән йиреннән бер бик киң мәйдан башлана. Мәшһүррәк отельләр, театр вә кинемотографлар вә шундый нәрсәләр шул мәйданның әтрафында яки шуңар якын. Мәйданның уртасында Габделхәмид[1] тарафыннан ясалган модалы бер җамигъ тора. «Шура»ның алтынчы җилденең 4 нче номерында зикер ителгән[2] «һәр җәһәттән мөкәммәл булачак, Аурупа стилендәге» отель дә шушы мәйданда. Бу отельнең хәзердә стенасы вә түбәләре (ягъни тышкы эше) тәмам булган. Тыштан караганда, бу бина Оренбургның «Американский» гостиницасыннан күп артта. Әмма эче вә җиһазы аннан алда булыр. Шәрыкта бер гадәт бар: биналарның тышкы күренеше начар гына булса да, эче гаять зиннәтле була. Фәкыйрь генә күренгән йортларга керсәң, андагы зиннәт вә матурлыкка шаккатып каласың. Быел тарих дәресендә профессорның «Салиф[3] сәфәрләренең берничәсе Аурупага Шәрык бидгатенең[4] вә Шәрык гыйш-гыйшрәтенең керүе булды», дигән сүзләрен ишетеп, ул кадәр әһәмиятсез бер нәрсәне мәшһүр бер вакыйганың нәтиҗәсе итеп зикер итүенә бераз гаҗәпләнгән идем. Ләкин Шамга барып, андагы хәят белән бераз танышкач, профессорның ул сүзләрен тәкъдир итә алдым. Шәрык сафасының, Шәрык зиннәтенең ни дигән сүз икәнен аңлап, гыйш вә гыйшрәт өчен дә ялгыз акчаның гына йитмәгәнлеген төшендем. Мәшһүр гостиницаның сахибе – мәшһүр Гыйззәт пашадыр. Аннан башка бүгендә Шамның иң мәшһүр вә иң мөкәммәл гостиницасыннан булган «Виктория» дә шул ук Гыйззәт пашаның атасыннан калган бер бинада урнашкан.

---

[1] Габделхәмид – Габделхәмид II (1842–1918), 1876–1909 елларда Госманлы империясе солтаны.

[2] Зикер ителгән – искәртелгән, искә алынган.

[3] Салиф – үткәндәге, электәге.

[4] Бидгатенең – яңа гадәтенең.

Шамның базар вә чаршылары[1] бик мөкәммәл булып, аларның эчендә дикъкатьне иң нык җәлеп итәрдәйләре – «Мидхәт паша чаршысы» берлән «Хәмидия» чаршысыдыр. Ләкин «Хәмидия» чаршысы үткән елгы янгыннан харап булып бетә язган, тик бер кыйсьме генә калган. «Мидхәт паша чаршысы» бүген дә сәламәт, әллә кайдан күренеп тора.

Урамнар тар вә пычрактыр. Трамвай үткән урамнар гына бераз яхшырак. Алар да соңыннан төзәтелгән булса кирәк.

Шамның җамигълары зурлыклары берлән дә, тышкы зиннәтләре берлән дә дикъкатьне җәлеп итеп тормыйлар. Бик күп капкалы койма берлән ихата ителгән[2] «Сөләймания» җамигы берлән «Өммия» җамигы аерылып торса да, башкалары күзгә дә чалынмый. Эче фәүкылгадә[3] зур булган «Өммия» җамигы да тыштан караганда мөмтаз[4] булып күренеп тормый.

1883 елдан элек ясалган бер хисапка күрә, Шамда унбиш мең ханә, бер йөз илле өч җамигъ, йитмеш бер мәсҗед, бер йөз туксан дүрт вәлиләр мәкаме[5], ундүрт тәкия[6], унйиде кәлисә[7], утыз тугыз мәдрәсә, туксан өч ирләр мәктәбе, утыз дүрт кызлар мәктәбе, алты мең алты йөздән артык кибет, йөз утыз тегермән, илле сигез хәммам[8], бер йөз ундүрт склад, бер йөз йитмеш ике каһвәханә, биш сабын заводы, утыз өч нәкыш эшләнә торган ханә, унсигез буяуханә, өч хастаханә вә бер мәҗнүннәр йорты бар, имеш.

Әһалисе йөз илле мең берлән ике йөз мең арасында хисаплана. Вакыйгда ул микъдардан артык булса кирәк. Халкының күбесе, табигый, гарәп. Дүрт меңгә якын төрек. Алты меңләп көрд вә бераз яһүди, вә бераз аурупалылар бар.

---

[1] Чаршы – өсте ябулы базар.

[2] Ихата ителгән – тирәли корып алынган.

[3] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

[4] Мөмтаз – өстенрәк.

[5] Вәлиләр мәкаме – изгеләр йорты.

[6] Тәкия – мөридләрнең ишан кул астына зикер әйтү өчен җыелып утыра торган урыннары.

[7] Кәлисә – чиркәү.

[8] Хәммам – мунча.

## IV
## Шамның тиҗарәте вә сәнәгате

Соңгы вакытларга кадәр Шам тиҗарәт җәһәтеннән[1] иң алдынгы шәһәрләрдән була килде. Хосусан Тәдмәр шәһәренең карары белән бөтен Һинд, Гаҗәм[2] вә Гыйрак сәүдәсен аңа күчергән иде. Икенче җәһәттән, корыдан китә торган хаҗ кәрванының юлы да аннан үтүе аның тиҗарәтен күтәрә иде. Ләкин XIX гасырның урталарында Бәхре сәфидтә[3] тиҗарәт көймәләренең йөри башлавы, Шамның Истанбул, Рум иле, Анатулы берлән булган мөнәсәбәтен кискән шикелле, Сүәеш каналының ачылуы да аның кулыннан Һинд, Гаҗәм, Гыйрак сәүдәсен алды. Вә шул көннән бу шәһәр бәйнәлмиләл[4] бер сәүдә шәһәре булу ихтималын югалтты. Әмма аның сәүдәсе бу көндә дә бик әһәмиятледер. Ул, әтрафындагы сахралыкка Аурупа малларын тараткан шикелле, үзе дә читкә бакча вә иген мәхсулаты[5] берлән йон вә тире чыгармактадыр. Һәр ел хаҗилар тарафыннан калдырылган акчаның суммасы да аз түгел.

Иске вакытларда Шамның шөһрәте тире иләү, сәдәф[6] батырып нәрсәләр ясау, төрле чәчәк, хайван вә йимешләр сурәте төшереп, бер төрле материя хәзерләү, төрле кылыч вә пычаклар ясау вә әйберләрне бик гүзәл итеп буяу берлән иде. Болардан башка сабынчылары вә балта осталары да бик маһир иделәр. Бу көндә Шамның иң алдынгы сыйфатлары – көзге, кресло, комод шикелле кыйммәтле мебель хәзерләү вә төрле сумкалар тегүдер. Көзге вә комодларны сәдәф батырып та ясыйлар. Күптән түгел берәү пыяла заводы да ачкан. Ясаган савытлары әтрафка таралып тора. Берме, икеме комач[7] фабрикасы да бар. Язлык кием өчен ефәктән гүзәл материал хәзерләп торалар. Тазалыклары белән шөһрәт тапкан бу нәрсәләрне һәркем яратып ала. Әгәр дә

[1] Тиҗарәт җәһәтеннән – сәүдә ягыннан.
[2] Гаҗәм – иранлылар, фарсылар.
[3] Бәхре сәфид – Ак диңгез, Урта диңгез.
[4] Бәйнәлмиләл – интернациональ.
[5] Мәхсулаты – продуктлары.
[6] Сәдәф – энҗе, перламутр.
[7] Комач – текстиль.

халыкның күзе бераз ачылып, аларга соңгы сәнәгать[1] ысуллары бераз күрсәтелсә, Шамның Сүрия, Фәләстыйн вә Гарәбстан өчен мөһим бер сәнәгать вә тиҗарәт мәркәзе булып китүе бик мөмкиндер.

Башка Шәрык шәһәрләре шикелле Шамның да иң дикъкатьне җәлеп итә торган урыны базарлар булса кирәк. Бу базар вә чаршылар иртәдән кичкә кадәрле кайнап торалар. Аларны бер әйләнеп чыккан кеше Шам әһалисен эш сөючән икән дип уйлый. Вакыйган, анда һәр йирдә бер эшлеклелек вә һәркем үз эше берлән мәшгуль. Бер кешенең мастерское берлән кибете икесе дә бер йирдә була. Хуҗасы, кеше килсә – сату итә, сатып алучы булмаса – әйбер ясый.

Шамда торган бер атнада, табигый, һәр көн ике-өч мәртәбә чаршылардан үтәргә тугры килде. Ләкин һичбер вакыт кибет алдына җыйналып утыручыларны күрмәдем. Кибеттә кешеләр йә саталар, йә эшлиләр. Әлбәттә иртәдән кичкә кадәрле йөз житмеш ике каһвәханәне (бу хисап моннан утыз ел мөкаддәм[2] ясалганлыктан, бүген дә каһвәханәләр – гадәте аннан күп артыктыр. Чөнки мөселманнар арасында мәктәп-мәдрәсә, җәмгыяте хәйрия шикелле нәрсәләр эволюция кагыйдәсенә буйсынмасалар да, каһвәханә, сораханә шикелле нәрсәләр эволюциянең аръягына чыгып китәләр) тутырып, суган сатып утыручы эшсезләр дә аз түгел.

## V
## Мәктәп-мәдрәсәләр вә китапханәләр

Иске заманнарда Шам үзенең ләтафәте[3], манзарасының гүзәллеге, суының муллыгы, инешләренең күплелеге вә әһалисенең ягымлылыгы берлән никадәр шөһрәт тапкан иде исә, аның гыйлем вә мәгарифтәге шөһрәте дә шул-кадәр иде. Багдад дәрәҗәсенә үк ирешә алмаса да, Шамның мәдрәсә вә китапханәләре бик мөкәммәл иде. Хосусан, Өмәвиләр дәверендә күп мәдрәсәләр ачылып, гыйлем юлына күп нәрсәләр вакыф

[1] Сәнәгать – промышленность, индустрия.
[2] Мөкаддәм – элек.
[3] Ләтафәте – гүзәллеге, матурлыгы, ямьлелеге.

ителгән[1] иде. Ләкин бер вакытларны мәдрәсәләр дә таләбәләр[2] берлән тулы булган ул мәдрәсәләрнең бу көндә исемнәре генә калган, биналары хәрабә хәлендә. Вакыфлары әхлаксыз кешеләр кулына кереп, гаип булып беткән.

Бу көндә Шамда хөкүмәт тарафыннан ачылган бер игъдади[3], табиб мәктәбе бер гаскәри рөшди, бер гаскәри игъдади вә бер дарелмөгаллимин бар. Гаскәри игъдади Сөләйман Кануни тарафыннан тәэсис ителгән имеш.

Хосусан, мәктәпләрен телгә алып сөйләрлеге булса, «Мәдрәсәи Госмания» булыр. Без аны кереп күрә алмадык. Ләкин читтән ишетелүенә караганда, гүзәл бер мәктәп булмаса кирәк. Бер вакытларны ул мәктәпкә безнең якташлардан берсе килеп кергән, имеш, ләкин истифадәсез булганлыктан, ташлап чыккан.

Мәдрәсәи Госманиядән башка да мәдрәсәи Гыйльмия, Дарелфазыйл фәлән шикелле бик матур исемле мәктәпләр бар диделәр. Ләкин шөбһә юк, аларның исемнәре генә матур. Алар, чынлыкта, мәдрәсәи җаһилә, дарелгазаптыр[4]. Бүген генә бер иптәшем Истанбулдагы «Дәрелсәгадәт» исемендә бер мәктәпнең мөдире таләбәләрне (кечкенә мәгъсумнәрне[5]) хайван урынына, аякларын бәйләп, кыйнаганлыгы вә мөдирнең дә бөтен вазифасы балаларның кулларын таяклаудан гыйбарәт дип аңлаганлыгын, шул мөдирнең кыйнавы сәбәпле, бер баланың кулын айлар буе муенына асып йөрергә мәҗбүр булганлыгын вә бер көнне мөдирнең бер баланың башына пепельница белән сугып, аннары кыйнап чыгарганлыгын сөйләде. Әфәнде шуларның барысын да үз күзе белән күргән. «Дарелсәгадәт» исеме никадәр матур, ләкин сәгадәт[6] шулай булырмы?

Бичара төрек баласы ниләр күрми? Төрек баласының тырышлык вә истигъдад[7] сәләте нинди хайваннар кулында болганып

[1] Вакыф ителгән – берәр кеше тарафыннан җәмәгать файдасына тотар өчен бирелгән мал, милек.

[2] Таләбәләр – шәкертләр, укучылар.

[3] Игъдади – хәзерлек.

[4] Дарелгазаптыр – газап йорты.

[5] Мәгъсум – гөнаһсыз яшь бала.

[6] Сәгадәт – бәхет.

[7] Истигъдад – зирәклек.

китми? Бу дөньяда утка атылырга мөстәхикъ[1] ике сыйныф халык булса, аның берсе – шөбһәсез, шул «Дарелсәгадәт» зобаниларыдыр. Фәкать бер мәгъсумнең өзелеп-өзелеп: «Мөдирчегем, аякларыңны үбәрем... Аһ мөдирчегем...», – дип елау вә ялваруларыннан мөтәэссир булырлык бер хискә малик булмаган бер мөдир вә бу мәктәпнең Истанбулда икәнлеген истән чыгармагыз. Пайтәхеттә[2] шундый бер мәктәпнең дәвамына мөсагадә иткән[3] бер хөкүмәт... мөнкариз булырга[4] хакы бар...

Шамдагы әҗнәби[5] мәктәпләренең күбесе ибтидаи[6] вә бераз рөшди[7] булса кирәк. Боларны тикшереп йөрергә тиеш күрмәдем.

Иске вакытларда Шамда Морадия, Гомәрия, Шәех Халид, Габдулла паша исемнәрендә китапханәләр булган. Вакытына күрә бик бай булганнар. Башка мөәссат[8] шикелле болар да таралып, югалып беткәннәр.

Габделхәмид дәверендә шуларның калдыклары гына тупланып, «Милләт әз-Заһир» төрбәсенә куелган вә китапларга бер фиһрист та тәртип ителгән. Ике мең дүрт йөз алтмыш биш җилд китапны үз эченә алган бу китапханә бүген «Милләт әз-Заһир китапханәсе» исеме берлән йөртелә. Мондагы китаплар: гыйль әл-Коръән, тәфсир, хәдис, фәраиз[9] тәүхид[10], лөгать, нәхү[11], сарыф[12], бәян[13], мантыйк[14], тарих, әдәбият, җәгърафия, тыйб[15], хи-

[1] Мөстәхикъ – лаеклы.
[2] Пайтәхеттә – башкалада.
[3] Мөсагадә иткән – мөмкинлек биргән.
[4] Мөнкариз булырга – юкка чыгарга.
[5] Әҗнәби – чит ил халкы.
[6] Ибтидаи – башлангыч.
[7] Рөшди – урта мәктәп.
[8] Мөәссат – биналар.
[9] Фәраиз – варисларга мирасның күпме тиешлеген билгели торган кагыйдәләр.
[10] Тәүхид – бер генә Аллага ышану.
[11] Нәхү – синтаксис.
[12] Сарыф – морфология.
[13] Бәян – әдәбият теориясенең сүрәтләү чаралары турындагы бүлеге.
[14] Мантыйк – логика.
[15] Тыйб – медицина.

мия, хикмәт, табигать, хисап, һәндәсә[1], һәййәт[2], зирагать[3] фәннәренә карый, имеш.

Монда Ибне Гасакәрнең сиксән җилдтән гыйбарәт Шам тарихы да бар, имеш.

## VI
## Шам

Поезд барып туктагач та, вокзалга төшеп, шәһәргә китү чараларын төшендек. Яныбызда авыр нәрсә булмаганлыктан җәяү китү дә мөмкин иде. Бервакытларны Истанбулда чыга торган бер журналда мөхәррирлек иткән кырымлы һәмшәһри[4]: «Татарга паспорт кирәкми», – дия. Вә моннан: «Татар кайда гына күренсә дә, ачык танылып тора», – диюне аңлата иде. Без сумкабызны отельгә алып бару өчен хәммаль[5] берлән сөйләшеп торганда, янымызга яшь кенә бер кеше килеп, татарча эндәште. Ул безне кыяфәтемездән таныган. Без дә аның килгәнен күрү берлән үз кешемез икәнен зан иткән[6] идек. Иштә кырымлы әфәнденең сүзләре дөрестер.

Бу әфәнде – Шамның «Мәккәи Мөкәррәмә» отелендә мосафир ирләр кабул итеп торучы русияле Талип әфәнделәр. Ул безне тугры үзләренең отеленә китерде.

Анда калган бер атнада һәр җәһәттән безне рәхәт итте. Төркиядә бер акча мәсьәләсе бар ки, кайда гына барсаң да, шуның рәхмәтен күрәсең. Син Истанбул я Бәйрутта теләсәң бөтен гомерең буе утыр. Шам, Хәлеб, Багдад шикелле башка бер йиргә барсаң, акча мәсьәләсендә аптырап каласың вә беренче мәртәбәсендә, мотлакан, алданасың. Талиб әфәнде безгә бу хосусларда да ярдәм итте. Безнең бер тиенемезне дә башкаларга йибәрмәде. Шамда алданмый, таланмый, рәхәт-рәхәт көн үткәреп китәргә

---

[1] Һәндәсә – геометрия.
[2] Һәййәт – астрономия.
[3] Зирагать – игенчелек.
[4] Һәмшәһри – шәһәрдәш, якташ.
[5] Хәммаль – күтәреп йөк ташучы.
[6] Зан иткән – уйлаган.

теләүчеләр мәзкүр Талип әфәндегә юлыксалар, һәр җәһәттән мәмнүн калачакларына ышанам.

Талип әфәнде аларның мәшһүр урыннарны карап-танышып йөреп чыгуларына вә юл өчен лязем булган әсбапларны, кайтышлый булса, Русиягә китерәчәк Шам хатирәсе һәдияләрене алданмый алуларына ярдәмче булачак.

Җае чыккач шуны да әйтеп үтим әле: Безнең Русия мөселманнарында тәшәббес[1] шәхсән төрекләр вә гарәпләрнекеннән күп алда диләр.

Менә моңа бер мисал кирәк булса, ул – Талип әфәндедер. Шамда берничә елдан бирле хаҗилар каршылау вә озату берлән шөгыльләнгән бу әфәнде читтән килүче мосафирларга Шамның мәшһүр урыннарын күрсәтерлек дәлилләр юклыгын игътибарга алып, аларга бераз ярдәмче булу өмиде берлән бу шәһәрнең мәшһүр урыннарын бәян итеп, бер рисалә тәртип иткән. Вә эченә Шам мосафирларына кирәк булган кайбер мәгълүмат вә рәсемнәр дә куелган. Ул аны тиздән бастырып чыгарачак. Мондый рисаләләрнең сәяхләр өчен булган әһәмияте язып бетергесез. Тарихи урыннарның рәсемнәрен күрү берлән, аларның ни икәнлеген белми генә карап чыгу арасында күп аерма юк. Талип әфәнденең бу тәшәббесе мондагы төрек вә гарәп зыялыларына бер гыйбрәт булырга тиештер. Ләкин, ышанамын, аны игътибарга алып, уйлап караучы булмас. Америкада утырган бер христианның Сүрия харитасын ясап бирүеннән мөтәэссир була алмаган кешеләр үз диндәшләреннән берсенең Шам дәлиле язып чыгаруына күп игътибар итмәсләр. Моннан соң Шамны зиярәт итүчеләр бу рисәләдән файдаланырга тиешле.

Номерга урнашып, бит-кулларымызны югач, ашау вакытына кадәр шәһәрне тамаша итәргә киттек. Мин үземне һаман шул Рәшид дәверендә хис итә идем. Урамда күренгән кәбабчылар, ширбәтчеләр, китапчылар барысы да миңа әллә кайдагы укыганым кыйссаларда искә алынган кәбабчылар, шәрабчылар... шикелле тоелалар иде.

[1] Тәшәббес – инициатива күрсәтү; тапкырлык.

Безнең башымызга, исламның иске шәүкәте[1] вә иске ислам пайтәхетләренең зиннәт вә мәгъмурияте[2] вә иске ислам мәдәнияте. Һарун әр-Рәшид дәвере берлән, Гранада вә Куртуба[3] хөкүмәтләре хакында укылган нәрсәләр берлән кергән ислам дөньясының бүгенге кан еглатырлык хәленнән дә шәхси мөшаһидәләребез[4] берлән хәбәрдар булганмыз. Боларның беренчесе, гарәп тәкъдире берлән әйткәндә, «кән»гә хәбәр булып кына калган, икенчесе исә – бүгенге ачы хакыйкатьтер. Ислам дөньясының бүгенге хәленә тәәсеф итеп утырганда, күңел, бераз гына юне килде исә мөселманнарның иске шәүкәт вә газаматларын искә төшереп, аз төсле табарга тели, вә шул иске дәүләтләрне искә төшерердәй манзаралар аңа бик нык тәэсир итә.

Бәйрутнең иске Багдадларга, Куртубаларга, Шамнарга охшашы бик аз. Монда Рәшид вә Габдрахманнар дәверен искә төшереп торырлык нәрсәләр юк. Шулай була торып, монда да сине хыялың кайсы вакытта Багдад, Куртуба урамнарына алып барып ташлый. Үзеңнен анализыңның язылган хәрефләргә күп мөнәсәбәте булмаган латин хәрефләрен берләштерә-берләштерә талган күзеңне, вә әллә кайда Инҗелтерә[5] йә Американың бер дәрелфөнүнендә укытып вә язып яткан бер мөэррих[6], йә философ, йә әдип, йә педагогны тәгъкыйб итә-итә[7] арган башыңны бераз ял иттерү өчен, төн урталарында тәрәзә аркылы тышка карыйсың.

Бөтен йирне караңлыгык каплаган була. Тып-тын, һич тавыш булмый. Тик ара-тирә карлыгып беткән этләр генә тынычлыкны бозып куялар. Анда-монда йолдыз шикелле генә ялтырап күренгән шәмнәрдән башка утлар сүнгән була. Ул утлы бүлмәләр инде, берәр, төнлә гыйбадәт кылучы дәрвишнең яки төннәрен йоклый алмый үткәрүче бер авыруның бүлмәседер дип уйлыйсың. Менә шул караңгылыкның дәһшәте вә ул тынычлыкның

[1] Шәүкәте – куәте, бөеклеге.
[2] Мәгъмурияте – төзеклеге, мәдәнилә шкәнлеге.
[3] Куртуба – Кордова.
[4] Мөшаһидәләребез – шаһитларыбыз.
[5] Инҗелтерә – Англия.
[6] Мөэррих – тарихчы.
[7] Тәгъкыйб итә-итә –, биредә: өйрәнә-өйрәнә мәгънәсендә.

газамәте[1] астында фикерең берлән икенче галәмдә гизә башлаган вакытында гына еракта-еракта бер гарәбинең бик моңлы тавыш берлән җырлап җибәрүе сине сискәндереп йибәрә. Күңелең Диҗлә буена кайтып киткән була. Ләкин бу дөньяда воспоминаниеләр берлән яшәп булмый. Татлы хыяллар вә куанычлы хатирәләр астында үзеңне бераз алдап тора алсаң да, ахырында хакыйкать бөтен дәһшәте берлән үзен танырга мәҗбүр итә. Кеше үзен үткәндәге шөһрәт вә шәүкәт берлән игъфал итәргә[2] тиеш түгел. Госманлы төрекләре бабаларының алты йөз еллык шәүкәте берлән ифтихар итә-итә[3] бу хәлгә килделәр. Ике сүзнең берендә «бабаларымыз Вена капуларына китмеш» диләр. Ләкин үзләренең, шул Вена капуларына кадәр китмеш бабаларының балалары булган хәлдә, Искидар капуларына кадәр чигенүләрен искә алмыйлар.

Шамның кичке манзарасы гаять шагыйранәдер. Каһвәханәләр вә башка иҗтимагый урыннары гаять рухлы. Урамнарның бәгъзеләре электрик берлән яктыртыла. Табигый каһвәханәләр, ашханәләр, кибетләр отельләрдән бик күпләре дә электрик алалар.

Аш ашап, каһвәләр эчкәннең соңында «Зөһрәт Димәшкъ» исемендә бер синематографка[4] кереп, бераз картиналар тамаша иттек тә отелемезгә кайтып татлы хыял вә хисләр астында рәхәт йокыга киттек.

## VII
## Өммия җамигысы

Иртә берлән йокыдан торгач та, игъдади[5] мәктәптәге ике һәмшәһрине[6] зиярәт иттек. Шамның үзен йөреп күрергә никадәр теләгән идек исә дә, һәмшәрилек мөхәббәте өстен чыкты. Мондый чит йирдә үз кешеңне күрү күңелләрне ачып йибәрә.

[1] Газамәте – тантанасы.
[2] Игъфал итәргә – белемсезлеккә төшәргә; алданырга.
[3] Ифтихар итә-итә – мактана-мактана.
[4] Синематограф – кинотеатр.
[5] Игъдади – хәзерлек (подготовителәный).
[6] Һәмшәһри – шәһәрдәш (якташ).

Игъдадидан кайтышлый җамигъ Өммиягә кереп карап йөрдек. Бу җамигъның утырган урыны бик искедән мәгъбәд[1] була килгән. Потпәрәстләр[2], яһүдиләр, христианнар бу урында Аллага гыйбадәт кылып үткәннәр. Шам гарәпләр кулына төшкәндә, анда кәлисә[3] булган икән. Гарәпләр аның яртысын җамигъ ясап, яртысын кәлисә хәлендә калдырганнар. Соңра Вәлид бине Габделмәлик[4] калган яртысын да христаннарга башка бер урыннан йир биреп алган. Вә ул йирнең бөтенесен капларлык бер җамигъ – эшләткән. Бүгенге җамигъ шул Вәлид эшләткән җамигъның калдыгыдыр. Ул вакыттан бирле җамигъ әллә ничә мәртәбә янып төзелгән. Аның бүгенге бинасы, шөбһәсез, Вәлид тарафыннан салынган бина түгелдер. Зурлыгы вә шәкеле үзгәрмәгән булса кирәк.

Фәүкыльгадә зур булган бу җамигъның эче никадәр мәһабәт вә мөзәйян[5] булса, тышы шул нисбәттә пычрак вә бәрбад[6] хәлдә. Тыштан караганда янындагы башка иске биналардан күпкә аерылмаса да, эченә керү белән сине тәмам башка бер манзара каршы ала. Идәненә кыйммәтле келәмнәр түшәлгән вә түшәменә дә мөзәйян кандилләр[7] асылган. Уратада юан баганалар тезелеп киткәннәр. Бер баштан барып караганда, алар да бик мөзәйян булып күренеп торалар. Диварлары бик гүзәл, мәрмәр ташлары ялтырап тора. Урта йирендә биек бер коббәсе[8] вә дүрт мәзһәб имамы, махсус дүрт михрабы[9] бар. Бу җамигъның капалы кыйсьме[10]. Моның киңлеге гади йөреш адымы берлән ике йөз адымнан бераз артык. Озынлыгы да алтмыш адым. Моның алдында бер ачык кыйсьме бар. Анысының да киңлеге табигый, капалы кыйсьменеке кадәрле. Ләкин озынлыгы аннан күп артык – туксан ике адым. Капалы кыйсьме берлән ачык кыйсьмен бергә кушканда, җамигъның

[1] Мәгъбәд – гыйбадәт кылу урыны.
[2] Потпәрәстләр – потка табынучылар.
[3] Кәлисә – чиркәү.
[4] Вәлид бине Габделмәлик – 705–715 елларда хөкемдарлык иткән хәлифә.
[5] Мөзәйян – зиннәтлегеннән.
[6] Бәрбад – эштән чыккан, җимерек.
[7] Кандилләр – люстралар.
[8] Коббәсе – гөмбәз.
[9] Михраб – мәчетләрдә мулла намаз укыр өчен аерым урын.
[10] Капалы кысьме – өсте ябулы өлеше (түбә астындагы).

озынлыгы бер йөз илле ике адым – вә киңлеге дә ике йөздән артык. Бу гадәдләр[1] җамигъның зурлыгы хакында бер фикер бирсә кирәк.

Җамигъның ачык кыйсьме дә бик тәмиз[2], мәрмәр ташлар берлән түшәлгән. Анда да аяк киемен салып йөриләр. Уратасында бер хәвез[3] дә бар. Моның әтрафында бераз бүлмәләр бар. Аларның кайсылары төрбә, кайсылары мөтәвәлли[4] бүлмәсе. Бәлки хадим[5] бүлмәләре дә шундадыр.

Җамигъның нәкъ уртасында мөзәйян бер коббә[6] бар. Аның ишегенең ике тарафына озынлыклары якынча өч вә юанлыклары биш карыш ике шәм куйганнар. Бу коббә хәзрәти Яхъяның төрбәсе, имеш. Бәйрутнең «җамигъ Гомәр»ендә дә шундый бер төрбә бар. Ул да хәзрәти Яхъя төрбәсе. Садад та тагын бер Яхъя галәйһиссәлам төрбәсе бар. «Дөньяга өч Яхъя килеп киткәнме», диярсез. Ләкин төрбәчелектә маһирлык кәсеп иткән мөселманнар моңар җавапны бик ансат табалар. Шамда хәзрәти Яхъяның башы, Бәйруттә кулы, Сададта тагын бер нәрсәсе, имеш. Шафи[7] җавап түгелме? Сададтагы төрбәче генә, нишләптер, бервакытны: «Шам берлән Бәйруттәге каберләр ялган, Яхъя галәйһиссәламнең хакыйкый кабере исә ошбу Сададтадыр», – дип сөйләп калган. Ихтимал, Бәйрут вә Шамдагыларның да шулай сөйләнгән вакытлары булгандыр. Ләкин без ишеткәнемез юк.

Без коббәгә якынаю берлән, шунда хөрмә яфрагы берлән идән себереп йөргән берсе йөгереп килеп, дога кыла башлады. Вә мәгъруф[8] догаларны укып тәмам иткәннең соңында, «төрбә файдасына» акча сорады. Җамигъдагы бүлмәләрнең берсендә хәзрәти Хөсәеннең кабере бар, имеш. Анда да китерделәр. Андагы сакчы бераз дога кылганның соңында, рәшәткәдән чыгып торган вә фабрикадан чykканнан бирле үбүчеләрнең төкрегеннән су төсе күрмәгән, кергә катып беткән бер яшел чүпрәкне үбеп, бит вә

[1] Гадәдләр – саннар.
[2] Тәмиз – чиста, пакь.
[3] Хәвез – бассейн.
[4] Мөтәвәлли – мәчет, мәдрәсә эшләре белән шөгыльләнүче.
[5] Хадим – хезмәткәр.
[6] Коббә – төрбә.
[7] Шафи – канәгатьләндерерлек.
[8] Мәгъруф – һәркем белгән.

күзләрене сөртте дә безгә дә сузды. Аннан китә башлагач, бер карт гарәп килеп «михраб Зәйнелгабидин»не зиярәт итүебезне үтенде. Анысын да зиярәт итеп, бу төрбәләрнең налогын-фәләнен түләгәннең соңында мәшһүр Сәлахеддин Әюбинең каберен эзләп киттек.

Дуслары гына түгел, бәлки дошманнары да ихтирам иткән бу мәшһүр каиднең[1] кабере җамигъның күршесендә генә кечкенә вә гүзәл бакча эчендә бер төрбәдә. Янында вәзире Гыймадеддиннең дә кабере бар. Төрбәнең эче мөзәйян. Идәненә кыйммәтле келәмнәр түшәлгән. Диварларына гүзәл ләүхәләр[2] асылган. Монда бер гадәт бар: биналар эчендә саклана торган мәшһүр адәмнәрнең каберләре өстенә табут шикелле бер нәрсә ясап куялар. Вә аның бер башында ясалган фәс калыбы шикелле нәрсәгә фәс кидереп чалма урыйлар. Вә кабернең өстен дә кыйммәтле пәрдәләр берлән каплыйлар.

Сәлахеддин Әюби берлән вәзире Гыймадеддиннең каберләре дә шулай ясалган. Башларына кидерелгән чалмалар «Сәлахеддин Әюби» пьесасын уйнаганда артистларның кия торган чалмалары шикелле. Кабернең бер тарафына «Иттихад вә тәрәккъый»ның Шам шөгъбәсе[3] тарафыннан тәкъдим ителгән вә өстенә, хәтеремдә ялгыш калмаган булса, «Әл-җәннәт тәхет зыйлә әс-сәйүф»[4] дип язылган бер ләүхә сөялгән. Кабернең баш тарафындагы диварда махсус ясалган пыяла капкачлы шүрлектә Алмания императоры тарафыннан тәкъдим ителгән мәгъдән[5] венок тора. Венокның астына «Вилһельм әс-сәни кайсар Алмания вә мәлик Прусия тәзкәран лил-баталь әс-солтан Сәлахеддин әл-Әюби. Иннә Аллаһе йухибел-мөхсинин»[6] дип язылган.

---

[1] Каиднең – җитәкченең.

[2] Ләүхә – матур язу белән язылып стенага элеп куйган нәрсә, шәмаил.

[3] Шөгъбәсе – бүлекчәсе.

[4] «Әл-җәннәт тәхет зыйлә әс-сәйүф» – «Җәннәт кылычларның күләгәсе астында» (хәдистән).

[5] Мәгъдән – металл.

[6] «Вилһельм әс-сәни кайсар Алмания вә мәлик Прусия тәзкәран лил-баталь әс-солтан Саләхеддин әл-Әюби иннә Аллаһе йухибел – мөхсинин» – «Алмания кайсары һәм Прусия патшасы Вильгельм Икенчедән каһарман солтан Сәлахеддин Әюбигә истәлек. Дөреслектә Аллаһы Тәгалә игелекле кешеләрне ярата». (Соңгысы Коръәннән аят.)

Венокның башындагы крест та бик ачык булып күренеп тора. Без сакчыдан: «Бу крест нигә алынмаган, кабергә аны кую дөрестме?» дип сорадык. Ул да: «Нисе бар, бөек бер зат тарафыннан ядкәр тәкъдим ителмештер» дип җавап бирде. Бу төрбәнең сакчысы ачык кына фикерле бер адәм булса кирәк, дип хөкем иттек. Чөнки без керү белән башка төрбәчеләр шикелле йөгереп килеп, үзе дә юньләп аңламаган нәрсәләрен укый башламады. Безне үз хәлемезгә куйды. Зиярәттән максат бер уч туфрак янына килеп, ватып-йимереп берничә «Иннә-атыйнә» вә беркадәр «Колһуалла» сүрәсе уку түгел, бәлки шул зур адәмнәрнең эшләгән эшләрен искә төшереп, аларның хәятеннән бер дәрес алу икәнлеген бу сакчы аңламаган да булсын, әмма аның зиярәт итүчеләрне алай мазасызламавы мактауга лаек.

Без Сәлахеддиннең кабере алдында берничә вакыт уйланып тордык. Хамиять[1] вә шәҗәгатнең[2] мисалы, мөҗәссәме[3] булган бу затның хәятен, хәтеремездә калганы кадәр, бер фикердән кичердек. Аның әҗәл түшәгендә яткан дошманына күрсәткән инсаниятләрен вә милләтен азат итү, саклау өчен күрсәткән фидакярлеген искә төшердек.

Бер вакытларны Гомәр бине әл-Хаттабларны[4], Халид бине Вәлидләрне, Зияд бине Тарикъларны,[5] Сәлахеддин Әюбиләрне йитештергән гарәп дөньясының бүгенге хәленә бер күз салдык. Бу мазыйлы[6] милләтнең бүген һич булмаса бер Саләхеддине яки бер Халиде булса иде, бу баһадирның төрбәсеннән шат күңел вә ачык йөз берлән чыгып кителер иде. Ләкин ислам дөньясының шәүкәте аның мазыйсында гына калуы, бу көндә Гомәр

[1] Хамиять – башкаларны зарар күрүдән саклау.

[2] Шәҗәгатнең – батырлыктың, кыюлыкның.

[3] Мөҗәссәме – гәүдәләнеше.

[4] Гомәр бине әл-Хаттаб – Гомәр бине әл-Хаттаб әл-Фарук (591–644), Мөхәммәднең варисы.Гомәр хәлифәлеге заманында (634–644) хәлифәтлек күпмилләтле, әмма бер динле зур мәмләкәт булып оеша. Аның җитәкчелегендәге мөселман гаскәре Палестинаны, Сүрияне, Мисырны Ливияне һәм Персиянең зур өлешен яулап алалар.

[5] Зияд бине Тарикъ – Тарикъ бине Зияд, гарәпләрнең бәрбәр кабиләсеннән чыккан яу каһарманы. Африкадан Испаниягә юнәлеп, 711 елда бу илне яулап алган мөселман гаскәр башлыгы.

[6] Мазыйлы – үткәне булган.

бине әл-Хаттабның гадаләте[1], Халидның мәһарәте[2], Тарикъның шәҗагате[3] урынына төрекләрнең идарәсе, гарәпләрнең гаталәте[4], гомум әһле исламның җәһаләттә[5] җәбанәттә калуы[6] вакытында файдалы хезмәтләр күрсәткән адәмнәрнең кабере берлән тулы булган Шамда бүген бер генә булса да шуларның хилафы[7] булмавы күңелдәге аз-маз өмидне вә йөздәге юк-бар шатлыкны тар-мар китерә иде.

Сәлахеддин Әюбинең төрбәсеннән чыккач, җамигъның манарасына чыгып, шәһәрнең манзарасын тамаша итәрмез дип уйлап куйган идек, ләкин аны икенче көнгә күчереп кайтып киттек. Чөнки, бердән, вакыт тар иде. Икенчедән, күңел манара башыннан күренәчәк манзаралардан ләззәт алырлык хәлдә түгел иде.

## VII
## Хәзрәти Гайсә төшәчәк манара

Икенче көнне манара башына чыгу касды[8] берлән җамигъка кереп, шунда йөргән бер хадимнән манараның капусын сорадык. Хадим: «Анда менәргә мөсагадә[9] юк», – диде. Без бу сүзнең мәгънәсен бик яхшы аңласак та, хадимгә ялынып, акча күрсәтеп торасымыз килмәде. Әгәр дә ул алай сөйләми генә ачып керткән булса иде, хезмәтен бушка калдырмаган булыр идек. Ләкин аның болай хакы булмаган нәрсәне соравы гыйнадымызны[10] арттырып йибәрде. Хадимнән ул җавапны алгач, мөтәвәллине эзләп киттек. Ул җамигъның әтрафындагы биналарның бер кыйсьмендә тора икән. Ак сакаллы, таза вә ачык кына бер адәм, имеш. Безне гүзәл кабул итте. Без үземезнең кайдан вә кем икәнлегемезне вә нинди максат берлән килгәнлегемезне сөйләп, манарага менәргә

[1] Гадаләте – гаделлеге.
[2] Мәһарәте – осталыгы, сәләтлелеге.
[3] Шәҗагате – кыюлыгы, гайрәте.
[4] Гаталәте – сүлпәнлеге, дәртсезлеге.
[5] Җәһаләттә – наданлыкта.
[6] Җәбанәттә калуы – куркып калуы.
[7] Хилафы – киресе.
[8] Касды – теләге.
[9] Мөсагадә – мөмкинлек юк, мөмкин түгел.
[10] Гыйнадымызны – кирелегебезне.

рөхсәт сорадык. Ул шул минутта җамигъ хадимнәреннән берәрсен чакырырга үз хадимен йибәрде. Без дә тәкъдим ителгән туңдырмаларны ашый-ашый, җамигъ хакында сүз ачып, бераз сөальләр сорадык: «Җамигъның эче гүзәл вә мөзәйян икән, ләкин тышы бер дә эче берлән мөтәнасиб түгел[1]. Аның тышын да бераз яхшырак сакларга мөмкин түгелме?» – дидек. Мөтәвәлли, бераз көлемсерәп: «Шулай кирәк иде. Ләкин акча юк. Җамигъның килере хадимнәреннән артмый. Йөз илле кадәр хадим бар», – диде. Без: «Ишетүемезгә күрә, ошбу җамигъка күрше булган чаршылар барсы да аңа карый, имеш. Аларның доходы йитәрлек түгелдер шул», – дидек. Мөтәвәлли: «Хәер, сезгә хата сөйләгәннәр. Алар җамигъка карамыйлар», – диде.

Ул җамигъка йөз илле хадим нигә кирәк, анда егерме биш хадимлек тә эш күренми. Келәмнәр өстеннән түшәмгә оя ясаган күгәрченнәрнең нәҗесен тазартып тору өчен дә бер кеше йитсә кирәк. Әгәр дә көненә биш мәртәбә югарыга менеп азанны бер дә азанга охшатмый торган җөмләләр арасында бер йоклап алырлык вакыт кадәр торып вә аларның ахырында әллә ничә миль сузып кычкырып төшү өчен хадим кирәк булса, монда кеше саны арттырырга түгел, азанны азан шәкеленә куярга гына кирәк иде.

Мөтәвәлли берлән сөйләшүебез тукталып торган бер арада, аның янында утырган бер карт:

– Шәһәремезне ничек таптыңыз? – диде.

– Әле яңарак килдек, барын күреп танышып беткәнемез юк. Ләкин беренче тәэсирләремездән сөйләсәк, «яраттык» дию дөрес булыр. Әһали безнең Бәйрутка нисбәттән инсафлы вә әхлакы исламия дә тәмам югалып бетмәгән икән», – дидек. Моңа каршы карт:

– Әвәт[2], мәгыйшәтемез вә халкымыз яхшы иде. Ләкин хәзерге хәлемез яхшыдан түгел, – диде. Без бу картта төрекләргә каршы дошманлык хисе булганлыгын аңлап, аның берлән бераз сөйләшергә теләгән идек. Ләкин бу вакытта хадимнең килеп йитүе безне аннан мәхрүм калдырды. Мөтәвәллидән рөхсәт алып, чы-

[1] Мөтәнасиб түгел – туры килми.
[2] Әвәт – әйе.

гып киттек. Мөтәвәлли бу картка безне җамигъ эченә кадәр алып барырга вә анда берәрсен кисәтеп куярга кушты.

Җамигъның ачык кыйсьмендә сигез терәк өстендә бер коббә тора. «Морадия» мәдрәсәсендәге бохаралы мөдәррис ул коббәдә әнбиягә[1] күктән килгән сыйххәт[2] саклана дигән иде. Коббәнең яныннан үткәндә, карттан аның эчендә ни барлыгын сорадык.

– Аның эчендә иске китаплар вә кул язулары саклана, – диде.

– Анда безнең өчен газиз нәрсәләр юкмы? – дидек.

– Бар иде, әфәндем. Ләкин һәр бәланең башы Истанбулдан килә. Безнең дөнья бәһасенә бирмәслек иске вә газиз бәгъзе нәрсәләребезне, Истанбулдан килгән әмер буенча, Алман кайсарына алып биреп йибәрделәр, – диде. Мин Алман императорының Сәлахеддин Әюбинең үз кулы берлән язган мәктүпләрен вә бәгъзе бер иске әсәрләрне алып киткәнлеген ишеткән идем. Шунлыктан «Бу шәехнең сүзләре бөтенләй нигезсез булмаса кирәк», дип уйладым.

Карт, хадимгә тиешле тәнбиһләрне[3] биргәч, безнең белән күрешеп китте вә кат-кат ханәсенә дәгъват итте. «Бер генә көн булса да безнең мосафирларымыз булып, безне мәсгуд[4] итегез», – диде. Ләкин үзе ханәсен ачыклап әйтмәде. Шул вакытта минем хәтеремә Гаяз әфәнденең[5] «Мелла бабай»ндагы «Безнең мелла баласы чыксын әле» дигән сүзләре килеп төште. Бик ачык фикерле булган бу карт, ихтимал, Шамның бик мәшһүр адәмнәреннәндер. Ләкин без Шамның үлекләрен бераз белсәк тә, терекләрен һич белми идек. Ни булса да, чакыруы өчен рәхмәтләр әйтеп, манарага менеп киттек.

Без кергәндә манарага менеп баручы, яки аннан төшеп килүче берничә хатын бар иде. Алар бер тарафта туктап калдылар. Без менеп киттек. Баскычлар йимерек[6], юл караңгы, бәгъзе урыннарда кармаланып кына барырга туры килә. Аяк астында

[1] Әнбиягә – пәйгамбәрләргә.

[2] Сыйххәт – дөреслек, тугрылык.

[3] Тәнбиһләрне – күрсәтмәләрне.

[4] Мәсгуд – бәхетле.

[5] Гаяз әфәнденең... – Гаяз Исхакыйның 1912–1913 елларда өч китап булып басылган «Мулла бабай» романы күздә тотыла.

[6] Йимерек – җимерек.

күгәрчен тизәге кырчын ташы шикелле булып ята. Йөз илле хадим бар икән, ләкин бу манара йөз илле елдан бирле себерке вә мунчала төсе күргәне юктыр. Башына чыгып йитәр алдыннан бер тар йирдән үтәргә туры килде. Ул йирнең ике ягына майланып тузан утырып беткән зәйтүн мае кандиләре асып куйганнар. Әгәр дә аларга аз гына бәрелеп китсәң, киемеңдә бетмәслек эз калдыралар. Иске кием киеп килмәвемә үкендем. Хәзрәти Гайсә төшәчәк манараның бу кадәр пычрак булачагы күңелемә кереп тә чыкмый иде. Манараның башы бик киң, тирә-ягында рәшәткә бар. Ләкин анда да пычраклык. Ул гына аз шикелле, зәйтүн мае кандилләрен, вә иске агач вә чүпрәкләрне тутырып куяр өчен, күзгә иң күренә торган бер урынга агачтан тавык кетәге сыман бер нәрсә ясаганнар, вә тышыннан да сары балчык берлән сылаганнар. Бу нәрсә манараны шулкадәр ямьсезләп тора ки, әйтеп бетерерлек түгел. Манараны тазарту вә аның ватык йирләрен төзәтү өчен акча кирәк булса да, аның иң башына чыгарып тавык абзары ясамас өчен акча кирәкми бит инде.

«Өммия» җамигының өч манарасыннан бу берсен сайлап мендек. Чөнки аның ике әһәмияте бар, имеш. Берсе – ул манара Вәлид дәверендә эшләнгән җамигъның калдыгы, имеш. Икенчесе дә – хәзрәти Гайсә шунда иңәчәк, имеш. Беренче фикергә бер нәрсә дә әйтеп булмый. Пычраклыгы вә бозыклылыгына караганда, «бу манара Вәлид дәверендә генә түгел, Нух галәйһиссәлам дәвереннән үк калгандыр» диясе килә. Әгәр дә ул фикерне тарих кабул итмәсә, анысы башка мәсьлә. Ләкин хәзрәти Гайса сәмават[1] галәменнән ул кадәр пычрак урынга төшәр микән? Ул үзенең оҗмах хөлләләрен мондагы зәйтүн маена вә җәннәтелфирдәүс башмакларын да күгәрчен тизәгенә буярга риза булыр микән?

Мөселманнар үзләренең көнлек хәятләренә вә башкалар арасында урын тотып мөстәкыйль яшәүләренә караган мәсьләләргә никадәр әһәмият бирмәсәләр, вөҗүди[2] вә мөсави[3] булганнары өчен шул нисбәттә әһәмият бирәләр. Хәзрәти Гайсәнең төшәчәк

[1] Сәмават – күк йөзе, күкләр.
[2] Вөҗүди – бар булу.
[3] Мөсави – тигез, бердәй.

урыны мәсьәләсе дә – шундыйларның берседер. Ничектер берсенә итифак итә алганнар.[1] Ул – Шамда иңәчәк.

Ләкин кайсы урында? Берсе: «Җамигы Өммиянең мәзкүр манарасында», – ди. Икенчесе: «Баб Шисрәкыйдагы манараи Бизаэда», – ди. Шуның өчен китаплар актаралар, рисаләләр язалар. Үткәннәрнең рухына бер фатиха дип кенә куяр идең, «ул вакытта бәлки шуннан башка эш булмагандыр» дип үзеңне юатыр идең. Ләкин бүгенге хәзрәтләремездән берсенең Шамга баручы бер шәкерттән шул хакта «Мәлик әз-Заһир» китапханәсеннән актарып тәхкыйкат ясап[2] йибәрүен риҗа итүенә[3] ни дияргә кирәк? XX гасырның иң мөһим мәсьәләсе шулмы? Хәзер хәзрәти Гайсәнең төшәчәк урынын эзләү вакыты түгел, бәлки үз милләтемезнең башка милләтләр арасында тотачак мәүкыйгын[4] вә әһәмиятен тәэмин итәргә вакыт.

Хәзрәти Гайсә төшәчәк урынның тәэмин ителмәвенең ни дөнья, ни ахирәт өчен бер файдасы бар? Ләкин милләтемезне башкалар каршында газиз бер тотып, бәхетле яшәвенең дөньямыз вә ахирәтемез өчен дә күп файдасы бар. Бүгендә ислам милләте юлбашчыларыннан хәзрәти Гайсә төшәчәк урынны күрсәтүләрен сорамый, бәлки мөселманнарны бүгенге җәһаләт[5], гадәләт[6] чокырыннан чыгарырга ярдәм итүләрен вә ислам дөньясын тәдәннидән[7] саклап алып калуның чараларын күрсәтүләрен сорый.

Манара башыннан күренгән манзара гаять гүзәл иде. Яшеллек диңгезенә баткан Шам, уч төбендәге шикелле күренеп тора. Шамнан, төрле ягын тамаша итеп, фотограф берлән берничә манзараи гомумиясен алганның соңында төшеп вә хадим әфәндегә хезмәте өчен рәхмәт әйтеп, җамигътан чыгып киттек.

[1] Итифак итә алганнар – килешкәннәр.
[2] Тәхкыйкат ясап – хакыйкатен эзләп, дөреслеген тикшереп табып.
[3] Риҗа итүенә – соравына, үтенүенә.
[4] Мәүкыйгын – урынын.
[5] Җәһаләт – наданлык.
[6] Гадәләт – эшлексезлек.
[7] Тәдәннидән – артта калудан.

## VIII
## Морадия мәдрәсәсе

Вакытында мәшһүр булган бу ислам мәдрәсәсе җамигъ Өммиянең күршесендә тар гына бер урамдадыр. Тыштан караганда ташландык бер күн заводын искә төшереп торган бу мәдрәсәнең ишегалдына керү берлән кешене каршы алган пычраклыкны аңлату вә тасвир итү өчен сүз табу кыендыр. Без башта кергәнемезгә үкенә башладык. Аркадашымыз, шакшылыкның бер хатирәсе булсын дип, рәсемен дә чыгарган иде. Ләкин бәхеткә каршымы, бәхетсезлегемезгә каршымы, кулланырлык дәрәҗәдә яхшы чыкмаган.

Шамда муллык булган нәрсәләрдән берсе – судыр. Бу муллык Морадия мәдрәсәсендә дә күренеп тора. Капкадан кергәч тә мәрмәр ташыннан ясалган зур бер хәвез[1] күрәсең. Ишегалдының икенче кыйсьмендә читтәрәк тә кечерәк бер хәвез бар. Уртасындагы зур хәвездә бөтен дөньяның пычрагы табылса кирәк. Без кергәндә ошбу хәвезнең янында күзе бетләп беткән бер карт юылмау җәһәтеннән бәлки үзе берлән бер яшьтә булган казаныннан бер песигә күмәч кисәкләре бирә иде. Хәвезнең бер башында киеме дә, үзе дә корым шикелле кара бер гарәп кызы әллә нәрсә юып шөгыльләнә иде. Болар мәдрәсәнең астагы катындагы бүлмәләрдә торучы фәкыйрьләр икән. Боларның торган бүлмәләренең, һич ялгансыз әйткәндә, күмерче алачыгыннан бер дә аермасы юк.

Өске катка чыгып, шунда карап торган берәүдән хәзердә бу мәдрәсәдә шәкертләр булып-булмаганын сорадык. «Монда шәкерт юк. Бүлмәләрнең беразында фәкыйрьләр тора. Күбесе хосусый кулларга күченеп беткәннәр. Әнә шул башта гына бер-ике шәкерт бар», – дип, бинаның икенче башын күрсәтте. Ул башка барып, югары чыктык. Караңгы гына бер бүлмәдә бер сарт берлән сарт баласы чәй эчеп утыралар иде. Әфәнде үзен «Морадия»нең мөдәррисе дип тәкъдим итте. Безнең русияле икәнлегемезне белгәч, үзенең русиялеләрне укыткан вакытлары да булганлыгын сөйләде. Мәдрәсә хакында бераз сораштык.

---

[1] Хәвез – бассейн.

Бу көндә таләбәләре бөтенләй юк, имеш. Вакыфлары таралган вә бүлмәләре дә хосусый кулларга күчеп беткән, имеш. «Әфәндем, бу зур мәдрәсә иде», – диде. Чынлыкта да моның гүзәл мәдрәсә булганлыгын аңлау кыен түгел. «Мәлик әз-Заһир» китапханәсенә кушылган «Морадия» китапханәсе шушы мәдрәсәнең китапханәседер.

## IX
## Иске кальга

Шамның нәкъ урта бер йирендә диярлек бер иске кальга[1] бар. Бу кальганың кай вакытта вә кем тарафыннан бина ителгәнлеген тикшереп йөрергә кирәк тапмадым. Бүгендә ишелгән калын диварлары, аның вакытында әһәмиятле булганлыгын күрсәтеп торалар. Эчендә бераз гаскәри даирәләр бар.

Без беренче керүдә, бәхетемезгә каршы, һичкемнән сорамый кереп киттек. Йимерелеп яткан диварларның башына чыгып тамаша иттек. Вә эчендә никадәр дикъкатьне җәлеп итәрлек нәрсәләр булса, барысын да күздән кичердек.

Биек бер урында бер-ике иске туп та тора. Ихтимал, гаетләрдә атыла торган туплардыр. Бу кальга диварларының башыннан Шамның бик күп кыйсьме күренә.

«Бәхетемезгә каршы сорамый кердек», – дидем, чөнки икенче бер мәртәбә Бәйруттән бер-ике көн кичегеп килгән мәзкүр шәһәрнең жандарм куманданының[2] углы, бер бәк әфәнде берлән барып, рөхсәт алып керәчәк булдык. Безне нәүбәтче забытка[3] йибәрделәр. Ул да ниндидер бер даирәгә йибәрде. Вә анда да «фәлән сәгатьтә генә зиярәт мөмкин» дип җавап бирделәр. Билгеләнгән сәгатьтә тагын бардык, нәүбәтчеләргә, даирәгә тагын йөрдек. «Паша әфәнденең әмере үзрә фәлән сәгатьтә мөмкин» дип башка бер вакыт сөйләделәр. Ачуымыз килде. Мин шунда торган бер забитка: «Әфәндем, без кичә генә килеп гиздек, каршы килүче булмады. Бу кальганың эчендә хәрби сер диеләчәк

[1] Кальга – крепость.
[2] Команда – (хәрби) җитәкче, начальник
[3] Нәүбәтче забытка – дежур торучы офицерга

бер нәрсә юк. Аның әһәмияте дә искелеге җәһәтеннән генә. Аны шулкадәр җентекләргә ни хаҗәт бар иде? Без ялгыз диварлар өстенә чыгып, шәһәрне тамаша итәчәк идек», – дидем. Забит: «Әфәндем, мин белмиюрем. Кумандан пашаның әмере буйлә улмалы», – диде. Аркадашымның да җаны сыкынды[1]. Ул үзе зур бер мәэмүрнең[2] угылы булганлыктан, аның гыйззәте нәфесенә[3] дә бераз тукынды.

«Идарәмез буйлә булдыкыннан соңра, аурупалылара бер шәй димия хакымыз вармы?»[4], – диде.

## X
## Шамның ибтидаи мәктәпләре

Беркөнне Шамның тар гына урамнарыннан тамаша итеп гизгәндә, бер мәктәбенә туры килдек. Аның мәктәп икәнен балаларның кычкыруыннан белеп, эченә кердек. Биш берлән унике яшьләр арасында алтмыштан артык бала пычрак вә караңгы бер бүлмәдә эскәмияләр артына тезелеп утырганнар. Бүлмә бераз такта кисәкләре берлән икегә аерылган.

Без кергәндә, кырык берлән илле яшьләр арасында чалмалы бер кеше берлән ике яшь кеше сөйләшеп утыралар иде. Чалмалының мәктәпнең мөдире вә ике яшенең мөгалимнәр икәнен аңладык. Чалмалы безне торып каршы алды, вә балаларга да ишарәт кылды.

Мөдир әфәнде безнең, бердән, төрекчә сөйләшүемездән вә, икенчедән, киемемездә булган знактан[5] безне тикшерүчеләр дип зан итте[6] булса кирәк. Гади бер сәяхләр тарафыннан бирелә торган сөальләремездән бик уңайсыз калды. Таләбәнең гадәден[7],ниләр укыганын вә мәктәпнең кем тарафыннан тәрбия

[1] Аркадашымның да җаны сыкынды – иптәшемнең дә эче пошты.

[2] Мәэмүрнең – чиновникның.

[3] Гыйззәте нәфес – үз-үзен сөючәнлек (самолюбие).

[4] «Идарәмез буйлә булдыкыннан соңра, Аурупалылара бер шәй димия хакымыз вармы?» – «Идарәбез мондый булгач, европалыларга нәрсә әйтә алабыз?»

[5] Знактан – билгедән, бу очракта: аерымлыктан мәгънәсендә.

[6] Зан итте – уйлады.

[7] Гадәден – санын.

ителгәнен сораганның соңында, мәктәпнең пычраклыгыннан сүз ачып, аны тазарттырмауларының сәбәбен сорадык. Шәех: «Әфәндем, ун пәнҗәрәсе[1]» вар. Без шәехнең зиһенендә генә булган пәнҗәрәләрне күрмәсәк тә: «Пәнҗәрәләр ун вә егерме була белер. Ләкин диварларны бераз тәмизләсәңез[2] булмасмы? Таләбәләрнең сыйххәтенә[3] бераз файда итәр иде», – дидек. Бу сүзләрдән соң безнең мөтәфтиш[4] булуымызда шөбһәсе калмады булса кирәк: «Пакьлармыз, әфәндем, япармыз[5]. Без һәфтәдән[6] һәпсе[7] улыр», – диде. Төрекчә укылып-укылмаганын сорадык. Хуҗа монда бик уңайсыз хәлдә калды. «Әфәндем, төрекчә укылмый. Без монда хисап берлән гарәпчә генә өйрәтәмез дә, төрекчә игъдадига[8] йибәрәмез», – диде.

Таләбәләргә бер күз салдык. Күп уку берләнме, авыру берләнме сап-сары булып беткән, кеп-кечкенә, курчак шикелле балалар, дип уйласак – эскәмия артында тезелеп утырган баларның күбесе тап-таза күренеп торалар. Битләрендә хәят нуры барлык вә күзләрендә дә истикъбаль[9] өмиденең утлары уйный, гарәпләрдә булган истигъдад[10] очкыны йөзләренә чыгып тора. Ләкин берничә ел эчендә бу мәктәп тәрбиясе астында ул хәят галәмәтләре, ул истигъбаль өмидләре дә югалып бетәчәктер. Кем белсен, ул балалар арасында ни кадәр Гомәр бине әл-Хаттаблар, Халидләр, Тарикълар, Сәлахеддиннәр бардыр. Кешенең холкы вә табигатенең нигезләре салына торган вакыт – балачак вә алар салына торган урын да – гаилә мохите белән ибтидаи[11] мәктәптер. Әгәр дә ул нигезләр шул вакытта салынып, тәрбия ителеп калмасалар, соңыннан аларны әллә никадәр монтазам[12]

[1] Пәнҗәрәсе – тәрәзәсе.
[2] Тәмизләсәңез – чистартсагыз.
[3] Сыйххәтенә – саләмәтлегенә.
[4] Мөтәфтиш – тикшерүче.
[5] Япармыз – эшләрбез.
[6] Һәфтәдән – атнадан.
[7] Һәпсе – һәммәсе дә.
[8] Игъдадига – урта мәктәпкә.
[9] Истикъбаль – киләчәк.
[10] Истигъдад – сәләтлек, булдыклылык.
[11] Ибтидаи – башлангыч.
[12] Монтазам – тәртипле, әйбәт.

мәктәпләрдә, белемле мөгаллимнәр тәрбиясе астында да тиешле дәрәҗәгә китереп булмас. Берәүнең яңа бер мохит тәэсире астында балалыкка бирелгән тәрбиядән башка бер тарафка үзгәреше, әгәр дә була калса, тыштан сыланып куйган балчык сыйфатында гына була. Кыскасы, аның хакында: «Изә сәмигатүм би җәбәлин зәләән мәканиһи фәсаддикубиһи; вә изә сәмигатүм биражулин тәгайреән хуликыйһи фәләтү саддикубиһи»[1] тугры була. Менә бу мәктәптәге балалар шул ике гамәлнең иң зур вә тәэсирлесеннән мәхрүмнәр. Ихтимал, шул алтмыш баланың алтысы Франциядә йә Германиядә укуларын дәвам итәрләр. Ләкин ибтидаи тәрбияләре ул хәлдә булганның соңында, матлуб[2] кеше булып чыкмаслар. Париждан диплом алып кайткан төрек яшьләренең үзгәрешләре дә, монда кайткач, өч-дүрт ай гына дәвам итә. Аннан соң тәхсиле гали[3] күргән бер бәк берлән тәхсиле ибтидаи[4] гына күргән берәү арасында аерма калмый. Тик һич укый-яза белмәгән яки уку-язуны үзлегеннән генә өйрәнеп, фазаил әхлакыясе иңсә дә[5], даирәләр арасында изелеп бетмәгән төрекләр генә күп вакытта тәхсиле гали күргәннәрдән алда булалар. Руссо[6] үзенең мәдәният хакындагы нәзариясен менә шундый хәлләрне күреп уртага сөргән булса, ул философка бераз хак бирми мөмкин түгел.

Бу мәктәптән китеп бераз баргач, тагын берсенә очрадык. Монсындагы тавыш тагын да шәбрәк иде. Эчкә кергәч, картлы-яшьле ике хуҗаның таләбәләре берлән сугышып ятканнарын күрдек. Мондагы пычраклыкны да сөйләргә хаҗәт юк. Ләкин мәдрәсә бераз яктырак иде. Төрекчә мөрәҗәгать иттек. Хуҗа әфәнде төрекчә белми, имеш. Гарәпчә сөйләшү мәҗбүриятен-

[1] «Изә сәмигатүм би җәбәлин зәләән мәканиһи фәсаддикубиһи; вә изә сәмигатүм биражулин тәгайреән хуликыйһи фәләтү саддикубиһи» – «Әгәр дә сез тауның үз урыныннан күчкәнен ишетсәгез – ышаныгыз шуңа; әгәр дә инде кешенең холкы үзгәргәнен ишетсәгез, сез аңа ышанмагыз».

[2] Матлуб – таләп ителгән, көтелгән.

[3] Тәхсиле гали – югары белем.

[4] Тәхсиле ибтидаи – башлангыч белем.

[5] Фазаил әхлакыясе иңсә дә – югары әхлакка ирешсә дә.

[6] Руссо – Жан-Жак Руссо (1712–1778), бөек француз философы, язучы һәм фикер иясе.

дә калдык. Talәбә хакында бераз сорашканнан соң, монда да пычраклыктан сүз ачып, бераз тәмизләмәүләренең сәбәбен сорадык. Хуҗа әфәнде җавабында әйтте:

– Әфәндем, бу мәктәп безнеке түгел. Вакыф хуҗасы шәех фәләннең угылы фәлән әфәнденеке. Моның һәр эшен ул күрә, – диде. Без:

– Теләсә кемнеке булсын, бераз төзәтү кирәк иде, бер дә мәктәпкә охшамый бит, – дидек.

– Гүзәл тәгъмир итәрләр[1], – диде.

Шамның чаршы вә кибетләрен тамаша итү максаты берлән номердан чыкканда, элек ибтидаи мәктәпләрдән зиярәт итеп, алар хакында бер фикер хасыйл итү уемда юк иде. Тәсадефи[2] гына килеп чыккан бу зиярәт мине бер нәрсә хакында уйларга мәҗбүр итте. Төркиягә читтән килгән кешеләрне тәхлил итеп[3] караганда, бер әҗнәбинең[4] кулы, берсенең интригасы күрелсә, хөкүмәтнең хәлен вә аны тәшкил иткән милләтләрнең кимчелекле якларын тикшереп караганда, төрекләрнең вазифаларын үтәүләре вә мәэмүрләренең дә хезмәтләренә әһәмият бирмәүләре күз алдына килә. Рум илендә ислахат[5] ясалмауга яки Албаниядә аллы-артлы тынычсызлыклар чыгып торуга, ихтимал, читләр сәбәп булгандыр. Ләкин Төркиянең бөтен шәһәрләрендәге югарыда күрсәтелгән мәктәпләрне төбеннән кырып ташлап, урынына яхшыракларын булдыру күп кыенлык вә чыгымнар таләп итсә дә, аларны бүгенге хәлләреннән күп мәртәбә яхшы итеп тоту өчен аз гына бер иҗтиһад[6] вә гайрәт йитәдер. Әгәр дә хөкүмәт мәэмүрләре үз вазифаларына тугры булсалар иде, меңнәрчә мәгъсумнар[7] тере килеш кабергә күмелмәсләр вә

[1] Тәгъмир итәрләр – төзекләндерерләр.
[2] Тәсадефи – очраклы.
[3] Тәхлил итеп – тикшереп.
[4] Әҗнәби – чит ил кешесе.
[5] Ислахат – үзгәртүләр, реформалар.
[6] Иҗтиһад – тырышлык.
[7] Мәгъсумнар – гөнаһсызлар.

истикъбаль[1] адәмнәрнең хәятләре сатлык җаннар кулларында бәрбад булмаслар[2] иде.

Төркиядә мәгарифне тәрәккый иттерергә әҗнәбиләр форсат бирмәде; Анатулы, Сүрия, Рум иле һәм башкаларны ислахка әҗнәбиләр форсат бирмәде; төрек яшьләренә милләт бәйсезлеге өчен бер гаяэ хыялия (идеал) ясап чыгарырга әҗнәбиләр форсат бирмәде...

Бүген без төрек зыялысы берлән Төркия хакында сөйләшсәк, ул сиңа шундый «форсат бирмәделәр»не бик күп китереп чыгара. Мәзкүр мәктәпләр хакында андый әҗнәби форсат бирмәүләре бөтенләй юк. Шул мәктәпләрнең хуҗалары гади бер сәях сөален бер инспектор сөале шикелле итеп, бер атна эчендә мәктәпләрен төзәттерәчәкләрен вәгъдә итәләр. Әгәр дә мәгариф мәэмүрләре вә бигрәк тә хөкүмәтнең айга ике йөз илле – өч йөз тәңкәсен ашап яткан мәгариф мөдирләре үз вазифаларын аңлап, шуны эшләп торсалар вә ул мәктәпләрне ислах итүгә ярдәм дә итсәләр, алар бүгенге көндә бераз мәктәпкә охшаган булырлар иде. Ләкин мәгариф мөдирләре ул мәктәпләрне, бердән, француз яки алман мәктәбе кебек ясый алмаганнарыннанмы, аларны төзәтүгә һич әһәмият бирмиләр. Ул гына аз шикелле, мәгариф мөдирләре үз кулларына табыш алган рәсми мәктәпләр өчен дә ул кадәр кайгырмыйлар. Бер вакытларны Хәлебтә мәгариф мөдире булып торган бер затның мөдирлек вазифасын башкарган вакытта госманлы тәрбиясе алып, госманлы хөкүмәтенә хезмәт итү фикеренә төшкән берәүгә: «Җаным, безнең мәктәпләрне ташла. Аларда мәгънә юк; кит әҗнәби мәктәпләренә», – дип нәсыйхәт биргәнлеген ышанычлы бер аркадашымыздан ишеттек. Мәзкүр әфәнде, мәгариф мөдиренең сүзләрен тотып, әҗнәби мәктәпләрнең берсенә кергән. Бүгендә, табигый, госманлылыктан артык французлык йә америкалыкка якын тора. Үзләре мәктәп хуҗалары булган әҗнәби миссионерлары да госманлы мәктәпләре хакында ачыктан-ачык шул мәгариф мөдире сүзләрен сөйләмиләр... Зәваллы[3] милләт!

[1] Истикъбаль – киләчәк.
[2] Бәрбад булмаслар – пыран-заран килмәсләр.
[3] Зәваллы – бәхетсез.

## XI
## Мәлик әз-Заһир китапханәсе

Морадия, Гомәрия, Ишмасия, Шәех Халид вә Габдулла паша китапханәләренең калдыкларын берләштереп, «Мәлик әз-Заһир» төрбәсенә куелганлыгы әйтелеп үтелгән иде. Мәлик әз-Заһирның каберен эченә алган бина гүзәл тарызда[1] эшләнгән. Ишек вә тәрәзәләре зур. Китапханә ясалган бүлмәнең (мәлик әз-Заһирның кабере дә шул бүлмәдә) дивар вә түшәмнәре мозаика берлән зиннәтләнгән. Ләкин бу бина да башкалары шикелле мөсаһәлә[2] җәзасын чигә. Ни вакыттан бирледер, төзәтелмәгән. Ишек, тәрәзәләре пычрак, стеналары тыштан кырылып беткән. Бу бинаның өстәге катында «Нәмүнәи тәрәккый»[3] исемендә бер мәктәп йирләшә икән[4]. Без барганда китапханә ачылмаганлыктан, югары чыгып, мәктәпне тамаша иттек. Сәгать иртәнге сигез булып, таләбәләр барысы да диярлек килеп йиткәне хәлдә, мөдир вә мөгаллимнәрнең килеп йитмәүләренә гаҗәпләнеп, «бәлки тәрәккыйның[5] бер нәмунәсе[6] дә шулдыр», дип чыгып киттек.

Мәлик әз-Заһирнең кабере бүлмәнең нәкъ уртасында икән. Кабер өстенә зур шкафлар куеп, эчләренә китап тутырганнар. Бу китапханәдәге китапларның санын вә нинди фәннәргә караганлыгын искә алып үткән идем. Тәртипсез генә булса да, бер каталог та ясатып куйганнар. Без кергәндә китапханәнең назыйре[7] идәнгә йомшак мендәр өстенә утырып, бик гүзәл бер рәсме хат[8] берлән китаплар күчерә иде. Безне истикъбаль итеп[9], сораган сөалләремезгә ачык җаваплар бирде. Китапларның барысы да диярлек кул язмасы икән. Бәгъзеләре мосанниф[10] вә

[1] Тарызда – ысул белән.
[2] Мөсаһәлә – игътибарсызлык, әһәмият бирмәү
[3] «Нәмүнәи тәрәкъкый» – «Алга китешнең үрнәге».
[4] Йирләшә икән – урнашкан.
[5] Тәрәкъкыйның – алга китүнең, прогрессның.
[6] Нәмунәсе – үрнәге.
[7] Назыйре – мөдире.
[8] Рәсме хат – язу почерк.
[9] Истикъбаль итеп – каршылап.
[10] Мосанниф – китап язучы (автор).

мөәллифләренең[1] үз куллары белән яки аларның шәкертләре тарафыннан язылган. Бу китаплардан бәгъзеләрен Аурупаның мәшһүр китапханәләре дә күчертеп ала икән. Үзенең шундый бер заказ буенча язып утырганлыгы аңлашылды.

Бу аз вакытта без китапханәдән мәшһүр адәмнәрнең кайсыларының кул язулары булганлыгын белү вә алардан бәгъзеләрен алып караудан артык файдалана алмаячагымызны белеп, шуңа керештек вә каталогтан шул хакта бер җәдвәл тәртип итеп алдык. Әүвәлдән таныш булган галимнәрдән берничәсенең рәсме хатларын алып карадык. Бу урында искә алып китәрлеге Ибн Тәймия[2] берлән Ибн Кыям әл-Җузиятьнең рәсме хатлары булса кирәк. Бу ике галимнең рәсме хатлары арасында бик зур аерма бар икән. Ибн Тәймиянең язуы бик болганчык: нокталар да ул кадәр куелмаган; хәрефләр бүлдерелеп, сызылып беткәннәр. Шул сәбәптән аны уку бик авыр. Ибне Кыямның рәсме хаты бик ачык вә бик матур. Хәрефләре язылган хәрефтән бигрәк ташка басылганга охшыйлар. Сүзләре үз-үзләреннән укылып торалар. Әгәр дә язуына карап берәүнең әхлак вә табигатен тәгыйин итү[3] гыйлеме белән бераз таныш булса идем, бу ике галимнең рәсме хатларын тәхлил итеп[4], аларның тәрҗемәи хәлләренә бер нәрсә арттырырга маташып караган булыр идем.

## XII
## Төрбәләр

Мөхтәрәм бер хәзрәтемезнең: «Шамда зур адәмнәр күп, ләкин барысы да үлек. Хале хәяттәгеләре[5] юк» диюе бик дөрестер. Бу шәһәрдә судан кала иң мулчылык булган нәрсә – төрбәләрдер. Кая гына борылсаң да бер коббәгә килеп чыгасың. Кай якка гына барып чыксаң да анда кабер күрәсең. Ул төрбәләрнең эчен-

[1] Мөәллиф – китап төзүче (автор-составитель).

[2] Ибн Тәймия – Әбү Габбас Тәкыйэддин Әхмәд бине Габдессәлам ибн Тәймия әл-Харани (1263 – 1328), дин галиме, мөселман хокуклары белгече.

[3] Тәгыйин итү – билгеләү, ачыклау.

[4] Тәхлил итеп – анализлап.

[5] Хале хәяттәгеләре – терек булганнары, исәннәре.

дә, табигый, искедән килгәннәре вә иснад[1] ителгән адәмнәрнең хакыйкый каберләре булганнары бар. Ләкин бәгъзе бер бик иске дәвернең кешеләренә караган хакыйкый кабер булуы хакында сүз әйтүе авыр булганнары да юк түгел. Мәсәлән, Ибн Тәймия, Ибн Гарәби[2], Сәлахеддин Әюби, Билал Хәбәши[3] шикеллеләрнең каберләрендә шөбһә булмаса да, хәзрәти Яхъя, Зөлкяфил пәйгамбәр каберләрен төртеп күрсәтү йиңел бер эш булмаса кирәк. Өммия җамигының уртасында хәзрәти Яхъя кабере дип күрсәтелгән урын хакында да «дикъкатьне җәлеп итү өчен бер нәрсә», дип сөйлиләр. Җамигъ Өммиянең урынында бик искедән бирле мәсҗед була килгәнлеге вә Шам ислам хөкүмәте кулына күчкәндә анда кәлисә булып, аның яртысы җамигъка әйләндерелгәне вә калган яртысының да Вәлид дәверендә алынып, бүгенге җамигъ бина ителгәнлеге искә алынган иде. Шул җамигъның нигезен казыганда йир астыннан бер табак эченә куелган инсан баш сөяге чыккан вә табакның читенә дә «юхна» дип язылган булган, имеш. Шул вакытта моның хәзрәти Яхъя башы булып-булмавы хакында мөзакәрә булып[4], ниһаять, шул пәйгамбәремезнең башы булуына карар бирелгәндә кабат шул урынга күмелгән, имеш... Ул кабернең хәзрәти Яхъя башының кабере булуына дәлил шулкадәр. Ул баш сөяге нигә хәзрәти Яхъяга нисбәт ителәдер, нигә Юхна исемендәге бер папуаска нисбәтле түгел? Бу соң безнең иске мәдрәсә тәгъбиренчә[5] тәрҗигъ[6] берлән мәрҗигъ[7] булмыймы? Башка иске төрбәләр дә шулай тикшерелсә, күбесе шундый бер нәрсәгә терәлеп калыр иде.

Троицкидан ерак түгел казакъларның «әүлия зиярәте» дип корбаннар чалып, ярдәмнәр бирүен сорап йөргән бер кабернең

[1] Иснад – кемгә дә булса нисбәт ителгән (приписываемый).

[2] Ибн Гарәби – Мөхетдин Мөхәммәд ибне Гали ибне Мөхәммәд ибне Гарәби әл-Әндәлүси (1165–1249), Әндәлүстән (Испаниядән) чыккан, Мисырда яшәгән суфи галим.

[3] Билал Хәбәши – Мәдинәдә Мөхәммәд пәйгамбәрнең төзеткән һәм үзе имамлык иткән беренче мәчетнең мәзине. Элекке кол, кара тәнле эфиоп.

[4] Мөзакәрә булып – фикер алышып.

[5] Тәгъбир – бер мәгънә белдергән фраза.

[6] Тәрҗигъ – кире кайтару.

[7] Мәрҗигъ – кайта торган урын.

бер калмык кызы кабере булып чыкканлыгын сөйлиләр иде. Бүген дә ислам дөньясының төрле урыннарында фәлән шәех, фәлән вәлинең[1] кабере дип күрсәтелгән урыннарның бик күбесе бәлки кабер дә түгелдер. Бәлки берәр мәҗүси, яки башка бер диндәге кешенең кабередер. Әгәр дә мөселманнар андый каберләрдән файда күрсәләр, ул каберләр янына баргач авырулар сәламәтләнсә, башка авырлыклар йиңеләйсә, бу файдалануларның элементлары кабердән чыкмый, бәлки ярдәм сорап баручыларның үзләре берлән бергә бара. Аларның үз күңелләрендәге игътикадларыннан[2] үсеп чыга.

Соңгы елларда Америкада «Мәсих тәгълиматы» исемендә бер мәзһәп барлыкка килде. Бу мәзһәп ияләренең дәгъваларына күрә авырудан дәвалану тиеш түгел, бәлки Аллага ышанырга вә аннан гына ярдәм сорарга тиеш. Алар: «Аллага игътикад итсәңез, барысы да була», – диләр. Шул ышанулары нигезендә күп урыннарда дәгъвалары дөрес тә чыга. Боларда бары тик ышану бар. Кабер фәләнне алар танымыйлар. Алар үзләренең эчке табигатьләрен кабер ташларын күрмичә дә хәрәкәткә китерә алалар. Аларның күңелләре кабер өстенә ятмый да Аллага юнәлә ала. Каберләр янында авыруларның шифа таба алуы вә каберләр өстендә карәмәләр заһир булуы[3] үзләренең барлыкларыннан башка бер нәрсәне дә исбат итә алмый. Бер кабер янында авыру шифа тапса, ул кабер хакында «анда авыру шифа таба»дан артык бер сүз әйтеп булмый.

Шамда искедән килгән кабер аз шикелле Әледән-әле яңаларын кәшеф итә[4] торалар, имеш. Шам бик иске шәһәр булганлыктан, аның утырган урынында йир астында ватык биналар вә чокырларның булачагы табигыйдыр. Шундый берәр урын бераз ишелеп бер тишек хасыйл булды исә, инде ул урын бер вәлинең кабере була. Тишекнең өстен аркылы-торкылы агачлар берлән каплыйлар да бер ак чүпрәккә кабер сахибының исемен вә оҗмахтагы урынын да язып, чүпрәкне кабер өстенә асып куя-

[1] Вәлинең – изгенең.
[2] Игътикадларыннан – ышану, инануларыннан.
[3] Заһир булуы – күренүе.
[4] Кәшеф итә – ачып, мәйданга чыгарып.

лар. Әгәр дә Алланың йомшак күңеллерәк берәр бәндәсе дә килеп чыкса, кабернең өстенә бер коббә дә салына вә шуннан соң мәшһүр бер зиярәтгяһ[1] була да китә. Мондый яңа ачылган каберләрдән берсен үз күзем берлән күрдем. Каберләрне төштә күрү буенча билгеләү дә мөселманнарда сирәк табыла торган нәрсә түгел. Истанбулдагы мәшһүр Әбү Әйюб әл-Әнсари[2] хәзрәтләренең кабере дип күрсәтелгән урында төш буенча гына тәгъйин ителгән[3] диләр.

Шамдагы зиярәтләрнең барысын да зиярәт итеп чыгачак булсак, үзенә генә бер атна вакыт кирәк булыр. Без Мөхетдин ибн Гарәби хәзрәтләренең Сәвика мәхәлләсендә әсхабтан[4] вә әзваҗ мотаһһарәдән[5] бәгъзеләренең вә хәзрәти Могавия[6] берлән Язиднең[7] каберләренә генә зиярәт иттек. «Салихә»гә бер барышымызда мәшһүр «Памук баба»ның аягын да тамаша итеп чыктык.

Сәвика мәхәлләсенең Баб әс-Сагыйр исемендәге каберлектә ошбу кешеләрнең кабере бар, имеш. Билал әл-Хәбәши (рәсүлулланың мәзине), Габдулла бине Җәгъфәр әт-Тайар, Габдулла бине Өммел-Мәктүм, Габдулла бине Зәйгелгабидин, Әбү Габидә әл-Җәрах, Госман бине Гаффан, Әсма бинте Әбүбәкер, Ләйлә бинте Зәбир, Сикинә бинте Хөсәен, Өммегөлсем бинте Гали, Фатыйма бинте Хөсәен; әзваҗ мотаһһарадан Өммехәбибә вә Өммесәлимә, рәсүлулланың җариясе Мәймүнә. Шәех Сәгыйд әл-Халид, шәех Хәсән Җәбави, шәех Әбел Бәйан. Имам Сәрүҗи, хәзрәти Хөсәен берлән Кәрбәлада шәһид булган йиде кешенең

[1] Зиярәтгяһ – зиярәт итә торган урын.

[2] Әбү Әйюб әл-Әнсари – Халид бине Зәйд (672 елда үлгән), Мөхәммәд пәйгамбәрнең тарафдары. Аның барлык походларында катнаша (Бәдер, Өхөд, Хандак һ.б. сугышларда). Мөселманнарның Константинопольгә походы вакытында 80 яшьләрдә үлә. Кабере Истанбул янында. Әнсари – «Мәдинә шәһәреннән» дигәнне аңлата.

[3] Тәгъйин ителгән – билгеләнгән.

[4] Әсхабтан – сәхабәләрдән.

[5] Әзваҗ мотаһһарәдән – изге ирләрдән.

[6] Хәзрәти Могавия – Әбү Габдеррахман Могавия ибн Суфиян әл-Өмәви әл-Корәйши (603–680). 661 елда Гали үтерелгәч, хәлифә дип игълан ителә. Могавия хәлифәтнең башкаласын Багдадтан Димәшкъка күчерә.

[7] Язид – Язид бине Могавия – Өммәвиләр нәселеннән икенче хәлифә (645–683), хәлифәлек еллары (680–683)

башлары да шунда мәдфүн[1], имеш. Бу каберләрнең төрлесе капада[2]. Капалар гүзәл вә мөзәйян[3]. Хәзрәти Могавиянең төрбәсе дип күрсәтелгән кабернеке генә эчендә дә, тышында да зиннәт юк. Бу кабер башкаларныкы шикелле матур шәкелдә шкатурланып ясалмаган, балчык берлән сыланып кына куелган. Читтән караганда кечкенә бер кирпеч сараена охшап тора. Бер барганда каберлекнең төрле йирендә әллә ничә кабер эшләп яталар иде. Эчләрен барып кардык. Күбесенең уртасында известь изелгән бер чокырдан башка нәрсә юк, һичберсенең эче кабер урынына охшамаган. Берәр ел соң барган кеше ул капалар эчендә бераз вакыттан язылган пәрдәләр берлән өртелгән кабер күрәчәк вә быел известь чокыры булган урыннарны киләсе ел мөкаддәс бер кабер дип зиярәт итәчәкләр. Ислам галәмендә әүлияләр кабере менә ничек үсеп чыга.

Күп каберләрнең өсте яшел агачлар вә чәчәкләр берлән зиннәтләнгән, вә бик күпләренең өстенә мөзәйян чатырлар корылган иде. Чатыр корылмаганнарының бәгъзеләренә ефәк яулыклар асылынган. Каберләрне әйләндергән рәшәткәләр эчендә төркем-төркем хатыннар утыралар иде. Каберләр өстендәге чатырларны күргәч, минем башка Чаталҗадагы[4] гаскәрләрнең хәле килде. Бу көндә утыз-кырык миллион бер милләтнең истикъляле[5] вә истикъбале[6] өчен генә түгел, өч йөз миллионлык ислам милләтенең шан вә шәрәфен мөдафәга[7] өчен каннарын түгеп яткан гаскәрләргә ятарлык вә тәннәрен аз булса да суыктан сакларлык чатырлар бармы-юкмы? Ләкин мондагы кабер балчыкларының һәрхәлдә кояш эсселегендә зәхмәт чигү ихтималлары юк икән дип уйладым. Шул хакта менә шул каберлектә

[1] Мәдфүн – җирләнгән.

[2] Капа – капка, ишек биредә: һәр кабер өстендәге аерым төрбә һәм аның ишеге күз алдында тотыла.

[3] Мөзәйян – зиннәтләнгән, бизәлгән

[4] Чаталҗак – Төркиядәге шәһәр.

[5] Истикълял – бәйсезлеге.

[6] Истиiъбале – киләчәге.

[7] Шәрәфен мөдафәга өчен – данын саклар өчен.

танышкан бер төрек хатибына[1] сөйләдем. Хатиб әфәнде: «Әвәт[2], әфәндем, шулай. Ләкин кайберләргә алай чатырлар корып, аларны чәчәкләр берлән зиннәтләү бер гадәт кенә. Чатырлар анда даими калмыйлар. Берничә көннән соң алыналар», – диде. Бу сабикъ[3] хатиб берлән Билал әл-Хәбәшинең[4] каберендә очрашкан идек. Төрекләр бик нәзакәтле булалар бит. Ул безнең бөтен каберлекне йөреп чыгачагымызны белгәч, үзенең безгә иптәш булып, күрсәтеп йөриячәген вә безнең берлән «гизмәк шәрәфенә наил улдыгыннан[5] тулаем фәүкылгадә мәсрүр[6]» улдыгын әйтте. Бергә киттек. Юлда хуҗа әфәнде үзенең тәрҗемәи хәлен сөйләде. Үзенең бер вакытта Истанбулда имам булып торганлыгын һәм шул вакытта милләткә файда китерү өчен бик күп тырышканлыгын, ләкин манигъларга[7] очравы сәбәпле тырышканлыкларының берсе дә тормышка ашмавын сөйләде. Шулкадәр көчле бер һиммәт[8] берлән тәшәббес иткәне[9] хәлдә хуҗа әфәнденең муафыйк була алмавына гаҗәпләндек. Сәбәпләрен ишеткәч, сөйләгән нәрсәләренең сиксән проценты үз файдасы өчен генә тырышкан нәрсәләр икәне аңлашылды.

Бераздан соң имам әфәнде сүзне каберлекләргә күчереп: «Әфәндем, шул каберлекләргә бер күз салыңыз. Һәр йирендә игътинасызлык[10] күренеп тора. Башка милләтләр исә каберләрен мөмкин кадәр мокаддәс вә кадерләп саклыйлар. Протестантлар ул яктан мөмтаз булсалар кирәк», – диде.

Моңа җавап итеп мин: «Әгәр дә игътинасызлыгымыз үлекләремез хакында гына булса иде, Аллага мең шөкерләр итәр идек. Ләкин безнең төрекләрдә истикъбаль адәмнәре булачак

[1] Хатиб – вәгазь сөйләүче.

[2] Әвәт – әйе.

[3] Сабикъ – үткән юлы очраган.

[4] Билал әл-Хәбәши – Мәдинәдә Мөхәммәд пәйгамбәр төзеткән һәм үзе беренче имамлык иткән мәчетнең мәзине.

[5] Шәрәфенә наил улдыгыннан – бәхетенәирешүеннән.

[6] Фәүкылгадә мәсрүр – гаять шат.

[7] Манигъларга – каршылыкларга.

[8] Һиммәт – тырышлык.

[9] Тәшәббес иткәне – керешкәне.

[10] Игътинасызлык – игътибарсызлык.

балаларымыз да ташландык хәлдә. Милләтләрнең сәгадәтендә иң мөһим роль уйнаган нәрсә – ибтидаи мәктәптер. Гаҗәп, бездә шуңа бераз булса да әһәмият биреләме? Безгә ләтыйф бу мәмләкәттә бер монтазам[1] ибтидаи мәктәпләр вөҗүденнән[2] хәбәр биреңез. Без мөселманнарны каберләргә әһәмият бирүдә артык киткәннәр дип беләмез. Менә шушы каберләрдә булган коббәләргә сарыф ителгән парәләргә[3] Шамда бер ибтидаи мәктәп бина ителгән булса иде, никадәр гүзәл булыр иде. Туфрак астында яткан сөякләрнең ул биналарга бер дә ихтыяҗлары юк. Ләкин йир өстендә йөргән җаннарга мәктәпнең әһәмияте аш-су дәрәҗәсендәдер. Бүгендә бер милләтнең бәка вә сәгадәте[4] шуңа терәлеп тора. Мәдәни милләтләр каберләргә әһәмият бирсәләр дә, үзләренең тәназыг бәка[5] мәйданнарындагы урыннарын тәэмин иткәч кенә бирәләр. Аларның ул әһәмият бирүләре дә ислам галәмендәге шикелле килеп ярдәмнәр сорау вә кабер сахибләрен Алла берлән үз араларында васита[6] ясау өчен түгел. Алар аны бары дөньяви эшләренә корал итү өчен эшлиләр. Зур адәмнәрнең каберләренә биналар салып, аларга тамашалар куюлары балаларына рух бирү вә аларга хезмәт иткән кешеләргә ихтирамның ни дәрәҗәдә икәнлеген күрсәтеп, аларны да хезмәткә кызыктырудыр... Мөселманнар шушы кабергә гыйбадәтләренең кайда барганын аңласалар...» Хатиб әфәндегә рәхмәтемне югарыда язылганның бер мисалы: моңа кадәр сөйләгәнемне бүлми тыңлап бара алды.

Бу вакытта без баш каберлектән чыгып, юл читендә булган Язиднең каберен эзләп киткән идек. Юлга килеп чыккач, ишәк йитәкләп баручы бер гарәптән: «Язиднең кабере кайда?», – дип сорадык. Гарәп бер сүз дә әйтми, йирдән бер таш алды да: «Алла каргаган Язид, хинзир[7]», – дип бер йиргә атты да юлына дәвам

[1] Монтазам – тәртипле, яхшы, рәтле.
[2] Вөҗүденнән – барлыгыннан.
[3] Парәләргә – акчаларга.
[4] Бәка вә сәгадәте – яшәве һәм бәхете.
[5] Тәназыг бәка – яшәү өчен көрәш.
[6] Васита – арадашчы.
[7] Хинзир – дуңгыз.

итте. Аның таш аткан урынын карадык. Өстенә иске тимер вә башка чүп-чар өелеп яткан бер өем таш. Без аны әүвәлдә дә күргән идек. Ләкин әүвәл бер кабер дип уйламаган идек. (Ихтимал ки, кабер дә түгелдер.)

Язид кабереннән шәһәргә борылгач, сөйләү хуҗа әфәнде нәүбәте икәнен белеп, сүздән туктадык. Хуҗа әфәнде намаздан сүз ачты. Үзе бу көннәрдә мөрәттәб[1] укый алмаса да, укырга тиеш дип игътикад иткәнлеген[2] аңлатты.

Мин:

– Соң сез фигыльдә[3] инкарь итү берлән игътикадта инкарь итү арасында аерма табасызмы? – дидем.

Соңра ул хәшердән[4] сүз ачып:

– Вольтер[5]: «Әгәр дә хәшер ялган булып чыкса, мин бер дә гаеп итмим. Ләкин тугры булып чыкса, дәһриләргә ни зур үкенеч дип әйткән, – диде. Без:

– Ул сүзне башлап сөйләүче – ислам философы имам Мәгарридер[6]. Әгәр Вольтер ул мәгънәдә бер сүз сөйләгән булса, ихтимал, Мәгарридән икътибас иткәндер[7]. Чөнки Мәгарри Вольтердан биш-алты гасыр элек килгән. Әгәр Вольтер аны үзеннән чыгарып сөйләгән булса да фазыйләт[8] Мәгарригә гаидтер[9]... – дидек. Хуҗаның минем бер ислам философын бер гареб[10] философыннан алга чыгарырга тырышуга бик кәефе килде. Бу вакытта шәһәргә дә килеп йиткән идек. Карта визитларымызны вә отель адресларымызны бирешеп аерылыштык...

---

[1] Мөрәттәб – тәртипле рәвештә.

[2] Игътикад иткәнлеген – инанганлыгын.

[3] Фигыльдә – эштә, гамәлдә.

[4] Хәшер – ислам динендә үлекләрне тергезеп бер җиргә туплау, җыю.

[5] Вольтер – Аруэ Франсуа Марш Вольтер (1694–1774), француз философы, язучы-сатирик, тарихчы, мәгърифәтче.

[6] Мәгарри – Әбел-Галә әл-Мәгарри (973–1058), гарәп шагыйре, философ.

[7] Икътибас иткәндер – алгандыр, файдалангандыр.

[8] Фазыйләт – өстенлек.

[9] Гаидтер – карый, бирелә мәгънәсендә.

[10] Гареб – көнбатыш.

## XIII
## Ибн Гарәби төрбәсендә

Бу затның төрбәсенә барырга җомга көнгә калдырган идек. Төрбәләр җомга көнне ачык булганлыктан, ул көнне зиярәт итүчеләр күп була. Бик зур галимнең кабере гүзәл бер җамигъ янында йир астынарак төшереп эшләнгән бер бүлмәдә. Эче мөзәйән, идәннәренә келәмнәр түшәлгән, тәрәзәләреннән салкын җил уйнап тора. Эссе көннәрдә ятып ял итү өчен дә бик уңайлы бүлмә икән. Без кергәндә дә, кыйбла тарафына башларын куеп сузылып йоклап ятучылар бар иде. Коббәнең әтрафын хатын-кыз, бала-чага әйләндереп алган. Чыр-чу килеп, Коръән укып, балалар берлән сугышып утыралар иде. Сахибе кабер рухының бу тавышлардан ни дәрәҗәдә истирахәт иткәнен вә аның шикелле хәрәкәтләрдән ни дәрәҗәдә риза булачагын уйлап, кабернең пәрдәсенә язылган язуларны бер күздән кичердек тә бу хатын, бала-чага хаосыннан тизрәк чыгып китүне карадык.

## XIV
## Памук баба

Бу затның кабере хакында Шамга бармастан борын бераз нәрсә ишеткән идем. Хакыйкатьтә гаҗәпләнерлек бит: кабердә яткан бер кеше аягын күрсәтеп ятсын, имеш. Вә никадәр мамык берлән күмеп куярга тырышсалар да мамыкны тибеп йибәрсен, имеш. Андый бер адәмнең «әүлия»легеннән шөбһәләнергә урын күп түгел. Куңелгә: «Нигә соң аны балчык белән күмеп карамыйлар икән, мамык йиңел нәрсә, бәлки аны җил очыра торгандыр», – дигән фикернең килүе мөмкин. Һәр ни исә бер көнне шул Мамык бабаның төрбәсен эзләп киттек. «Салихия»нең көнчыгышында көрдләр мәхәлләсе дигән урында икән, чынлыкта бу адәм үзе дә көрд. Өстенә «Памук баба төрбәсе» дип язылган кечкенә пычрак бер капкадан кереп, тугры алдымызда күренеп торган кечкенә бер бинага бардык. Кабере шул бинаның эчендә икән. Күрше генә яткан ике кабернең берсе аяк сахибе салих[1]

[1] Салих – изге.

Әйюб әл-Көрдинең, диделәр. Каберләрнең өсте көймәләндереп таш берлән әйләндереп куелган. Вә берсенең бер башыннан кечкенә бер тишек тә калдырылган. Шул тишекле Мөхәммәд Әйюб әл-Көрдинең кабередер[1]. Аннан караганда көймәнең икенче башында кечкенә генә, кеше аягына ул кадәр охшап та бетмәгән кап-кара бер аяк, ярты кадәрле мамык арасыннан чыгып күренеп тора. Зиярәт итүчеләр килгәч, шәм ягып көймәнең эченә сузалар...

Ишектән кергәч тә беренче күз төшкән нәрсә баулары мамыкка буялып беткән бер үлчәү булды. Бердән, ошбу үлчәүдән, икенчедән, бер якка өелеп яткан мамыктан. Монда мамык сәүдәсенең тәрәккыйдә булганын[2] аңладым.

Зиярәт итүчеләр бабай көймәсендәге мамыкны «бабаны тәбрикләү өчен» алалар, имеш тә, шуларның урынын тутырыр өчен мамык кирәк була, имеш. Үзе «потлап алган мамыкны мыскаллап[3] саткан» кабер сакчысы шулай файда күрә, имеш.

Бу аяк белән мамык сәүдәсенең кәрамәт вә изгелек берлән мөнәсәбәте булмаганлыгын белгәннәре хәлдә, моның зоһурына[4] сәбәп сораучылар, бигрәк тә аның бүгенгәчә дәвам итүенә мөсагадә[5] бирелүгә гаҗәпләнүчеләр бәлки булыр. Шулар өчен ул тугрыларда бер-ике сүз әйтеп, бу үлекләр галәменнән тизрәк чыгып китәргә телим. Халык арасында сөйләгән хикәя вә кыйссалардан да бер вакыйганың асылы хакында бер фикер хасыйл итү авыр түгел. Бер нәрсәнең хакыйкатенә төшенү, ачыклау өчен, аның хакында сөйләнгән хикәятләрне тәхлил итеп[6] карау – иң ышанычлы юлларның берседер. Мамык баба аягына да шушы ноктлардан бер күз салыйк.

Бер вакытны бер көрд берлән бер гарәп бәхәсләшкәннәр, имеш. Гарәп «Көрдләрдә әүлия юк» дип, иптәшен кимсетмәкче булган икән. Шул сәгатьтә Мамык баба аягын күтәреп йибәргән!

---

[1] Мөхәммәд Әйюб әл-Көрди (Памук баба дип мәшһүр) – Урта гасырларда яшәгән дин галиме, танылган суфи. Чыгышы белән көрд.

[2] Тәрәккыйдә булганын – «чәчәк атуын», ягъни активлыгын.

[3] Мыскал – элек замандагы үлчәү берәмлеге, якынча 4,26 граммга тигез.

[4] Зоһурына – килеп чыгуына, күренүенә.

[5] Мөсагадә – мөмкинлек, рөхсәт.

[6] Тәхлил итеп – анализлап.

Бу кыйсса Мамык баба аягының асылын яхшы күрсәтсә кирәк. Монда каблә татбикъ[1] булмаган бер генә нәрсә бар ки, ул да булса, бәхәсләшкән дәкыйкадә[2] Мамык бабайның аягын чыгаруыдыр. Монысы инде йә кайд[3], йә нәкыль[4] хатасыдыр. Ул аяк һич булмаганда өч-дүрт көннән соң заһир булган[5] булыр. Көрдләр бу кыйссаны Мөхәммәд Әйюб әл-Көрдинең мәңгелек кәрамәт сахибы булуын исбат итү өчен зур бер ифтихар[6] берлән сөйлиләр, имеш. Ләкин ул аякның сонгый[7] булуын исбат өчен – аны тотып карарга рөхсәт ителмәгән вакытта – моннан да куәтле бер дәлил булмаса кирәк.

Аның бүген дә шулай дәвам итүенә ни өчен юл куела? Ни өчен эш башындагы затлар, галимнәр халыкка аны аңлатып, аларны хорафат коллыгыннан чыгарырга тырышмыйлар? Мамык баба кабере Аурупада йә Америкада булса, бу «ни өчен»нәр килер иде. Ләкин мөселман эшендә «ни өчен» юк. Ул эшли, ләкин эшеннән үзенә хисап бирми.

Ни өчен эшләгәнен үзе дә белми. Башка милләтләр тәрәккыйга тырышып ятканда, мөселманнар үзләрен һәлакәт вә инкыйраз чокырына өстериләр. Ни өчен? Бер ислам әмире бөтен дәүләтен вә милләтен бер әҗнәби хөкүмәткә сата. Ни өчен? Дистәләп ислам әмирләре бер аурупалы хөкемдар алдына егылып сәҗдә кылалар. Ни өчен? Бөтен дөньядагы милләтләр иттифакка килергә тырышып ятканда, мөселманнарның егермесе утызга аерыла. Ни өчен? Башкалар милләте өчен малын вә җанын фида иткәндә[8], мөселманнар шәхси мәнфәгатьләре өчен милләтләрен, ватаннарын фида итәләр. Ни өчен? Башкалар күктән оча башлаган бер вакытта, мөселманнар йирдән дә бара алмый. Ни өчен? Башкалар мәмләкәтләрен дарелфөнүн берлән тутырган вакытта, мөселманнарда юньле ибтидаи мәктәп тә

[1] Каблә татбикъ – алдан килештерү.
[2] Дәкыйкадә – минутта.
[3] Кайд – язып куючы.
[4] Нәкыль – телдән телгә сөйләүче.
[5] Заһир булган – күренгән,пәйда булган.
[6] Ифтихар – мактану, горурлану.
[7] Сонгый – ясалма.
[8] Фида иткәндә – кызганмаганда, корбан иткәндә.

юк. Ни өчен? Болар вә башка очсыз-кырыйсыз «ни өчен»нәр барсы да җавапсыз. Мамык баба «ни өчен»е дә – шуларның берседер. Шамда хакыйкый аяк сахибы булган каберләр дә аз түгел. Андый балчык аякларга бездә лөзүм[1] юк иде дә бит, ни эшлисең соң?

## XV
## Җәбәл Касиюнда кырыклар мәкаме

Каберлек галәменең хатимәсендә җәбәл Касиюндагы «кырыклар мәкаме» берлән аның башыннан агып төшеп килгән Һабилнең канын зикер итеп кую бик үк мөнәсәбәтсез булмаса кирәк. Шамның шималендә[2] булган бу тауның башыннан киртләчләнеп яткан бер кызыл ташлык бар. Ул һабилнең каны, имеш. Канның ташка әйләнүе биология ноктаи нәзарыннан[3] мөмкинме-түгелме, анысына катыша алмый. Шул киртләчлеге ташлыкның янында бер бина да бар. Аның эчендә бер мәгарәдә күзгә бик охшаган бер тишектән су тамып тора, имеш. Күзнең янында авызы да вә авыз эчендә тешләре дә бар, имеш. Күздән тамган су шул тауның күз яше, имеш. Ул Һабилнең үтерелүенә шулай кыяматкә кадәр елап торачак, имеш. Бу мәгарәне үз күземез берлән күрә алмадык. Чөнки без барганда, аның капучысы килмәгән иде. Бинаның бер тарафында ат абзары шикелле сузылып киткән бер бүлмә бар. Аның кыйблага караган диварына кырык михраб эзе ясап куйганнар. Михраб эзеннән уртадагы берсе башкаларыннан күп зур. Бу бүлмә – кырыклар мәкаме, имеш. Уртадагы зур михраб та имамнарының михрабы вә калганнары җәмгыять әгъзаларының калганнарына махсус, имеш. Имам михрабына килгән бер кеше чүпрәк кисәге асып китә булса кирәк. Чөнки анда асылып торган чүпрәк кисәкләре санап бетергесез.

[1] Лөзүм – ихтыяҗ, кирәклек.
[2] Шималендә – төньягында.
[3] Ноктаи нәзарыннан – теориясе ноктасыннан.

## XVI
## Мәүләвиләр тәкиясендә

Бер көнне мәүләвиләр[1] тәкиясен[2] тамаша итәргә киттек. Тәкия шәһәргә якын. Хөкүмәт кунагының артында гына. Елга буена агачлыклар арасына салынган. Шамның иң гүзәл урынында диярлек. Мин күргән өч шәһәрдә (Истанбул, Шам, Траблис-Шам[3]) бу тарикать[4] әһелләренең тәкияләре иң гүзәл урынга салынганнар. Аркадашларымыздан берсенең сөйләвенә күрә, башка шәһәрләрдә шулай, имеш. Мәүләвиләр бу хәлне тарикатьнең мөәссисе[5] Җәлалетдин Руми[6] хәзрәтләренең фатихасына хәмел итәләр[7], имеш. Ихтимал, шулайдыр. Ләкин «Бу тарикатьнең әһле сәрвәт[8] каршында бик кадерле көннәре булган булса кирәк» диеп тә уйга килә.

Капкадан кергәч тә озын киез бүрек кигән берәү, дәрвишме диим, каршы алып, яр читенә салынган бер беседкага алып барып утыртты. Гыйбадәтләренең икенче көнне өйләдән соң булачагын аңлагач, тәкияне тамаша итәргә рөхсәт алдык. Тәкияне бер яктан каплап торган бу агачларның күләгәсенә төшеп карап йөри башлагач, дикъкатемне җәлеб иткән беренче нәрсә – үземнең Сакмар буйлары искә төште. Чөнки балчыгы аксыл, агачлары өянке вә усак. Елганың чите таллык, агач төпләренә кычыткан, көрән, бер зәңгәр чәчәкле исле үлән, бөрлегән сабагы... үскән.

---

[1] Мәүләвиләр – Җәлалетдин Руми юлына иярүчеләр, ягъни дәрвишләр, суфичылар.

[2] Тәкия – мөридләрнең ишан кул астына зекер әйтү өчен җыелып утыра торган урыннары.

[3] Траблис-Шам – хәзерге Ливан территориясендә урнашкан Триполи шәһәре.

[4] Тарикать – дини юнәлеш.

[5] Мөәссисе – башлап нигез салучысы.

[6] Җәлалетдин Руми – Мәүляна Җәлалетдин әр-Руми (1207–1273), Әфганстанда Бәлх шәһәрендә туган фарсы телле суфи шагыйрь. Суфи-дәрвишләр җәмгыятен барлыкка китерә. Кабере Төркиянең Конья шәһәрендә.

[7] Хәмел итәләр – юрыйлар.

[8] Әһле сәрвәт – байлык, мал ияләре, ягъни бай кешеләр.

Нәкъ Сакмар буе агачлыкларының суга якын җирләрендә табыла торган бер табигать.

Икенче көнне өйлә вакытында бардык. Капка төбенә полиция куелган, керергә теләүчеләрне кертмиләр. Бу хәлгә гаҗәпләндек. Шулай да безгә бер сүз дә әйтмәделәр, кереп киттек. Без кергән шәехнең салонында кеше күп вә тәкиянең каһвәчесе дә йөгерә-йөрә наргилә[1] вә каһвә ташып тора иде. Полиция куелуның сәбәбен бераздан аңладык. Күп тә үтмәде бөтен әркяне[2] берлән вали[3] килеп керде. Аны каршы алып түргә уздырдылар вә бик тизлек берлән наргилә вә каһвәләр тәкъдим ителде.

Каһвәләр эчелеп, наргиләләр тартылып тәмам булганның соңында, зекер әйтелә торган урынга китә башладылар. Без галәбәлектән[4] качып, бераз соң бардык. Әүвәлге көнне безне гиздергән шәех (дәрвиш) ишек төбендә тора икән. Безне югарыга алып менеп, курай уйнаучы вә барабан сугучылар янына утыртты.

Зекер бүлмәсе җамигъ тарызындарак[5] эшләнгән. Уртасын цирклардагы шикелле итеп әйләндереп алганнар. Ул түгәрәкнең тышкы ягында урындыклар, түр тарафына йомшак кәнәфиләр тезгәннәр. Намаз тәмам булгач, кунаклар, дәрәҗәләренә күрә, шул кәнәфи вә урындыкларга утырдылар.

Заирләр[6] эчендә валидән башка Шам ардусы куманданы[7] паша да бар иде. Мәлики[8] вә гаскәри ике зур мәэмүр ике сәгать буе бераз мәгънәсез кычкырыш, йөгереш вә сикерешләргә башларын селкеп утырып киттеләр. Кумандан паша моның өчен гафу ителер дә, гаскәре Чаталҗага алынып беткән бу пашаның, ихтимал, шундый йирләргә барып баш селкүдән гайре эшләре юктыр. Ләкин валигә ни әйтергә кирәк? Дәүләте кыл өстендә генә торган вә күршесе генә булган Бәйруттә әһали ислах сорап, кибетләр

---

[1] Наргилә – кальян.
[2] Әркяне – свитасы.
[3] Вали – губернатор.
[4] Галәбәлектән – шау-шудан.
[5] Җамигъ тарызындарак – мәчет рәвешендәрәк.
[6] Заирләр – күрергә, карарга килүчеләр.
[7] Ардусы куманданы – гаскәре башлыгы.
[8] Мәлики – дәүләт җитәкчелегенә караган.

ябып яткан вә Шамның үз газеталары да ул ислах хәрәкәтен кабартып вә күпертеп язган вакытта мәүләвиләр тәкиясенә барып ике-өч сәгать вакытын зая итеп кайту бер валига гафу ителерлек түгелдер. Мондый вакытларда вали шикелле мәмләкәтнең бер кыйсьменең язмышын үз кулында тоткан бер мәэмүрнең секундлары мең алтыннан кадерлерәк. Әгәр дә вали ул вакытын бер таҗир[1] тарафыннан таләп ителгән ислахатларны иҗра итү[2] чараларын уйлап үткәргән булса иде Бәйруттагы хәрәкәтнең Шамга килеп йитмәвенә вали ничек имин булган? Әгәр дә булмаса шушы бер яклы итүнең чараларын төшенергә тиеш түгел идеме? «Иттихад вә тәрәккый» эше башына чыккач, Сүрия вилаяте шикелле мөһим бер урынга тәгъйин ителеп[3] садре әгъзам[4] вә дахилия назыйрыннан[5] «Тәгълимат вә тәүсыя»лар[6] алып килгән бер вали шулай хәрәкәт итәргә тиешле идеме соң? Бу мәмләкәтнең инкыйразын шундый мәэмүрләр[7] хәзерлиләр. Мәэмүрләре канунга түгел, кәефләренә табигъ булган[8] – эш башындагы адәмнәре гакылларын түгел, хисләрен рәһбәр[9] итеп тоткан бер дәүләт нинди могҗиза аркасында инкыйраз булмасын?...

Кунаклар кәнәфи вә урындыкларга утыргач, дәрвишләр дә түгәрәкнең эченә хилкаланып[10] төзелгәч, безнең янда сәндерәдә утырган берсе бик озын сузып, көйләп бер нәрсә укый башлады. Озакламый аңа янында утырган бер картның бик моңлы курае да кушылып китте. Күп тә үтмәде барабаннар да даңгыр-доңгыр, чатыр-чотыр итеп сугыла башладылар. Барабан сугыла башлагач та, түгәрәкләнеп утырган дәрвишләр сикереп торып, берсе артыннан берсе акрын гына әйләнеп йөри башладылар. Шулай берничә минут йөргәч, шәех туктады. Аның артыннан башка-

[1] Таҗир – сәүдәгәр.
[2] Иҗра итү – үтәү.
[3] Тәгъйин ителеп – билгеләнеп.
[4] Садре әгъзам – баш вәзир (премьер-министр).
[5] Дахилия назыйры – эчке эшләр министры.
[6] «Тәгълимат вә тәүсыя» – «Күрсәтмәләр һәм киңәшләр».
[7] Мәэмүрләр – чиновниклар.
[8] Табигъ булган – буйсынган.
[9] Рәһбәр – юл күрсәткеч.
[10] Хилкаланып – түгәрәкләнеп.

лар да өстке җөббәләрен салдылар вә бию киемендә генә калып, әйләнергә хәзерләнделәр. Боларның биергә башлап китүләрен тасвир итүдән элек, аларның бию киемнәре хакында бер-ике сүз әйтеп китүне тиешле табам.

Бу тарикать әһеленең биегән вакытта кия торган киемнәре, Русиядәге авыл теле белән әйтсәң, бер кыска сарафан берлән бер бик киң бөрмәле юбкадан гыйбарәт. Башларында, үзләренә махсус, сарык йонынннан басылган биек бер фәс. Юбкалары, бермәсе күп булу җәһәтеннән, шансонеткаларның итәкләренә охшый. Бии башлагач, шансонеткаларның итәкләре ничек түгәрәкләнеп әфкый (горизонтально) күренсә, дәрвишләрнең итәкләре дә биегәндә шуңа якын.

Биючеләр шул киемнәре белән генә калгач, уң кулларын сул йилкәләренә вә сул кулларын уң йилкәләренә куеп, бераз алга таба бөкерәеп, берсе артыннан берсе, акрын гына, туктап торган шәехнең алдыннан үтә башлыйлар. Шәех янына йиткәч, башларын бераз ияләр дә, аның алдыннан тиз генә бер адым берлән атлап чыккач, кире әйләнеп шәехкә тагын бер баш иеп, юлларына дәвам итәләр иде. Шул рәвешчә берничә мәртәбә әйләнгәч, шәехнең алдына барып, башларын түбән салындырып туктадылар. Шәех аларны берәм-берәм йилкәләреннән үбеп чыкты. Шәехтән үбелгән берсе әйләнергә керештеләр. Баштарак акрын гына куллары йилкәләренә куелган хәлдә генә әйләнделәр. Ул вакытларда аяклар да акрын гына хәрәкәт итә, итәкләре дә ул кадәр кабарып китми иде. Ләкин соңга таба шулкадәр шәп әйләнә башладылар ки: аякларына күз иярми башлады. Итәкләре дә зонтик шикелле кабарып китте.

Бу вакытта куллары да югары күтәрелгән, башлары да артка табаауган иде. «Музыкантчылар» да бию көенә охшашлырак бер көй уйный башлаганнар иде. Бераздан соң шәех үзе дә кушылып әйләнә башлады. Ләкин шәехнең әйләнүе акрын вә киеме дә бию киеме түгел иде. Бераздан соң музыка туктады. Биючеләр дә туктадылар. Шәех әүвәлге урынына килеп, кычкырып төрекчә дога кыла башлады.

Бу зиярәттә миңа иң тирән тәэсир калдырган нәрсәләрдән берсе дә ошбу шәехнең шәхесе булды. Ул бик таза вә гаять мәһабәт

бер кеше. Аңарга мәүләвилекнең риязыйятләре[1] бер дә тәэсир итмәгән – чиертсәң битеннән кан чыгарга тора. Башында яшел чалма вә өстендә бик килешле тегелгән күк җөббә. Аның бөтен вөҗүде вә хәрәкәте башкалардан итагать[2] кенә теләп тора. Бу шәех, җөббәсенең бер читен тотып, мөридләре арасында акрын гына әйләнә башлады. Күз алдыма Ассурия вә Бабил руханиларын китергән шикелле булды. Аның соңында, туктап, әмранә бер тарызда[3] киң йиңнәрен салындырып дога кыла башлавы да Зароастраны исемә төшерде. Минем ни Ассурия вә Бабил руханиларының рәсемнәрен күргәнем юк, ни Зароастраның тәгълиматыннан хәбәрдар түгелмен. Шулай була торып та, бу мәүләви шәехнең шуларны исемә төшерүен үзем дә аңлый алмыйм.

Биючеләр барысы уннан артык иде. Күбесе ир уртасындагы кешеләр. Араларында яшь кенә ике бала да бар иде. Бу ике баланың ун-унике яшьләрендәге берсе, төс вә кыяфәтенә караганда, шәехнең мәхдүме булырга кирәк. Мин барсыннан бигрәк шул ике баланы кызгандым. Без аларны ишегалдында очратып бераз сөйләшкән идек. Һәр икесе үткен вә талантлы балалар. Битләрендә хәят вә өмид уйнап тора. Яхшы тәрбия бирелсә, кем белә, бәлки алар Сүриянең Бисмаркы[4] кебек булырлар иде. Ләкин ул бичаралар табигатьләре (характер) ясала торган бу дәүләттә мәгънәсез генә түгел, зарарлы бер нәрсәгә өйрәteләләр. Аларның истигъдадлары сәләтләре бетерелә, үтерелә. Алар киң дөньяда, якты кояш астында, тәмиз мәктәпләрдә фән һәм гыйлем нуры берлән хәяткә хәзерләнәчәк урында, алар каберләр берлән ихата ителгән караңгы бер подвалда бөтен кешелек һәвәсләрен югалтып, ялкаулык вә тилелек үрнәге булырга хәзерләнәләр. Менә шуларны күргән бер кеше «Ислам дөньясының инкыйразында мөселманнарның эшлексез вә җаһил булып калуларында зур эш күргән гамәлләренең берсе – дистәләп саналган шундый

[1] Риязыйят – ашау-эчүдә читләнү, ябыгу.

[2] Итагать – буйсыну, күндәмлек.

[3] Тарызда – кыяфәттә.

[4] Бисмарк – Отто Эдуард Леопольд фон Шенкаузен Бисмарк ((1815–1898), кенәз, сәясәтче, дәүләт эшлеклесе. Германия империясенең беренче канцлеры.

тарикатьләрдер», дигән бер фикергә килсә, ул кеше бу фикерендә хаклы.

Бу көндә тормыш шулкадәр каршылыклы вә аның таләпләре шулкадәр күп, хәят иҗтимагыя[1] мәйданындагы урыныңны саклап, башкалардан калышмый бару өчен, хәятнең тәкъдим иткән мәсьәләләрен хәл итү өчен куәтле баш вә таза фикер, соңгы икене кулда итү өчен дә, сәламәт бәдән кирәктер. Мәдәни милләтләр шушыны игътибарга алып, кешенең тәнен, гакылын, фикерен балалыктан тәрбия итүгә күп әһәмият бирәләр. Мәктәпләрендәге тәрбияләрен мөмкин кадәрле хәяткә якын итәргә тырышалар. Алар арасында мәзһәбләр[2], мәсләкләр мәйданга чыкса, шул нокталардан чыга. Алар бер-берсе берлән шул мәйданнарда әдәби сурәттә тартышалар. Берсе бер тәртипне, нәзарияне[3] алга сөрә. Икенчесе башка берне тәкъдим итә. Ахырда файдалырак табылганын барысы да кабул итә. Бездә исә таш санауныңмы, яки кулны югары күтәреп әйләнүнеңме, яки кул тотышып сикерүнеңме Аллага якынрак китерәчәге хакында ихтиляф итешәләр[4]. Кешене хәяттән вә дөньядан ераклатуның иң мөәссәр[5] чараларын эзлиләр. Берәүнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан ихсан ителгән сәламәт гакылын вә таза бәдәнен эшлектән чыгарырга тырышалар. Алар өчен тәкияләрнең эче берлән мәнсуб булган[6] шәехе даирәсеннән башка дөнья юк. Алар өчен бу дөньямыз рәхәтлек түгел, зиндандыр. Алар өчен ахирәттәге урын дөньядагы сәгый[7] вә гайрәт нисбәтендә түгел, бәлки тәкияләрдәге җәһаләт вә гаталәт нисбәтендә. Алар өчен тәкияләрдә сөйләгән сүзләрдән мөкаддәс сүз юк. Сәгый вә иҗтиһад тәрәккыйның беренче баскычларыннан булганлыктан, «Тарикатьләр инкыйразында зур гамәл иде», диярг юл булса кирәк.

[1] Хәят иҗтимагыя – иҗтимагый тормыш.
[2] Мәзһәбләр – тоткан юл, карашлар.
[3] Нәзарияне – теорияне.
[4] Ихтиляф итешәләр – дау, ызгыш бәхәс чыгаралар.
[5] Мөәссәр – йогынтылы, тойгылы.
[6] Мәнсуб булган – билгеләнгән.
[7] Сәгый – тырышу, тырышлык.

Меңнәрчә кешенең гакыл вә фикерләрен әсир итеп тотарлык бу хасият тарикатьләргә кайдан килгән? Аларның мәңгелек сәгадәткә тугры вә имин юл булуы шөбһәсез дәрәҗәгә килгәнме? Бүген тарикать әһелләренең берсе берлән моназарә итсәң, ул сиңа үз тарикатенең файдалылыгы яки кирәклеге хакында гакыллы дәлилләр китерми яки китерә алмый. Бәлки шул тарикать мөәссисенең[1] зур галимнәрдән булуын гына күрсәтә. Аның файдалылыгы вә турылыгы хакында шөбһәләнүгә юл юк. Әһле тарикать кулында бердәнбер булган бу дәгъва – бер тарикатьнең файдалылыгына китереләчәк дәлилләрнең иң зәгыйфедер. Тарикать мөәссисләренең зур галимнәрдән булуы, аларның мәсләк вә мәдхияләренең заман ахырына кадәр дәвам итүенә бер дә мөстәлзим[2] түгел. Ул галимнәр газизи вә мөхтәрәмдер, ләкин бер милләтнең хәят вә бәкасы[3] алардан да мөхтәрәм. Андый хәрәкәтләр мөәссисләре заманында, ихтимал, файдалы булгандыр. Ул вакыттагы халыкның әхваль рухиясе ислах вә аларның табигатьләрен күтәрү өчен бәлки шундый гамәлләргә ихтыяҗ күрелгәндер. Бүгендә исә алар, файдасыз гына түгел, зарарлы булганлыктан, ташланырга тиешле.

Тарикать сахибларының мөридләре хәтта моны аңламаган булуын исбат итү дә авыр. Ихтимал, аларның максатлары кешене бераз мәгънәсез хәрәкәтләргә этәрү булмагандыр. Ләкин аларның мөридләре шәехләренә булган мәхәббәтләреннән әллә ниләр арттырып бетергәннәрдер.

Үткән ел кадер кичәсендә Бәйрутның иң алдынгы җамигы булган җамигъ Гомәргә бардык. Без барып кергәндә, җамигъның уртасында бер өем халык түгәрәкләнеп, кул тотышып сикерешмәктә вә бер нәрсәне бик кычкырып укымакта иделәр. Боларның сикерешүләрен тасвир итү өчен әдәп даирәсеннән тыш берничә сүз кулланырга тиешле булганлыктан, анысын калдырамын. Алар шул хәлләренчә сихер вә фетнәдән таң атканчы сикерешеп, кычкырышып бөтен кешенең мазасын[4] алдылар. Аларның

[1] Тарикать мөәссисенең – дини юнәлешнең башлап нигезен салучының.
[2] Мөстәлзим – сәбәпче.
[3] Бәкасы – дөньяда яшәве.
[4] Мазасын – тынычлыгын.

характерлары, шулкадәр каты тавышланулары, шулкадәр кабих иде ки, гыйбадәт исеменнән шуларны эшләүчеләргә рәнҗүдән күңелне тыеп булмый иде. Шул «гыйбадәтчеләр» сәбәбеннән елның иң мөкаддәс бер кичәсендә вә төннең дә иң тыныч, тавышсыз бер вакытында гыйбадәтханә почмагында, күңеле берлән Аллага юнәлеп, берничә минут кына булса да дөньяның бөтен гамен онытып торырга вә үзләренең үткән хәятләреннән хисап биреп, моң-зарларын Аллага гарыз итәргә[1] барган кешеләр, шөбһәсез, барысы да мәхрүм кайтып киттеләр.

Шул вакытта җамигъның бер читендә утырган Сүриянең мәшһүр галимнәреннән шәех Гомәр Мөхәммәд әс-Сани янына барып, ул тарикатьнең исемен сорадым вә дидем: «Гаҗәп, бу тарикатьнең мөәссисе шәех мөридләренең ул хәрәкәтләреннән мәмнүн калачакмы?» Шәех Мөхәммәд әс-Сани шул тарикатьнең шәехе танылган зат тарафыннан сөйләнгән бер бәетне укыды вә диде: «Шөбһәсез, разый түгел. Болар шәехне хата аңлаганнар», – димеш. Ул тарикатьнең шәехе андый бернәрсә әмер итмәгән. Җәлалетдин Руми хәзрәтләре вә мәүләвиләрнең дә бөрмәләрен кабартып әйләнүләренә разый микән?

Ниһаять, бер адәм, Аллаһы Тәгалә тарафыннан күндерелгән пәйгамбәр булмаган вакытта, никадәр зур вә мәхзүм[2] булса да, аның һәр сүзе вә эше үрнәк итеп тотылырга тиешле түгел. Адәм баласы мәүкыйг[3] игътибары берлән никадәр югары булса да, ул инсанга гариз була торган[4] нәрсәләрдән мәсүн[5] була алмый.

Җәлалетдин Руми курай уйнатып, барабан суктырып әйләнүне, шәехе дә кул тотышып сикерүне Аллага якынайта вә ахырында сәгадәткә ирештерә торган гамәлләрдән тапкан вә аларны эшләүне дин исеменнән әмер иткән булса, аларның иҗтиһадларындагы хаталары булыр. Бу, әлбәттә, бик табигый нәрсә. Табигый булмаганы исә, аларның шул хаталарын гыйбәдәт урынына күчерүләре генәдер.

[1] Гарыз итәргә – җиткерергә, уртаклашырга.
[2] Мәхзүм – хөрмәткә лаек.
[3] Мәүкыйг – кайбер очракларда.
[4] Гариз була торган – тумыштан булмыйча, соңыннан барлыкка килгән.
[5] Мәсүн – имин.

Тарикать шәехләренең рухани халәтләре сәламәт булган булуларына да табиблар консультациясеннән шәһадәтнамә бирелмәгән. Ихтимал ки, алар вакыт-вакыт үзләрен контрольдә тота алмый, сикереп вә йөгереп киткән булырлар. Аларның мондый вакытларындагы фикерләренең галилегенә вә хәрәкәтләренең гакыллылыгына карап, ихтыярларыннан тыш эшләгәннәрен дә тәсвиб итәргә[1] тиешле түгел. «Титаник»та һәлак булучыларның берсе бүген дә иң зур галимнәрдән булган мистер Исситид иде. Мәдәният дөньясы бу галимне гыйлеми вә икътидары[2] өчен никадәр ихтирам итте исә, аның әрвахлар берлән хәбәрләшү дәгъвасын шул нисбәттә игътибарсыз калдырды. Аның әрвахлар берлән булган хәбәрләшүен рухани хәстәлек дип кенә каршы алдылар.

Мәүләвиләр тарикатендәге бию вә җырлауны Җәлалетдин Руми хәзрәтләренең угылы үтерелгәч вә остазы Шәмсетдин Тәбризи юкка чыккач башланып киткән, имеш. Димәк, үзләре дә нормальный булмаган ул хәрәкәтләр нормальный бер хәл астында башланып китмәгәннәр. Җәлалетдин Руми җырлап курай уйнарга кушкан булса, һәрхәлдә, угылы вә остазы өчен әрнегән йөрәген бераз басу өчен кушкандыр. Андый эч пошкан вакытларда музыкадан юаныч эзләү бик табигый. Моның өчен Җәлалетдин Румига әйтергә бер сүз юк. Шелтәләнәчәк кешеләр исә берәүнең эче пошкан вакытында күңел күтәрү өчен эшләгән бер нәрсәсен гыйбадәт итеп алып китүчеләрдер.

Шамнан Бәгальбәккә барганда, Хәлебкә баручы бер мөдәррис берлән бер вагонда туры килдек. Мин аның ул тарафтагы мәшһүр бер мөдәррис икәнен аңлагач, берничә мәсьәлә хакында фикерен сорадым. Аларның берсе мәүләви тарикаты хакында иде. Башкаларын үз урынына калдырып, мөдәрриснең ул тарикать хакындагы сүзен бу урында искә алуны тиеш табам.

Мин мөдәрристән: «Мәүләвиләрдәге әйләнүнең асылы кайдан килгән?» диеп сорадым.

Ул миңа түбәндәге сүзләрне сөйләде: «Бер вакытны рәсүл әкрәмгә хәзрәти Әбүбәкер хакында бер вәхи килгән (вәхинең

[1] Тәсвиб итәргә – дөрес дип санарга.
[2] Икътидары – таланты (способность).

нидән гыйбарәт булганы хәтеремдә калмаган. Ләкин ничек булса да хәзрәти Әбүбәкерне бик күтәрү иде). Рәсүлулла аны Әбүбәкер разый Аллаһка сөйләгәч, ул шул кадәр мәхзуз булган[1] ки, урыныннан торып бер әйләнеп утырган. Бүген дә мәүләвиләр үзләренең шул зур сахабәгә иярүләрен дәгъва итәләр, имеш. Рәсүл әкрәмнең[2] ул сүзеннән хәзрәти Әбүбәкернең шатланырга хакы булганлыгын – вә андый бер сүздән тәвазенен[3] гаеп итә язып куюы да табигый булганлыгын сөйләргә хаҗәт юк. Ләкин шуны бер гыйбадәт итеп алып, аның өчен тәвазеннәрен генә түгел бөтен хәятләрен югалтучыларга ни әйтергә кирәк инде? Бу бик кызык хәл түгелме? Берсе үзен тота алмый китеп бер нәрсәне эшли. Икенчеләре шуны һич кирәге булмаган бер гыйбадәт итеп алып, барлык вакытларын диярлек шуның берлән үткәрәләр».

Болар хакындагы шул ике сүзне бергә кушканда, ул тарикатьнең асылы хакында бер фикер чыгарып була. Ихтимал, башкалары да шундый бер нәрсәгә барып терәләдер.

## XVII
## Иран консулы янында

Шамның гайре рәсми[4] адәмнәреннән бер-икесен зиярәт вә фикерләрен истифадә итәргә[5] дип Бәйрутта үк күңелемә беркетеп чыккан идем. Ләкин анда консул фәлән шикелле рәсми адәмнәр берлән сөйләшермен дип күңелемә дә кереп чыкмаган иде. Эшләр исә мин фараз иткәннең киресе булып чыкты. Күрермен дип барганым Җәмалетдин әл-Касими берлән Йосыф Нәбәһани һәр икесе Шамда булмаганлыктан, аларны күрә алмадым. Күрүен исемә дә алмаган Иран консулын күрдем. Иран консулын зиярәтмезне язып үтүдән элек, мәшһүр ике шәехне тасвирлап китим. Шәех Җәмалетдин әл-Касими Шамның

[1] Мәхзуз булган – шатланган.
[2] Әкрәм – кешене бик хөрмәтләүчән.
[3] Тәвазенен – тиңләшүен, биредә: чынлап та шулай дип уйлавын.
[4] Гайре рәсми – рәсми булмаган.
[5] Истифадә итәргә – файдаланырга.

ачык фикерле мөдәррисләреннән булып, бәгъзе газеталарда мәкаләләре дә күренгәләп куя. Бәгъзе китапларга хашияләр[1] язган вә кайберләрен тәсхих итеп[2] бастырган, зурлар каршында кадер вә хөрмәте бар. Искерәкләр каршында да «ваһаби» дип шөһрәт тапкан бу шәех берлән аз гына булса да сөйләшеп, фикерләрен истифадә кылырга теләгән идек. Ләкин, тәэссефемезгә каршы, сөйләшергә мөмкин булмады. Бер килгәндә Мисырга киткән иде.

Шәех Йосыф Нәбәһани тәмам Җәмалетдин әл-Касиминең киреседер. Ул үзенең тәгассыбы[3] вә хыялпәрәстлеге[4] берлән мәшһүр. Хәмид дәверендә[5] Әбүлһадиның ярдәме берлән Бәйруттагы истинаф мәхкәмәсенә[6] рәис итеп билгеләнгән һәм, хөррият игълан ителгәнче, егерме биш ел шул урында калган.

Исламиятне рәсүл әкрәмгә мәдех вә касыйдәләр язудан гыйбарәт дип белгән бу шәехнең мәдех ән-нәби[7] хакында язганнары күп. Нәбәһанинең теңкәсенә иң нык тиючеләр ваһабиләр булса кирәк. Ул шуларга рәддия[8] язам дип, үз ише булган бер ваһабилыкка каршы калын бер китап язып чыгарган.

Тәгассыбы[9] берлән ул христианнар диненә дә тиеп, рисаләләр язып тора. Хөррият игълан ителгәч, Нәбәһани дә урыныннан чыгарылган иде. Үткән елга кадәрле Бәйрутта торды. Ләкин шул елда христианнарның хиссияте динияләренә тукынып язган бер рисаләсе өчен хөкемгә тартылачагын сизгәч, Мисырга качты. Аннан Мәдинәгә барып, шунда тапшырылачак иде. Ләкин Бәйруттагы танышларының риҗасы[10] буенча, хөкүмәт Нәбәһанине

[1] Хашия – бер китапның эчтәлеген ачыклый торган.
[2] Тәсхих итеп – төзәтеп, дөресләп.
[3] Тәгассыбы – фанатизмы.
[4] Хыялпәрәст – хыялланырга яратучы.
[5] Хәмид дәверендә – 1878–1909 елларда Төркия солтаны Габделхәмид II (1842–1918) идарәсе еллары турында сүз бара.
[6] Истинаф мәхкәмәсенә – апелляция судына.
[7] Мәдех ән-нәби – пәйгамбәрне мактау.
[8] Рәддия – кире кагу, дөрес түгеллеген күрсәтү.
[9] Тәгассыбы – фанатизмы.
[10] Риҗасы – соравы, үтенече.

Бәйрутка килмәү шарты белән, гафу итте. Шул көннән бирле ул Шамда тора иде.

Шәех Нәбәһани Төркиядәге әҗнәби миссионерлар мәктәпләрендә укучыларның барысын да кяфер дип игълан иткәнгә, без аңа үзебезнең Американ көллиятенең таләбәсе икәнемезне әйтми генә тәкъдим ителәчәк идек. Яшь мөхәррирләремездән берсе: «Мин күңел ачасым килсә, кулыма көлке журналлары вә порнографический рисаләләр алмыйм, «Дин вә мәгыйшәт» журналын гына укыйм», – ди торган иде. Шуның шикелле без дә йиде ай буе Американ профессорлары вә докторларының җәдиденнән[1] арган күңелләремезне Нәбәһани берлән әңгәмәдән бераз ял иттерергә теләгән идек. Ләкин моңа ирешеп булмады. Без барыр алдыннан гына Нәбәһани Мәдинәгә киткән икән.

Иран консулы белән күрешүем очраклы гына булды диярлек. Бездән берничә көн соңрак Шамга көллияттәге таныш иранлы таләбәләрдән берничәсе килгән иде. Бер көнне иртә берлән барымыз да Салихиягә чыгып киттек. Анда барып төшкәч, иранлы дусларымыз үзләренең иранлы консулын зиярәт итеп чыгачакларын сөйләп, безне дә бергә барырга дәгъвәт иттеләр.

Бер ислам дәүләтенең икенче бер ислам дәүләтендәге вәкиленең әфкярен[2] бераз тыңлау, аңлауны зур ганимәт[3] санап, аркадашларымызның дәгъвәтен шатланып кабул иттек. Янымызда Шамда торучы бер таҗир[4] да бар иде. Безне консулга тәкъдим итәчәк иде.

Иран консулханәсе дә башка дәүләтләрнеке янында кечкенә генә гүзәл бер бинада икән. Безне ишектә атташе вәкиле каршы алып, тугры бакчага китерде. Анда яшь кенә бер егет берлән күрештек. Ул егет консулның борадәре[5], имеш. Консулның безне кабул итәргә хәзерләнеп бетмәгәнен аңлагач, бакчаны тамаша

[1] Җәдиденнән – яңалыгыннан.
[2] Әфкярен – фикерләрен.
[3] Ганимәт – бәхет, уңыш.
[4] Таҗир – сәүдәгәр (бизнесмен).
[5] Борадәре – туганы.

итеп йөри башладык. Кеченәнәрәк кенә бер бакча. Уртасында зур гына бер хәвездән[1] ургылып-ургылып су чыгып ята.

Бер тарафта читлек эчендә күгәрченнәр, тавыклар, күркәләр тора. Бераз йөреп, хәвез янына кайтып килгәндә аның әйләнәсенә урындыклар төзелгән иде. Утырдык. Янымдагы иптәшемә нинди булса да комплимент әйтәсем килә иде. Чөнки ул үз консулханәсендә, үз милләтенең бер дипломаты хозурында иде. Ләкин ул консулханәсенең бүген расход берлән исемнән башка әһәмияте калмаганын тәхәттыр итеп[2] әгәр бу мөнәсәбәт берлән иптәшемә дәүләтләренең истикъляль[3] вә сәсадәтен исенә төшерердәй бер нәрсә әйтсәм, бәлки кәефе китәр дип, аптырап тордым. Иптәшем минем авыр уйларымны аңлаган шикелле үзе башлап: «Мин бу йирне күрү берлән ифтихар итәмен[4]. Монысы үз консулымыз вә үз консулханәмез», – диде. Мин дә аңа җавап итеп: «Әвәт, сезнең һич булмаса консулларыңыз бар...» – дидем.

Күп тә үтмәде, эчкә чакырдылар. Тар гына бер баскычтан югары менеп, вак-вак берничә бүлмә аркылы үткәннең соңында, тәрәзәләре урамга караган мөзәйян[5] бер бүлмәгә барып керлек. Бүлмәнең идәненә Иран келәмнәре түшәлгән, стеналарга төрле ләүхә[6] вә рәсемнәр асылган иде. Ишеккә каршы стенаның алдында Мозаффареддин шаһның һәйкәле тора. Мебельләре вә башка җиһазлары гаять нәфис иде.

Бераздан соң кыска гына буйлы, симез генә бәдәнле, тулы йөзле, ачык чырайлы, чәч вә мыеклары агара башлаган, штатский киемдә, каракүл бүректән бер зат килеп керде. Кыяфәтеннән вә атлап килүеннән моның консул икәнен аңлап, торып сәламләдек. Таҗир әфәнде аңа иранлы таләбәләрдән берсен тәкъдим итте вә ул шәкерт тә калганнарын берәм-берәм тәкъдим итеп чыкты. Үземнең әллә ничә хан берлән юлдаш булып килгәнлегемне шунда аңладым. Әфәнделәрнең барысы да хан

[1] Хәвез – биредә: фонтан мәгънәсендә.

[2] Тәхәттыр итеп – искә төшереп.

[3] Истикъляль – бәйсезлек.

[4] Ифтихар итәмен – горурланам.

[5] Мөзәйян – зиннәтле.

[6] Ләүхә – шамаил.

да хан. Безгә килеп йиткәч кенә эш башкача булды. Җәнүб[1] төрекләрендә һич булмаса бер «бәк» бар. Янымдагы төрек иптәшем шул исем берлән тәкъдим ителде. Бездә бит бер титул да юк. Оренбург берлән Чиләбе арасында йөргәндә, марҗаларның ике тиенлек лепешкаларын сатар өчен, «пожалуйста, князь у меня свежая и мягкая» диюләренә бик ачуым килә торган иде. Иран консулы янында шундый гына булса да бер кенәз булып торасым килде.

Күрешеп утыргач, консул иранлы таләбәләргә карап: «Иранның истикъбаль өмиде сезсеңез», – диде. Озакламый каһвәләр килде. Төрле мәсьәләдән сүз ачылды. Сәгать ярымнар дәвам иткән бу әңгәмә, табигый, фарсы лисанында иде. Консул төрекчә белсә дә, иранлылар арасында ул телне белгәннәре бер-ике генә иде. Мин сөйләгән сүзләрнең эчтәлеген бераз аңлап утыра алдым. Чөнки күбрәк сөйләүче консул иде. Ул Аурупа халыкларының истыйляхларын[2] күп куллана иде.

Фарсычада гарәби атамаларның күплеге дә мәгълүм. Шуларның кушылуыннан бер нәрсә чыкты. Соңыннан консул безгә мөрәҗәгать итеп: «Сезне ялгыз калдырдык», – диде. Без дә мосахәбәнең мәфһүмен тәгъйин итә[3] алуымызны сөйләдек.

Консул Германиягә тәхсил кылган[4] вә соңра Аурупада бераз мөддәт[5] сәяхәт иткән. Французча, алманча белә. Фикере ачык вә мәсьәләләргә нәзары[6] киң күренде.

## XVIII
## Шамда мөһаҗирләр

Шамда унбиш гаиләгә кариб[7] эчке Русиядән һиҗрәт иткән[8] мөселманнар бар. Үзләренә Салихия тарафыннан йир бирелгән.

---

[1] Җәнүб – көньяк.
[2] Истыйляхларын – терминнарын.
[3] Мосахәбәнең мәфһүмен тәгъйин итә алу... – әңгәмәнең мәгънәсен (эчтәлеген) аңлата (аңлый алу).
[4] Тәхсил кылган – белем алган.
[5] Мөддәт – ара, вакыт.
[6] Нәзары – фикере, карашы.
[7] Кариб – якын.
[8] Һиҗрәт иткән – күчеп килгән.

Барысы да бер урында җыйналышып утыралар. Болар монда килгән вакытларда бик кыенлыклар күргән булсалар да, хәзер өйрәнеп алганнар. Үзләренә яраклы хезмәтләре дә табылган. Отель, телеграфханә, чуен юлы идарәсе шикелле йирләрдә хезмәт итүчеләр бар. Балаларын хөкүмәт мәктәпләренә биргәннәр. Алары доктор, забит[1], адвокат, профессор булырга хәзерләнеп яталар.

Безнең бу һәмшәһриләремез[2] монда килеп гарәп-төрек хәяте хаосы эченә керү берлән үзләренең мәгыйшәт ысулын онытмаганнар. Өйләрен Русиядәге шикелле итеп салганнар, эчләрен Русиядәге шикелле итеп җыештырганнар. Җиһазлары арасында үземезнең авыл өйләрен искә төшереп тора торган нәрсәләр күп. Ишек алдында да үземезнең ысулда. Себеркеле кара мунча да бар. Үземезчә катышалар, үземезнең тел берлән сөйләшәләр. Үземезнең ысул берлән кунакка йөрешәләр икән. Бүгенгә кадәрле кода-кодагыйлык ясау өчен дә читкә мөрәҗәгать итәргә ихтыяҗ булмаган. Болар бер җәһәттән күршеләренә дә тәэсир иткәннәр. Аларны себеркеле мунча керергә өйрәткәннәр. Хәтта болардан күреп күршеләрдән берсе үзе дә себеркеле мунча ясаган. Аның вакыйгасы да кызык кына. Бер көнне күршеләреннән берсе, боларның мунчаларын карап чыккан да, кайтып үзе дә шундый мунча ясаган. Тәмам булгач, ягып кергән. Ләкин ташка никадәр су салсалар да ләүкәгә җылы килмәгән. Моңа бик аптырап безнең якташларга барганнар. Алар керсәләр күрәләр: мунчаның төннегеен ябарга тиешлекне белмәгәннәр икән. Анысын да өйрәнеп алгач, рәхәтләнеп чабынып керә башлаганнар.

Шамда каен агачы юк. Ләкин һәмшәһриләр аның өчен каен кадәрле гүзәл булмаса да аннан мөкаддәс бер агач тапканнар. Шамның иң пычрак бер кыйсьмендә – тимерче, күмерче алачыклары арасында иске бик юан бер агач бар. Ул агач хәзрәти Гали таягыннан үсеп киткән, имеш. Ул бер вакытны дөлделен бәйләп куяр өчен шул урынга таягын кадаган икән. Соңыннан шул таяк – аны хәзрәти Гали алмый киткәнме, яки ул эшен бетереп әйләнеп чыкканчы үсеп куйганмы, анысын белмәдем – агач бу-

[1] Забит – офицер.
[2] Һәмшәһриләремез – якташларымыз.

лып үскән. Ул агачның ботаклары ак калинкурга[1] охшаган. Салаватлар язып асканнар. Вакытлар үтү берлән агачның төбендә хасил булган бер куышка шул тарафның пычрагын тутырганнар. Аллаһы Тәгалә йөзен хөрмәтләгән кешенең агачын шул дәрәҗә хөрмәтсез итү бик килешеп бетмәсә кирәк. Менә шул таяктан үскән мөкаддәс агач, табигый, унөч гасыр буе үрчегән вә Шамның һәр тарафына таралган. Безнең якташларымыз аны, себерке өчен файдалы табып, куллана башлаганнар.

* * *

Талиб әфәнде ханәсендә без дә бер көн кунак булдык. Себеркеле мунча, самавырлы чәй, кош теле... шикелле үземезнең ашлар вә нәрсәләр берлән сыйландык. Бу мәмләкәткә килеп озак калган кешенең сагына торган нәрсәсе – эчендә иң алда торганы самавырлы чәй берлән, себеркеле мунчадыр. Безнең себеркеле мунча төрек ысулындагы зур, мөзәйян, ванналы, душлы хамамнарга[2] нисбәте мәнзилендә[3] булса да, ул үзеңнең кечкенәдән аңлашылган вә үз кавемеңнең мәгыйшәтендә мөһим бер роль уйнаган нәрсә булганлыктан сиңа бик якын тоела. Аның кап-кара стена вә ләүкәләре, кечкенә генә тәрәзәләре, керәле-чыгалы идәннәре, ватык-йимерек ишекләре вә тишек-тошык савытлары, бигрәк тә аның үзенә махсус бер исе синең башыңа кечкенәдән урнашып калган. Алар синең иң тәшвишсез, ата вә анаң һимаясы[4] вә тәрбиясендә үткән ләззәтле минутлары берлән багланган.

Талиб әфәнденең мунчасы ишегеннән барып керү берлән борыныма капланган таныш ис минем дә балалык тәэсиратымны болгап чыгарды. Ул вакытлардагы гамьсез, шат вә табигый хәятемә бер әйләнеп карадым. Бүгенге хәлемә күз салдым. Үземне бу сонгый[5] хәяттә, аның һәяҗанлы[6] диңгезнең дулкыннары арасында ары да, бире дә ташланып ярдан еракланмакта булган

[1] Калинкур – киҗе-мамыктан эшләнгән тукыма.
[2] Хамам – мунча.
[3] Мәнзилендә – йортында, бинасында.
[4] Һимаясы – кайгыручанлыгы.
[5] Сонгый – ясалма, табигый булмаган.
[6] Һәяҗанлы – дулкынланган.

кечкенә бер каек эчендә күрдем. Менә шул каек сине сәламәт килеш читкә алып барып чыгарачакмы? Чыгачак йир дә ерак. Дулкыннар киткән саен арта вә куәтләнә баралар. Ул каек бер ташка бәрелеп ватылмасмы? Яки дулкын астында калып төпкә батып китмәсме?

Мин кечкенә вакытымда бер китап укып чыккан идем. Китап Петербургта басылган вә исеме дә «Мәгыйшәт»[1] иде шикелле. Аның бер йирендә бәхет кошы турында сүз бар. Бер кеше бәхет кошы эзли. Аның кунмавыннан зарлана. Бервакыт икенче бер кеше килә дә: «Сиңа инде бәхет кошы кунган», – ди. Хикәянең бу урынына йиткәч, нindiдер бер сабырсызлык вә шатлык берлән укуымны дәвам иткәнем бүгенгедәй исемдә; чөнки тизрәк бәхет кошының ни нәрсә вә кайда икәнен белеп алып, аны үз башыма кундырырга тели идем.

Балалык түгелме инде? Ләкин ахырга таба кешенең бәхет кошы итеп кайнап утырган самавырны күрсәтүеннән ни дәрәҗә мәййүс булганымны[2] да оныта алмыйм. «Ул самавыр ничек бәхет кошы булсын соң инде. Ул бит... бездә дә бар», – дидем.

Талиб әфәнденең ярлы мунчасында хәзрәти Гали таягыннан үскән яфрак берлән чабынып чыгып, шаулап торган зур сары самавыр янына утыргач, мин дә шул кешенең фикерен тасдыйк итә[3] язып куйдым.

Чөнки Русия мөселманнары шамлыларны себеркеле мунча керергә өйрәткән булса, Бохара мөселманнарыннан берсе аларны чәй эчәргә өйрәтеп ята. Бер бохаралы чәйханә ачкан вә кисмәк зурлыгында өч-дүрт самавыр алып куйган. Чәйне бик зур стаканнарга ясап бирә. Эченә шикәрен дә күп сала. Шуннан барысы да моталик (ике тиенән бик аз артык) ала. Бу чәйханәдә башкаларындагы шикелле уен фәлән юк. Монда халык чәй эчәр өчен генә керә. Шушы чәйханәгә чәй эчәргә Шамның читләреннән трамвайга ике моталик түләп килүчеләр бар, имеш. Монда кереп чәй эчүчеләр – табигый, түбән сыйныф халкы.

[1] Санкт-Петербург ахуны Гатаулла Баязитовның «Мәгыйшәт вә дөнья» исемле әсәре булса кирәк.

[2] Мәййүс булганымны – гаҗәпләнеп, аптырап калуымны.

[3] Тасдыйк итә – раслый.

Тәмиз киемлеләр бик аз күренә. Әгәр дә чәйханә бераз таза тотылса иде, югары сыйныфлардан да килүчеләр күп булыр иде. Әлхасыйль, бу сарт гарәпләрне чәй эчәргә тәмам өйрәткән. Алар сусаган вакытларында гына түгел, карыннары ачкан вакытта да берничә моталиклык күмәч, панир[1] шикелле нәрсәләр алып керәләр дә чәй эчәләр. Бер мәртәбә Бәйрутта бер гарәп минем кечке аш урынына сөтләп чәй эчеп утырганымны күреп гаҗәпләнгән иде. Шамдагы бохаралы исә гарәпләрнең үзләрен сөтсез чәйне аш урынына эчәргә өйрәткән.

Бу чәйнең шундый абруе чыгуына сәбәп тә аның чәйне яхшы хәзерләведер. Ул бервакытта да кайнатмаган судан ясап бирми. Самавырлары алмашлап кайнап торалар. Чәйне дә яңартып тора. Гарәп каһвәләрендә исә, бер кеше чәй сорады исә, бер чәйнек төбенә чәй салалар да өстенә суык су салып күмергә утырталар. Бераз җылынгач, «чәй» дип китереп бирәләр. Әгәр дә бу сарт чәйханәсен тәмизрәк бер урынга ачып йибәрсә, тагын да күп файда итәр иде. Аның бүгенге сәүдәсенең дә утыз-кырык тәңкәгә йиткән көннәре була, имеш.

Ләкин ул булган кадәресенә генә канәгать итеп утыра. Артык теләми икән.

* * *

Шамда күргәннәремнән бу мәртәбәдә язарга теләгәнем шунда тәмам булды. Сүз арасында, җае чыкканда бераз нәрсәләрне тәнкыйть иттем. Җаным әрнегән кайбер нокталарда каләмемә хөррият бирдем. Ләкин моны төрек вә гарәпләргә дошманлыгымнан түгел, бәлки дуслыгымнан эшләдем. Төрек углы төрек булганлыгымнан төрекләрнең идарә дәрәҗәләрен, гатыйләтләрен[2] тәнкыйть итәргә мәҗбүрмен. Мөселманнарның тәрәккый вә сәгадәтен бөтен җаным вә тәнем берлән теләгәнгә күрә, аларның тәрәккыйларына манигъ[3] дип уйлаганым бераз гадәтләрне тәнкыйть иттем. Тәнкыйть фикерләремнең барысын да тугры дип дәгъва итмим. Әгәр дә фикерләремез хата икәнен күрсәтеп, тугрылыкларына дәлил бирүчеләр булса, аларга иярүгә дә хәзермен.

[1] Панир – сыр.
[2] Гатыйләтләрен – эшлексезлекләрен.
[3] Манигъ – киртә, каршылык.

Сүз ахырында Шамның халәте гомумиясе хакында бер-ике сүз әйтеп үтүне мөнасиб[1] табамын.

Бу шәһәрдә гарәп тәэсире бер җәһәттән, чагыштырмача, ул кадәр көчле түгел. Андагы шикелле мәдәният вә мәгариф нашире, мөҗәссәләр[2] монда юк. Бинаэ галәйһи[3] әһалинең фикере дә ул кадәр зәһәрләнмәгән. Төркиягә мәхәббәтләре бәйрутлеләргә караганда алда. Төрекчә белүчеләр дә күп. Без анда торган мөддәттә[4] берәүгә төрекчә хитап итеп[5] тә, «мин төрекчә сөйләшмим» дигән җавап бик аз ишеттек. Һәр йирдә диярлек, ватып-йимереп булса да, төрекчә сөйлиләр. Шамда Урду мәркәзе булганлыктан, анда төрек забит вә гаскәрләрнең күп булуы да төрек теленең тәгълим итүенә[6] бераз ярдәмче булгандыр.

Мөгамәләләрендә мөмкин кадәрле тугры булырга тырышалар. Истанбул, Измир, Бәйрут (минем күргән шәһәрләрем шулар гына) шәһәрләрендә синең гаҗәми[7] икәнлегеңне белеп алсалар, хәзер алдаталар. Ашханәгә керсәң, бер нәрсә сатып алсаң, синнән ике-өч мәртәбә артык алалар. Мин Истанбулда бер китапчының золымыннан андагы абруйлы һәмшәһридән[8] шифаһи[9] рекомендация алып баргач кына котылган идем. Шамда андый нәрсә юк. Әллә без тугры килмәдек. Синнән артык сорап кәефеңне йибәрмиләр. Башкаларга ни бәядән сатсалар, сиңа да шулай. Тик бер китапчы гына Гаспринский нәшере булган кырык тиенлек кечкенә кулдагы Коръәннән бер тәңкә сорап карады.

Саррафлардан[10] башкалары акчаны да бик тугры итеп тиененә кадәр кайтарып бирәләр. Безнең мөхтәрәм шәехемезнең Шам мәгыйшәтен әсхаб[11] мәгыйшәте шикелле табуы, ихтимал, ошбу җәһәтләрдән. Ләкин әсхаб мәгыйшәтенә генә караган бер нәр-

[1] Мөнасиб – яраклы.
[2] Мөҗәссәләр – журналлар.
[3] Бинаэ галәйһи – шул сәбәпле.
[4] Мөддәттә – вакытта.
[5] Хитап итеп – эндәшеп, мөрәҗәгать итеп.
[6] Тәгълим итүенә – барлык җиргә кертелүенә, таралуына.
[7] Гаҗәми – тәҗрибәсез; гарәплердән булмаган кеше.
[8] Һәмшәһридән – якташымнан.
[9] Шифаһи – телдән.
[10] Сарраф – процент белән акча ваклаучы.
[11] Әсхаб – сахабалар.

сә түгел, бәлки сәүдә вә мөгамәләнең этикасы вә бер кешенең абруен, башкалар каршындагы мәүкыйгын[1] мөхафәза итүнең[2] бердәнбер юлларыдыр.

Бу мәгънәдә әсхаб мәгыйшәтенең иң куәтле урыны – Шам, Мәккә, Мәдинә түгел, бәлки Париж, Лондон, Нью-Йорктыр. Өммия җамигының ачык йирендәге таш өстендә кояшка кызынып вә кечкенә җанварлар берлән канга батып сугышып утыручы «Әсхаб сафа» истисна ителсә[3], без Шамда әсхаб мәгыйшәтен искә төшерерлек бер нәрсә дә күрмәдек. Ихтимал, әсхаб мәгыйшәтеннән безнең хәбәрсез юктыр. Һәрхәлдә пычраклык, гаталәт[4], гасыры сәгадәт хосусыйятләреннән булмасалар кирәк.

Шамда отельләр гаять арзан. Безнең төшкән отель, хаҗ вакыты булганлыктан, бик тәмиз[5] иде. Отельләре электрик берлән яктыртыла. Уртасында чәчәкләр берлән капланган бер хәвез бар. Читлектә кошлар сайрап торалар. Хәвезнең[6] әйләнәсенә кәнәфиләр төзелгән. Бер читендә шәрык ысулында түшәлгән гүзәл бер солоны да бар. Менә шушы отельнең бәһасы суткасына[7] егерме бер тиен иде. Кырык тиен вә артыграк торган отельләр, табигый, бәһалары мөнәсәтләрендә, тагын да яхшырак. Ашау-эчү арзан. Гомумән, катык, сөт, май шикелле нәрсәләр очсыз.

(*бетте*)

*«Шам хатирәләре» исемле юлъязма «Сакмарый» тәхәллүсе белән «Шура» журналының 1913 елгы 18 нче, 19 нчы, 20 нче, 21 нче, 22 нче, 23 нче, 24 нче; 1914 елгы 1нче, 2 нче, 3 нче саннарында дөнья күрә. Автор үзенең чын исемен күрсәтмәсә дә, текст эчендә үзе турында кыскача мәгълүмат китерә. Ул Россия дәүләтендә Сакмар суы буендагы бер татар авылында туып үскән татар егете булуын, шушы вакытта Төркиянең Бәйрут шәһәрендә Америка көллиятендә укучы студент икәнлеген дә искәртә*

[1] Мәүкыйгын – урынын (дәрәҗәсен).
[2] Мөхафәза итүнең – саклау, яклауның.
[3] Истисна ителсә – чыгарма булса.
[4] Гаталәт – эшлексезлек, сүлпәнлек.
[5] Тәмиз – чиста.
[6] Хәвез – бассен, фонтан.
[7] Суткасына – тәүлегенә.

**Сакмарый**

## СҮРИЯ ӘХВАЛЕ

*«Кәшфез-зөнүн» зәйле. Җәмил бәк әл-Газыйм. Йосыф Бәһани. Мөхәммәд Таһир әт-Тәнир.*

Җәмил бәк әл-Газыймны зиярәт кылып «Кәшфез-зөнүн»[1] зәйле[2] хакында сораштым. Мөсәүвәдәсе[3] язылып тәмам булган. Мөкаддимәсен[4] дә акка күчереп куйган. Бастыручы табылмадыгыннан, аны бастырыр дәрәҗәдә байлык үзендә булмаганга, китабын акка күчермәгән. Шул мөсәүвәдә хәлендә торадыр. Мөсәүвәдәләр язылган дәфтәрләр кечерәк бер шүрлекне тутырып яталар.

Җәмил бәк:

– Мин боларны егерме ел зәхмәт сарыф кылып җәмгъ иттем.[5] Хезмәтемнең иң авыр өлеше тәмам булды. Акка күчерү өчен бер ел гомер йитәчәктер. Ләкин басылуы тәэмин ителмәгәнгә, аңа тотынып булмый. Моннан мөкаддәм бер китап табгы иттермеш идем, үз милләтемез өчен. Алучы булмады. Аурупалылар берничә данә алдылар. Шул әсәрем өчен тәшәккер вә тәбрик мәктүбләре дә шул аурупалылардан килде. Бернең милләт мазасыз[6] вә хыялый хикәятләрдән башканы тәкъдир итә алмый[7], – диде.

[1] «Кәшфез-зөнүн» – XVII гасыр әдибе Хаҗи Хәлифәнең (Кәтиб Чәләби, 1609–1657) мөселман дөньясында киң таралган әсәрләр һәм аларның авторлары турында библиографик хезмәте. Тулы исеме – «Кәшфез-зөнүн ган әсамил-көтүб вә-л-фөнүн» (Китап һәм фән исемнәре турында ачык гыйлемнәр). Элекке мәдрәсәләрдә өлкән сыйныф шәкертләре өчен уку китабы буларак та кулланылган.

[2] Зәйл – өстәмә, кушымта, берәр әсәргә автор яки икенче берәү тарафыннан өстәмә язылган кушымта; текстка комментарий.

[3] Мөсәүвәдәсе – караламасы (акка күчерелмәгән варианты).

[4] Мөкаддимәсен – кереш сүзен.

[5] Зәхмәт сарыф кылып җәмгъ иттем – хезмәт куеп тупладым.

[6] Мазасыз – борчылмый, тыныч.

[7] Тәкъдир итә алмый – бәяли алмый.

Җәлил бәк моңа кадәр яшәгән мохитеннән бизмеш, һәр эшкә мәэюсиять[1] илә карарга башламыш. Сүз арасында: «Мин бәгъзе вакыт газиматкә чигелеп[2] заһид булуны[3] да күңелемә алып куям. Ләкин вөжданым вә инсаннарга булган рабита мәгънәвиям[4] моңа манигъ[5] буладыр. Мин бу мәмләкәттән китәчәкмен. Мин сөйләдем, ләкин ишеткән вә аңлаган булмас. Утыз еллык хезмәтемә каршы миңа философ, бөек адәм исемнәре кеби бер шәйләр[6] бирделәр.

Ләкин миңа ул ул ләкабларның[7] ни кыйммәте бар; әҗдадымызның[8] эшләгән эшләрен күрсәтергә теләдем. Без бу көндә голүм вә куәтнең олпатыннан дә хәбәрсез яшимез. Бабаларымыз дөньяда бар нәрсә калдырмый китап тәэлиф итмешләр[9], вә бер «сиурийсенең» хакында бөек китап язмышлар исә, милләттәшләремне шуларны бер уйлап карарга сәвекъ итмәкче[10] булдым. Ләкин, тәэссеф ки[11], муафыйк улмадым[12]. Аурупа безгә түбән күз берлә карый. Безне сәляхиятсез[13] халыклардан саный. Бу сүзгә каршы мөдәфәгадә булынамыз[14] вә: «Хата сөйлисез» – димез. Ләкин игътираф итмәле[15], Аурупа тугры сөйли. Без үземез хакыйкатьне инкяр итү юлына басамыз».

Җәмил әфәнденең бу сүзләре, госманлылар арасында таралган «тәэсирсез зарлану»дан гына гыйбарәт булмыйча, чын калебтән чыккан сүзләр булуы ачык иде.

---

[1] Мәэюсиять – өметсезлек.

[2] Газиматкә чигелеп – күңелемнән уйга бирелеп.

[3] Заһид булуны – дөньялык эшләреннән китеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнергә.

[4] Рабита мәгънәвиям – рухи бәйләнешем.

[5] Манигъ – каршы.

[6] Шәйләр – нәрсәләр.

[7] Ләкабларның – исемнәрнең.

[8] Әҗдадымызның – бабаларыбызның.

[9] Тәэлиф итмешләр – язганнар.

[10] Сәвекъ итмәкче – юнәлтмәкче, этәрмәкче.

[11] Тәэссеф ки – ни үкенеч.

[12] Муафыйк улмадым – ирешә алмадым.

[13] Сәляхиятсез – сәләтсез, булдыксыз.

[14] Мөдафәгадә булынамыз – каршылык күрсәтәбез.

[15] Игътираф итмәле – кимелекләрне танырга кирәк.

«Кәшфез-зөнүн» зәйлен моннан биш ел элек Алманиядәге мөстәшрикъ[1] җәмгыяте үз хисабына бастырыр өчен, Алмания консулы васитасы илә[2] сораган. Ләкин ул вакыт Габделхәмид истибдады[3] бәлаләренә төшүдән куркып, Җәмил бәк бер җавап та бирә алмаган. Юкса җәмгыять яхшы гына мөкяфәт[4] тә вәгъдә иткән. Бу вакытларда француз җәзәвит (миссионерлар) мәктәбе идарәсе берничә мәртәбә сораган булса да, Җәмил бәк аларга бирмәгән.

«Кәшфез-зөнүн» зәйле дүрт яки биш җилд тәшкил итәчәк вә «Кәшфез-зөнүн» кадәр ике булачактыр. Шулкадәр бөек гыйлем хәзинәсе язылып тәмам булдыгыннан соң, ялгыз милләтемез вә мөселманнарның гыйлем кадере белмәүләре вә җәһаләтләре шомлыгыннан басылмый торуы – хакыйкать хәлдә кан-яшь илә агъларга[5] тиешле бер хәлдер. Бүгенге форсарлар бер вакыт килеп искә төшәрләр, ләкин ул вакытта «инде үткән» булыр.

* * *

Йосыф Нәбәһани. Тәхкыйк әһелләре[6] каршында түгел, бәлки урта дәрәҗәдәге кешеләр каршында да кадерле вә игътибарлы адәм түгелдер. Аның бөтен шәһәрне, үз мәсләгендә булмаганнарны, урам балалары гыйбарәләре илә сүгүдән тыш сөйләве вә кайберәүләргә ифтира кыйлып[7] такмак чыгарудадыр. Асылы «Гакя» шәһәреннән булып, Мисырда бераз тәхсыйль иткәннән[8] соң, Истанбулга барып, Гыйззәт паша вә Әбүлһадилар тирәсендә йөрмеш. Шуларның васиталары[9] илә Бәйрут шәһәрендә исти-

[1] Мөстәшрикъ – Көнчыгышны өйрәнү (востоковедение)

[2] Васитасы илә – арадашлыгы белән.

[3] Галделхәмид истибдады – Төркия солтаны Габделхәмид II нең бернинди законга да буйсынмыча эзәрлекләве, деспотизмы.

[4] Мөкяфәт – хезмәт өчен түләү, гонарар.

[5] Агъларга – еларга.

[6] Тәхкыйк әһелләре – тикшерүчеләр.

[7] Ифтира кыйлып – яла ягып, ялган гаеп ташлап.

[8] Тәхсыйль иткәннән – укыган, белем алган.

[9] Васиталары – арадашлыгы, ярдәме.

наф мәхкәмәседә[1] рәис итеп билгеләнгән. Шул хезмәтендә 25 ел дәвам кылмыштыр. Төркиядә хөррият игълан ителгәннән соң, хөкүмәт тарафыннан генерал ителеп Бәйруттә тормыш иде. Үткән ел христианнарның гакаид динияләренә тукынып, бер китап язды. Шуның сәбәбеннән христианнарның ачуын китерде. Китабы хөкүмәт тарафыннан конфисковать ителеп, үзен тәүкыйф итәргә[2] әмер чыкты. Ләкин ул арада Нәбәһани качып өлгергән иде. Ул ошбу качуында Мисырга барган вә анда Габбас Хилми пашаны мәдех кыйлып[3] бер китап язган вә күп кенә мөкяфат[4] алган. Габбас паша моның мәдех кыйлуыннан мәмнүн булган булырга охшый. Чөнки китабы өчен биргән мөкяфәтеннән тыш айга ун лира тәгъйин итеп[5], үзен Мәдинәгә йибәргән. Ләкин Нәбәһани Мәдиннәдә кулга алынды вә Шамга китерелде. Биредә ул хөкем ителәчәк иде. Ләкин үзенең дусларының ижтиһады[6] илә гафу кылынды. Бүгендә Шам шәһәрендә тора. Гаделия мәхкәмәсендә кятиблек[7] хезмәтен кылучы бер угылы бар. Нәбәһани ошбу угылы хакында: «Бу угылым «мәһди»[8] булачак, рөэямдә[9] шулай күрәм» дия сөйләп йөрмәктә исә дә, угылы һаман кятиблек хезмәтеннән югары күтәрелә алмыйдыр. Ихтимах XX гасыр «мәһди»ләре ошбу рәвешчә булачактыр.

Нәбәһанинең әсәрләре күп булса да, телгә алып сөйләрлек нәрсәсе булмаса кирәк. Язмалары файдасыз нәрсәләр булу өстенә үз малы булмаенча, төрле хорафатлардан күчерелмеш, мәгънәсез нәрсәләрдер.

* * *

Бу сәнәдә Мисыр вә Сүрияне шаулаткан нәрсәләрнең бере Мөхәммәд Таһир әт-Тәнир исемле бер зат тарафыннан тәэлиф

[1] Истинаф мәхкәмәседә – яңадан тикшерү (апелляция) судында.
[2] Тәүкыйф итәргә – кулга алырга.
[3] Мәдех кыйлып – мактап.
[4] Мөкяфат – бүләк, премия.
[5] Тәъйин итеп – билгеләп.
[6] Ижтиһады – тырышлыгы.
[7] Кятиблек – секретарьлык.
[8] Мәһди – туры юлга төшерүче.
[9] Рөэямдә – төшләремдә.

вә нәшер ителгән[1] «Әл-гакаид фи әд-динияt ән-нәсарият» исемле китап булды. Бу китап илле сәхифәдән артык инглизчә әсәрләрдән интихаб ителеп[2] язылмыш вә эченә бераз рәсемнәр дә куелмыштыр. Мөндәриҗаты[3] исә бүгенге христианлыкның мәҗүсилектән башка нәрсә түгел икәнлеген исбат итмәктән гыйбарәт. Китап мәүзугъ[4] җәһәтеннән бик мөһим булмаса да, Бәйрут шикелле миссионерлар берлә тулы булган бер шәһәрдә басылып таралуы җәһәтеннән мөһимдер. Таһир Тәнирнең бу турыдагы хезмәте христианлык илә мәҗүсилек арасындагы мөшәбәһат вә гыйниятне[5] күрсәтү генәдер. Китапның баш сәхифәсендә: «Бу китапны XX гасырның христиан миссионерларына һәдия итәмез», – дип язылган. Бу җөмлә миссионерларга авырга килгәнгә охшый. Китап басылып таралгач, Бәйрут шәһәрендә кыямәт купты. Христианнар вә миссионерлар ни эшләргә дә белмәделәр. Нәсара[6] руханилары валигә[7] мөрәҗәгать итеп, китапны сатудан алдыруны үтенделәр. Вали бу үтенечне кабул да иткән иде. Ләкин Тәнир ул китапның үз малы булмаенча, бары христиан әсәрләреннән күчергәнлекне вә шул әсәрләр Аурупада түгел, хәтта Бәйрутнең үзендә һич манигъсыз таралып, сатылып тора дип сөйләп, мондый бер әсәрнең манигъ ителүе юлсыз икәнлекне дәгъва кылды. Моны тикшергәннән соң хөкүмәт китапны сатарга вә таратырга мөсагадә итте[8]. Таһир Тәнир – Бәйрут шәһәрендә америкаи көллиятендә укып чыккан бер адәмдер.

[1] Тәэлиф вә нәшер ителгән – язылган һәм басылып чыккан.
[2] Интихаб ителеп – сайлап алып.
[3] Мөндәриҗаты – эчтәлеге.
[4] Мәүзугъ – тема, проблема.
[5] Мөшәбәһат вә гыйниятне – охшашлыклар һәм аерымлыкларны.
[6] Нәсара – христиан.
[7] Валигә – губернаторга.
[8] Мөсагадә итте – мөмкинлек бирде.

## Җәмил бәк илә мөсахәбәт

*«Кәшфез-зөнүн» зәйле[1]. Әһле исламның истикъбале[2]. Аурупада гомуми бер сугыш. Ислам дөньясының тәдәннисенә[3] сәбәпләр. Гомуми бер конференс[4]. «Ислах» мәсьәләсе. Халифәт мәсьләсе. Җирҗи Зәйдан әфәнденең «Тарих әт-тәмәдден әл-ислами» исемле китабы[5] хакында.*

Җәмил бәк әл-Газыйм әфәнденең кем икәнлеген Русия мөселманнары арасында белүчеләр аз булмаса кирәк. Җәмил бәк – Бәйрут шәһәрендә олуг бер мәнсабтә хезмәт итүе[6] өстенә, галим бер адәмдер. Ошбу ел тәгътыйль[7] көннәрендә Хамас, Хама, Хәлеб тарафларында сәяхәт итеп кайтты. Сәфәрдән кайту мөнәсәбәте илә аның белән мосахәбә кылырга һәвәсем төшкән иде[8]. Моңа муафыйк булдым[9]. Җәмил бәк хәзрәтләре өч сәгать кадәр гомерен минем өчен тәхсыйс итте[10]. Аның мәҗлесе гаять ләззәтле булуы илә тәкәллефсездер[11]. Гадәти сүзләренең дә күбесе хәят өчен дәстүрел-гамәл[12] булырлык мәгънәле нәрсәләрдер.

Мин сүзне «Кәшфез-зөнүн» зәйленнән башладым (Җәмил бәк китабына зәйл язганлыгы «Вакыт» һәм «Шура»да сөйләнгән

[1] Зәйл – өстәмә, кушымта, берәр әсәргә автор яки икенче берәү тарафыннан өстәмә язылган кушымта; текстка комментарий.

[2] Истикъбале – киләчәге.

[3] Тәдәннисенә – артта калуына.

[4] Конференс – конференция.

[5] Җирҗи Зәйдан әфәнденең «Тарих әт-тәмәдден әл-ислами» исемле китабы... – Җирҗи Зәйдан (1861–1914) – атаклы гарәп (Ливан, Мисыр) әдибе, публицист, «Әл-Һилял» журналы мөхәррире. Гарәп халкын үз милләте тарихы белән таныштыру концепциясен популяр романнар аркылы пропагандалый. Аның «Тарих әт-тәмәдден әл-ислами» исемле хезмәте 1901–1906 елларда биш томлык китап булып дөнья күрә.

[6] Мәнсабтә хезмәт итү – олуг бер урында эшләү (дәүләт хезмәтендә), ягъни чиновник.

[7] Тәгътыйль – каникул (озын ял).

[8] Мосахәбә кылырга һәвәсем төшкән иде – сөйләшергә теләгем туган иде.

[9] Муафыйк булдым – ирештем.

[10] Тәхсыйс итте – багышлады.

[11] Тәкәллефсездер – самими, ясалма түгел.

[12] Дәстүрел-гамәл – практик кулланма.

иде). Ул аны үзе бастырачак булган. Шунда бераз башкарак план тәгъкыйб итәргә[1] карар биргән: аны җөзьэ[2]- җөзьэ итеп чыгарачак вә һәр җөзьэне бер фәнгә тәхсыйс итәчәк икән. Бу хәлдә китапның нашире дә кулай булачак, һәм һәр җөзьэ аерым бер нәрсә тәшкил иткәнлектән, әһәмияте дә югалмаячак. Бу кыш тәфсиргә караган берничә җөзьэ нәшер ителәчәктер.

Әүвәлдә дә бер язган идем: Җәмил бәк әһле исламның истикъбаленә өмидсез карый[3]. Мөселманнар читләр кулында изелеп мәхү булачаклар[4], ди.

Шушы һәлакәттән котылу өчен чара барлыгына игътикад кыла[5]. Вә аны да исламиятнең гамәлгә куелуыннан гыйбарәт диядер. Ул үзе шушы юлда егерме елдан бирле хезмәт итүе сәбәпле бәгъзе бер юлларын да тапкан. Фәкать шул юлларны тәтәббыг кылу[6] бәгъзе бер нәрсәләргә генә терәлеп тора икән. Җәмил бәк бу планының нидән гыйбарәт икәнен тәфсилләп сөйләде. Бәлки бервакыт язармын. Җәлил бәк, үз планы йөртелсә, мөселманнарның дөньяда мөнкарыйз булмый[7] калуларына өмиде камил.

Җәмил бәк: «Аурупалылар, бүгенге хәлләренә ирешер өчен алты йөз еллардан бирле тырыштылар һәм һаман да тырышалар. Без исә шан вә шәриф алыр өчен алты көн тырышып канәгать итәмез. Әгәр дә йиденче көнгә калырын сизсәк, кул селтәп китәмез. Инде ул гадәтне ташларга кирәк, әгәр дә армый-талмый тырышсак, без дә бу дөньяда башкалар шикелле хөрмәтле бер милләт вә хөрмәтле бер дин әһеле була алырмыз», – ди.

[1] Тәгъкыйб итәргә – күзәтергә, биредә: башкачарак планда эшләргә мәгънәсендә.

[2] Җөзьэ – кисәк, том.

[3] Сакмарый бу турыда «Шура»ның 1913 ел 2 нче санында «Сәях» имзасы белән басылган «Сүрия әхвале» дигән мәкаләсендә яза.

[4] Мәхү булачаклар – юкка чыгачаклар.

[5] Игътикад кыла – чын күңелдән ышана.

[6] Тәтәббыг кылу – эзләү, өйрәнү.

[7] Мөнкарыйз булмый – юкка чыкмый.

Җәмил бәк фикеренә күрә, Аурупа бик ашыгыч сурәттә һәлакәт чорына китеп бара. (Моны бүгенге иң моктәдир[1] галимнәре, философлары да икърар итәләр[2], имеш). Озакламый Аурупада инфиҗар[3] мәйданга киләчәк, вә бөтен дөнья ут эчендә калачак, чөнки дәүләтләр арасындагы тартыш, вә алардагы тамигъ[4] көннән-көн арта вә көчләнә. Алар бу вакытка кадәр берәз мәсьәләләрне солых берлә ятыштырып килделәр исә дә, бер вакыт киләчәк – мондый солых-фәләннәргә урын бәтәчәк. Корал кулланмый мөмкин булмаячак. Менә ислам дөньясы, әгәр дә йоклап тормаса, үзләренең хәлләрен ислах кыла алыр. Шуның өчен хәзерлекләр булырга тиешле.

Мөнәсәбәт чыгуы илә шушы сүзне дә сөйләп китим: бүген генә бәһаиләрдән бер кеше берлә сөйләшеп утырган идем. Бәһаиләрнең башлыклары булган Габбас әфәнденең Аурупада дәһшәтле бер сугыш күтәреләчәген вә аннан соң дөньяда яңа бер тынычлык булачагын сөйләвен хикәят итте.

Җәмил бәк: «Мөселманнарның берләшүе башкаларга тәҗавез кылу[5] вә зарар китерү юлында түгел, бәлки солых вә инсанлык юлында булырга тиешле. Шуның өчен үз кул астында булган башка милләтләрнең хәлләрен дә игътибарга алырга вә аларны сакларга вә алардан хөрмәт, мәхәббәт иттерерлек рәвештә юл лязем», – ди.

Бер урында Җәмил бәк, үзенең мәҗлесен гомумиләштереп, бүгенге афәтләрнең сәбәпләрен тәхлил итте[6]. Аның фикеренчә, бөтен дөньяда булган начарлык, бозыклыкларның асыл сәбәбе – «тамигъ» берлә «акча»дыр.

Моннан соң мөхтәрәм Гаспринский[7] җәнапларының уртага сөрелгән гомуми бер конференциясенең булып-булмавын,

[1] Моктәдир – көчле.

[2] Икърар итәләр – таныйлар.

[3] Инфиҗар – шартлау.

[4] Тамигъ – комагайлык, ач күзлек (жадность, алчность).

[5] Тәҗавез кылу – басып керү.

[6] Тәхлил итте – анализлады.

[7] Гаспринский – Исмәгыйль бәк Гаспралы (1851–1914), мәгърифәтче, нашир һәм сәясәтче.

мөмкин булган тәкъдирдә файдасы булу-булмавы хакында фикерен сорадым.

Моңа каршы: «Андый бер конференция булса, бик файдалы булыр иде. Ләкин хәзерге хәлдә аны мәйданга чыгару бераз шөбһәле. Аны ясаудан элек мөселманнар арасына дуслык вә мәхәббәт хисләрен салырга тиешле. Соңыннан конференция булганда, анда әмирләр вә зур түрәләр дә ишетерлек итәргә кирәк», – диде.

Бу сүзеннән Җәмил бәкнең морады конференциянең сәяси булуы тиешле икәнен аңладым. Әмма Гаспринский җәнабларының морадлары, безнең аңлавымызга күрә, саф дини генә булачак иде. Шуның өчен икесенең максудлары арасында бераз башкалык буладыр.

Гарәпләр арасында күтәрелгән ислах хакында Җәмил бәк фикерен сорадым. «Бер нәрсә дә эшли алачаклар түгел. Гарәпләрдә эш эшләрлек куәт тә юк, истигъдад[1] та юк. Әхлак бозыклыгы шул дәрәҗәгә килгән ки, бу бозыклык эш эшләргә юл бирәчәк түгел. Ислах артынан йөрүчеләрнең үзләре дә саф ният берлә йөрмиләр. Аларның берәр төрле сәви[2] ниятләре булмавыннан бер кеше дә имин түгел. Кыскасы, мин ул ислах эше астында йөргән нәрсәләргә шөбһәле карыйм. Йөрүче кешеләрнең табигатьләрен яхшы беләм. Сак булыгыз, аннан бернәрсә дә чыкмас», – диде.

«Ягъни кайбер газеталар: «Төрекләр ислах вәгъдә иттеләр, ләкин аларда ислах эшләрлек куәт юк. Шуңа да без эшне үз кулымызга алырга тиешлемез», – дип язалар. Әгәр дә бүген төрекләр идарәне гарәпләрнең үз кулларына тапшырсалар, гарәпләр шул газеталарга ышанып, төрекләрдән яхшырак идарә итә алырлармы?»– дип сорадым.

Моңа каршы Җәмил бәк: «Гарәпләр кулыннан андый нәрсә киләчәк түгел. Мәмләкәт идарәсе өчен лязем булган сыйфатларның гарәпләрдә берсе дә юк. Тугры, төрекләрдә әхлак бозык, ләкин гарәпләрдә әхлак бозыклыгы төрекләрдән әллә ничә мәртәбә артык. Дөрес, төрекләр идарә итә белмиләр, ләкин

[1] Истигъдад – булдыклылык, зирәклек.

[2] Сәви – дөрес, туры.

гарәпләр идарә итә белмиләр генә түгел, белки идарә эшендә җаһилләр[1]. Гарәпләрнең мәшһүр гаиләләре арасындагы дошманлыклар, хөседләр идарә эшләрен үз кулларына алуда зур манигъдыр[2]. Боларның берсе эш башына менсә, икенчесе бөтен көче берлә эшнең барып чыкмавы өчен тырышачактыр. Әгәр дә гарәпләргә истикъляль[3] бирсәң, алар бик тиз вакыт эчендә чит бер дәүләткә кол булачаклар. Истикълялдән дәм[4] алучылар, ихтимал, шул башка бер дәүләткә кол булуны күз уңында тотып сөйли торганнардыр. Дөрес, төрекләр золым итәләр, алар безгә йодрык берлә сугалар, әмма башкалар безнең күкрәкләремезне изеп бетерәчәкләрдер. Төрек идарәсеннән чыгып, бер гадәләтле хөкүмәт кул астына керү безнең өчен файдалы булачак түгел. Төрекләр берлә гарәпләр арасындагы дошманлыклар, аңлашылмаулар әҗнәбиләр[5] дәсисәсеннәндер[6]. Шундый дәсисәләр тәэсире илә соңгы ярты гасырда ислам дәүләтләренең башларына килгән нәрсәләр күз алдында. Әгәр дә гарәпләр төрекләрдән аерылып чыксалар, башка төшкән нәрсәләр аларның башларына да киләчәктер», – диде.

«Урталыкта халыкны төрекләрдән аерып алу, Мисыр вә Сүрия һәм дә Гарәбстан кыйтгаларын берләштереп гарәп хәлифәлеге тәшкил кылу фикере йөри. Гарәпләр арасында шул фикергә тарафдарлар күпчелек тәшкил итәләрме?» – дип сорадым.

Моңа каршы Җәлил бәк: «Гарәпләр арасында шул фикергә керү дәрәҗәсендә бер ахмак адәм табылуына ихтимал бирмим. Аның кыен эш икәнлеген һәркем белә. Ләкин аның чыккан урыны Мисыр вә Сүриядән түгел, бәлки инглиздәндер. Ул фикер дә – әҗнәби дәсисәләреннән бер дәсисәдер. Фараз итик, гарәпләр хәлифәлекне алдылар ди, шуннан нинди эш күрсәтәчәкләр? Чөнки бүгенге хәлифәлек – үзе дә уйдырма бер нәрсә. Хакыйкый хәлифәлек Могавиягә кадәр генә булды. Ләкин шул соңгы хәлифә

[1] Җаһилләр – наданнар, белемсезләр.
[2] Манигъдыр – киртә, тоткарлык.
[3] Истикъляль – бәйсезлек.
[4] Дәм – бик кыска вакыт.
[5] Әҗнәбиләр – чит илләр (кешеләре).
[6] Дәсисә – хәйлә, алдау, ялганга корылган эш.

исеменең әһле исламга иткән хезмәте бик зур булды. Бөтен йир йөзендәге мөселманнарны бер мәркәзгә җыйнап торган нәрсә шул исем булды. Бу көндә мөселманнар кулында калган берике туп берлә дүрт-биш мылтык шул исемне тоткан хөкемдар кулындадыр. Аннан ул исемне алу бүген мөселманнарны зур бер куәттән мәхрүм итү димәктер. Хөррият игълан ителгәч тә, «Яшь төрекләр»нең бер кыйсьме шул исемне ташлау хосусында киңәшкәннәр иде. Әгәр шуңа корал биргән булсалар, дәүләтнең тамырына балта чабудан гыйбарәт булган бер хаталык иткән булалар иде. Без ул исемне алырга түгел, бәлки барлык көчемез берлә аны шул торган урынында сакларга тиешмез. Әһле исламның мәнфәгате шундадыр»,– диде.

Җирҗи Зәйдан әфәнденең «Тарих әт-тәмәдден әл-ислами» китабы хакындагы фикерен сорадым. (Җәмил бәк үзе сүзне тарих китаплары турында башлаган иде). «Мәзкүр әсәр хакында күп сүз сөйләнде. Һиндстан галимнәреннән берсе «Әл-Мәнар»да[1] аны бик нык интикад кылды[2] вә башка җәридәләр[3] дә яздылар. Шул нәрсәләр, әлбәттә, Сезгә дә мәнзур[4] булгандыр», – дидем.

«Әвәт[5], «Тарих әт-тәмәдден әл-ислами»дә хаталар бар. Ләкин алар – идракь[6] вә мәгълүмат кимлегеннән килгән хаталардыр. Җирҗи әфәнденең мөрәҗәгать иткән китаплары бик мәхдүд[7] булуы өстенә, ул аурупалылар фикеренә капкан. Аурупалылар ул фикерләрен, әлбәттә, безнең үз язучыларымыздан алганнар. Ләкин алар бераз үз максатларына муафыйк сурәттә[8] алмаштырганнар. Безнең бүгенге язучыларымыз исә мөстәшрикъләрнең[9] шул, асылда үзгәртелгән әсәрләрен үземезгә тәкъдим итәләр. Бүгенге мөхәррирләремезнең икенче

[1] «Әл-Мәнар» – Мисырда чыккан газета.
[2] Интикад кылды – тәнкыйть итте.
[3] Җәридәләр – газеталар.
[4] Мәнзур – күренгән, игътибарыгызны җәлеп иткән.
[5] Әвәт – әйе.
[6] Идракь – төшенү, аңлау.
[7] Мәхдүд – чикләнгән.
[8] Муафыйк сурәттә – туры китереп.
[9] Мөстәшрикъләрнең – шәркыятчеләрнең.

бер кабахәтләре дә үзләренә мәгълүм булмаган һәрбер нәрсәне нәфи вә инкарь итүләредер[1]. Мәсәлән, Җирҗи Зәйдан әфәнде «Әл-гарәб каблел-ислам» исемендә бер әсәр язган. Шул китабында, гарәпләрнең исламнан әүвәлге хәлләре хакында язылган китаплар юк, ди. Хәлбуки, ул вакытка караган тәмам ике мең китап язылган. Әлбәттә, ул китапларның бер өлеше бүгенгә килеп җитмәгәннәр. Безнең күңелсез эшләремезнең берсе – мәгълүматымыз кимлеге. Кулымызда булганнарны да татбикъ итә[2] алмавымыз вә һәр эштә аурупалыларга мөрәҗәгать итүемездер»,– диде. Җәмил бәкнең бу сүзләрдән максаты ислам тарихын язучыларымызның Аурупа чыганакларын гына алда тотуларын интикад кылуы булса кирәк. Сүзенең җаеннан мин шуны аңладым. Безнең өчен вакыт табуларына тәшәккер итеп[3] вә мөсахәбәмезнең бәгъзе кыйсемнәрен «Шура»га язар өчен изеннәрен[4] алып, яннарыннан чыктым.

*Сакмарыйның бу язмалары «Шура» журналының*
*1913 елгы 2 нче санында «Сәях»имзасы белән,*
*1913 елгы 22 нче санында «Сакмарый» имзасы белән*
*басылып чыккан*

[1] Нәфи вә инкарь итүләредер – кире кагулары, танымаулары.
[2] Татбикъ итә – чагыштырып карый.
[3] Тәшәккер итеп – рәхмәтемне белдереп.
[4] Изеннәрен – рөхсәтләрен.

**Сакмарый**

# ШАМНАН БӘГАЛЬБӘККӘ

## I
## Шамнан китү. Юлда бер мөдәррис белән мосахабә

Шамнан[1] кайтышлый Бәгальбәккә дә сугылып андагы мәшһүр хәрабәләрне вә иске әсәрләрне тамаша итеп кайтуны Бәйруттан үк ниятләп чыккан идек. Бәгальбәк хәрабәләренең тарихи әһәмияте икенче дәрәҗәдә генә булса да, анда гыйбрәт алыначак вә гакылларга хәйрат бирәчәк[2] күп нәрсәләр барлыгы мәгълүм иде.

Бәгалъбәк шәһәре Хәлеб юлы өстендә вә Шамнан Бәйрутка үтә торган юлдан 20–30 чакрым чамасы ераклыктадыр. Анда бару өчен Рияк дигән станциядә икенче поездга күчеп утырырга тугры килә. Чөнки Бәйрут берлән Шам арасындагы юл – тар юллар сафына мәнсүб булган[3] хәлдә, Хәлеб – Рияк юлы киң юлдыр. Шуның өчен Бәйрут – Шам юлында йөргән вагоннар Хәлеб – Рияк юлында вә соңгысында йөргәннәр беренчечендә йөри алмыйлар.

Чыктык. Чөнки бу поезд берлән киткәндә Бәгальбәккә барып хәрабәләрне тамаша иткәч, шул ук көнне Бәйруткә әйләнеп кайтып йитеп була иде.

Поезд төнлә китсә дә, Хәлебкә баручы поезд берлә согласование булганлыктан юлчы бик күп иде. Бәхетемезгә каршы без утырган купеда барасы биш кеше булырга туры килде.

Төркиянең диңгез буендагы шәһәрләреннән эчкә таба киткәндә полиция бернәрсә дә тикшермәсә дә, эчке шәһәрләрдән сахилгә[4] килүчеләрне нык тикшерәләр. Андыйларны рәтләп озатып

[1] Шам – хәзерге Сүриядәге Димәшкъ (Дамаск) шәһәре.
[2] Хәйрат бирәчәк – гаҗәпләндерәчәк, хәйран итәчәк.
[3] Мәнсүб булган – караган.
[4] Сахилгә – диңгез кырыена.

йибәрү өчен яшерен комитетларга кадәр тәшкил ителгән[1]. Күп акча бәрабәренә качучыларны үткәреп торалар. Шуның өчен эчке шәһәрләрдән йөреп Траблис, Хәйфа, Яффа станцияләренә килүчеләрнең кем икәнлекләрен вә кайда баргалыкларын тикшерәләр. Бәгъзе бер шөбһәле күренгәннәрнең нөфүс тәзкирәсен[2] дә алып калалар. Бу тикшерүләр белән генә дә канәгатьләнмичә, полицейскийлардан берсе поездга утырып юлда да сораша-сораша бара. Абайсызрак барып чыкканда, әҗнәбиләрнең[3] төрек кыйфәтендәгеләре дә шактый уңайсызлыкка төшеп калгалыйлар. Бу җәһәттән Шамда андый уңайсызлыкларга төшүдән мин Талиб әфәнденең танышлыгы вә янымдагы иптәшемнең жандарм куманданы[4] угылы булуы аркасында котылдым. Юкса Халебтән Траблиска вә Шамга китә башлаган вакыттагы уңайсызлыклар монда да киләчәк иде.

Поездны озата баручы полицейский үзе дә безнең күрше купега утырды вә юл буе безнең берлә сөйләшеп барды. Ул үзе гарәп булып, утырган урыны да Шам гына булганлыктан төрекчәне аз гына белә иде. Шулай да аркадашым куманлан угылы берлә аңлашып бара алды.

Поезд кузгалып китә башлагач, мин озатырга төшкән аркадашым берлә саубуллашып, Шам өстенә бер күз салдым. Мәрҗә мәйданындагы зур электрик лампаларының һавага күтәрелгән якты баганалары вә еракта җәбәл Касиюн[5] буендагы Салихия[6] өстендә йолдыз шикелле генә күренгән шәмнәр барысы берләшеп, күңелгә әллә нинди бер хис салалар иде.

Поезд кузгалып киткән вакытта вокзал өстендәге «Шәм – Бәрмәкә» дип язылган тактага тагын күзем төште. Ләкин бу вакытта ул тактаның биргән хисе беренче күргәндәге кебек түгел

[1] Тәшкил ителгән – булдырылган.
[2] Нөфүс тәзкирәсен – кешеләрнең рәсми документын (паспортын).
[3] Әҗнәбиләрнең – читтән килгәннәрнең.
[4] Куманданы – коменданты, начальнигы.
[5] Җәбәл Касиюн – Касиюн тавы.
[6] Салихия – Димәшкъ шәһәренең бер районы.

иде инде. Ул чакта мин үземне Һарун әр-Рәшид дәверенең[1] бер гражданы шикелле күргән идем. Ул вакытта алдымдагы Шам бик күп тарихи газыймәтләре[2] берлә мәдәни шәүкәтләрнең[3] зур бер мәгариф вә гыйлем мәнбагы[4] шикелле күренгән иде. Инде шул шәһәр хәяте эчендә бер атна торып, әхвале белән танышып, китә башлагач, үземне бер вәхши вә мәгънәсез хәят эчендә сиздем. Артымда калып барган шәһәрнең дә Багдад вә Куртубалар[5] берлә һичбер мөнәсәбәте булмыйча, аны төрек паша вә министрларының шәхси мәнфәгатьләре өчен залим кулларга сатып, хаксызлык вә истибдад[6] күсәкләре астында изелгән бер урын шикелле күрдем. Бу хәлләр миңа бик авыр тәэсир итте. Шамның аръягында шәүләсе генә күренеп торган таулары вә йолдыз шикелле генә ялтырап, иске хикәятләрдә сөйләнгән, төнен дөньяны очып әйләнә торган убырлы карчыкның утларын искә төшереп торган фонарьлары вә агачлар арасыннан шарылдап аккан Бәрда елгасы берлә видагълаштым[7] да башымны тәрәзәдән тартып алып эскәмиягә утырдым.

Купедагы юлчыларның берсе чалмалы бер шәех, икенчесе бер бала вә өченчесе дә гади эшче иде. Шәех үзенең Хәлебтә мәшһүр бер мөдәррис икәнлеген аңлатты. Үзен бервакыт Һиндстан көллиятләреннән берсенә мөдәррислеккә дә чакырганнар икән. Ләкин Хәлебтә калуны теләп, бармаган. Бала үзенең хәлебле икәнлеген вә аннан Шамга Салихиядәге Габделгани әнНәбаси тәкиясенә шурпа эчәр өчен (тәкияләрдә һәр көн бер-ике мәртәбә бушлай шурпа эчертү гадәте була) килгәнлеген вә хәзер үзенең Хамаста «Хамис әл-мөшаигъ» та булыр өчен китеп барганлыгын сөйләде.

---

[1] Һарун әр-Рәшид дәвере – Әбү Җәгъфәр Һарун бине Мөхәммәд (763–809), гарәп хәлифәсе (идарә еллары – 786–809). Һарун әр-Рәшид дәвере хәлифәлекнең аеруча алга киткән, шөһрәтле, данлыклы чоры санала.

[2] Газыймәтләре – әһәмиятләре.

[3] Шәүкәтләрнең – бөеклекләрнең, куәтләрнең.

[4] Мәнбагы – чыганагы.

[5] Куртуба – Кордова – Испаниядәге шәһәр. 929–1031елларда Өммәвиләр хәлифәлегенең башкаласы. 1226 елда христианнар тарафыннан яулап алынганчы, дөньядагы иң зур мәдәни вә икътисади үзәкләрнең берсе була.

[6] Истибдад – диспотизм.

[7] Видагълаштым – саубуллаштым.

Бу баладагы үткенлек вә каблиять[1] фәүкылгадә[2] иде. Ләкин шул каблиятьләр хата юл берлә йибәрелгән, баланы кешелек юлына түгел – бозыклык юлына тартып алып керткәннәр.

Мөдәррис минем русияле икәнлегемне белгәч, миңа аеруча илтифат күрсәтте вә Русия исламнарының әхвален сорашты. Сүзгә полис[3] та килеп катнашты. Сүз минем Шамдагы тәэсирләремә күчкәндә, мин җамигъ Өммиядәге шәехнең: «Әннәлмүлүкә изә дахәлү карьятән әфсадүһә вәҗаәлүкә гыйззәтә әһлиһа әзилләтән»[4] дигән сүзләрен нәкыль итеп[5]: «Гарәпләрдә төрекләргә каршы бик куәтле дошманлык хисе бар икән» дидем.

– «Гаҗәп, төрекләр, шул шәех әйткәнчә, сезнең хәлләреңезне начарландырдылармы? Бүгенге начарлыкларның башында да төрекләр гаепмеме?» дип, сөальне полицейскига бирдем. Полис: «Хәер, кабәхәтнең чиреге төрекләрдә булса да, калганы үз өстемездә» диде. Мөдәррис бер җавап та бирмәде.

Каршымда утырган шәехнең гомумдөнья вә ислам мәркәзе булган шәһәрләрдән берсенең мәшһүр бер мөдәррисе икәнлеген игътибарга алып, мин сүземне күбрәк дини мәсьәләләр тирәсендә йөрттем. Игътикад[6] вә гыйбадәт мәсьәләләре хакында сүз булды. Мәдрәсәнең мәүләви тарикате турындагы фикеремне язып үткән идем. Ахырда мин шәехкә соңгы сөалемне бирдем вә җавапларына игътираз итәргә[7] башта ук мөсәгадәсен[8] алдым.

«Гүзәл канәгатьләнмәдекеңез нокталарда теләгәнеңезчә игътираз итеңез» – диде. Шуннан соң мин сүзгә башлап, дидем:

Мөселманнарның артта калуына вә бер вакытларны дөньяның иң эшлекле вә иң мәдәни халыклары булган әһле исламның

---

[1] Каблият – сәләтлелек.

[2] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

[3] Полис – полицейский.

[4] Тәрҗемәсе: «Дөреслектә патшалар шәһәрләрне басып алсалар, анда хөсет вә бозыклык таратканнар һәм гыйззәтле, көч-куәткә ия булган әһелләрен түбәнсетә торган булганнар.

[5] Нәкыль итеп – сөйләп.

[6] Игътикад – (Аллага) ышану.

[7] Игътираз итәргә – каршы төшәргә, кире кагарга.

[8] Мөсәгадәсен – рөхсәтен.

бүген иң зәлил[1] вә иң хәкыйрь[2] милләтләр сурәтенә кичүенә сәбәп ни? Әнә Фас[3], әнә Җәзаир[4], әнә Мисыр, әнә Иран, әнә Һиндстан – болар барысы да бер вакытларны шәүкәтле вә газыймәтле[5] хөкүмәтләр булганнары хәлдә, бүген аурупалыларга кол булып, аларның басымы астында хәкыйрь вә пәришан[6] сүрәтендә яшиләр. Ниһаять менә Төркия. Моның да бит кул-аяклары баглы. Аурупаның ишарәсенә карап тора. Һинстанның хаким вә түрәләре инглиз кылычы астында үләчәк йирдә, король алдына сәҗдә кылулары берлә ифтихар итәләр[7]. Фасның «галим» вә «мокътәдир» әмире үз милләтен аяк вә кулын бәйләп французларга тапшыра. Бер вакытларны милләте вә дәүләте өчен дошман кылычы астында һәлак булуны дан, дәрәҗә санаган әмир вә хакимнәр ни өчен бүген аурупалылар аягына егылу берлә ифтихар итәләр? Мөселманнарның артта калуларына сәбәп итеп ислам дошманнары исламиятнең үзен күрсәтәләр. «Исламият мәдәнияткә мөсагыйд[8] түгел. Ул һәр төрле тәрәккыйга каршы вә үзенә буйсынучыларны хур вә хакыйрь булып яшәргә этәрә», диләр. – Мөселманлык кешегә шәрәф вә намус берлә мөстәкыйль яшәү юлларын күрсәтә алмый. Мөхәммәд галәйһисәламның күрсәткән кануннары бу заманның таләпләренә җавап бирә алмый. Шунлыктан мөселманнарда гыйззәт, нәфес вә истикъляль[9] калмады. Инде алар бетәргә мәҗбүр. Коръән вә сөннәткә ябышып ятулары берлә мөселманнар үз каберләрен үзләре казыйлар, – дияләр.

Менә боларга ни җавап бирергә тиешле. Юкса аларның әйткәннәре бер дәрәҗәгә кадәр тугрымы? дидем.

Шәех үзе дә бәгъзе шундый сөальләрне уйлаганы яки фикер йөрткәне булган кеби сөйләп китте.

---

[1] Зәлил – кадерсез, түбән.
[2] Хәкыйрь – хурланган, түбән дәрәҗәле.
[3] Фас – Марокко.
[4] Җәзаир – Алжир.
[5] Шәүкәтле вә газыймәтле – куәтле һәм бөек.
[6] Пәришан – харап булган сүрәттә.
[7] Ифтихар итәләр – мактаналар, горурланалар.
[8] Мөсагыйд – мөмкинлек бирүче, ярдәм итүче.
[9] Истикъляль – бәйсезлек, берәүгә дә буйсынмау.

«Мөселманнарның һәр囯эштә артка калуларына сәбәп аларның ислам хөкемнәрен бер тарафка ташлап Аурупа канун вә кагыйдәләрен кабул итеп китүләредер. Иске дәверләрдә мөселманнар һәр эштә Коръән вә сөннәт берлә гамәл итә, вә һәр эшләрендә шул икене рәһбәр[1] тота иделәр. Шуңа күрә ул вакытта мәмләкәтләр бөек, идарәләр гадел вә әһали мәсгуд[2] иде. Инсаннарның дөнья вә ахирәт сәгадәтләре өчен кирәк булган әхкямен[3] барлык исламият кануннарын үтәүнең берлеге һәр нәрсәдә күренә иде. Аллаһның сүзе вә рәсүлнең сөннәте каршында башка әмерләрнең куәте юк иде. Кәйфи[4] идарәләр, кәйфи әмерләр ул вакытларда мәйданда юк иде. Ул вакытларда дөнья эшләре ахирәт хәзерлекләрен туктатып калмый иде. Дин хөкемнәре бик авыр минутларда да үтәлә иде. Ул вакытта һәр кем дин берлә яши иде. Ни вакыт мөселманнар дини хөкемнәрдә мөсаһәлә итә[5] башладылар. Ни вакыт алар Коръән, хәдис урынына Аурупа кануннарын татбикъ иттеләр[6]? Ни вакыт алар дөньяви файдаларны ахирәт сәгадәткә алмаштырып, дөнья рәхәте, дөнья ләззәте өчен даими әхкямдә[7] мөсаһәлә[8] күрсәтә башладылар – шул вакыттан игътибара алар зәлил[9] булдылар. Шул дәкыйкадән башлап аларда хурлык вә хәкыйрьлек күренде. Иранның да, Фасның да, Җәзаирнең дә, Төркиянең дә фаҗигасы ошбудыр. Эш башына Камил паша килә – төзәлми, Сәгыйд паша килә – һаман төзәлми... Мәхмүд Шәүкәт килә – бер үзгәреш юк. Ничек төзәлсен соң ул? Төркиянең хакыйкый кимчелеге кеше юклык түгел, бәлки дин әхкямен ригая итмәүдер[10].

Ислам хөкемнәрен тиешенчә тотмагач, эш башына кемне генә куйсаң да файда чыкмый. Төркияне төзәтәчәк нәрсә сәясиләр-

[1] Рәһбәр – юл күрсәткеч, үрнәк (итеп).
[2] Әһали мәсгуд – халык бәхетле, игелекле.
[3] Әхкямен – хөкемнә,. законнар,
[4] Кәйфи – формаль.
[5] Мөсаһәлә итә – әһәмият бирми.
[6] Татбикъ иттеләр – килештерделәр, яраклаштырдылар.
[7] Әхкямдә – хөкемнәрдә, карарларда.
[8] Мөсаһәлә – йомшаклык, әһәмият бирмәү.
[9] Зәлил – хурлыклы, кадерсез.
[10] Дин әхкямен риная итмәүдер – дин хөкемнәрен кайгыртмау.

нең мәһарәте[1] түгел, бәлки ислам хөкемнәренең тотылуыдыр. Угрының кулын кис – шуннан соң дөньяда угры күрмәссең. Зина итүчене рәҗем берлә[2] үтер – шуннан соң берәү дә ул эшкә бармас. Кыскасы, мөселманнарның артта калуына, башлыча, сәбәп диндәге мөсаһәләләре вә икенче дәрәҗәдә – әмирләрнең золымнары».

Мин Аурупа кануннарын кабул итүләре мөселманнарның артта калуларына сәбәб булды, дип вакыйгка мотабикъ булуы[3] бетмәсә кирәк. Шул ук кануннар буенча хәрәкәт иткән аурупалылар артка калмадылар, бәлки гаҗәп бер рәвештә алга киттеләр. Ислам хөкүмәтләре арасында Аурупа канунын гамәлияткә куйган хөкүмәт, безнең белүебезчә, ялгыз Төркиядер. Мөселман дәүләтләренең инкыйразына сәбәп, аларның Европа кануннарын алмый, Коръән вә сөннәткә ябышып ятулары булды, дип әйтергә мәйданда дәлилләр күбрәк булса кирәк. Фаста ислам кануны татбикъ ителә иде. Бохара вә Иранда рәҗемнәр йөртелә иде.

Аларга үзләре мөнкариз[4] булганчы Аурупа кануны кермәде, ләкин мөнкариз булдылар. Мөселман идарәсе астында яңадан хәят кәсеп итеп киләләр. Аурупаның кануны да, санагате[5] да кермәгән мөкаддәс хәрәмәен[6] бар. Ләкин ул иң мөкаддәс шәһәрләрдә дә төзек хәят, хакыйкый мәсгудият[7] юк. Мөселманнарның артта калуларына сәбәпне читтән килүче тәэсирләрдән түгел, үз араларыннан, үз эчләреннән эзләргә кирәктер.

Корал вә мәгариф куәте ярдәмендә галиб булу[8] берлә диндә мөсаһәләләр арасында күп мөнәсәбәт булмаса кирәк.

Бәйрүт лиманындагы[9] «Гаун Аллаһ» вә «Әнкара» сугыш көймәләрен Шам «Өммиясендә «Сахих Бохари» хәтем итүләр

---

[1] Мәһарәте – осталыгы, маһирлыгы.
[2] Рәҗем берлә – кешене билгә кадәр җиргә күмеп таш атып үтерү.
[3] Вакыйгка мотабикъ булып – дөреслеккә туры килеп.
[4] Мөнкариз – сүнгән, юкка чыккан.
[5] Санагать – промышленность,
[6] Хәрәмәен – Мәккә, Мәдинә шәһәрләре.
[7] Хакыйкый мәсгудият – чын бәхет, рәхәтлек.
[8] Галиб булу җиңүгә ирешү.
[9] Лиман – диңгез култыгы.

дә[1] Италия тупларының һәлакәтеннән коткарып алып кала алмадылар.

Элек диндә мөсаһәлә[2] юк иде. Инде мөсаһәлә башланды. Хәятләре дә юньнән чыкты. Һәр эштә артка калдылар, дияргә юл булмаса кирәк

Әмирләрнең золымнары да бүген генә мәйданга килгән нәрсәләр түгел. Гарәп дәүләтенең иң парлак[3] дәвере булган Һарун әр-Рәшид халифәтен алыңыз да аның әмер идарәсе астында эшләнгән вәхшәт вә золымнарга бер күз салыңыз. Коруне вөстада[4] Аурупадагы король вә императорларның золымнары астында нинди трагедияләр уйналды. Шулай була торып та коруне вөста Аурупасы бүгенге мәдәни Аурупаны үстереп чыгарды.

Госманлы солтанатын алыңыз. Золым берлә үтерелгән инсаннарның каны берлә коенган солтаннар дәверендә госманлы төрекләре Вена капулары төбенә килделәр. Шунлыктан мин сезнең бәян иткән нәрсәләреңездә ислам дөньясының тәдәннисенә[5] хаклык күрә алмыйм. Сезнең сөйләгән сүзләреңез һәрберсе тагын бер «нигә алай булган?» сөален генә арттыра», дидем. Сохбәт шул кадәр татлы булганга без «Рияк»ка йиткәнемезне тоймый да калганмыз. Мин фикерләремне әйтеп бетерүгә поезд туктап, халык төшә башлады. Без дә ашыгып төшеп, безне көтеп торган Хәлеб поездына барып утырдык. Анда урын бик тыгыз булганлыктан, без шәех берлә бер вагонга туры килә алмадык.

Моның өчен бик тәәссеф иттем.[6] Чөнки шәехнең минем сорауларыма бирәсе җаваплары, ихтимал, тагын бераз нәрсәләрне кәшеф итәрләр[7] иде.

[1] Шам «Өммия»сендә «Сахих Бохари» хәтем итүләр – Димәшкънең «Өммия» мәчетендә «Сахих Бохари» дип йөртелгән Бохари туплаган хәдисләрне уку да.

[2] Мөсаһәлә – йәмшаклык күрсәтү, игътибар җитмәү.

[3] Парлак – шөһрәтле, данлыклы.

[4] Коруне вөстада – урта гасырларда.

[5] Тәдәннисенә – түбән төшүенә, артта калуына.

[6] Тәәссеф иттем – ачындым, үкендем.

[7] Кәшеф итәрләр – ачырлар, мәйданга чыгарырлар.

Күп тә тормый поезд кузгалып китте. Кояш яңа гына күтәрелеп килгәндә, безне Бәгальбәк станциясенә алып барып төшерде. «Рияк» берлә «Бәгальбәк» арасында киң вә тигез йирдән шималь-шәркыйга[1] таба оча иде. Бик еракка сузылган бу тигез йирдә йитешкән бодай бөтен тирә-якны туендырып торадыр.

## II
## Бәгальбәк хәрабәләре

Вокзалга килеп төшкәч тә әйберләремезне урнаштыруның бер җаен карадык. Чөнки Бәгальбәктә кунмаячак булганымыздан аларны номерга алып барып йөрү бер дә файдасыз расход булачак иде. Ләкин кая куярга? Сүриядәге француз чуен юлларында сакларга бирү ысулы да юк. Ахырда станциядә торучы жандарманың бүлмәсенә куеп киттек.

Шәһәргә барып, бер кечкенә генә, пычрак кына ашханәдә иртәнге ашны ашагач та, беренче эшемез хәрабәләрне тамаша итәргә китү булды.

Бәгальбәк хәрабәләре үзләренең гүзәллекләре вә таза саклантулары берлә Сүриядәге хәрабәләрнең барысыннан да өстен торалар.Тик Пальмира хәрабәләре генә алардан яхшырак диләр. Ләкин тарихи җәһәттән Бәгальбәк хәрабәләре, югарыда дигәнемчә, икенче дәрәҗәдә торалар. Траблис, Каркамиш вә Бугаз көе хәрабәләре убылып баткан балчыктан гына булсалар да, тарихи ноктадан караганда, беренче урында торалар. Бәгальбәк хәрабәләре никадәр тәфтиш ителсәләр[2] дә, аларның зур бер милләтнең тарихын ачып салу шикелле мөһим бер нәтиҗә бирү ихтималлары юк. Бәгальбәкнең асыл нигезләре, искә алынган милләтләрнең тарихлары да бик ышанычлы чыганаклардан мәгълүм. Ул милләтләрнең җенеси, дәрәҗәи мәдәнияте вә тарихындагы мәүкыйгы[3] әллә кайчан билгеләнгән диярлек. Төрле зан вә тәхмин[4]астында гына йөргән, вакыйгалары яхшы-

[1] Шималь-шәркыйга – төньяк-көнчыгышка.
[2] Тәфтиш ителсәләр – өйрәнелсәләр, тикшерелсәләр.
[3] Мәүкыйгы – урыны.
[4] Зан вә тәхмин – шик вә чамалау, якынча билгеләү.

лап тәкъдир ителмәгән бер милләтне уртага чыгарачаклардыр. Тарихта исемнәре генә билгеле булган җенес – милләте, дине, мәдәнияте вә тарихи әһәмияте күрсәтелә алмаган хәтитләрнең мөстәкыйль бер милләт булып танылулары вә аларның бүген дә терек булган кавемнәрдән кайсысына туган булулары, ялгыз шул хәрабәләрдә булган нәрсәләрне тәдкыйк саясендә[1] булачактыр. Хәтит кавемен – Хәтит мәдәниятен әйтсәләр шул хәрабәләр раслый алачаклардыр. Җәсим-җәсим[2] бинालары берлә гакылларга хәйрат вә дәһшәт биреп торган Бәгальбәкнең икенче дәрәҗәдә булып та, өелеп яткан балчыктан гына гыйбарәт булган Каркамиш вә Траблисларның беренче дәрәҗәдә булулары ошбу ноктадандыр.

Хәтит шәһәренең хәрабәләре вә алар хакында табылган әсәрләр безнең төрек тарихы һәвәслеләре өчен дә гүзәл бер мәйдан була алыр иде. Чөнки хәтитләрнең төрек нәселеннән булуларын дәгъва итүчеләр бар. Әгәр дә бу расланса вә яңа гына очы күренеп килгән хәтит мәдәниятнең җебе тулысынча мәйданга чыга. Мисыр, Ассур, Бабил, Рума, Юнан, Кытай мәдәниятләре янында, бердән, төрекләрнең мәдар ифтихары[3] булып бер хәтит-төрек мәдәнияте дә торыр. «Төрек кауме вәхшәт вә гарәттән[4] башкага сәләтле түгел. Алар башкаларның мәдәниятен аз-маз икътибас итә[5] алсалар да үзләре бер нәрсә бирә алмыйлар» диючеләрнең йөзләрен кызартыр иде. Чөнки хәтит мәдәниятенең мөстәкыйль бер мәдәният икәнлегенә дәлилләр күренә башлады.

Бәгальбәк хәрабәләре берничә еллар тәртипсез яткан булсалар да, соңгы елларда (Хәмид дәверендә[6] булса кирәк) музаэ һәмаюн[7] идарәсенә башлыча немец мөтәхассыйсләрен[8] йөрткәннәр. Император Вильһельм дә Фәластыйн сәяхәтендә

[1] Тәдкыйк саясендә – нечкәләп, детальләп тикшерү рәвешендә.

[2] Җәсим-җәсим – зур-зур.

[3] Мәдар ифтихары – горурлыклары нигезләре.

[4] Гарәт – басып алу, баскаклык.

[5] Икътибас итә – үрнәк ала.

[6] Хәмид дәверендә – Төркия солтаны Габделхәмид II (1842–1918) күздә тотыла. Аның идарә еллары – 1878–1909.

[7] Музаһәмаюн – бирелә: үзәк музей мәгънәсендә.

[8] Мөтәхассыйсләрен – белгечләре, специалистлары.

Бәгальбәкне зиярәт иткән. Шуңа ядкәр итеп Бахус мәгъбәденең[1] стенасына бер мәрмәр таш куйдырып, шуңа үзенең зиярәтен яздырып киткән. Хәрабәләрне әйләндереп алган бик биек таш койма булганлыктан аның эченә кайдан тугры килсә-шуннан керерлек түгел. Тамашачылар зур тимер капкасына килеп музәэ һәмаюн файдасына алына торган сиксән тиенне биреп, заирләр[2] дәфтәренә исемнәрен язып керәләр. Без дә, сиксән тиенгә сатылган марканы алганның соңында, салмак кына ачылган тимер капудан кереп, баскыч буйлап югары катка менеп киттек.

Хәрабәләрне мәфсыйл сүрәттә[3] тасвир итәргә мәҗбүрлек юк. Бу аның урыны да түгел. Тарих мөтәхассыйсы булмаганнар өчен аның ул кадәр кызыгы да булмас. Шунлыктан мин аңар керешмим. Ләкин кальганың капкасыннан барып кергәч сине каршы алган дәһшәтле вә газамәтле мәгъбәдләрне[4], һаваларга чыгып утырган[5] төрле нәкышле юан-юан төрбәләрне, яртылай ишелгән калын вә җәсим диварларны вә алар өстендә бүгенгә кадәр сәламәт саклаган төрле нәкышләрне, уртада өелеп яткан зур түгәрәк ташларны, төрле йирдә күренеп торган хәвез вә михрабларны әйтми үтеп булмый. Кайсы бер михраб алдында потларның эзләре дә тора.

Йир өстенә хәлифә булырга яратылган адәм балалары ничә гасырлар шул потлар алдына тезләнеп никадәр хайваннар вә бәлки дә инсаннар корбан иткәннәрдер. Гакыл нигъмәте берлә мәсгуд ителгән адәм балалары ничә потлар алдына тезләнеп вәһем[6] вә хыял әсире булып яшәгәннәрдер. Әгәр дә шул вакытта аларга барып ул хәрәкәтләренең мөнәсәбәтсезлеген аңлатсаң вә андый вәһем әсире булмыйча, реальрәк бер юл тотарга кирәклеген сөйләсәң, алар ул «дин»нәрнең тугрылыгына әллә никадәр гакылый дәлилләр китерәләр вә шуннан башка бер юл берлә

[1] Мәгъбәденең – гыйбадәтханәсенең.
[2] Заирләр – карарга килүчеләр (посетитель).
[3] Мәфсыйл сүрәттә – биредә: җентекләп мәгънәсендә.
[4] Газамәтле мәгъбәдләрне – мәһабәт гыйбадәтханәләрне.
[5] Һаваларга чыгып утырган – (түбәләре) күккә ашкан.
[6] Вәһем – хыялдагы уй, буш уйлар.

дөньяви вә ахирәви[1] сәгадәткә ирешү мөмкин түгеллеген бик күп «дәлил»ләр берлә күрсәтерләр иде. Чөнки инсанның дини хәятендә гадәт кадәр зур роль уйнаган бер гамәл юктыр. Шул гадәт һәр эшне диярлек тугры вә мөнасиб[2] күрсәтә. Күптән түгел Франциядә дин берлә хөкүмәт бер-берсеннән аерылгач, бәгъзе «суллар» инсаннарны вәһем вә хыял әсире булып йөрүдән коткардык, дип мактандылар.

Гаҗәп, бүгенге Франция – бүгенге галәм вәһем вә хыял әсире булуда иске заман әһалисеннән күп алга киткәнме? Бу уйларга җавап гади генә түгел.

Стенасы бүген дә бөтенләй диярлек сәламәт торган «Бахус» мәгъбәде янына барып кәрнизләргә салынган зур ташларны вә мәгъбәднең әйләнәсендә утырган гранит баскычларны вә диварлар салынган таш кисәкләрен тамаша иткәндә: «бу шәһәрне җеннәр салган» дигән фикерләргә кушыласы килеп куя. Хәзерге заман шикелле механика вә җәрре әскаль[3] галәмнәре[4] тәрәкъкый иткән бер заманда да аларны салу, шул кадәр зур ташларны әллә ничә аршинлы биеклеккә күтәреп аларны әллә ничә мең еллар торырлык мәхкәм[5] итеп кую гадәп тоелыр иде. Иске замандагы корал вә ысуллар берлә аларны эшләү могъҗизадыр. Кальганың бер читендә яткан, озынлыклары 27 берлә 26 аршын арасында вә киңлеге берлә калынлыклары 6 аршын булган өч зур таш гакылларга хәйрәт бирерлек[6].

Өчесе бергә алынганда сиксән аршын озынлыкта булган бу ташлар шул кадәр гүзәл беркетелгәннәр ки, дикъкать берлә карамаганда араларындагы җекләр[7] күренми.

Мәгъбәдләренең[8] тирә ягындагы баганалар 22–25 аршын озынлыкта булып, әйләнәләре тугыз аршындыр.. Кызыл граниттан ясалган бу баганалар берсе өстенә берсе утыртылган өч

[1] Ахирәви – ахирәттә, теге дөньяда булачак.
[2] Мөнасиб – яраклы итеп.
[3] Җәрре әскаль – механика фәне.
[4] Галәмнәре – өлкәләре.
[5] Мәхкәм – чыдам, нык.
[6] Хәйрәт бирерлек – гаҗәпләндерә, аптырашта калдыра.
[7] Җекләр – (бер-берсе белән) тоташкан урыннар.
[8] Мәгъбәдләренең – гыйбадәтханәләрнең.

кисәктән гыйбарәт. Мисыр вә Фәләстыйнда андый гранит юк. Аларны Африкадан, Нубия мәмләкәтләреннән китерелгән дип зан итәләр[1]. Болардан Бәгальбәкне бина итүгә сарыф ителгән вакыт, иҗтиһад вә куәт хакында бер фикер алу мөмкиндер.

Кальга эчендәге биналар барысы да иске булмыйча, араларындагы гарәпләр тарафыннан арттырылганнары да бар. Ләкин гарәп биналары шул кадәр күрексез. Алар мәгъбәдләр янында, корылган алмаз янындагы кырчык ташы шикелле торалар. Гарәпләр ул биналарны мөдафәга[2] максаты берлә ясаганлыктан, гүзәллек фәлән шикелле җәһәтләргә игътибар да итмәгәннәрдер. Алар тарафыннан ясалган калын диварлы бер таш бина бүген дә тәмам сәламәт, нинди генә нәрсәгә әйләндерсәң дә ярарлык.

Вакытында ул зиндан булган, имеш. Кальганың бер почмагындагы тирән базлы бер бинаны да безгә юлбашчылык итеп йөргән вә Бәгальбәк тарихында ихтисас[3] дәгъва иткән бер кеше мәлик әл-Заһир мәхбүс булган йир дип, күрсәтте.

Югарыда зикер ителгәннәр барысы да кальганың өстәге катында булып, баскыч берлә аска төшкәч тә бик күп йир асты юллары, тирән базлар вә рәттән сузылып киткән ат абзары шикелле нәрсәләр күренә. Ләкин эчләре караңгы вә урыны берлә пычрак булганлыктан, андагы караңгы базларда йөрергә тугры килмәде.

Бәгъзе тарихчылар Бәгальбәкнең тарихын өч дәвергә бүлеп – румалылар дәвере, христианнар дәвере, гарәпләр дәвере дип йөртәләр. Гарәпләр дәвереннән югарыда искә алынган зиндангар берлә бер мәсҗед хәрабәсе калган. Дәллялның[4] сүзенә күрә ул мәсҗед солтан Сәлахеддин Әйюби[5] тарафыннан бина кырылган, имеш. Ләкин христиан дәверенә караган нәрсәләр күземә төшмәде.

[1] Зан итәләр – фаразлыйлар.

[2] Мөдафәга – (дошманга каршы торып) үзен саклау, каршы торып сугышу.

[3] Ихтисас – белгечлек, бер эшнең яхшы белгече булу.

[4] Дәллялның – юл күрсәтүче, экскурсовод.

[5] Солтан Сәлахеддин Әйюби – Сәлахеддин Йосыф бине Әйюб (1138–1193), күренекле хәрби һәм дәүләт эшлеклесе. Сүрия һәм Мисыр солтаны. Күренекле гаскәр башлыгы.

Бу гаҗәиб кальганың бани вә мөәссәсләре хакында тарихчылар арасында ихтиляф[1] бар. Бәгъзеләр «аскы каты финикиялеләр вә өске каты румалылар эше» диләр. Бәгъзеләр бөтен кальганы бина итүче Сөйләйман галәйһиссәләләм диләр. Хакыйкатен, әлбәттә, бер Аллаһ кына беләдер. Ихтимал, киләчәктә мәгълүм булыр. Ләкин кем генә бина итсә дә, ничә мең еллык җил вә яңгырларга күкрәк киереп утырырлык вә гасырлар кояшына каршы мөтәәссир[2] булмый тора алырлык бер мәтинлек[3] вә мәхкәмлек[4] берлә бина ителгән мәгъбәдләр калдыгын күргәндә гаҗәпләнми мөмкин түгел.

Бәгальбәктә иске әсәрләр әледән әле табыла вә тарихи кыйммәте булганнары Истанбулга музәэ һәмаюнга озатыла тора, имеш. Истанбулга йибәрелми калган нәрсәләргә махсус та хәрабәләрнең бер читендә «музәэ һәмаюн шөгъбәсе»[5] ачылып, алар шунда сакланалар. Балтачылык сәнгатеннән бер дә хәбәре булмаган берсе тарафыннан утыртып куелган бер капка өстенә «музәэ һәмаюн шөгъбәсе» дип бик начар язылган язуны күргәч, төрекләрнең мәдар ифтихарлары булган нәрсәләреннән берсенең исемен алай пычратуларына ачуым килеп, чыгып киттем. Төркиянең йәмәндәге идарәсен күреп кенә Истанбул вә Анатулы әхвәле хакында язучы вә сөйләүче сәяхләр булган шикелле, музәэ һәмаюннең бу «шөгъбәсен» күреп, аның Истанбулдагысы хакында да фикер йөртүче вә сөйләүчеләр ихтимал бардыр дип хәтеремә килде.

## III
## Бүгенге Бәгальбәк шәһәре

Бүгенге Бәгальбәк хәрабәләрнең шәркында[6] ике тау арасына елга буена бик матур бер йиргә утырган күңелле генә бер уездный шәһәрдер. Манзара вә һава җәһәтенчә ул якын

[1] Ихтиляф – фикер төрлелеге.
[2] Мөтәәссир булмый – йогынтыга бирешмичә.
[3] Мәтинлек – чыдамлык, какшамаслык.
[4] Мәхкәмлек – тазалык, ныклык.
[5] Шөгъбәсе – бүлеге.
[6] Шәркында – көнчыгыш ягында.

тирәдәгеләрдән бик күпкә өстен тора. Утырган урыны диңгез сатыхыннан[1] бик күп югары тора. Анда табыла торган йимешләрдән бик күпләре йитешә. Үзендә арзанчылык. Сөт, катык, май, ит, күмәч, сәбзә[2] вә шуның шикелле нәрсәләр бик арзан.

Сәяхләр бик күп килә торган бер урын булганлыктан, Бәгальбәктә гүзәл вә мөкәммәл гостиницалар бар.

Кайберәүләр иске әсәрләр берлә сәүдә итә. Әһалисенең кәсебе мосафирләргә дәляллык[3] эше вә төрле йимешләр йитештерүдер.

Бәгальбәкнең бер шөһрәте – суы берләдер. Бик саф вә суык елгасының чыгып яткан урыны да шәһәрдән бик ерак түгел. «Раэсел-гайн» дигән җирдәдер. Шәһәр халкы вә сәяхләр анда йөрер вә истирәхәт[4] итәр өчен барырлар. «Раэсел-гайн» янында Бәгальбәкнең иң гүзәл гостиницасы вә бик гүзәл бакчасы, каһвәханәсе бар. Хәрабәләрне тамаша итеп беткәч, без дә анда барып «Раэсел-гайн»нең яшел үлән берлә капланган яры өстендә истирәхәт иттек вә шундагы каһвәханәдә чәй хәзерләтеп эчтек. Биргән чәе бәрабәренә акчаны да ала белде. Ләкин әллә ничә урында ургылып кайнап торган саф вә салкын суда уйнаган балыкларга карый-карый агач күләгәсе астында эчелгән ул чәй бик татлы булды. Каһвәчегә алганы хәләл булырлык иде. Чишмәнең янында гына зур бер мәсҗед хәрабәсе бар. Стенасы вә михраблары – барысы да сәламәт, тик түбәсе генә юк.

Ишек вә михраб өстләрендәге язулары да ачык укылып торалар. Ташларына караганда бу мәсҗед хәрабә ташларыннан салынган булса кирәк.

Бер вакытларны мөселманнарның көненә биш мәртәбә калебләре берлә Аллага юнәлә торган урыны булган бу мәсҗедкә бүгендә дә үткән-киткән кешеләр көненә әллә ничә мәртәбә кереп чыгалар икән. Ләкин бөтенләй башка бер максат өчен.

Хәрабәләрне тамаша итеп «Раэсел-гайн» вә башка мәшһүр урыннарны күргәч, урамда очраган балаларның «бәхшиш[5], бәх-

[1] Диңгез сатыхыннан – диңгез өсте биеклегеннән.
[2] Сәбзә – яшелчәләр
[3] Дәлияллык – арадашчылык, юл күрсәтеп озатып йөрү (экскурсовод)
[4] Истирәхәт – ял
[5] Бәхшиш – бүләк итеп, бушай бирү.

шиш» дигән тавышлары вә зурракларының «иске нәрсәләр, иске акчалар алмыйсызмы?», – дип кычкырулары астында станциягә юнәлдек.

Без барганда поезд китәргә күп калмаган иде. Жандарм бүлмәсеннән нәрсәләремезне алып, үзенә бераз һәдия бирәчәк булдык. Ләкин никадәр тәклиф итсәк[1] тә алмады.

Без Бәйрутка килеп төшкәндә сәгать унбер бар иде. Ул вакытта көллияткә керү мөмкин булмаганлыктан, бер номерның кандалалы, пычрак бүлмәсенә урнаштым. Ләкин үземнең тауларга карап торган гүзәл һавалы вә гүзәл манзаралы бүлмәмдәге үземнең тимер караватым күз алдыма килеп, йоклый алмадым. Икенче яктан, кандалалар да бик нык кунак иттеләр. Бик кыенлык берлә төнне үткәргәч, көллияткә кайтып, андагы дуст-ишләрне күреп, әхвальләрен сораштым. Ләкин төнлә бер дә йокламаганлыктан бик борчылган идем. Шул сәбәптән, көндезге ашны ашагач та, сәгать көндезге бердә үз бүлмәмә кереп таза караватыма рәхәтләнеп ятып йоклап киттем. Мин уянганда сәгать иртәнге сигез иде... Иртән торганда үземне сәяхәтемнән шул кадәр мәмнүн[2] хис иттем ки, икенче елны Хәлеб вә Хамас[3] якларына барып кайтырга күңелемне шунда ук беркетеп куйдым.

*«Шамнан Бәгальбәккә» дип аталган бу сәяхәт язмасы «Сакмарый» тәхәллүсе белән «Шура» журналының 1914 елгы 6 нчы һәм 7 нче саннарында басылып чыга*

[1] Тәклиф итү – көчләп бирү, көчләп тәкъдим итү.
[2] Мәмнүн – канәгать.
[3] Хәлеб вә Хамас – Урта диңгез буендагы шәһәрләр.

**Х. М.**

# КАВКАЗ СӘЯХӘТЕННӘН

Беренче августта Сызраньнан пароходка утырып Хаҗитарханга китдем. Мин кайда булса барсам, һәрвакыт күзем берлә мөселманнарны эзлим, күрсәм, анларны һәм анларның хәлләрене тикшереп багам. Пароходда мөселманнан әйтерлек, күзгә чагылырлык кеше күрелмәде.

Саратовта безнең пароходымыз биш сәгать торачак булганга, шәһәрне гизәргә китдем. Анда яхшы урамнарны, күркәм өйләрне, багчаларны багып йөрдем. Берәр кибетгә вә берәр каһвәханәгә кердем, үземә төрле халык очрады: урыс, нимес, әрмән, яһүд – әмма һичбер мөселман күрелмәде. «Анларны кайда күрермен?» – дип берәүдән сорасам: «Анлар талчукда булырлар», – диде. Пароход кузгалып киткәч, Саратов чиркәүләре, өйләре күренеп калды. Шунлар арасында биноколь берлә бик тырышып баксам да, мәгаттәсеф[1], мәсҗедне эзләп таба алмадым. Саратов губернасында мөселман байтак булса да, шәһәрдә мөселманнарның үзләре, тормышлары вә барлыклары түгел күзгә бәрелеп торырга, эзләп табарлык түгелдер икән.

Сорочинда пароходымыз тагын биш сәгать торырга булды. Мин тагы шәһәрне гизәргә чыкдым. Яхшы урамнарны, багчадагы, бездә үсми торган җәнүб агачларыны, гөлләрене тамаша кылгач, арбачы берлә мөселманнар тора торган урамнарга китдем. Башда арбачы: «Урамнар бик койты[2], багар өчен анда берни дә юк һәм үзе бик ерак, шәһәрнең иң читендә», – дип, үземне бармаска үгетләсә дә, минем мөселман икәнне һәм мәсҗед күрәсем килгәнне аңлагач, барырга разый булды. Байтак озак баргач, мөселман мәхәлләсенә ирешдем. Арбачының сүзләре бар да чын булды. Анда, урамда берничә мөселман ир, хатын, бала күрдем. Мөселман фамилиясе язган кечкенә генә кибетләр

[1] Мәгаттәсеф – кызганычка каршы.
[2] Койты – начар.

очрады, ахырда мәсҗедне күреп бераз баккач, кире пароходка кайтдым. Мәсҗед урамның почмагында ташдан салынган, үзе зур түгел карсак[1], архитектурасы бик ямьсез, янына барып йиткәнче күрелми. Баруым бушка булмады: арбачы бер мөселман хәлене сөйләп мине куандырды. Анда бер яхшы ук бай гына мөселман булып, зур гына эш кыла икән. Байтак йортлары, мал куяр өчен амбарлары бар икән.

Хаҗитарханга йитдек. Монад күренеш бөтенләй алмашынды. Эчке Русиягә бер дә охшамый. Пароходны каршы алырга урыс, татар, иранлы, кавказлы, әрмән, яһүд чыкканнар. Бар да кайнашып, мыж итеп йөриләр. Тәҗрибә берлә баксам[2], арада күбрәк мөселман күренде. «Менә бу шәһәр чыннан мөселман каласы икән», – дип, күңелгә шадлык керде. Иранлылар монда күбрәк йөк ташучы икән.

Петровскига барыр өчен, мин икенче пароходка утырдым, халыклар бер-берсе берлә саубуллаша, бер-берсенә башра яулык селки башладылар. Күзләрем мөселманнарны эзли башлады, әмма беренче вә икенче классларда бер мөселман да таба алмадым. Бая шадланганга күңелем суынып китде. Шулкадәр мөселман арасында беренче йә икенче классда бер генә адәм күрелмәде. Байлык берлә тормышның яхшы ягы башкалар кулында булгач, мөселманнарның коры күбчелекләрендә күп мәгънә юк.

Парходымызда бер әрмән кәшише[3] бар иде. Яхшы, ыспай киенгән, үзене озатучы әрмәннәр дә юкары[4] сыйныфдан икәнлекләре мәгълүм иде. Араларында бер инженер вә бер дахилия вәзарәтендә[5] хезмәт итүче дә бар иде. Кәшиш берлә юл буе сөйләшеп бардык. Урысча бик яхшы, әдәби тел берлә сөйли. Хаҗитарханда 5–6 әрмән мәхәлләсе булып, кәшишләр мәхәлләдән вазифа[6] алалар икән. Әрмәннәрдә кәшишләр укып чыгар өчен,

---

[1] Карсак – тәбәнәк.
[2] Баксам – карасам.
[3] Әрмән кәшише – әрмән рухание.
[4] Юкары – югары.
[5] Дахилия вәзарәтендә – эчке эшләр министрлыгында.
[6] Вазифа – хезмәт хакы.

берничә семинария бар икән. Анда уку әрмән телендә булып, дин гыйлеменнән башка дөнья фәннәрене һәм урыс телене дә укыталар, шунда имтихан биреп чыгучылар кирәкле йирләргә кәшиш була ала, башкача имтихан-фәлән кирәкми һәм бездәге муллалар кебек губернаторның тасдыйк кылуы[1] да хаҗәт түгел, мәгәр полициядән: «Бу кешенең кәшиш булуына бер-бер тоткар юкмы», – дип кенә сорала икән. Нинди кечкенә бер милләт нинди зур хокукларга ирешкән. Әрмәннәрдә вакыф акчалары бик күп икән. Семинарияләр бар да шул вакыф акчаларына асралалар икән.

Пароходмыз Каспий диңгезенә чыккач, диңгез уртасында бер пристаньга барып туктады да, икенче пароходга күчдек. Монда да йөк ташучылар барысы да иранлылар иде. Хезмәт бик авыр, хак арзан булырга охшый, өст-баш киемнәре бик начар, яланаяк йөриләр. Анларга матросларның мөгамаләләре дә Идел буендагы урыс йөкчеләренә караганда күп начар икән. Яхшы сүз кушу, эшне юньләп әйтү һич юк. Тугры килгәндә үзләрене төртеп-сугып да йибәрәләр. Иранлылар үзләре бик эшчән. Әмма юаш халык булырга охшыйлар. Кешеләрнең шундый каты мөгамаләләренә чыныгып беткәннәрдер ахрысы, һичбер протест кылмыйлар. Наданлыклары да бик көчле булырга кирәк: үз хокукларын аңламыйлар да, сакламыйлар да, үзләре диндарлар булырга охшыйлар: минем мөселман икәнемне белгәч, иң элек: «Син рузамы?», – дип сорадылар.

Петровскига килеп йитдек. Петровски бөтенләй Асия шәһәре булып, халыкларның күбесе Шәрык кыяфәтендәләр. Бер мәсҗед бар, шәһәрнең читендә булса да, башка биналардан аерым күркәм генә. Ташдан салынган. Үзе зур түгел. Мәсҗеддән ерак түгел мөселман йортлары бар, кайсы таштан, әмма күбесе балчыкдан салынган. Кечкенәләр. Күренешдә фәкыйрьләр.

Петровскидан тимер юлга утырып, Ессентукига китдек. Юл бик күңелле, Кавказ таулары күренеп торалар. Кайсыларыны болыт каплаган, кайсылары болыт өстеннән чыгып баралар. Монда да һәр ыстансада[2] йөк ташучылар. Һәммәсе дә иранлылар.

---

[1] Тасдыйк кылуы – раславы.

[2] Дөресе: станциядә.

Юлда чиркәсләр күренә башлады. Ыстансаларда, рамазан булса да тәмәке тартып, чәй эчеп утыралар. Хатын-кызның ирләрдән качу гадәте монда юк икән. Һәркайсы очраган танышлары берлә исәнләшеп, сөйләшеп утыралар. Башларындагы яулыкларыны да йөзләрене кабламаслык итеп бәйләгәннәр. Кондуктордан: «Бу нинди халык?», дип сорагач, минем татар икәнлегемне белмичә, үзләрене кимсетеп: «Татарлар», – дип җавап бирде.

Грозный каласына якынлаша башлагач, бу чиркәсләр күбәя башладылар. Кайсы поездга утыра, кайсы берәр ыстансага барып поезддан төшә. Ыстансаларда да байтак күренә башладылар. Анлар бик киенеп, ыспай йөрергә яраталар, үзләренең киемләре берлә бик мәшьгульләр. Кайсы яшел, кайсы кызыл төсле киемләр киеп, көмеш хәнҗәр буып, платформа буенча йөренәләр, ләкин эш кешеләренә охшамыйлар... Хохол, казак вә иранлылар һәртөрле эшләрдә күреләләр. Әмма чиркәсләр йә агач күләгәсе атсында кәеф чигеп ятып торалар, йә тау башына менеп сугышга хәзерләнгән кеше кебек бик ыспай торып, поездны багып озаталар. Иген эшләүче вә үгезләрне йигеп ашлык ташучы чиркәс юлда һич очрамады. Андыйлар булса, йә хохол, йә казак булалар. Чиркәс авыллары да очраклады[1]. Хатын-кызлары, бала-чагалары күрелеп калалар. Өйләре кечкенә генә, фәкыйрь генәләр. Безнең татар авылларындагы кебек ялт итеп тора торган мәсҗедләр һич күрмәдем.

Минем Кавказ курортларына баруым сезон ахырына тугры килде. Шул вакытда хөкүмәт хезмәтендә булган төрле кешеләр тиген[2] дәваланырга киләләр икән. Кайда баксаң генераллар, афитсәрләр[3], инженерлар, әлхасыйль[4], төрле министрлыкларда хезмәт итүче ялтыравык төймәле, кокардалы[5] кешеләр очрый. Шунлар арасында бер-ике Кавказ инженерларыннан башка

---

[1] Очраклады – очрады.

[2] Тиген – бушка.

[3] Дөресе: офицерлар.

[4] Әлхасыйль – кыскасы.

[5] Кокардалы – кокарда – хәрби яисә бүтән профессиональ униформада баш киеменең маңгай өлешенә беркетелә торган махсус билге, значок *(Г. Ханнанова иск.).*

һичбер мөселман вә яһүди күрелмәде. Хөкүмәт ошбу халыклар өчен бик күп акчалар түли торгандыр. Ләкин бу акчалар мөселманнардан башка халыкларның кулларына керәдер. Мөселманнар үз наданлыкларының җәзасыны күрәләр. Анлар хөкүмәт хезмәтене дә, җәмәгать хезмәтене дә башкара алмыйлар, хөкүмәт бәлешен ашарга әле дә үсеп йитмәгәннәр.

Кавказның мөселман кулыннан чыгуына күп вакыт узган булмаса да, хәзер анда мөселманлык һәм татарлык галәмәте күрелми. Мөселман гәзитәләре вә китабларыны табып булмый. Анларны укучы һич күрелми. Эчке Русиядә мөселман кәсебчеләре йә буфетларда хезмәт итүчеләр, чи бер рус каласына җибәрелсәләр, хәзер җәмгыять ясап мәхәллә коралар, имам алалар, балаларыны укытырга мөгаллим чакырталар, мәктәб вә мәсҗед сала башлыйлар. Мәсәлән: Архангельск, Тверь, Харьков, Киев шәһәрләре кеби. Әмма монда мөселман җәмгыяте дә юк, мәсҗед дә юк, мәхәллә дә юк, мулла вә имам да юк. Әлхасыйль[1], дин вә милләт рухы һич юк. Кавказ гәзитәләрене малайлар иртәдән үк кычкырып сатып йөриләр, әмма шунлар арасында мөселман гәзитәсе булган «Каспий» да юк. Аны алыр өчен вокзалга барырга кирәк буладыр. Тирә-якда мөселман авыллары да бар, курортларда да Кавказ мөселманнары байтак күренәләр. Киенешеп, ясанышып багчаларда, бульварларда маршировать итеп йөриләр, яки ат өстенә менеп йөрү илә үзләренең егетлекләрене күрсәтәләр. Мөселман галәмәтене карачай татарларында гына күрдем. Анларның юлда һәм сахрада бергә җыелышып намаз укыганнары һәрвакыт очрыйдыр иде.

Мөселман сәүдәсенә килсәк, ул да күңелне шадландырырлык түгел. Урамда яки кечкенә генә кибетләрдә: таяк, камчы, каләм саблары, кәгазь кискечләр, бил бугчалар һәм мәшһүр Кавказ эше дип аталган вак-төяк көмеш нәрсәләре саталар һәм бик оста русча монограммалар язып бирәләр (мөселманча белмиләр). Әмма төрле Кавказ киемнәре, буркалар, папахлар, бишмәтләр, Кавказ күн һәм бурка итекләре, Кавказ иярләре, паласлар, төрле кыйммәтле нәфис көмеш нәрсәләр – һәммәсе дә әрмәннәр вә

[1] Әлхасыйль – кыкасы.

гөрҗиләр[1] кибетләрендә сатыла. Кыйммәтле мал булганга күрә, монлар берлә сату итәр өчен байтак акча һәм сәрмая[2] кирәк. Мәгаттәссеф, мөселманнарда акча күренми. Аның өстәвенә һәр йирдә мөселманны наданлык баскан. Кавказ мөселманнары аллы, гөлле киемләр киеп, папахны арткарак салып, көмеш хәнҗәр тагып, билдән кысып, кулыны биленә куеп яки кыска таяк тотып, авызына папирос кабып багчаларда бик ыспай йөрсәләр дә, әйтергә оят, күбесе укый-яза белмиләр. Әлбәттә, шундый надан булгач, сәүдәдә зур эш килү мөмкин түгел.

Ничә еллар Эчке Русия татарлары берлә эш кыла торган Кавказда торучы бер рус комиссионер миңа ошбу сүзләрне сөйләде: «Мондагы мөселманнар сәүдә ягына авырлар, тупаслар, файда вә зарарны һич аңлатып булмый, әмма сезнең татарлар файда киләчәкне әллә кайдан аңгарып торалар һәм эшнең җаена бик тиз төшенәләр». Әлбәттә, бу сүз дөрест булса кирәк, чөнки татарлар инде күбдән Аурупа мәдәнияте вә мәгыйшәте берлә таныша килгәннәр. Әмма кавказлылар яңа мәгыйшәтне яңа гына күрә башладылар. Кавказ халкы арасында байлык әрмәннәрдә күренеп тора. Үзләрендә зур вә яхшы кибетләр, дәваланыр яки истирахәт[3] өчен килгәннәр арасында төрле инженерлар, афитсәрләр[4] вә хөкүмәт мәэмүрләре күп һәм зур сәүдәгәрләр, банкирлар, яхшы вә кыйммәтле отельләрдә яки үз дачаларында торалар, үз атларында яхшы экипажларда яки автомобильләрдә урамда йөриләр.

Бервакыт Петербургда аристократиянең шулай дөньяны тибеп торуларыны, бай кыланышларыны бер татарга күрсәткән идем. Ул шуны күреп миңа ошбу бәетне укыды:

«Бу дөнья кяферә[5] җәннәт улыбдыр, мөэминә[6] зиндан!». Менә безнең мөселманнарда шундый ялган игътикад[7] вә ышану

[1] Гөрҗиләр – грузиннар.
[2] Сәрмая – капитал.
[3] Истирахәт – ял.
[4] Дөресе: офицерлар.
[5] Кяферә – кяфергә.
[6] Мөэминә – мөэмингә (мөселманга).
[7] Ялган ышану – ялган инану.

бар. Шундый ышанулар мөселманнарның дөнья тормышында алга баруларына бик күп зарарлар бирә, хәтта мөселманнарның һәр халыкдан артда калуына бу игътикад иң беренче сәбәб буладыр.

Курортларда төрле йирләрдән кешеләр бар иде. Безнең татарлардан да бер-ике кеше күренде. Иранлылар һәм йирле, ягъни андагы кавказлылардан кайсылары хатыннары берлә үк килгәннәр. Безнең татарлар урамнарда яки багчаларда хатыннары берлә бергә йөриләр, хатыннары ирләренә ябышканнар, һич аерылмыйлар. Әмма кавказлылардан ирле-хатынлы бергә йөрүчеләрне һич күрмәдем. Бәлки ирләре башка, хатыннары башка йөриләр. Иран хатыннары күбесенчә ялңыз, башдан аяк кара чаршаф[1] ябынып, күләгәләр кебек булып йөриләр. Тел белмәүләре сәбәбле булса кирәк, берәү берлә дә сөйләшмичә, берәүгә дә катнашмыйча, ялңызлары гына йөриләр вә Аурупа мәгыйшәтеннән бик ерак торалар.

*Шура. 1914. № 2*

[1] Чаршаф – пәрдә.

**Искәндәр әл-Хәмзәви**

# КАВКАЗИЯДӘ СӘЯХӘТ

*Чиркәсләр. Икътисадка ригаяләре. Владикавказ.*
*Уку йортлары. Халкы вә мөселман чиркәсләр.*

4 июнь поездымыз дөбердәп, пошкылдап, Донской область үтә Терской областька кереп китте. Көн бик матур, бөтен юл буенда яшеллек, кыр диңгезе волнап[1] ята, үлгән күңелләргә (безнең кеби беркайда чыга алмый яткан татар муллаларына) яңа җирдә йөрү, күрмәгән халыкны күрү, табигатьтә булган хәлләрне тамаша итү хыялы тәэсир итә, рухани җиңеллек, күңелле-күңелсез тойгылар пәйда итмәктә иде. Ыстансалар берсе артыннан берсе үтеп китә, поездны каршыларга килгән тубал кадәр йонлы бүрек, озын киң җиңле кием кигән, билен кәмәр берлә бик каты итеп кысып нечкәрткән чиркәсләр (кабарда, ингуш, осетин, лезгин, комык фиркаләренә[2] берьюлы исме җенес[3] уларак чиркәсләр диеп әйтү мәгъруф[4]) бөтен платформаны ишгаль итәләр[5].Чиркәсләрдән юлчылар да була башлады. Владикавказга йитәр алдында чиркәс юлчылар берлә вагоннарда бик каты тыгызлык, урын өчен талашулар да күрелде. Мин платформада йөргәндә һәм вагонда юлдаш булган чиркәсләрнең әхлакы заһирияләренә[6] күз салам, вә саф табигыяләренә дикъкать нәтиҗәсендә хәйран була идем. Чиркәсләрнең гомумән ире[7] гәүдәле, киң күкрәкле, үткен күзле, сугышчан табигатьле, гаять тә чыдамлы бер халык икәнлекләре өстләренә бер кәррә[8] карагач ук күренеп тора. Тарихта азмы-күпме шанлы, баһадир

[1] Волнап – дулкынланып.
[2] Фиркаләренә – төркемнәренә.
[3] Исме җенес – этноним.
[4] Мәгъруф – билгеле.
[5] Ишгаль итәләр – билиләр.
[6] Әхлакы заһирияләренә – тышкы әхлакларына.
[7] Ире – эре.
[8] Кәррә – тапкыр.

кыяфәтле чиркәсләрнең әхвәле гыйльмия[1] вә әхвәле сәясияләреннән[2] бәхәс итүдән элек, аларның гомумән икътисадка ригаяле[3] бер халык икәнлекләрен язып китәм. Чиркәсләр, гомумән ябык, ашаган ашлары икътисадка бик ригаяле. Сорашып белүемә күрә, чиркәсләр хайван асрасалар да, ит ашау бик аз, урта вә түбән дәрәҗәле сыйныфлар фәкать икмәк, су, яшелчә белән көн итәләр диелсә, хата булмас. Чиркәсләрдә иң беренче урында йөртелә торган нәрсә – суган. Моңа дәлил уларак юлчыларының бөтен юл буенда икмәк белән суганнан башка нәрсә ашамауларын күрсәтә алам.

Пенза вокзалында Борис Фусның бер туктамый йиде сәгать ашавы ни-кадәр гаҗәпләндерсә, чиркәсләрнең бик зур аппетит берлә суган ашаулары да шулкадәр ят тоела. Юлда 5–6 чиркәснең берьюлы икмәксез-нисез шатыр-шотыр суган ашауларыннан янымдагы ирле-хатынлы рус кызыксынып, көлеп йибәргәнлегедер. Кобар табигатьле чиркәсләрнең көлүне яратмый, бүре күзе берлә карап куюлары, мине көлүгә кушылырга ирек бирми иде. Чөнки хасыйл булган юлдашлык мөнәсәбәтенең бозылуына, әллә нинди тәмсезлеккә сәбәб булуы ихтимал иде.

5 июньдә Владикавказга килеп йитдем. Шәрык ысулында ике ат җиккән фаэтонга утырып, кунак өемә юнәлдем. Владикавказ областной бер шәһәр саналып, 70–80 мең кадәр нөфүсе[4] бар. Шәһәр ул кадәр гыймарәтле[5] булмаса да, мәүкыйгының[6] тигезлеге, һавасының ләтафаты, шәһәр уртасыннан карлы тагларыннан агып килгән Тирек суының бертуктамый шаулап агуы, Русиянең бик мәшһүр шәһәрләрендә күрә алмадыкым Тирек намындагы гүзәл бакчасы, шәһәрдә агачларның, хосусый бакчаларның күплеге, болытлардан бик аз вакыт кына арчылып торган, итәкләре ямь-яшел үлән, яки урман берлә өретелеп, башында каты эсселәрдә дә эреми яткан карның булуы берлә

[1] Әхвәле гыйльмия – монда:мәгърифәт торышы.
[2] Әхвәле сәясияләреннән – сәяси хәлләреннән.
[3] Икътисадка ригаяле – икътисади мәнфәгатьләрен кайгыртучан.
[4] Нөфүсе – халкы.
[5] Гыймарәтле – төзелешле, корылмалы.
[6] Мәүкыйгының – урынының.

гаҗәеб бер манзара тәшкил иткән таглары, шәһәргә хосусый рәнг[1] бирә вә имтияз кәсеп иттерәдер[2]. Бу шәһәрдә ирләр өчен – 1, кызларга 2 гимназия, 2 реальный, алты классны гаскәри мәктәп, кадетский корпус, казачий военный семинария, һөнәр мәктәбе, учительский семинария, моннан башка бик күп хосусый уку йортлары бар. Мәктәпләренең күплеге берлә Владикавказ Тифлистән дә өстен диләр. Төрле хөкүмәт мәктәпләрендә безнең татарлардан ике генә кеше булса да, мәхәллә мөселманнардан байтак бар. Кадетский корпуста – 50, реальныйда 90 кадәр мөселман баласы бар дип, шушы мәктәпләрдә дин дәресе укыткан татар имамы Сөнгатулла хәзрәттән ишеттем. Моннан башка мәктәпләрдә дә укучылар булса да, анларда дин дәресе юк икән. Чөнки бу хакта бала аталары тәшәббес итмәгәч[3], мәктәп идарәләре үз ихтыярлары берлән генә куймыйлар. Владикавказ күп нөфүсле шәһәр булмаса да, җенес-гыйрык ягыннан[4] иң бай шәһәрләрдән санала. Асыл халкы: ингуш, кабарда, осетин, лезгин, грузин, малакан кеби төрле фирка чиркәсләр булып, читтән килеп урнашкан казакъ, яһүд, әрмән, иранлы, татар, чегән кеби әҗнасы мөхтәлифә[5] бар. Урамга чыгып тротуарга күз салсаң, йирдән ничә төрле җенес күрергә тугры килдекеннән, Мәккә, Мәдинә шәһәрләренең хаҗ вакытлары хәтергә төшә. Владикавказның уннан бер проценты мөселман. Фәкать җирле мөселманнар арасында дини вә милли җәһәттән бик каралык хөкем сөрә. Чиркәсләрнең һичбер фиркасендә милли мәктәп дигән нәрсә юк. Миллионнар берлә оборот ясый торган байлары, олуг зыялылары булса да, бер данә булсын мөселманча рәтле бер мәктәп иҗад итәргә гайрәтләре йитмәгән.

Мин түбән вә югары сыйныф чиркәсләре берлә сөйләшдекем хәлдә, һичбер берсендә әсаслы[6] миллият фикере сизмәдем. Дөрест, чиркәсләр милли киемнәрен, билләрендәге кечкенә

[1] Рәнг – төс.
[2] Имтияз кәсеп иттерәдер – өстен итәдер.
[3] Тәшәббес итмәгәч – тырышлык күрсәтмәгәч.
[4] Җенес-гыйрык ягыннан – этник состав ягыннан.
[5] Әҗнасы мөхтәлифә – төрле этнослар.
[6] Әсаслы – нигезле, төпле.

кылычларын саклыйлар әле, бу да бәлки үз мохитларында яшәүдән генәдер, фәкать миллиятнең кием берлә генә сакланып калуы бик шөбһәле.

Буннан 14 еллар элек безнең татарларның башлап керешүләре, төрле тарафтан килгән иганәләр берлә салынган 70–80 меңлек бик гүзәл мәсҗед хәзер чиркәсләргә калган, ләкин мәсҗед бу вакытка кадәр үзенә муафыйк имам күргәне юк. Хәзер исә һичбер рәсми имамлары юк, мәүкыйт[1] имам уларак бер мәгълүматсыз дәрвиш тора. Буннан [...] ел элек рәсми имамнары булса да, мәгыйшәте тәэмин итә алмадыкыннан, ташлап китәргә мәҗбүр булган. Ничә меңнәр чиркәсләрнең бер имам тәрбия кыла алмауларыннан, дингә ихлас вә мәхәббәтләрен үлчәп була инде.

*Кояш. 1915. 9 июль*

[1] Мәүкыйт – вакытлы.

**Назархуҗа Габдессамад углы**

# ЮЛ ХАТИРАТЫМНАН

*(Алтышәһәргә[1] йөреш)*

Үткән сәнәнең кайгы вә кәдәрләрене[2] китәреп[3] кальбемә бер кадәре тәслият[4] вирмәк максады илә бераз көн сәфәрдә улмакны арзу итдем[5]. Кайда ата-бабаларымызның ватаны, мәдәниятле уйгыр бабайларның җәвәлангяһы[6], ислам мөҗаһидләренең соң гасырда гына бөек вә көчлек бер төрек ханлыгы тәэсис итдеке[7] нокта. Бәгъзе хаиннарның[8] тәдбирләре саясендә[9] тиздән гаиб улдыгы[10] Алты шәһәр тарафына!...

Алтышәһәр: Кашгар, Яркәнд, Хөтән, Аксу, Көчә, Турфаннан гыйбарәт булып (Турфан, Яркәнд), уйгыр бабайларның пайтәхет[11] шәһәрләреннән саналырмыш[12]. Ул гасырларда уйгыр төрекләре дә, заманының улдыкча[13] мәдәни кавемнәреннән бер кавем имеш!...

---

[1] Алтышәһәр – Кашгария – элеккеге Көнбатыш Кытайның Синьцзян вилаятенең көньяк өлеше *(Г. Ханнанова иск.).*

[2] Үткән сәнәдә гомум ислам галәменә килгән мөштәрәк (уртак) кайгылар бар иде. Аның өстенә хосусый кайгыларым да булды. Пәдәре газизем Габдессамад баба һәм дә угылларым дүрт яшьли Риза илә энесе вафат итделәр. Кайгы түгелме? Аһ! Үлем! *(Н. Габдессамад иск.).*

[3] Кәдәрләрне китәреп – хәсрәтләрне таратып.

[4] Тәслият – юаныч.

[5] Арзу итдем – теләдем.

[6] Җәвәлангяһы – яшәгән урыннары.

[7] Тәэсис итдеке – төзегән.

[8] Хаиннарның – хыянәтчеләрнең.

[9] Тәдбирләре саясендә – гамәлләре аркасында.

[10] Гаиб улдыгы – юкка чыккан.

[11] Пайтәхет – башкала.

[12] Саналырмыш – санала икән.

[13] Улдыкча – шактый.

Бер вакытларда Кашгар да боларның пайтәхет шәһәрләреннән улмыш. Алтышәһәр мөәррихләренең[1] хәбәренә күрә, Кашгарда хөкүмәт сөрмеш уйгыр ханнарыннан Бугра хан 350 һиҗри тарих тирәләрендә исламият зөмрәсенә[2] кермеш вә боннан Алтышәһәр өлкәсендә исламият җәйрәмеш. Бугра хан ислам кабул идүенә сәбәб булган Йосыф Кадир атлыклы ислам сәргаскәренә[3] мәмләкәтнең барча эшләрен ислам кануннарына муафикъ[4] йөртмәк өчен тапшырмыш... буннан тулае[5] Алтышәһәр әһалисе Йосыф Кадирга Йосыф хан исемене вирмеш. Бара-бара бу сәрдар[6] Йосыф Кадир хан «Гази[7]» исеме илә шөһрәт табмыш. Димәк, безем исламият кабул идүемезгә янә 18 сәнәдән киен[8] там[9] мең сәнә тулачак икән. Хәтерләнәчәк бер эш. Һәр киләчәк якындыр!

* * *

Кил, киләлем сәфәремезә[10]:

Бүген (4 гыйнвар) биш-алты һәмраһларым[11] илә бергә Алтышәһәр тарафына рәван улдым[12]. Тикәснең киң даласында улынырым. Бонда мәдәният әсәре аслән[13] күренми, һәр нәрсә табигый көенчә. Гөҗ килеб, кайнап торган инсаннар, ала яшел[14], йорт вә ягашлар[15] юк. Тып-тын вә сакин[16]! Тик ялан уртасындагы

[1] Мөәррихләренең – тарихчыларының.
[2] Исламият зөмрәсенә – мөселман дөньясына.
[3] Сәргаскәренә – гаскәр башлыгына.
[4] Муафикъ – туры килгән.
[5] Буннан тулае – бу сәбәпле.
[6] Сәрдар – юлбашчы.
[7] Гази – дин өчен сугышучы.
[8] Киен – соң.
[9] Там – нәкъ.
[10] Кил киләләлем сәфәремезә – сәфәребезгә килик.
[11] Һәмраһларым – юлдашларым.
[12] Рәван улдым – юнәлдем.
[13] Аслән – бөтенләй.
[14] Ала яшел – ямь-яшел.
[15] Ягашлар – агачлар.
[16] Сакин – тыныч.

магулларның[1] гүзәл вә мөзәйян[2] бер мәгъбәде[3] илә магул балаларының ара-сәрә[4] «Ай, ау, әй» дигән моңлы тавышлары табигатьгә бер- төрле үзгәреш бирә иде. Юлчылар акрын вә салмак йөриюр[5]. Көнәш дә[6] яваш-яваш[7] нурыны гаиб идәюрды[8]. Бер аралык ахшам вакыты булган иде. Без дә мәгъбәддән ерак түгел бер йирдә урын алдык. Мәгъбәд янында улынырмыз. Кичәнең золмәте гаиб улыб[9], таң нуры галәмә баканча[10], магул саумәгасыннан[11] «чаң-чуң» дигән тавышлар, монахларны гыйбадәтләренә чакырган вакытларда, икенче бер тарафдан моңлы бер тавыш илә азаны мөхәммәди сәдасы[12] яңгырамакда иде. Без дә бондай бер саумәгадә азаны мөхәммәди ишетенчә[13], сөенечемездән шашдык. Һәман калкыб[14] гыйбадәтемезә шоруг итдек[15].

Шунда бер төркем кәрванга очрадык. Боларның сүзләүләренә күрә безем ашачак даванымыз[16] – Боз даван ифрат куркыныч имеш. Ходай сакласын, даван өстендә кар пуртынасы[17] улачак исә, һәммәмез һәлак улачак имешез... тик Ходай оңшап[18] Боз-арт хуҗам мәдәд[19] кылса гына, аннан сәламәт ашарга мөмкин имеш. (Боз-арт хуҗам хәйятта[20] диләр) йитмәсә, гөнаһлы бәндәгә

[1] Магулларның – монголларның.
[2] Мөзәйян – бизәлгән.
[3] Мәгъбәде – гыйбадәтханәсе.
[4] Ара-сәрә – ара-тирә.
[5] Йөриюр – баралар.
[6] Көнәш дә – кояш та.
[7] Яваш-яваш – әкрен-әкрен.
[8] Гаиб идәюрды – югалта иде.
[9] Кичәнең золмәте гаиб улыб – төннең караңгылыгы таралып.
[10] Баканча – карагач.
[11] Саумәгасыннан – монастыреннән.
[12] Азаны мөхәммәди сәдасы – мөселман азаны тавышы.
[13] Ишетенчә – ишеткәч.
[14] Һәман калкыб – шундук торып.
[15] Шоруг итдек – керештек.
[16] Даванымыз – үткел (ике тау арасындагы юл).
[17] Кар пуртынасы – кар давылы.
[18] Оңшап – мәрхәмәт күрсәтеп.
[19] Мәдәд – ярдәм.
[20] Хәйятта – исән,тере.

Боз-арт хуҗам аслән[1] юл бирмәюрмеш[2]. Тик бу вакытларда гына Боз-арт хуҗам бераз явашлап калгангамы[3], әллә нигәдер бәгъзе бозык адәмнәр дә ашкалаган имеш. Без һаман элгәреләюрмыз[4]. Кальбемез үткәндәге гөнаһ картинкаларымызны тамаша идәюр. Алдымызда куркыныч таг тәпәсендә[5] кар пуртынасы шауриюр[6]. Боны күрәнчә, күңелләр дәһшәтләниюр. Хыяллар һәлакәт чокырына өстерәп ыргытыр иде. Ибдәшләр дә бик тирән хыял дәрьясына чумдыклары хәлдә, сакин йөриюрды[7]. Өн юк...

* * *

Йитдек Бозартга!

Үңемездән[8] каршы булган шаурган[9] бераз рәхәтсез идәюрсә[10]дә, анча[11] куркыныч түгел иде. Шундак[12] булса да, күңелләр хуш түгел, әллә нәрсәгәдер бик рәнҗи, нәрсәдәндер сызлана иде. Без көн буе һаман боз өстендә йөриюрдык[13]. Шәрык вә Гареб тарафымызы чолгап алган күп-күк пыяла кеби боз тавы, тәпәләрендә кар пуртынасы уйнаюр, ә астымызда җәһәннәм чокыры! Хыялый хикәяләрдә генә булырга мөмкин булган җенпәри «урдалары» тик булган имеш әллә кайчангы заманнарда бонда бер карчык, бер аждәрһа карчык җаудә кылган[14] саен, боз арта имеш, аждәрһа да тик ятмаган... тик бу вакытларда гына төрек батырларыннан бер батыр, Чынтимер батыр, акбүз атына менгән дә, сөрән кылычы таккан да, бу җаудәгәр[15] карчык

[1] Аслән – бөтенләй.
[2] Бирмәюрмеш – бирми икән.
[3] Явашлап калгангамы – экренәйгәнгәме.
[4] Элгәреләюрмыз – алга барабыз.
[5] Тәпәсендә – итәгендә, битендә.
[6] Шауриюр – давыллана.
[7] Йөриюрды – баралар иде.
[8] Үңемездән – алдыбыздан.
[9] Шаурган – давыл.
[10] Идәюрсәдә – иткән булса да.
[11] Анча – аның хәтле.
[12] Шундак – шулай.
[13] Йөриюрдык – бара идек.
[14] Җаудә кылган – сихер кылган.
[15] Җаудәгәр – сихерче.

илә аждәрһаны үлтергән дә, Алтышәһәргә юл ачкан имеш. Хәерле юл.

Һәр нә исә[1], боз өстендә һаман улынырмыз, адым саен бер үләксә, юл буе катар тезелгән[2] төрек мөһаҗирләре! Ялан-ялангач, чыр-чыплак[3], бала-чага, карт-карчык һәммәсе пиядә[4]. Кайберәүләр хәлсезлектән абына-сөртенә йөриюрды. Бер йирдә гөнаһлы бәндәләрдән беренең җәсәдене[5] таш төбенә ыргытып йибәргәне дә күз көюрде[6].

Әй, укучы кардәш!

Төрек[7] мөһаҗирләре дигәч, балканлыларның золымларыннан качкан Рум иле төрекләрен исгә төшерәчәк түгелмесеңез? Хәер, монда балканлылар юк. Ләкин балканлылардан да залим бер көч бар ки, ул да «юксызлык вә мәгыйшәт тарлыгы[8]». Иштә[9] сезә әфәндем Алтышәһәр картинасы: 5 балалы бер гаилә, ана – ханәдә балаларга карый, анларны юбата[10]. Ата – боларга ризык эзләп базарга чыккан, ләкин бу көн буе кайткан юк. Балалар үткән көн кич генә бер парчадан[11] нан[12] ашаган иделәр. Төгәл бер тәүлекдән бирле ашаган юк. Бичара балалар анасына мөлдер-мөлдер бакып ыңгыраша, шәфкатьле ана эчдән яна, төрле ялган сүзләр берлән балаларын юбата. Күрше Әхмәддән үтенә, нан алып торар иде, уда шул[13]..., «кузуларым[14], атаң нан алып кайтыр» дип еглыйеглый юбата, ләкин үзе дә 2 тәүлекдән юньләп ашамаганга күрә, күзләре алдындагыны күрми, аяклары калтырый!.. Ә ата көн буе

---

[1] Һәр нә исә – ничек кенә булмасын.
[2] Катар тезелгән – тезелеп барган.
[3] Чыр-чыплак – киемсез.
[4] Пиядә – җәяү.
[5] Җәсәдене – үле гәүдәсен.
[6] Күз көюрде – күзне кисте.
[7] Төрек – монда төрек дигәндә, төркиләр күздә тотыла.
[8] Мәгыйшәт тарлыгы – тормыш авырлыгы.
[9] Иштә – менә.
[10] Юбата – юата.
[11] Парчадан – кисәктән.
[12] Нан – икмәк.
[13] Уда шул – ул да шул.
[14] Кузуларым – балаларга эндәшү формасы. Кузу – сарык бәтие.

эшләп табдыгы пулы[1] бәрабәренә (6 тиен акчасы) базардан нан алып, ашыга-ашыга ханәсенә кайта, бу вакыт бу гаилә эчендәге куаныч вә хөрсәндлекне[2] тассавыр идү[3] мөмкин түгел, бакыңыз, җаным! 6 тиенгә 6 кеше, нәя[4] куана. Бу гаҗизләрнең эчәрене вә йакарыны да[5] төшенеңез. Ходай күрсәтмәсен! Бу гаилә эчендә ата бер көн генә агырык булса, кыямәт хазир булмасмы[6]? Димәк, бундак җәфаны йөкли алмаган, аз гына дөньяда яшәргә теләгән төрекләр кыш уртасында бала-чагасын чубалтып[7], ирексез улардак Или вилаятенә[8] һиҗрәт итә, табигый, булар да суыкдан сакланырлык эңгел-аяк[9], кием-кичәк[10] булмый, юлга йитәрлек азык күбдән юк. Суык булды исә, 3 яшьлек угылы, 3 айлык кызын өстендәге киемнәренә урап, анларны суык тиюдән саклый, бичаралар үзләре бер генә кар пуртынасы булса, көзге яфрак шикелле түкилә[11]. Менә кардәш, бәнем аңлавыма күрә, Боз-арт хуҗам да бондак[12] гөнаһлы бәндәләрне Боз даваннан үткәзмәюрмыш[13]. Хаклы да!

«Хөкүмәт нишләюр, бу мөһаҗирләргә берәр төрле уңгайлык эшләмиюрмы?» дирсеңез[14] түгелме? Җавабән диюрым ки[15], хөкүмәт – Шәрык хөкүмәте!.. Ачык әйтергә мосагадә вирсәңез[16], Хатай[17] падишаһлыгы...

---

[1] Пулы – акчасы.

[2] Хөрсәндлекне – шатлыкны.

[3] Тассавыр идү – күз алдына китерү.

[4] Нәя – нәрсәгә.

[5] Йакарыны да – утын ягын да.

[6] Хазир булмасмы – җитмәсме.

[7] Чубалтып – чуалтып.

[8] Или вилаяте – Синьцзянның Или елгасы һәм аның кушылдыклары үзәненнәрендә урнашкан төбәк *(Г. Ханнанова иск.)*

[9] Эңгел-аяк – аяк киеме.

[10] Кием-кичәк – кием.

[11] Түкилә – түгелә.

[12] Бондак – мондый.

[13] Үткәзмәюрмыш – үткәрми икән.

[14] Дирсеңез – дисез.

[15] Җавабән диярым ки – җавап итеп әйтәм ки.

[16] Мосагадә вирсәңез – рөхсәт итсәгез.

[17] Хатай – Кытай.

* * *

Төгәл дүрт тәүлек таг эчендә йөреп пәк йорылдык[1] исәк дә, арам алачак[2] – өнҗәчек бер җайга йитмәдек[3]. Бүген генә (22 январ) үңемездә[4] бер ярык[5] күренде. Бу исә ачык бер далага чыгачакымыза ишарәт иде. Көн дә суык түгел, бондан үтере[6] йөреш күңелле генә булып, юл маңгып ялыккан[7] атларымыз да бертөрле шәп атлаюрды. Һайди, кардәшләр, йөрең! Һаман йөримез... тик таг агызына йитә алмаймыз... бер аралык ахшам вакыты булган иде – йитдек. Нә күрәсең! Ике таг арасы сәдд илә торалган[8] иде, тик урта бер йирендә генә бер тишек барлыгы да беленерде[9]. Бардык, шунда... Бу Алтышәһәр өлкәсенә чыгачак капка иде. Капкадан керүемезлә бер хатай мәэмүре[10], олугланып, гүя бездән сәҗдә көтмәкдә иде. Ләкин без сәҗдәгә бару урынына тиз билетымызны чыгардык. Мәэмүр безем рус фокарасы[11] икәнемезне аңлады бугай, һәман[12] «хуш кәлдеңез» әйтде. Корган[13] эчендә бер дә гөмрек[14] мәэмүре бер төрек улынырды. Чәүрәмезә бакдык[15]. Сәдд[16] бозылган, корган эчендә бер-ике ханә истисна иделсә[17], барчасы хәраб, йимерек вә бәрбад[18]. Ләкин шундак булса да[19], бу кальга вә сәдд үз вакытында ниһаять дәрәҗә игтина илә[20]

[1] Пәк йорылдык – бик арыдык.
[2] Арам алачак – ял итәчәк.
[3] Өнҗәчек бер җайга йитмәдек – тыныч бер урынга җитмәдек.
[4] Үңемездә – алдыбызда.
[5] Бер ярык – бер яктылык.
[6] Үтере – үтә торган.
[7] Маңгып ялыккан – йөреп ялыккан.
[8] Сәдд илә торалган – стена белән ябылган.
[9] Беленерде – беленә иде.
[10] Мәэмүре – түрәсе.
[11] Рус фокарасы – монда: рус иле кешеләре.
[12] Һәман – шунда ук.
[13] Корган – крепость.
[14] Гөмрек – таможня.
[15] Чәүрәмезә бакдык – әйләнә-тирәбезгә карадык.
[16] Сәдд – стена.
[17] Истисна иделсә – исәпкә алмаганда.
[18] Бәрбад – җимерек.
[19] Шундак булса да – шулай булса да.
[20] Игтина илә – хасиятләп.

мөхкәм ясалдыгы[1] мөшаһадә улынырды[2]. Иштә[3] бер мәсьәлә: Хатай хөкүмәте мәмләкәт уртасында бондак[4] бер сәдд салырга ничөн мәҗбүр улган? Бондак бөек бер кальганы 2 нәфәр[5] мәэмүр өченме ясаган? Бу көндә ник болай хәрабә хәлендә? Бу сөальләрнең җавабына гакылымыз ирешмәде. Сорадык. Шуннан... Бу сәдд вә корганнарны ясаткан Кашгар хөкемдарларыннан бәдәүләт җәнаблары[6]. Ул бонда Или тарафыннан әмин улмак өчен, 2 таг арасыны сәдд илә тусаткан[7], йитмәсә шушы кальгада биш йөз мөнтазам[8] кораллы сәрбаз (пиядә чәрик[9])да асраган имеш. Талдык хыялга: ул галиҗәнаб затның бу сәддне нә кеби бөек хыял вә идеалларла бина итдерүе, бу мөкаддәс хыял вә идеалларның җөзьи генә[10] бер эшдән мәңгелеккә очуы... күз уңымызда бәдәүләтнең ачык, шад вә һәрбере бер шәһәр фәтех итәчәк кадәр[11] баһадир... арыслан кеби гаскәре. Капка башында байрак өстендә яңа туган урак шикелле матур гына ай парчасы[12]. Нәләр, нәләр[13]... хыялымызда тәрәссем идәюр иде[14]. Гүя без XIX гасырда идек. Бундак хыялларла корган дәрвазәсыннан[15] чыкдык. Хуш азадлык әсәре!

Бүген Кызыл болак карьясына йитдек. Тәсадеф итдеке[16] бер ханәя индек[17]. Ханә сахибы[18] да «хуш кәлдеңез, сафа кәлдеңез»

---

[1] Мөхкәм ясалдыгы – нык ясалуы.

[2] Мөшаһадә улынырды – күренә иде.

[3] Иштә – менә.

[4] Бондак – мондый.

[5] Нәфәр – данә.

[6] Моннан максуд, мәшһүр Ягкуб бикдер. Тәрҗемәи хәле 1913 елгы «Шура»да бар (*Шура редакциясе иск.)*

[7] Тусаткан – каплаган.

[8] Мөнтазам- төзек.

[9] Пиядә чәрик (сәрбаз) – җәяүле гаскәр.

[10] Җөзьи генә – кечкенә генә.

[11] Фәтех итәчәк кадәр – яулар алырлык кадәр.

[12] Парчасы – кисәге.

[13] Нәләр – ниләр.

[14] Тәрәссем идәюр иде – гәүдәләнә иде.

[15] Дәрвазәсеннән – капкасыннан.

[16] Тәсадеф итдеке – туры килгән.

[17] Ханәя индек – өйгә туктадык.

[18] Ханә сахибы – өй хуҗасы.

сүзләр илә тәлаттыф идеб[1], ачык йөз илә кабул итде. Бундак миһманпәрвәрлек төрек иленә генә хас булган бер мәзиятдәндер[2] ахыры! Кызыл болакда мәктәб булмаса да, гүзәл генә бер ханәкаһ[3] вар имеш. «Безләр ахирәт адәмнәре булгач, дөнья мәктәбе намә лязем!» – дидек.

## Җам карьясе

Шимде[4] Аксудан 30 чакрым ераклыкда булган Җам карьясенә йитдек. Бу зур гына ислам карьясе икән. Җамның үзенә ярарлык гына базары булып, дүшәмбе гомуми базар хисаб иделдеkeннән, бүген күчәләр әтраф карьяләрдән килгән халыклар илә җык тулы. Шуңа күрә бу әтраф халыклары әхвале тугрысында беркадәр мәгълүмат алырга мөмкин икән. Бу чәүра[5] адәмләре: тугры, сафдил, садә, ялган сүзләмәс, ифрат юксыл[6], әхвале заманнан хәбәрсез, кыскасы, бундан мең ел әүвәл ничек яшәмеш исә, хәзер дә дә шундак яшәирләрмеш. Бунда мәктәб намына мәхәллә имамы идарәсендә бер мәктәб вар исә дә, бу тарафларда матбуг әсәрләр[7] булмаганга күрә, хәзрәте Нухдан калмыш такта парчаларына[8] язып укытмакдадыр. Бунда Нәүрузны һәфтәләрчә[9] бәйрәм идәюрләрмеш. Безем баруымыз да Нәүруз бәйрәменә тәсадеф итдегеннән[10] тулае, күрдек. Хатын-кыз, ир-угыл һәммәсе бергә «чука гөләнгеч» дидекләре очкычларында очышып уйнаюрлар иде. Димәк, безем йирдәге хиҗаб – тастарлар юк имеш.

Кичкырын «Углак» дидекләре милли уенны уйнамакда идерләр. Без Алтышәһәр халкының Яңа елны бундак сөенечкуанычларла каршы алып, һәфтәләрчә бәйрәм идүенә хәйран

[1] Тәлаттыф идеб – сәламләп.
[2] Мәзиятдәндер – өстенлектер.
[3] Ханәкаһ – суфиларның монастыре (тәккәсе).
[4] Шимде – инде.
[5] Чәүрә – тирә-як.
[6] Ифрат юксыл – бик фәкыйрь.
[7] Матбуг әсәрләр – басылган әсәрләр.
[8] Парчаларына – кисәкләренә.
[9] Һәфтәләрчә – атналар буена.
[10] Тәсадеф итдегеннән – туры килгәнлектән.

булдык. Бу җивар[1] халкының төрекләрдән зиядә[2] үлекләргә әһәмият вирдеке, бөзөргварлар[3] биналарында мөшаһадә улынырды[4]. Фәкыйре гаҗизләре бу һәмҗенесләрем[5] әхвәлләрене күреп, кайгырып утырдыгымда бер баба бәдәүләт дәверен пәк парлак[6] тасвир идәюррды:

– У заманда бу дияр абад вә мәгъмүр, фәкырь вә мәскәнәт юк[7], әһали[8] бай вә тырыш. Мәэмүрләр[9] бүгенге хатай мәэмүрләре кеби әһалие таламак шөйлә торсын, әһали тарафыннан бирелгән пулны[10] да кабул итмәс. Билфарыз[11] берәү кабул итәр икән, катыг куллык[12] бәдәүләттән мөкяфатыны[13] күрер... Шәһәрләр пакь вә таза. Һәр йирдә гомуми хәммам[14]. Гаскәр монтазам, егет-бәччәләр атлык[15]. Сәрбазлар пиядә, гаскәр киеме һәммә бертөрле тимер төслек мавыт[16] чапан, шалбар. Корал астындакы даими гаскәре 82 мең хисабланыр, гаскәри мәнсабдарлары[17]: йөз бәге, фансад[18], дадхаһ. Дадхаһ дидекләре гаскәри һәм фокара[19] бәге. Буның кул астында 5–6 фансад гаскәр. Берәр бөек шәһәр фокарасы гаскәргә кирәклек һәрнәмә булса, тәмам йитеш. Бәдәүләт хозурында мәхрәм, ясавыл, мөлязим дидекләре пар-

[1] Бу җивар – бу як.
[2] Зиядә – күбрәк.
[3] Бөзөргварлар – зур кешеләр.
[4] Мөшаһадә улынырди – күренә иде.
[5] Һәмҗенесләрем – кавемдәшләрем.
[6] Парлак – чәчәк аткан.
[7] У заманда бу дияр абад вә мәгъмүр, фәкырь вә мәскәнәт юк – ул заманда бу ил төзек һәм эшкәртелгән, фәкыйрьлек һәм мескенлек юк.
[8] Әһали – халык.
[9] Мәэмүр – түрә, чиновник.
[10] Пулны – акчаны.
[11] Билфарыз – әйтик, мәсәлән.
[12] Катыг куллык – каты куллы.
[13] Мөкяфатыны – җәзасын.
[14] Гомуми хәммам – җәмәгать мунчасы.
[15] Атлык – атлы.
[16] Мавыт – йон тукыма.
[17] Гаскәри мәнсабдарлары –
[18] Фансад – биш йөзле кешедән гыйбарәт гаскәри берәмлек.
[19] Фокара – монда: гаскәри булмаган, гади.

ча – вак мәэмүрләр улынырды, угылым. Хасыйле[1], пәк көчлек падишаһ иде, диде.

– Ондак[2] булса, Хатайдан нәмә сәбәбдән йиңелде икән?

– Хатайдан сугышып йиңелмәде. Ләкин талигъ[3] шундак төшерде, бәдәүләт агу эчеп үлде. Соңындикләре[4] Чин дәүләте менән сугышу урынына үзара тартышдылар. Чин гаскәре дә сугышсыз гына мәмләкәткә хуҗа булдылар.

– Бәдәүләтнең агу эчеп үлүенең сәбәбе нәмә икән?

– Шу мизгелдә Чин гаскәре бәдәүләтнең Турфанда торган 17 фансад гаскәрене мөхасарә иткән[5], боларга әсир төшкәнләрдән үзбәк ругы[6] булса, һәммәсен кылычдан кичергән. Алтышәһәр әһалисеннән улганларны билгакес[7] азад иткән. Бу хәбәр бәдәүләт хәзрәтенә йитде. Ул бу чакда Күрләдә улынырды. Бу вакыйгадан тулае ифрат кайгырды. Хатайлар илән Алтышәһәр әһалисе һәмгәб гөман итделәр[8]. Тиздән Турфан гаскәр команданнары булган бер угылы илә бер нәмә түрәмне (баба исемен әйтсә дә онытканмын) кайтырга кушып язды. Әмма болар кайтмады. Сәбәбе: анда барсак шунча норгын гаскәр илә сугышмай нәмә сәбәбдән мөхасарә улындың дип, берәр газабларына[9] очравымыз ихтимал, дип куркышып килмәде. Боңа бәдәүләт хафаланды. Үз угылының әмеренә буен игмәвенә гарьләнеп, үзенең икъбаль Чулпанының[10] сүнәренә фал кылды да зәһәр эчеп үлде. «Ирне намус үлтерә...», – диләр. (Бәдәүләт Хатай гаскәренә каршы чыгып сугышса, шөбһә юк, йиңәр икәнләр).

– Алтышәһәр бәкләреннән бере тарафыннан агу бирелдеке ялган микән?

[1] Хасыйле – кыскасы.
[2] Ондак – алай.
[3] Талигъ – язмыш.
[4] Соңындикләре – аннан соңраклары.
[5] Мөхасарә иткән – камап алган.
[6] Ругы – ыруы.
[7] Билгакес – киресенчә.
[8] Һәмгәб гөман итделәр – бер сүздә дип уйлады.
[9] Газабларына – ачуына.
[10] Икъбаль Чулпанының – бәхет йолдызының.

– Ул булмас. Бәдәүләт пәк ихтыятлы[1] кеше иде. Бондак гөманлы чакларында[2] түгел, әмин[3] заманнарда да ниһаять сак улыныrды. Ашчы аш хәзерләп килтергәндә, ул үзенә тәнавел иттердекдән соңра[4] үзе ашар иде. Бән бәдәүләтнең мәхрәмләрендәнем[5]. Шунынчөн башка берәү тарафыннан зәһәр бирелде дигән сүз дөрест түгел.

Бу арада бән Алтышәһәр әһалисе хакында берәр сүз ычкындырдым бугай. Бабай: «Угылым, сез дә Алтышәһәр әһалисендәнсеңез. Һәлә[6] сезләрнең Или өлкәсенә күчеп баруыңызга дүртбиш атна гына үткән. Шундакмы? Бәли?[7]

– Шундак. Чин дәүләте Илине алгач, у тарафны абад вә мәгъмүр әйләп[8] мәдәниләшдермәк өчен, буннан күчмән күчәрене уйлаган. Хандан Или вилаятенә һиҗрәт итүчеләргә төрле мөкяфат-кәңчелекләр[9] вәгъдә иделгән ярлык чыккан. Бундан тулаедыр ки[10], һиҗрәт итүчеләр күбәйгән. Бунда да байлар, бәкләр, үз туган, үз бала-чагаларын күчерергә тырышкан. Һәммәсе шундаклардан күчкән дә. Бу мөһаҗирләргә шундак иркенлек бирелгән ки, бер егет берәүнең кызын: «Бән сәне алам», – дип йөрдисә, кызның ата-анасы карыша алмаган, диде. Баба сүз арасында Илинең вәҗһе тәсмиясе[11] тугрысында мөхтәрәм Халиди хәзрәтнең «Тәварихе хәмсә»[12]сендәге әкиятне дә ялгап йибәрде. Бу чынлап та мөәррих баба икән. Богра хан вә Йосыф Кадир хан хакларында да беркадәр сүзләр сүзләде, имди исемен дә язаем: Торды Ахун баба иде.

---

[1] Пәк ихтыятлы – бик сак.

[2] Бондак гөманлы чакларында – мондый шөбһәле чакларда.

[3] Әмин – имин.

[4] Тәнавел иттердекдән соңра – авыз иттергәннән соң.

[5] Мәхрәмләрендәнем – югары дәрәҗәдәге якыннарыннанмын.

[6] Һәлә – хәзер.

[7] Шундакмы? Бәли? – шулаймы? Әйе?

[8] Абад вә мәгъмүр әйләп – төзекләндереп һәм матурлап.

[9] Мөкяфат-кәңчелекләр – бүләкләр һәм ташламалар.

[10] Бундан тулаедыр ки – бу сәбәпледер ки.

[11] Вәҗһе тәсмиясе – шушы исем алу сәбәбе.

[12] Биредә Корбангали Халидинең (1846–1913) «Тәварихе хәмсәи шәркый» (1910) хезмәте күздә тотыла *(Г. Ханнанова иск.)*

## Аксу

Бүген (20 гыйнвар) Аксу шәһәренә кәлдек. Аксу бик кадим[1] шәһәрләрдән булып, борын заманнарда төрек ханнары да торгалаган имеш... Тик тукыз өзенче еллар тирәләрендә Мирза Абабәкри дигән бер хан бу шәһәр әһалисен, Әхмәд хан дигән берәүгә тарафдарлык итдегеннән, тулае кырдырган. Йитмәсә, сәламәт калганнарын һәммәсен сөргән, шуңа күрә Аксу уналты ел микъдары хәрабә хәлендә могатталь[2] яткан. Соңыннан Солтан-Сәгыйд дигән берәү ханлык тәхетенә менгәч, янәдән этраф шәһәрләрдән мөһаҗирләр күчереп ултыргызган[3]. Солтан-Сәгыйдь Аксу халкыннан ун ел микъдары падишаһлык налог алмаган (ягъни албан-ясакдан могаф кылган[4]), бундан тулае Аксу янәдән абад[5] булган. Мөәррихләрнең «Аксу халкы мөтәфәррикъ пәракәндә[6]» дидекләренең мәгънәсе шу булса кирәк. Аксу күңелләрне үзенә җәлеп итеп торырлык, хуш манзаралы бер шәһәр түгел, тик ата-бабаларымыз чыккан җай[7] булгач кына хуш күренә. Күчәләр монтазам түгел[8], һәммәсе бертөрле диярлек тар тыкрыклардан гыйбарәт. Шәһәрдә гүзәл генә ясак[9] бер гыймарәт[10] юк. Һәммәсе далаларда гына улачак землянкалар кеби ханәләр. Халык рухсыз вә төшкен. Фәкыр вә мәскәнәт тарафы йитеш, уку-укыту сос[11]. Билгакес[12] ишанизм пәк[13] көчле. Һөнәр вә сәнәгать күптән юк. Әмма игенчелек ярарлык гына. Аш вә эш арзан. Фәхеш вә фахишәлек хуплы. Әһалидә булган фәкыйрьлек фахишәләрнең санын көндән-көн үсдерә генә. Муллаларда

[1] Кадим – борынгы.

[2] Могатталь – ташландык хәлдә.

[3] Ултыргызган – утырткан.

[4] Могаф кылган – азад иткән.

[5] Абад – төзек.

[6] Мөтәфәррикъ пәракәндә – берәм-берәм таралышкан.

[7] Җай – урын.

[8] Күчәләр монтазам түгел – урамнар төзек түгел.

[9] Ясак – ясалган.

[10] Гыймарәт – җәмәгать яки хәйрия бинасы.

[11] Фәкырь вә мәскәнәт тарафы йитеш, уку-укыту сос – фәкыйрьлек һәм мескенлек ягыннан уңган, уку-укыту ягы сүлпән.

[12] Билгакес – киресенчә.

[13] Пәк – бик.

да боңа каршы торырлык икътидар[1] юк. Ихтимал, хөкүмәт мосагадә бирмәй[2] торгандыр. Бундагы мәэмүрләр: «Арба сынса – утын, үгез үлсә – ит», – дип карый. Бунда фахишәләргә фәхешханәләр булмый, шунлыкдан фахишәләр түнгән[3] сарайларында мөстәкыйль сурәтдә яши. Янларына барсаң, һәман[4] назланышып гыйшык җырларын җырлый. Бунларны күрү үз-үзеңне хурлый. Хосусан бәнем кеби карьядә генә үскән бер кешегә бик гариб (ят) тоела да. Бунларның гомумән мөгамәләләре хатайлар илә улдыгыннан барчасы бәңги[5] булып, базарлары[6] да тиз югала. Шуңа күрә бераз яшьлерәкләре хатайларга өйләнәләр[7]. Яки гомуми йирләрдә комар[8] уйнап гомер уздыралар. Бу тарафларда «вакытлы никах» да хәйли тәрәккыйда[9] икән. Бунларның бары да юксыллык сәмәрәсендәндер[10] ахыры!

Хатайда улан үзгәрешләр вә идарә алмашынулар бу йирдә аслән тәэсир итмәгән. Инкыйлаб заманында бер-ике бөек мәэмүр үлтерелеп, урыннарына инкыйлабчылардан куелмыш исәләр дә, бу мәэмүрләр теге иске идарә адәмләреннән дә начаррак булган. Бу көннәрдә бу тараф бик кысанлыкда улыныркән[11], Аксу халкында сәүдә эше дә бик начар икән. Боны хөкүмәтнең нәрсәләрдән пошлинаны фәүкыльгадә[12] күп алуыннан күрәләр. Күптән түгел генә «эчдән парламентга сайлап йибәреңез» дигән боерыкга бинаән Аксу халкы үзләреннән бер вәкил сайлап бирмеш исәләр дә, нәмә сәбәбкә мәбнидер[13] Өремчедән ары

[1] Икътидар – көч.
[2] Мосагадә бирмәй – мөмкинлек бирми.
[3] Түнгән – дунган.
[4] Һәман – шунда ук.
[5] Бәңги – әфьюнче, наркоман.
[6] Базарлары – җәлеп итәрлек кыяфәтләре.
[7] Өйләнәләр – биредә: кияүгә чыгалар.
[8] Комар – отышлы уен.
[9] Хәйли тәрәккыйда – саны бик арткан.
[10] Юксыллык сәмәрәсендәндер – фәкыйрьлек җимеше.
[11] Улыныркән – булганда.
[12] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.
[13] Нәмә сәбәбкә мәбнидер – ни сәбәпледер.

йөргезмәгән[1]. Ләкин бу тарафларга Балкан сугышы нык тәэсир иткәнгә охшый: могтәбәр генә бер хәзрәтнең әйтүенә күрә, Истанбулга 200 ямбу[2] көмеш йыгып[3] бирелгән. Бу фәүкыльгадә бер.... бер..... нең һәнүз[4] каннарында бар икәнен белдерә. Ләкин! Бу Аксу халкында хәмияте диния вә малиядән[5] мәхрүм түгел икәнен күстәрә[6], бу тарафларда гәзитә укучылар булмаганга күрә, Аксу халкы галәме исламнан хәбәрдар түгелләр. Төрекләр хакында да Или вә Кашгар якларыннан килгән адәмләрнең мобаләгале[7] хәбәрләренә ышанып йөрерләр. Аксудан ун чакырым микъдары ераклыкда Асык дидекләре яңы шәһәрдә Хатайның монтазам йөреп торган почта вә телеграфлары булса да, аннан хәзергә төрекләр файдаланмый торалар.

Аксуда борыннан калма[8] әндиҗанлыклар[9] булса да, казакъ-кыргыз, таранчы, нугайлар күренми, яурупалылар күптән юк. «Нугай бармай, уңгай булмас», ахыры!..

*Голҗа*

*Шура. 1914. № 8*

[1] Шыңтай дигәннәре шәһәр башлыгы тәрҗеманы шундак әйтде (*Н. Габдессамад иск.)*.
[2] Ямбу – Кытайдагы авырлык берәмлеге.
[3] Йыгып – җыеп.
[4] Һәнүз – әле дә.
[5] Хәмияте диния вә малиядән – дини һәм икътисади тырышлыктан.
[6] Күстәрә – күрсәтә.
[7] Мобаләгале – арттырылган.
[8] Борыннан калма – борынгыдан калган.
[9] Әндиҗанлыклар – Әндиҗан өлкәсеннән чыккан кешеләр.

# ТЕКСТЛАРНЫ ГАМӘЛДӘГЕ ЯЗУГА КҮЧЕРҮЧЕЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘҮЧЕЛӘР

*Алиева Ә.Х.* – филол. фән. канд., Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре:

- Надиев Н. Сәяхәт хатирәләре.
- Паташева М. Истанбул хатирәләре.
- Сакмарый. Шам хатирәләре
- Сакмарый. Сүрия әхвале.
- Сакмарый. Шамнан Багальбәккә.

*Ханнанова Г.М.* – Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре:

- Шәрәф. Б. Иран мәктүбләре.
- Г.И. Төркиядә бер сәяхәт.
- Х.М. Кавказ сәяхәтеннән.
- әл-Хәмзәви И. Кавказиядә сәяхәт.
- Назархуҗа Габдессамат углы. Юл хатиратымнан.

## ЭЧТӘЛЕК

XX гасыр башы татар матбугатында сәяхәтнамәләр . . . . 5

*Шәрәф. Б.* Иран мәктүбләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

*Надиев Н.* Сәяхәт хатирәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87

*Г.И.* Төркиядә бер сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119

*Паташева М.* Истанбул хатирәләре . . . . . . . . . . . . . 148

*Сакмарый.* Шам хатирәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

*Сакмарый.* Сүрия әхвале . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244

*Сакмарый.* Шамнан Багальбәккә . . . . . . . . . . . . . . . 256

*Х.М.* Кавказ сәяхәтеннән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 272

*әл-Хәмзәви И.* Кавказиядә сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . 279

*Назархуҗа Габдессамат углы.* Юл хатиратымнан . . . . . 283

Текстларны гамәлдәге язуга күчерүчеләр
һәм шәрехләүчеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298

**ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ**
**поиски и открытия**
Выпуск 13

Редактор Л. Г. Шариффуллина
Компьютерная верстка Н. Т. Абдуллиной
Дизайн обложки А. Б. Шляпкина

Подписано в печать: 03.12.2021 г.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная, печать офсетная.
Усл.-печ. л. 17,4. Уч-изд. л. 13,5. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20